ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# Казан утлары

2.2014





*Шәриф Камал*
*(1884 – 1942)*

Казан утлары
Qazan utlari

2014

2
(1096)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Илфак Мирза улы**
**Ибраһимов**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фаттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст. 1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст. 1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

**КАЗАН УТЛАРЫ**

www.kazanutlaru.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ренат ХАРИС. Аргы ягы аның – чиксезлек!.. *Шигырьләр.* ..... 5
Хәким ГАЛИДӘН. Патша солдаты Әхмәтнәсир. *Роман.* ..... 11
Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Вакытның юк башы, азагы. *Шигырьләр.* ..... 64
Фәнзаман БАТТАЛ. *Хикәяләр.* ..... 67
Тамара ИСКӘНДӘРИЯ. Төрки дөнья. *Шигырьләр. (Р. Гаташның кереш сүзе белән).* ..... 90
АХИР. Таш калада баш кала... *Роман.* ..... 94

**ТАРИХ**

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре. ..... 128

**МИЛЛИЯТ**

«Түгәрәк өстәл»дә – тулы бер гасыр. *Галимнәр Д.Исхаков, А.Юзеев, Р.Мөхәммәтдинов, М.Габдуллин, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире И.Ибраһимов катнашында.* ..... 133

**СӘНГАТЬ**

«Музыка теле – иң үтемле тел...» *(Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин белән Гүзәл Сәгыйтова әңгәмәсе).* ..... 147
Тәлгат НӘҖМИЕВ. Саба туфрагы биргән талантлар. ..... 157

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 164
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 167

**ШИГЪРИ ХӘТЕР**

Ринат МӘННАН. Күңеле һәркемгә ачык иде. ..... 170
Нияз АКМАЛ. Сизгер булсаң... *Шигырьләр.* ..... 171

**ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ**

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. «Томан арты якты була». ..... 176

**РӘФЫЙК ШӘРӘФИЕВКӘ 75 ЯШЬ**

Камил КӘРИМОВ. Горурлыкка мәдхия. ..... 180

**«ПЕЧӘН БАЗАРЫ»**

Рәдиф ТИМЕРШИН. Алтын тарак. ..... 184
Нәҗибә САФИНА. Гыйбрәтле гыйбарәләр. ..... 186

**КАЙТАВАЗ**

Зәбир ҖАББАРОВ. Изге эш бу! ..... 189

«Казан утлары» архивыннан. ..... 126
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 190

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Х.ГАЛИДАН. Роман «Царский солдат Ахметнасир».
АХИР. Роман «Город — пожиратель душ»; рассказы Ф.БАТТАЛА;
стихи Р.ХАРИСА, Х.БАДИГИ, Т.ИСКАНДАРИИ, Н.АКМАЛА.
«История»: И.ГИЛЯЗОВ. «Мусульманские пленные в Германии в Первой Мировой войне».
«Татарский мир»: «Круглый стол» с участием учёных Д.ИСХАКОВА, А.ЮЗЕЕВА,
Р.МУХАМЕТДИНОВА, М.ГАБДУЛЛИНА и главного редактора журнала
«Казан утлары» И.ИБРАГИМОВА.
«Искусство»: беседа Г.САГИТОВОЙ с Р.КАЛИМУЛЛИНЫМ, посвящённая 75-летию
Союза композиторов Татарстана; статья Т.НАЗМИЕВА «Таланты Сабинской земли».
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Сенной базар»: Р.ТИМЕРШИН. «Золотой гребень»;
Н.САФИНА. «Поучительные фразы».
«К 130-летию Ш.Камала»: статья А.ЗАКИРЗЯНОВА о драматургии Ш.КАМАЛА.
«Юбилеи»: статья К.КАРИМОВА, посвящённая 75-летию Р.ШАРАФИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Ягодная слобода». Работа М.УСМАНОВА;
поэт, учёный Х.БАДИГИ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: H.GALIDAN. Doman «Tsar's soldier Ahmetnasir»
AHIR. Doman «City — devourer of souls»; stories by F.BATTAL;
poems by R.HARIS, H.BADIGI, T.ISKANDARII, N.AKMAL.
«History» I.GILYAZOV. «Muslim captives in Germany in the First World War».
«Tatar World»: «Round table» with the participation of scientists D.ISKHAKOV,
A.YUZEEV, R.MUHAMETDINOV, M.GABDULLIN and chief editor of «Kazan
Utlary» I.IBRAGIMOV.
«Art»: Interview G.Sagitova with R.Kalimullin dedicated to the 75th anniversary of the Union
of Composers of Tatarstan; article by T.Nazmiev «Talents of the Sabin land».
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«Hay Market»: R.TIMERSHIN. «Golden Comb»; N.SAFINA. «Instructive phrases».
«To the 130th anniversary of Sh.Kamal»: article by A.ZAKIRZYANOV
about Sh.Kamal drama.
«Anniversaries»: article by K.KARIMOV devoted to the 75th anniversary of R.Sharafiev.
Diary of social-cultural life.
On our covers, «Berry settlement». Work by M.USMANOV;
poet, scientist H.BADIGI.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 31.01.2014, график буенча 31.01.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-199. Тираж 3107.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Тираж сертификацияләнгән.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Ренат
Харис

# АРГЫ ЯГЫ АНЫҢ – ЧИКСЕЗЛЕК!..

## Татар татарны ярата

**Татар татарны ярата!
Якмагыз кара яла!
Ярдәм кирәксә, татарга
канын да бирә ала.**

**Тарих агышында һәрчак
без нәкъ шулай иткәнбез –
каннарыбызны өстәшеп,
бер кан булып беткәнбез!**

**Татар татарны ярата –
гәрчә кайбер гадәте
җанына борыч сипсә дә,
чигерсә дә гайрәтне.**

**Бердәй канның бер тамчысын
өстен күрер үзеннән –
татар дигән исем өчен
чыгар энә күзеннән.**

**Татар татарны ярата!
Җитте! Юләр сатмагыз,
ике татар бергә килеп,
ут чакса да чакмагыз.**

**Чаткысын уртак учакка
әйләндерә ала ул!..
Татар татарны ашый, дип
әйтү чеп–чи яла ул!**

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең дәүләт премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Кара түгәрәк

Малевичның «Кара квадрат»ында
яшькелт, сары һәм ал сызыклар,
онытылып карап тора белсәң,
әйләнәләр җанлы кызыкка.

Теләсәң ни күреп була анда!
Теләсәң ни була ишетеп!
Әллә нинди дөньяларга ачык
каралыкның якты ишеге...

Кара төндә, йокы алмаганда,
әллә нинди хәлгә керәм мин —
күзем йомсам, ялпак түгәрәктә
каралыкның йөзен күрәмен.

Онытылып карап торам шуңа
белмим нәрсә көтеп-искәнеп...
Акылымда кинәт чәчрәп шартлый
аллы-гөлле-яшькелт сискәнү,

һәм яңадан каралыкка бата...
Аргы ягы аның — Чиксезлек!..
Чиксезлекнең бу ягында тота
акыл билгеләгән чик безне...

Аһ, чыгасы килә, океанын
тишеп чыккан балык сыман бер!..
Ә бәлки, мин, Чиксезлектән бигрәк,
Аллаһ белән кызыксынамдыр!..

## Байбәтчә

Килененең глобустай
корсагына төбәп күзен,
ул туачак оныгына,
ми корытып, ватан эзли.

Эзли төрле кыйтгалардан
җылырак һәм баерак илне —
оныгының кендек канын
монда тамызасы килми...

Монда — үзен кеше иткән
ата-бабасы җиренә!
Ә тегендә — билгесезлек
алсу хыялга төренгән...

Җирәнәме үз иленнән,
юкмы әллә ышанычы?!
Ләкин эзләп тә карамый
чуалган уйлары очын...

Чит ил кешесе бабасы
булу, ахры, абруйлырак —

акылы долларга якын,
йөрәге рубльдән ерак...

Ул туачак онытына,
ми корытып, ватан эзли
килененең глобустай
корсагына төбәп күзен...

## Курыкмыйча яшик

Курыкмыйча яшик әле
галәмдә очкан ташлардан.
Беләсезме –
бәхетсезлек
куркып яшәүдән башлана.

Курыкмыйча яшик әле
яшеннәрдән, зилзиләдән.
Беләсезме –
курыкканда
кеше әйләнә бәндәгә.

Курыкмыйча яшик әле
күк гөмбәзе тишелүдән.
Беләсезме –
курыкканда
бар нәрсә куш ишетелә.

Курыкмыйча яшик әле
ахырзаман күренә дип.
Беләсезме –
курыкканнар
яши сират күперендә.

Курыкмыйча яшик әле
акча бәясе төшүдән.
Беләсезме –
байлык кына
бәхет китерми кешегә.

Курыкмыйча яшик әле
кризислардан, дефолтлардан.
Беләсезме –
Ходай үзе
тырышларга бирә ярдәм.

Курыкмыйча яшик әле
сугыш ядрәсе шартлаудан.
Беләсезме –
илбасарлар
курка безнең курыкмаудан.

Ләкин куркыйк бер нәрсәдән –
җан иясе рәнҗешеннән.
Беләсезме –
сыңар рәнҗеш
бәхетсез итә кешене....

## Кунак хакы

Кунагыма авыр сүз әйттеләр...
Ә ул килгән иде сагынып –
мәгънәсе һәм яме арткан иде
мин яратып корган табынның.

Төкерделәр шушы табыныма –
йөрәктәге иң саф коема...
Кунакчыллыгымның яме китте
һәм тәм качты минем сыемнан...

Агу тамды сап-сау йөрәгемә
һәм телемне каргыш тунады –
мин бит Җиргә кеше төкереген
йотып яшәр өчен тумадым...

Кунак хакы минем өчен мәңге
халык хакы булып калачак.
Халык хакын хакламаучы бәндә
минем сүздән җәза алачак!..

## Мескен

Гафу итәргә өйрәндем бугай
гафу үтенә белмәүчеләрне –
эреде-акты канда кантарлар,
бетте дә китте йөрәгем әрнү...
Күзләрем галәм киңлеген иңли –
мин хәзер үзем үземнән өстен!
Күзен тизәктән куптара алмый
гафу үтенә белмәүче мескен...

## Беренче хәбәр

Шатландыммы,
әллә каушадыммы,
әллә курыктыммы икән мин,
«Мин авырлы...» дигәч...
Истә түгел
бу турыда хәбәр иткәнең...

Балалар да инде олыгая –
өйләнделәр хәтта оныклар...
Эх, яшьлекнең ваемсыз хәтере
нинди! нинди! көнне оныткан –

яңа дөнья тууы турында
хәбәр алган бөек мизгелне!..
Оныклардан бала көткән көннәр
әллә ничек безгә тиз килде...

Гомер сиздермичә үтеп бара,
чабуында безне өстерәп...
Ә без һаман әле элеккечә!
Дөнья гына бераз искергән...

* * *

Аһ, хатын-кыз! Алга бара
артка чигенә-чигенә...
Ул тумыштан «кутузовчы» –
җиңә җиңелә-җиңелә...

Ул һәрвакыт өскә чыга,
һаман аста кала-кала,
җанын-тәнен бирә-бирә,
бар дөньяңны тартып ала!

Аһ, хатын-кыз — баллы борыч,
утлы суык, тирән сайлык,
ас белән өс, плюс-минус...
назлы газап, авыр байлык!

## Сөйгән яр бир

Җаным өзгәләнгән минутларда,
уйнаганда дәртем ташкыны,
башым белән мендәр төя идем,
йолдызларга таба ашкынып...

Йөрәгемдә каннар кайнаганда
сөюемнең кысыр утыннан,
җаным диңгез эзләп оча иде
ташланырга төпсез упкынга...

Кар көртләре басып киткән чакта
наз көтүдән янган куенны,
күпме каһәрләдем һәм каргадым
кеше белән язмыш уенын...

Иң газаплы, татлы бер сусын бар,–
ул да булса — сөю сусыны.
Акыл аңа хәтта башын ия,
ләкин йөрәк никтер буйсынмый.

Керфегеңнән бәсләр китмәгәндә,
күз карасы хәтта күшегә...
Сөелеп һәм сөеп яшәр өчен
сөйгән яр бир, Ходай, кешегә!

## Елатмаска иде бәбиләрне

Яратмыймын бәби елаганны –
алар елаганда бөтен дөнья елый кебек:
юллар җебеп,
күлләр кибеп,
таулар күбеп,
җилләр –
үлгән дулкыннарның салкын маңгайларын үбеп...

Бар нәрсә дә интегә кебек ачтан:
дым җитми агачка,
җим җитми кошка,

хайванга җитми утлык,
кешегә җитми шатлык...
Бар нәрсәгә бөтен нәрсә кытлык!..

Илләр чирле сыман:
халыкларның аяк-кулы сынган,
тыны кысылган,
авырта башы —
ташкын-ташкын хәтәр хәбәр
агулый минем һәр ерымын —
хәтта аулак урыннарына хәтле орынып,
яга фаҗигаләр корымын...

Ничек елатмаска бәбиләрне?
Алар елаганда тотыла кояш,
бөердә кузгала таш,
тозга әйләнә аш,
чатный баш,
җан әрни,
кан әрни,
аң әрни...
Ничек елатмаска,
ничек елатмаска бәбиләрне?

## Учым

Күрәзәче ни күрәдер
учымдагы сырларда,
шуны әйтәм: һәр сыр тоташ
шигырьләргә, җырларга...

Урак, чабагач тотарга
минем учлар соңгарды,
ә сука мөгезен кысып,
бераз буразна ярды.

Чүкечне дә тоткалады,
үткен балта сабын да,
бәлешләр дә тураштырды
төрле-төрле табында.

Чалгылар да чүкеде ул,
энә дә тота белде...
Хәтта парламент өстенә
дәүләт байрагы элде...

Шәраблар да агызды ул
бәйрәмнәр тустагына.
Гармун бармакларында да
биеде оста гына.

Рәссам пумаласын да ул
үз итте, ятсынмады...
Кабер ташларын сыйпады —
туңса да, суынмады...

Президентлар кулын кысты —
сеңдерде хаким көчен...
Күтәрелде илне яклап
мин тавыш бирсен өчен...

Йодрыкка да әверелде
теш кысылган чакларда —
җимерергә түгел ләкин,
ә яхшыны якларга...

Шатлык яшьләре сөртте ул,
дәртле тәнгә кагылды,
ләкин иң бөек ләззәтне
кәгазь-каләмнән алды!

Ни күрәдер күрәзәче?..
Учымдагы һәр сызык
яшерен гыйшык шигыре
юллары кебек кызык...



Хәким Галидән

# ПАТША СОЛДАТЫ ӘХМӘТНӘСИР

РОМАН

21

Сентябрь ае башында Шереметьев гаскәрне ике өлешкә бүлде. Бер өлешенә улы Михаил Борисовичны житәкче итеп куйды. Полковник Кропотовны улы Михаилнын ярдәмчесе итеп билгеләде. Әхмәтнәсирнен якташлары икенче төркемдә иделәр. Егет үтенеп сорагач, полковник анын якташларын үз төркеменә алды. Ряпино сугышында катнашып, үз гомерләрендә беренче мәртәбә үлем күзенә караган якташлары, Әхмәтнәсир канаты астында чирканчык алып, чыныктылар, тәжрибә тупладылар.

Декабрь азагындагы Эрествер сугышында алар төркеме иң беренчеләрдән булып дошман катына үтеп керде. Раштуа көнен бәйрәм итеп яткан исерек шведлар арасына бәреп кереп, паника куптардылар. Тиз арада анга килеп өлгергән дошман туплардан атып көчле каршылык күрсәтте. Ядрәләр аргта шартлап драгуннар арасында югалтулар булды. Әхмәтнәсирләр төркеме алгы рәттә булганга, күрәсен, аларга зур зыян килмәде. Ярдәмгә килеп житешкән пехота белән артиллерия басымы астында хәлләр кискен үзгәрде.

Дошман артыннан куа чыккан иделәр. Алар инде чәчелде. Артларыннан куу зур нәтижә бирмәс, кирәкмәгән югалтулар гына булуы мөмкин дип, полковник кире борды үзләрен.

1702 елнын дүртенче гыйнварында Псков шәһәре аларны туплардан атып, зур тантана белән каршы алды. Берничә көнгә сузылган жиңү тантанасы азагында Мәскәүдән Петр I ярдәмчесе Меньшиков килеп, Шереметьевка «Андрей Первозванный» ордены такты, фельдмаршал дәрәжәсе бирелүен житкерде. Сугышта катнашкан барлык хәрбиләргә берәр көмеш тәнкә өләштеләр.

22

Татар-башкорт атлыларынын Ряпинода күрсәткән батырлыгы Борис Петрович Шереметьевка мәгълүм иде. Бәйрәм шау-шуы басыла төшкәч, полковник Кропотов белән очрашып, хәлләрен сорашты, уй-фикерләрен белеште. Читтәрәк басып торган Әхмәтнәсир янына ымлап:

---

*Ахыры. Башы 1 санда.*

— Не тот ли это воин, который нас однажды с кониной выручил? – диде.

– Да, тот самый, Ваше Благородие.

– Ну, здравствуй, джигит! Как нога? Не беспокоит?

– Зряем жилаем Ваш Блгаруди! Никак нит! Спасибы за воткы, воткы памагал.

– Как воюется?

–Ваш Блгаруди! Зимляки на падмугы приехали. Хараша вают!

Фельдмаршалның кайгыртучанлыгы урынсыз түгел иде. Полкларда кеше саны тулы түгел. Регуляр атлы гаскәр, пехота кирәк. Атлар житешми. Бөтен булган мөмкинчелеген эшкә җигеп, Шереметьев Армияне тулыландыру өчен тырышты. Яз урталарында көткән өч мең калмык белән мең дә өч йөз татар атлылары килде. Шереметьевка гына хас салкын үҗәтлек белән унсигез мең кешедән торган гаскәр җыелды. Аның күбесе регуляр сугышчылардан тора иде. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, Нарва фаҗигасеннән соң Петр I, Манифест игълан итеп, чит илләрдән гаиләләре белән оста белгечләр чакыртты. Унайлы шартларда җирләр һәм эш урыннары бирде. Эшләнгән эшкә көмеш һәм алтын тәңкәләр белән түләп, ирекле рәвештә, Рәсәй көчен арттыруда зур эшләр башкарылды. Урал ягында чуен, корыч кою эшләре сыйфатлы рәвештә киң колач алды. Дары эшкәртүнең дә сыйфаты артты. Бу бик мөһим, урыслар көчен арттырган һәм вакытлы гамәл иде.

Петр I фәрманы белән Шереметьев июнь урталарында шведлар җиренә яу белән чыкты. Патшаның ашыктыру сәбәбе урынсыз түгел иде. Англия, Голландия һәм Австрия белән Франция арасында сугыш, Испания байлыгын бүлешү бара. Урысларның үз кайгысы, шведларга ярдәм килер дип уйлыйсы да юк. Швед короле Архангельскига килерме әллә диеп көткәннәр иде, ә ул Варшау ягына яу чыккан. Эстляндия белән Латвия җирләрен сакларга калган Шлиппенбах кулы астында барлыгы җиде мең тирәсе атлы һәм җәяүле көчләре бар. Бу вакытта Шереметьев кулы астында тугыз драгун полкы, сигез пехота һәм төрле шәһәрләрдән җыелган регуляр булмаган өч полк иде. Шулар өстенә өч мең тирәсе калмык һәм татар-башкорт атлылары. Шведлардан үч алыр өчен иң унай вакыт иде бу.

Шереметьев драгун полклары алдына обозларны калдырып, үзләре белән сигез көнлек азык алып, Красно борыны ягына бару бурычын куйды. Ә үзе, пехота һәм артиллерия белән Юрьев Ливонск юлы буйлап баруын дәвам итте. Полковник Кропотов татар-калмык атлы гаскәре белән янәшә барырга тиеш иде.

Родион Христианович Боур житәкләгән Преображенск драгун полкы, Красно мызына унбиш чакрым ара кала, шведлар ягыннан көчле каршылыкка очрадылар. Көчләр тигез түгел иде. Красно мызына икенче яклап һөҗүм иткән Кропотов гаскәре шведларны тар-мар итеп, Боур полкларына ярдәмгә ташланды. Ике яклап көчле басымны күтәрә алмый, шведлар, Красно мызын калдырып, Гумолово ягына чигенделәр. Фельдмаршал Шереметьев, Кропотовка дошманны эзәрлекләргә әмер биреп, пехотасы белән төнгелеккә Красно мызында калды.

Шул вакыт эчендә Шлиппенбах, калган барлык көчләрен туплап, Гумоловога ун чакрым кала елга аръягында урнашты. Елганың бире ягына биш йөз кешедән торган заслон куйды. Куа чыккан Кропотов белән полковник Боурның атлы гаскәре, шведлар заслонын тар-мар итеп, елга аша күпер салуга керește. Иртәнгә күпер әзер иде. Тулысынча ял да итмәгән килеш, күпер аша Гумолово борыны ягына ыргылдылар. Куа килүчеләрнең артык күп булмаганын белеп алгач Шлиппенбах үз гаскәрләренә: «Берсен дә

әсир алмаска! Урысларны мөмкин кадәр күбрәк юк итәргә!» — дигән әмер бирде. Каршылык күрсәтергә әзерләнеп өлгергән шведлар куып килүчеләрне туплардан көчле ут ачып каршы алды. Андый көчле каршылыкны көтмәгән куучылар бер мәлгә каушап калдылар. Анга килеп өлгергән арада, кыргый җанвар үкерүенә охшаш быргы тавышы астында, шведларның атлы гаскәре һөҗүмгә ташланды. Башка чара юклыктан үлем әчесе белән сугышкан шведларның көчле басымы астында куып килүчеләр чигенергә мәҗбүр булды. Өч сәгатькә сузылган бу бәрелештә драгун атлы гаскәре күп кенә сугышчыларын югалтты. Татар-калмык гаскәрләре арасында да үлүчеләр аз булмады.

Куа чыккан гаскәрнең көчле каршылыкка очраганын ишетеп, Шереметьев калган атлы гаскәрләрен ярдәмгә җибәрде. Көндезге сәгать өчләр тирәсендә, ярдәм килеп җитеп тагын бер сәгать тирәсе көчле сугыш барганнан соң, шведлар Гумолов борыны ягына чигенергә мәҗбүр булдылар.

Шереметьев полковникларына югалтуларны барларга кушты. Драгун атлылары арасында унбиш кеше үтерелгән, илле биш кеше җәрәхәт алган, тагын өч кеше авыр яралы. Житәкчеләре арасында бер подполковник, бер полковник үтерелгән, өч капитан, бер прапорщик җәрәхәт алган. Атлы гаскәре арасында унөч калмык, жиде татар үтерелгән, егерме өч калмык белән унбер татар сугышчысы яраланган, житәкчелектән бер капитан белән полковник һәм Кропотов тән җәрәхәте алган иде. Пехота арасында да югалтулар бар.

Полковник Кропотовның җәрәхәт алуы болайрак булды. Елганы кичеп чыгып дошман утына эләгү белән Әхмәтнәсир, хәлнең мөшкеллеген аңлап алып, полковник янәшәсендә булырга тырышты.

— Ваш блгаруди! Назад нады, назад! Пушкы нады ждат!

— Поздно, Ахмет, поздно! Они скоро в атаку пойдут. Надо их встречать.

Чынлап та, озакламый шведның атлы гаскәре, стена шикелле кубып, алар өстенә ташланды. Бу очракта качып китү үлем белән бер иде. Көчле бәрелеш башланды. Киеме буенчамы, өлкән офицер икәнен сизенеп, полковник ягына ике дистә атлы ыргылды. Әхмәтнәсир белән тагын унлап татар егете, шведлар юлына каршы төшеп, һөҗүмне үзләренә юнәлтте. Мылтыктан атарга форсат юклыктан Әхмәтнәсир аны, көпшәсеннән тотып, тәпәч урынына кулланды. Җан-фәрманга чаптырып килгән дошманны атыннан бәреп төшерде. Икенче якка кизәнгәндә, ат башына мылтык түтәсе тиеп дошман җиргә мәтәлләде. Бу хәлне күреп алган егетләр дә шуны ук кабатладылар. Әхмәтнәсир, полковникның аты сөртенеп, хуҗасы җиргә егылганын күреп алды. Җирдә килеш аны таптап, изеп китүләре мөмкин иде.

— Егетләр! Камандир җирдә! Камандир! Камандирны сакла! — дип, җан көченә кычкырып, полковник янына килде. Саф татар телендә әйтелгән бу авазны ишетеп, калмык егетләре дә аның янына ашыкты, командирны уратып алдылар. Бер урында укмашып дошманны каршы алу унай нәтиҗә бирде.

— Битләренә төзәгез, егетләр! Йөзләренә атыгыз! — дип, Әхмәтнәсир, җәясен алып, уктан атарга кереште. Аралар якын булганлыктан төзәп ату җайлы иде, күп кенә дошманны сафтан чыгардылар. Ул арада полковник аягына күтәрелгән иде инде. Хуҗасыз калган швед атын тотып алып, Әхмәтнәсир:

— Бири, Ваш Блгаруди! Пишком нилзә! — диде.

Әхмәтнәсир сузган йөгәнне кулына алып, полковник ияргә менәргә тырышып карады. Аягы яраланган иде, күрәсең — ияр үкчәсенә баса

алмыйча җәясенә ябышты. Житез генә иелеп, егет аның бил каешыннан тотты, күтәреп алып атка атландырды.

Бераздан ярдәм килеп, мөмкинчелек туу белән, полковникның ярасын карады. Мылтыктан атып чәлтерен (сыйрагын) яралаганнар, сөяккә тимәгән. Шуна карамастан канын югалтып өлгергән, итеге эче тулы кан иде. Юл капчыгыннан бинт алып, яраны бәйләде, атка менәргә ярдәм итте.

Сугыш кырында бик күп кешесен калдырып, Шлиппенбах качып котылды. Бу аның соңгы мәртәбә котылуы иде. Шведларның үкчәсенә басып куып бара торгач, Гумолов тирәсендә йөздән артык сугышчысы белән Шлиппенбахны әсир алдылар. Шведлар кулы астындагы ундүрт мен сугышчыдан биш мен туксаны үтерелгән, күп кенә кеше кулга төшерелгән иде. Бик азы качып котыла алды, тирә-якка таралып сибелде.

Фельдмаршал Шереметьев өч тәүлек буена Гумолов борынында ялга туктады. Яна көчләрне тирә-якларга җибәреп авылларны таларга, йорт-кураларын утка тотарга әмер бирде. Дүртенче көнне Рига ягына китә торган юл белән барып, Мыниста ныгытмасын камап алды. Мынистаны ике көн эчендә бирелергә мәҗбүр итеп, бөтен көчләрне Мариенбург ныгытмасына юнәлтте.

Мариенбург ныгытмасы утрауда булып, тирә-ягы су белән уратып алынган. Ныгытманы аз санлы кеше саклауга карамастан, тиз генә җиңүгә ирешеп булмады. Көне-төне көчле туплардан ату нәтиҗәсендә ныгытма эчендә янгыннар башланды. Уникe тәүлек буе көчле утка тотып, егерме бишенче август көнне, ниһаять, ныгытма саклаучылар бирелергә мәҗбүр булдылар. Меннән артык сугышчыны, алтмыш сигез офицерны әсир алып, илле бер пушка һәм егерме алты әләмне кулга төшереп, тугызынчы сентябрьдә Шереметьев Псковка әйләнеп кайтты. Петр I Шереметьевтан бик канәгать иде: «Борис Петрович в Лифляндии гостил изрядно довольно долго и успешно!» — дип, Апраксин алдында фельдмаршалын мактап та алды.

Бу сугышның тагын бер үзенчәлеге шунда — Мариенбург ныгытмасында әсир төшкән халык арасында Марта исемле бик чибәр швед хатыны бар иде. Төрле куллардан үтеп, ул соңгы чиктә Петр I карамагына эләкте. Бу — Петр патшаның булачак хатыны, киләчәктә Русия белән идарә итәчәк императрица Екатерина I иде.

## 23

Шереметьев Псковтан гаскәр туплап ятканда Петр патша, Голландиядәге илчесе аша, Карл XII Архангельск ягына зур яу туплый дигән өркеткеч хәбәр ала. Архангельск (Город) белән Холмогорны ике мен өч йөз илле биш кешедән генә торган аз санлы һәм начар коралланган көчләр саклый иде. Бу хәбәр Петр Iне куркуга салды. Тиз арада дүрт менлек гвардия батальоны туплап, 1702 елның унсигезенче апрелендә юлга чыкты. Озата баручылар арасында, Ф.Головин, кенәз А.Голицын, Ю.Трубецкой, Б.Прозоровский, А.Меньшиков һәм башкалар бар иде.

Юл бер айга сузылды. Швед гаскәрен көтеп өч айга якын Архангельскида яшәделәр. Бишенче августта инглиз һәм Голландия дингезчеләреннән караблар яллап, Соловкига, Соловкидан Ак дингезгә уздылар. Юлда очраган сәүдә караблары капитаннарыннан бу якка килүче швед корабларын күрү-күрмәүләрен сораштылар, Карл XIIнең Польшага яу белән чыгуын ачыкладылар. Шереметьевның Лифляндиядә җиңүгә ирешүен дә искә алып, Петр I шведларның көчле ныгытмасы Нотебургка һөҗүм итәргә карар кылды. Нотебург ныгытмасына кадәр булган йөз егерме чакрым араны, күлләвекләр, вак-төяк елгачык һәм сазлыклар аша юл салып, сентябрь

ае башында гына көч-хәл белән уза алдылар. Юлга чыгар алдыннан ул: «Изволь, не мешкав, быть к нам!» — дип, кайсы урында очрашырга кирәклеген әйтеп, Шереметьевка хат юллаган иде. Шул айның азакларында Нотебург ныгытмасын камау эшләре төгәлләнде. Ике Гвардейск һәм ун хәрби полк, барлыгы уникемен биш йөз кешедән торган гаскәр өстеннән житәкчелек итүне патша Шереметьевка йөкләде.

Мариенбургны алганнан соң Шереметьев Псковта озаклап ялга туктарга, сугышта югалткан көчләрне торгызып тулыландырырга ниятләгән иде. Патшага җавап итеп ул: «Больше того быть стало невозможно, в конец изнужились крайне, и обезхлебели, и обезлошадились, и пушки везть стало не на чем.» — дигән хат юллады. Хатлар юлда озак барганлыктан, җавап алып өлгермәгән патша, әйтелгән урынга тиз арада килеп житәргә боерык биреп, яңа хат салды. Дошман кулына эләгүдән шикләнеп булса кирәк, ашыгуның сәбәбен ачыклап язмады. Шуңа карамастан бомбардирның житди хәлдә булуын ул хат аша аңларга була иде.

Сентябрь азагында Нотебург ныгытмасы тирәсендә көчләр җыелып бетеп, ныгытманы саклаучыларга бирелергә кушып, быргычы-парламентер аша хат юлладылар. Ныгытма хуҗасы подполковник Густав Вильгельм Шлиппенбах, генерал Шлиппенбахның бертуган абыйсы, камаучыларның таләбен кире кагып, дүрт көнлек вакыт сорый. Имеш, ул Нарва ныгытмасы коменданты Горнга буйсына, аннардан рөхсәт алырга тиеш. Шул ук вакытта ныгытма каланчасына король әләмен элеп куялар. Бу — ярдәм сорау билгесе иде. Урыслар бу хәлне сизенеп, беренче октябрь көнне ныгытма ягына көчле ут ачтылар. Ныгытма, су белән уратып алынып, Ладога күле ягыннан биек кыя белән бүленгән. Стеналары биек. Шуның өстенә көчләләр — дүрт йөз илле кешегә йөз дә кырык ике эре туп һәм күп кенә башка төрле кораллары бар.

Ныгытма эчендә янгыннар башланып китте. Өч көн буе барган көчле атышлардан соң, офицер хатыннары мәрхәмәтлек сорап урыслар катына чыкты. Аларны бомбардир Петр Михайлович үзе каршы алып, үтенечләрен тыңлады. Хатын-кызларның балалары белән иреккә җибәрүләрен үтенүен белгәч:

— Ирләрегезне дә кызганып үзегез белән алсагыз, без рәхәтләнеп сезнең үтенечне үтәргә әзербез, — дип җавап бирде.

Хатын-кыз ул тәкъдимне кире какты. Җиденче октябрь көнне, көймәләр белән йөзеп кереп, ныгытманы алу каралды. Аның өчен үз теләкләрен белдергән көчле кешеләр сайлап алынды. Шулар рәтендә җинел киемле, көчле куллы һәм житез татарлар белән калмыклар да бар иде. Өч көн рәттән ныгытма стеналарына атып тишекләр тиштеләр. Унберенче октябрьдә иртә белән, көймәләрдә йөзеп кереп, баскычлар аша шул тишекләргә үрмәләү башланып китте. Баскычлар кыска булып, беренче һөҗүм көткән нәтиҗә бирмәде. Ныгытма эчендәгеләр өстән ташлар ыргытып, кайнап торган су сибеп, һөҗүм итүчеләр арасында паника башланды. Арттарак булганнар, көймәләргә утырып, кире якка ташландылар. Подполковник Михаил Голицын, Семеновск житәкчесе, көймәләрне читкә йөздереп, качарга теләүчеләргә мөмкинчелек тудырмаска әмер бирде. Озакламый, озын баскычлар һәм яңа көчләр белән, Александр Меньшиков һөҗүм итүчеләргә ярдәмгә килде. Унике сәгать тоташ сузылган һөҗүмнән хәлсезләнгән ныгытма саклаучылар бирелергә мәҗбүр булды. Алда әйтелгәнчә, кораллары, дүрт туп һәм әләмнәре белән, музыка астында аларга ныгытманы калдырып китәргә рөхсәт ителде.

Өч көн эчендә янадан җыенып, Нева елгасы буйлап Ниеншанц ныгытмасына китеп бардылар.

Бу һөҗүм урысларга бик кыйммәткә төште. Биш йөз утыз сигез кеше үтерелде. Бу сан ныгытма эчендәге халыктан да күбрәк иде. Тугыз йөз егерме биш кеше яраланды. Шуна да карамастан, андый нык корылманы баскычлар аша менеп кулга төшерә алу чит ил вәкилләре арасында соклану, гаҗәпләнү хисләре уятты. Җинүчеләргә төрле зурлыктагы йөз дә утыз сигез туп, шулар өчен унбер мең бер йөз ундүрт ядрә, бик күп гранат, дары һәм хәнҗәрләр кулга төште.

Беренче чиратта бомбардир Петр, сыйфатлы туплар ясатканы өчен, Винниусны чын күнелдән тәбрикләп рәхмәтен белдерде. Шундый каты тышлы «Чикләвекне» вату шатлыгыннан Нотебург (аларча «чикләвек» дип аталган) ныгытмасын «Ачкыч шәһәр» Шлиссельбург дип үзгәртте. Шлиссельбургның коменданты итеп А.Меншиков билгеләнде. М.Голлицынны полковник дәрәҗәсенә күтәрде. Күп кенә офицерларга җир, авыллар бүләк итте, алтын тәнкәләр өләште. Беррәттән күп кенә кеше җәзага да тартылды. Ныгытма алганда качып киткән егерме ике солдатны астылар. Кайберләрен таяк белән кыйнадылар, кайсыларын богаулап Себергә озаттылар. Шулар белән беррәттән Мертвой улы Осипов Андрей дигән кешене, татар сугышчысын кылыч белән яралаганы өчен, арба кырыена бәйләп, камчы белән «ярдылар».

Ул хәл болайрак булды. Унынчы октябрь көнне Әхмәтнәсир полковник Кропотовка килеп: «Мин штурмда катнашырга телим. Тик мин суда йөзә белмим. Шуна карамастан, зинһар өчен рөхсәт итегез мина да катнашырга!» — дип үтенеп мөрәҗәгать итте. Икенче көнне беренчеләрдән булып ныгытма ягына йөзеп чыктылар. Буйчан, таза булганлыктан, ана баскычлар белән тәэмин итү вазифасы йөкләнде. Икенче кат баскыч артыннан килгәндә, ныгытма янында паника башланып, халык артка, яр буена чаба башлады. Өстән әмер ишетү белән, Әхмәтнәсир буш көймәләрне ярдан читкә этеп җибәрде. Качып баручыларның кайберләре, көймәләрне көчләп тартып алып, икенче ярга йөзә, кайсылары көймәсез генә суга ташландылар. Соңгы көймәне ярдан этеп җибәреп торганда, җан-фәрманга чаптырып килгән бер сугышчы аның өстенә кылыч белән ташланды: «Оставь лодку, бусурманин! Уйди с дороги!» — дип кизәнеп суккан җирдән Әхмәтнәсир тайпылып өлгерде. Янәшәдә тагын бер татар кешесе бар иде, кылыч теге бәндәне яралады. Икенче кат урыс кылыч белән кизәнгәндә Әхмәтнәсир кулын өскә күтәрде. Үткен кылыч, таеп китеп, кулбашын уеп алды. Аңа килеп өлгергән берничә кеше, тегенең өстенә ташланып, җиргә егып салдылар, кылычын тартып алып кулын бәйләделәр.

Бу гамәлне югары бәяләп, Әхмәтнәсирне утыз сум көмеш тәнкә белән бүләкләделәр. Теге адәмне җәзага тартып, камчы белән суктырдылар. Башка яралылар белән Әхмәтнәсирне Псковка алып кайттылар. Бу юлы аларга ачык һава астында төн уздырырга туры килмәде. Төн уртасы булуга карамастан, яралыларны күтәп алдылар, түбә астына урнаштырдылар. Икенче көнне, төш вакыты тирәсендә, алар яткан бүлмәгә шул ук түгәрәк ак сакаллы духтыр керде. Чират Әхмәтнәсиргә житте. Бер күз ташлау белән духтыр аны таныды.

— Ну как нога, батенька?

— Нага хараша, рукам плухы.

Янәшәсендәге кыз кан белән укмашып каткан бинтны куптарганда егет ыңгырашып куйды. Кан ага башлау белән яраны юдырып, өстенә көл кебек нәрсә сиптеләр, катлы-катлы чүпрәк белән каплап, кысып бәйләп тә куйдылар. Шуннан соң гына карт, басынкы тавыш белән егеткә:

— Целый кусок оттяпали, батенька. Главное, сустав не поврежден, — дип, егетне юатып, икенче яралы янына күчте.

## 24

Умырып ите киселеп алынган яра тиз генә төзәлергә теләмәде, бөтен кул башы кып-кызыл булып кызара, йөрәгенә тиеп сызлый, сулкылдый. 1703 елның март азакларында гына хәле жинеләюгә китте. Язга, кояш яктысына чыгып һава алыштыра башлады, танышлары белән аралашты.

Көннәрнен берендә, яна яралылыр белән, ике дистәгә якын арбалы обоз килеп төште. Көндез Әхмәтнәсир урам яклап ишек катында утыра иде. Яралыларны бүлмәләргә урнаштыра башладылар. Шулчак ул таныш йөз күреп алды.

— Ваш Блгаруди, иты Вы?

Яралы башын күтәрде.

— А, Ахмет, это ты! Да, браток, и меня угароздило.

Бу — полковник Кропотов иде. Бер атна тирәсе анын янына керергә кушмадылар. Ниһаять, жаен табып керде. Полковник аны елмаеп каршы алды.

— Мин хәзер ат кебек чабулап йөрим, минем хәл яхшы. Ә сез кай арада яраланып өлгердегез? Әлегә сугыш-мазар юк шикелле, — дип, Әхмәтнәсир полковникнын хәлен сорашты.

— Чтоб получить ранение необязательно большая война, Ахмет, — дип, полковник сонгы берничә ай эчендә булып узган хәлләрне сөйләп узды.

Шлиссельбургта Меншиков тик ятмаган. Ниеншанц ныгытмасы тирәсен саклаган ике швед полкын тар-мар итеп, берничә офицер белән сугышчыларны һәм ике мен тирәсе гади халыкны әсир төшергән. Күпсанлы йорт хайваннарын, атларын трофейга алган. Сонгы сүзен полковник:

— Тебя не было рядом, Ахмет. Ты же у меня был ангелом-хранителем, — дип очлап куйды.

Ярасы авыр иде, бот төбендәге сөягенә ядрә кыйпылчыгы кергән. Яраны ярып, сөяген урынына утырткannар. Аксак булып калуы мөмкин икән. — На одну ногу прихрамывал, вот и вторую угораздило, — дип, яралану тарихын сөйләп узды. Атна-ун көн тирәсе полковник янына кереп йөри торгач, бер көнне батырчылыгын жыеп, күнелен тырнап торган соравын бирде егет.

— Ярам төзәлгәннән сон да миннән рәтле сугышчы чыкмастыр дип куркам. Мине кая куярлар, кем итеп кулланырлар икән?

— Ул турыда курыкма, Ахмет. Син — минем адъютантым. Терелеп бетеп сафка басарлык булганчы авылда яшәрбез, көч жыярбыз, ял итәрбез. Авыл тормышы сагындырмадымы үзенне?

— Мин ул турыда хыялланырга да куркам. Мин бит авыл баласы. Ничек итеп сагынмыйм ди, Ваш Блгаруди, кәнишне, ыскучаю.

— Вот и договорились. Все будет хорошо! Главное, мы живы, мой друг!

## 25

Май аенын беренче яртысында Әхмәтнәсир тернәкләнү төркеменә күчерелде. Озатып калганда, дәвалаучы карт духтыр: «Кискен хәрәкәт ясап кулына көч китерергә тырышма! Ашыкмыйча, әкренләп күнектер кулынны. Һәрхәлдә, үз икмәгенне үз көчен белән эшләп табарга мөмкин булачак» — дип, егетнен күнеленә ышаныч иңдерде.

Полковник Кропотовнын ярасы да әкренләп төзәлеп килә. Июль ае башларында култык таягы ярдәмендә аягына басты.

## 26

Полковник Кропотов яра алган Ниешанц бәрелешендә Меньшиков беркадәр унышка ирешә алса да, ныгытманы яулар өчен көче житәрлек дәрәҗәдә түгел иде. Шуна да карамастан, ул бәрелешнен нәтиҗәсе яна

мөмкинчелек ачты. Кулга алынган әсирләр аша нытытмадагы гаскәр саны, коралның күпме булуы ачыкланды. Иң мөһиме — алар нытытманы якыннан күрделәр. Шлиссельбург нытытмасы белән бу нытытма арасында аерма зур. Чөнки ул, коры жир өстендә урнашып, балчыктан өйгән валдан гына тора иде.

Егерме алтынчы апрельдә Шереметьев ярдәмгә килде, нытытма камалды. Фельдмаршалның ультиматумын нытытмадагылар кабул итмәгәч, утызынчы апрельдә, бөтен булган туплардан көчле атышлар башланды. Көчле артиллерия белән жиде йөз кешедән торган гаскәр саклауга карамастан, урысларның көчле басымына җавап уты ачмый гына нытытма бирелергә мәжбүр булды. Нытытманы алып дүрт-биш көн вакыт узу белән, Нева тамагында, Нумерс эскадрасыннан ике швед карабы күренде. Нытытманың урыслар ягына күчкәнен алар әле белми иде, күрәсең, нытытмага якынаерга рөхсәт сорап ике мәртәбә туптан аттылар. Каршы җавап биреп, урыслар шведларны алдады. Петр I, тиз арада утыз көймәне икегә бүлеп, бер төркеменә дошманның юлын капларга, икенчесенә карабларга һөҗүм итәргә әмер бирде. Корган планны ике көн эчендә тормышка ашырып, жиденче майда һөҗүмгә күчтеләр һәм ике карабны да кулга алдылар. Шулай итеп, Ладога күленнән алып Нева елгасы тамагына кадәр ара, тулысы белән Русия патшалыгы кулы астына күчте.

Шведларның урысларны тынычлыкта калдырмасын алдан тоеп, Петр I нең уенда Нева тамагында яна шәһәр-нытытма кору нияте туды. 1703 елның уналтынчы маенда яна нытытма-шәһәргә беренче нигез ташы салынды. Буласы шәһәргә Санкт-Петербург исеме бирелде. Төзелә башлаган алты бастионның берсендә Петр Михайлович үзе катнашты. Калган бишесе Меньшиков, Головкин, Зотов, Трубецкой, Нарышкинга йөкләнде.

Нумерсның караблар эскадрасы, жәй буе Нева тамагы тирәләрен сак астында тотып, кышкылык ялга киткәч, Петр I Котлин утравы ярларын барлап чыгасы итте. Эре ташлардан торган сайлык белән Котлин арасында фарватер үтә. Әгәр шул ташлыкта ясалма утрау ясап, туплар урнаштыра калганда шведларга Нева тамагына узып керү мөмкин булмаска тиеш иде. Кичектермичә бу ниятне тормышка ашыру эшләре башланып китте. Кыска гына вакыт эчендә башкарып чыгып, утрауга тупларны урнаштырып та куйдылар.

Урыс патшасының Нева елгасы тамагында шәһәр торгызу эшләре башлап жибәрүе Аурупа илләренә мәгълүм булды. Шул ук елның ноябрь аенда чит ил сәүдә караблары Нева ярында якорь ыргытты. Шведлардан яшерен рәвештә узып кергән беренче карабның шкиперына биш йөз алтын тәнкә, матросларына утызар таллер бүләк бирде. Әнә шулай, Русия тарихында беренче мәртәбә Аурупа белән якын арада дингез сәүдә юлы барлыкка килде. Яулап алган бу жирләрне нытытыр өчен шведлар белән Русия арасындагы кан койгыч сугышлар әле алда иде.

## 27

Утыз беренче июль көнне полковник Кропотов белән Әхмәтнәсир Псковтан Мәскәүгә килделәр. Өч тәүлек буена патша канцеляриясе аша ялалану нәтиҗәләрен законлаштырган кирәкле язулар туплап, дүртендә Тамбовка, анда бер кич куныи, алтысында Вишневка утарына кайтып төштеләр. Халык аларны зурлап каршы алды. Алар кайту хөрмәтенә, кызу печән өсте булуга карамастан, бер көн тулысы белән бәйрәм итеп узды. Авылда тагын өч гаилә арткан. Авыл зурая. Болында печәннәр жыелып беткән. Елга аръягындагы яна жирдә әле эшләр төгәлләнмәгән иде.

Бияләр саны бермә-бер арткан. Кымыз ясауны үзләштереп, колачны кин җәйгәннәр. Маллар өчен көтү җирләре кинәйтелгәнлектән, сыерлар белән сарык көтүен дә ишәйткәннәр.

Очрашу кичәсендә Иван Егорович: «Как удачно, что вы вернулись!» — дип, чын йөрәктән шатланып тост күтәрде.

Шул кичәдән соң, һава суларга чыккан Әхмәтнәсир янына килеп, кулын егетнең инбашына куйды:

— Син мина үз улым шикелле якын. Син безгә кайтырсың әле дип йөрәгем сизенгән иде, сизгерлегем алдамаган. Человек ты добрый. Спасибо, что сберег сына моего единственного! Так что живи у нас столько, сколько душа пожелает! Если хочешь, мы тебя женим и дом добротный возведем. Русская девка не по душе тык, татарочку найдем.

Төн уртасына кадәр шулай хыялланып утырып, Әхмәтнәсир йокларга ятты. Даласын хәтерләткән хуш исле печән исе аны балачагына алып кайтты. Язмышына канәгать иде ул. Чөнки гомер юлында гел яхшы кешеләр очрап торды, алар һәрчак яхшы теләктә булдылар. Бу минутларда анардан да бәхетлерәк кеше юк иде дөньяда.

Икенче көнне мунча яктылар. Хуш исле каен себеркесе белән чабынып, егет озак кына юынды. Өч ел буена тозланып каткан тир белән бергә, аруталу, әрнешүләр себерке белән куптарылып, печән вагында кайнаган чишмә суында юылып юкка чыкты. Яна туган сабый тәне шикелле жинеләеп, жаны хушланып, нәүмизләнеп калды. «Ходай кушып, туган ягыма кайта калсам, ин әүвәл мунча торгызачакмын!» — дип, күнеле түренә уеп, зиһененә салып куйды.

Берничә көннән печәннәр чабылып бетте. Алдарак чабылганнарын жыеп, шул ук урыннарда чүмәләгә салдылар. Башка халык белән таннан торып Әхмәтнәсир дә болынга чыккалады. Чалгы сабын аркалык каешы белән биленә бәйләп, уң кул ярдәмендә печән чапты. Жан теләсә булдырып булмас эш юк, әкренләп жайланды, күнекте. «Иншә Алла, көйләнер барысы да!» — дип үз-үзен дәртләндереп, егетнең рухы күтәрелде, өмет чаткысы кабынды.

Бер көнне, төш вакытларында, егет янына Иван Егорычның онгы Егор килде.

— Ахмет! Сегодня на рыбалку пойдем! С ночевкой! — диде ул шатлыктан балкып.

— Ладны, Егор. А мне шас ышто делайт?

— Ничего не делать. Просто будь готов. А я иду червей копать. Курицу зарезали.

— А курицы зачим?

— Как зачем? Потроха для сомов, а с курицой архирейскую уху сварим.

Унбер яшьлек малай, элеккеге шикелле, Әхмәтнәсир тирәсенә елыша, дала тормышы турында сорашып, аралашырга ярата. Соңгы өч ел эчендә буйга тартылган, тормышка карата кызыксынучанлыгы арткан. Атасын ул: «Здравие желаем, господин полковник! С благополучным возвращением Вас!» — дип каршылаsucca, кулларын җәеп, Әхмәтнәсирнең кочагына ташлана: «Как хорошо, что ты вернулся, Ахмет! Ты научишь меня освоить татарский язык?!»

Ул элек тә, кайбер сүзләрнең тәржемәләрен сорап, кызыксына иде. Ә хәзер аның: «А это по-вашему как будет?» — дип, тулы җөмләләрнең тәржемәсен беләсе килә.

«Зачим иты тибә? Эс ким будиш абшатсы?» — дисән, ул: «Когда я стану взрослым, обязательно поеду в твою страну, — ди. Бертын уйланып алганнан

сон: «В городе некоторые отзываются о татарах плохо. А я своими глазами вижу, что татары очень хорошие люди», — дип елмая.

— На эты люди не абижайсы, Егор. Разный люди есть и среди татар и среди уруских. Ани, навирны, плахими людими абшалис.

Кичке якта ат жигеп балыкка киттеләр. Әхмәтнәсир белән Егордан башка Еремей дигән бер авыл мужигын да үзләре белән алдылар. «Еремей рыбак от бога. С ним мы без рыбы не останемся», — дип, алдан ук юлның унышлы булачагына ышаныч юрадылар.

Кичүгә житәрәк, елга борылышында туктадылар. Атны тугарып, Еремей учакка коры-сары җыйды. Яр кырыендагы ачыклыкта учак өчен урын әзерләде. Егор белән Әхмәтнәсир чатыр кордылар. Ә полковник: «Төнлә эзләргә туры килмәсен», — дип, арбадагы кирәк-яракны үз урыннарына урнаштырды. Яр буенда җайлы урын сайлап, берничә урында балыкларга жим салды. Кичү яклап чишмә бар иде. Еремей, су алып килеп, таганга казан элде. Шуның белән әзерлек эшләре тәгәлләнде. Түземсезлек белән көткән Егор беренчеләрдән булып кармак салды. Еремей, үз кирәк-ярагын алып, таллар артына кереп югалды. Ашаткан урында балыклар җыелып өлгергән иде инде. Кая карама, шап та шоп сикергәләп, балык уйный. Беренче балыкны Егор тартып чыгарды. Бу кушбаш иде. Аның артыннан ук Әхмәтнәсиргә дә бәхет елмайды. — А иты какой рыбы? — дигән соравына, Иван Егорыч: — Ого! Это язь. Большая. Около килограмма потянет, — дип, егетнең шатлыгын бүлеште. Полковникның үзенә алабуга эләкте. Еремей гына, куак артында посып, тавыш-тынсыз утыра бирде. Ул гел тирәннән тота икән.

Кармак салу белән чиртләкне чумдырып балык чиертә, үзара сүз катырга вакыт юк. Дәртнең кызып киткән чагында шактый күп балык тотып өлгергән иде алар. Еремей белән Егор балык тазарткан арада казанда су кайнады. Иван Егорыч тавыкны кисәкләргә кискәләде, Әхмәтнәсир бәрәңге әрчеде. Моңа кадәр егетнең бәрәңге күргәне юк иде әле. Вишневкада да аны күптән түгел генә утырта башлаганнар. Ярмаланып пешкән бу азык егет күңеленә хуш килде. Уха пешерүне Еремей үз өстенә алды, ә егет, кызыксынып, читтән күзәтеп торды. Кайнап торган суны чиләккә бушатып, Еремей казан төбенә берничә кисәк тавык ите салды. Тураган суган сибеп, бер кат балык кисәкләре тезде. Өстенә тәмләткеч үләннәр җәеп, шул ук хәлне тагын берничә кат кабатлады. Шулар соныннан бәрәңгеләрне тезеп, өстенә кайнар су салды. Ярты сәгать тирәсе пешкәннән соң, тозлап, тагын су өстәде. Ун-унбиш минуттан казан капкачын ачып җибәрү белән тирә-якка хуш ис таралды. Әрхәрәй ухасы, чынлап та, искиткеч тәмле иде!

Ашап-эчеп тамакларны туйдыру белән, Еремей, балта тотып, таллык арасын ботарларга кереште. Яртылаш корый башлаган беләк юанлыгы талларны төпләп, учак янәшәсенә чыгарып өйде. Коры утын өелеп яткан җирдә чи таллар ниемә кирәк дип аптыраганнар иде... Еремей кискән агачларын яргалады. Тишкәләнеп беткән агач эчендә чәнти бармак зурлыгында кортлар бар икән.

«Вот вам хорошая насадка. На них можно рыбу покрупнее поймать», — диде тәҗрибәле балыкчы.

Күк йөзенә меңләгән йолдызлар кабызып төнге караңгылык инде. Йокларга яттылар. Якында гына, күңелгә шом салып, мәче башлы ябалак ухылдый. Иртәгәсе тотылачак эре уңышка өмет уятып, янәшәдә генә шаптыр-шоптыр балык уйный. Гомерендә беренче мәртәбә балык тотып караган егетнең күз алдында биегән калкавыч, сихерле җан иясе шикелле батып-чумып, йоклап китәргә ирек бирмичә, күңелен җилкендерде. Онытылып йокыга талгач та карт полковник аларны татлы йокыларыннан

уятты. Офык буе агарып килә. Инеш өстенә сыек кына булып томан ингән.

Таллык артындагы бушлыкта Еремей балык белән көч сынашып ята иде.

— Жирдән бечевканы алыгыз, аякка урала! — диде ул.

Кылдан үреп сумалаланган калын жеп жәя кылы шикелле киерелеп тартылган. Әйтерсен лә жепнен икенче башында балык түгел, ә дүрт аягын жиргә терәп яшь үгез басып тора иде. Әле бер, әле икенче якка йөздереп, ара якынаямы дигәндә генә су асты иясе, суны болгатып, янадан кире упкын төбенә тартыла.

Әкренләп көн яктырды. Дөньяларын онытып барысы да тамаша күзәтә. Ара-тирә кинәш биргәлиләр. Ниһаять, билгесез жан иясе арыды. Суны кин итеп сөздереп ярга якынайды. Уникедән үргән каеш камчы шикелле ике мыек күренде.Артыннан ук, подаука соскы зурлыгында, иләмсез кин авыз пәйда булды. Яр кырыена кадап куйган таякны алып, Еремей балыкнын өске иренenә сукты. Киерелеп китеп балык тынып калды. «Помогите пока он не очухался!» — дип, балыкнын аскы ирененнән тотып, ярга сөйрәде. Дүртәүләп ябышып балыкны яр өстенә менгерделәр. Шунда ук жан инеп өлгергән балык боргаланырга керешге. Хром итек шикелле елтыр тәнле, Егордан да зуррак жәен балыгы иде бу... Калган ике кармак та буш түгелләр. Аларга да жәен эләккән. Алары артык эре түгел — берәр пот чамасы булыр.

Балыклар бозылганчы дип Егорыч юлга әзерләнергә кушты. Балыкны тиз генә чыптага төреп арбага салдылар да кайту ягына кузгалдылар. Шул чак ат алдыннан өерелеп бер көтү кыр тавыгы, бүдәнәләр пырхылдады. Артык югары күтәрелми генә очып барып, алдарак янә юлга төштеләр. Берничә кат шулай очып китеп, кунгалап, ярты юлны озатып бардылар да сонынннан кире якка очып күздән югалдылар.

— Күп алар быел. Симерсеннәр әле бераз. Ачтан үлмәбез, — диде Егорыч, сөенеп.

## 28

Июль азакларында арыш басуына төштеләр. Бодай житешеп килә, ашыгырга кирәк иде. Чалгыларга жәя тарттырып, ир-атлар арыш чаба, хатын-кызлар көлтә бәйләп чүмәлә куя. Берничә көн чүмәләләрне ындыр табагына ташып, суктыра да башладылар. Икмәк суктыру үзенә күрә бер күнелле тамаша иде. Көлтәләрнен башаклы якларын уртага куеп жәяләр дә, тирәсен уратып алып агайлар, чабагачлар белән, бер ритмда дөнкәчли башлыйлар. Берничә кат әйләндергәләп суккалый торгач, саламын жыеп алып, шул ук хәл янадан кабатлана. Такыр жир өстендә бөртек өеме барлыкка килгәч, жыеп алып, олырак агайлар түшәм астында иләктә илиләр. Бер читтәрәк хатын-кызлар, каен тузыннан ясаган савытлар белән баш очларына күтәреп, орлыкны жилдә жилгәреп торалар. Бала-чагаларга да эш житәрлек. Берәүләре кырдан көлтә ташый, икенчеләре, ындыр табагында көлтә биреп, суктырган көлтәләрне жыеп алып тора. Иген өстендә олысы-яше эштә. Ырудан чыккан хәлсез карт-коры белән имчәк балалары гына бу эштән азат иделәр.

Әхмәтнәсиргә дә эш житәрлек. Чистартылган орлыкны капчыкларга тутырып амбарга ташый. Түшәм астындагы зур үлчәүдә үлчәп, булышчысы Егор дәфтәргә теркәп бара.

Арыш басуын тәмамлап килгәндә, күк күкрәтеп, көчле янгыр явып узды. Чыланган сонгы көлтәләрне ачык һава астында жәеп кояшта киптерделәр. Кипшендереп суктырганнан сон да орлыгын аерым келәткә салырга туры

килде. Аларын ярмага тарттырачаклар. Бодайга төшкәнче тагын берничә мәртәбә яңгырлар булып узды.

Кыш җитеп беренче кар күренү белән, кыр тавыгына ауга бардылар. Анда да Еремей үз осталыгын күрсәтте. Иван Егорыч белән Әхмәтнәсир мылтык күтәреп чабулап йөргән арада Еремей мылтыксыз гына да унлап тавык тотып алды. Сарайлар артындагы печән өеме тирәсенә кичтән кибәк сибеп калдырган булган. Шуның өстенә кылдан үргән ятьмә җәйгән. Таң белән печәнлеккә бүдәнәләр төшеп, тибенгәләп, ятьмәгә чуалганнар.

— Ах этот Еремушка, опять обдурил старика! — дип, гаҗәпләнгән булып, Иван Егорыч Еремейга канат куйды.

Еремей кышкылыкка бәйләм-бәйләм нечкә тал чыбыклары әзерләп калдырган булган. Аларны кайнар суда пешекләп кыш буе кәрҗиннәр үрә. Әхмәтнәсирне ул, балык тотар өчен, «морда» дигән нәрсә үрергә өйрәтте. Иван Егорыч алып килгән тегәрҗептән Еремей ятьмә, ау, сөрәкә үрде.

Раштуа бәйрәме алдыннан хуҗалар килеп төште. Утар өендә тәртип булуын күреп хуҗабикәләр бик канәгать калдылар. Юк, без ачыкмадык диешеп барысы да кымызга ябырылды, үз гомерләрендә беренче мәртәбә кымыз авыз иткәндәй, Әхмәтнәсирне мактадылар.

Сүз барышында егет үзенең аларча хәреф танымаганлыгын искәрткән иде... Юк-бардан гына башланып киткән әңгәмә Әхмәтнәсир өчен бик мөһим борылыш алды. Кунаклар ике атна буе авылда торган арада, көннәр буе дәрес әзерләп, укырга, язарга өйрәтә торгач, егет әкренләп белемне үзләштерде. Шәһәргә китәр алдыннан Егор аңа каләм белән чиста дәфтәр, китаплар калдырды. Бәхетенә каршы, Егорның беренче сыйныфта кулланган китаплары түшәм астында сакланып калган булган. Май ае җитеп, хуҗалар җәйгелеккә күченеп килгәндә, Әхмәтнәсир аларча яхшы гына укый-яза белә иде инде.

## 29

Семен Иванович, иртәгә юлга чыгачакларын әйтеп, кирәк-яракны кичтән әзерләргә, таң белән үк атларны җигеп куярга Трифонга кушты. Таң атканда атлар юлга әзер иде инде. Бер арбада кымызлы шешәләр тутырган зур дүрт кәрҗин, икенче җиңел тарантас хуҗалар өчен. Полковник үзе белән Әхмәтнәсирне алып, юлга кузгалдылар.

— Кымыз прдават штули будим? — дип, егет сорап куйган иде.

— Нет, Ахмет. Едем в Уварово. Там для раненных лечебницу открыли, — дип, полковник егетнең аркасыннан сөйде.

Урман эчләрендә юл кардан әрчелеп бетмәгән. Урыны белән чокыр-чакыр, баткак. Олы юлга чыккач, ат йөге җиңеләйгәндәй булды.

Бу тирәдә табигать бөтенләй бүтән иде. Каен катыш нарат урманы, усаклар да очрый. Кардан ачылган урыннарда ямь-яшел булып чирәм күтәрелеп килә. Юл аркылы поши юыртып узды. Әнә, кырыйлатып, тагын икәү килә. Ана пошый ике яшьлек бозавы белән тукталып, җигүле атны озатып калды. Берничә урында төлке дә күренде. Кышкы киемнәреннән арынып бетмәгәннәр, йолкышлар.

Төш вакытларында Уваровога барып керделәр. Юлда очраган кеше аша белешеп тагы бер чакрым ара узарга туры килде. Нарат урманы уртасында киң генә алан иде. Урманга терәп салган зур гына берничә нарат өй күренә. Каршы яклап утын өемнәре белән тулган сарайлар, каралты-куралар. Урта бер урында түгәрәк ике түшәм. Түшәм астында өстәлләр белән эскәмияләр. Бер төркем ир-ат, өстәл тирәли утырып, гәп сата. Янәшәләренә килеп туктау белән полковник тарантастан төште.

— Здравствуйте, господа! — дип, күтәренке тавыш белән сәлам бирде.

Яннарына килде. — Командир драгунского полка полковник Кропотов! — дип, һәрберсе белән кул бирешеп, исәнләшеп чыкты.

— Ну как отдыхается? Воздух тут у вас чудесный!

Янәшәдәге өй эченнән урта яшьләрдәге бер адәм күренде.

— Слушаю Вас, господа. Чем могу быть полезен? — дип кул сузып, Кропотов белән күреште.

— Это мой адъютант Ахмет. Участник Азовских баталий. Был ранен при взятии крепости Мариенбург. А я — полковник Кропотов. Ранение получил при взятии крепости Ниешанц.

— Приехали восстановить здоровье? Милости просим, господа! Я, стряпчий, Андрей Иванович Казимиров, к вашим услугам!

— Спасибо! Но у нас цель приезда иного характера, Андрей Иванович. Тут недалеко у меня имение. Производим кумыз. Очень полезный напиток!

— Спасибо... но...

— Никаких но! Мы Вам предлагаем свои услуги безвозмездно.

— Премного благодарен, господин полковник! Это очень похвально с Вашей стороны. От помощи мы не откажемся.

Полковник, егет ягына борылып:

— Ахмет, встречай Трифона. А я пока тут ознакомлюсь с условиями, — диде.

Кымызны бушатып, Трифонны кире кайтарып җибәрделәр. Бирелдәге тормыш белән якыннанрак танышыр өчен полковник берничә көнгә тоткарланырга булды. Әлегә халык күп түгел, егетләренә ятак урыннар җитәрлек.

Чын дәвалаучы өлкән духтыр Воронежда булган икән, кичке якта кайтты. Кропотовның тәкъдимен белеп алгач бик шатланды:

— Как это хорошо! Вы вовремя приехали! — диде.

## 30

Ничек итеп вакыт уздырырга белми йөргән егеткә, ниһаять, җаваплы эш табылды. Мона кадәр нинди генә эшкә тотынмасын: «Ахмет, Иван Егорыч нам запретил утруждать тебя работой», — дип, Трифон адым саен гел искәртеп торды. Кышкы ялда килеп киткән хуҗалар алдында приказчикны яклап чыкканлыктан, Трифонның егеткә карашы кискен үзгәрде. Аңа кадәр егетне ул үз көндәше итеп күрә иде, ә хәзер бар эштә дә киңәшләшә, үз фикерен уртаклаша. Күп кенә тормыш хәлләрен Трифон аша өйрәнсә, кайбер очракта егет биргән киңәшләр приказчикка файда китерә иде. Үләннәр белән им-том итә белгәч, Әхмәтнәзир авыл халкына да хәленнән килгәнчә булышты, дәвалап ярдәм итте. Килгән елны шундый хәл булды. Бер гаиләдә өч айлык бала көн елый, төн елый. Зәхмәт тигән, күрәсең, диеп ни эшләргә белми аптыраган гаилә янына кергәч: «Карарга мөмкинме?» — диде. Аркасында яткан бала, күкрәген киереп, бик каты елый иде. Егет баланы кулына алып, аркасын карады.

«Аңлашыла», — дип анасына күкрәк сөтен учына тамызырга кушты Әхмәтнәсир. Ана сөте белән әкренләп уа торгач, каты төктән түгәрәк йомгак хасил булды. Бер үк хәлне берничә кат кабатлый торгач, сабый бала егетнең кулында килеш изелеп йокыга талды. Шул вакыттан халык теленә кереп калган Әхмәтнәсир әлегесе көнгә кадәр авыл халкын ярдәменнән ташламый иде.

Май аеннан алып көзгә кадәр егет үләннәр, үлән тамырлары җыеп киптерде. Киндер тукымадан янчыклар тектереп, һәрбер үләнне янчыкларга салды, исемнәрен язып, нәрсәдән кулланырга икәнен теркәде. Иван Егорыч белән Егор июнь аенда гына килгән иделәр. Килү белән егет Егорны да

бу эшкә тартты, язу-сызу эшләрен йөкләде. Июль ае азакларында, жыеп киптергән үләннәрен алып, егет белән Егор дәвалау йортына бардылар. Адам Карлович аларны, күптәнге танышлары шикелле, кочагын җәеп каршы алды.

«Монысы фәлән, монысы тегән», — дия-дия һәр үләннең исемен атады, нәрсәдән кулланырга кирәклеген аңлатты, ә Адам Карлович русчага тәрҗемә итеп торды. Соңыннан мактап егетнең кулларын кысты.

Үләннәрдән башка кымыз белән ике сарык түшкәсе дә алып килгәннәр иде. Чын күңелдән рәхмәт әйтеп, бик канәгать булып калды духтыр.

Яз көне килеп киткәннән соң тана суйдырып, Семен Иванович Трифон аша җибәрткән иде. Июнь аенда да приказчик кымыз белән ике сарык түшкәсе китереп китте.

Нева елгасы тирәсеннән куып чыгарылган шведлар урысларны тынычлыкта калдырырга теләмәде. Сестр яры буенда генерал Крониорт, зур көчләр туплап, Петербургка һөҗүм итәргә әзерләнде. Дошман һөҗүмен көтеп ятмыйча, Петр I, дүрт атлы, ике җәяүле полк белән җиденче июльдә үзе һөҗүмгә күчте. Шведларның меңләгән гаскәриен кырып, күбесен яралап, тар-мар итте. Урыслар ягында барлыгы утыз ике кеше һәлак булып, утыз ике кеше яраланды. Шуның нәтиҗәсендә, Уварово дәвалану йортында кеше саны артты.

## 31

Күнегелгән бертөрле тормыш мәшәкатьләре белән, 1703 ел да узып китте. Яна туган ел илгә җиңеллек китермәде. Киресенчә, илдә булган үзгәрешләр, «Төньяк» сугышы чыгымнары халык җилкәсенә авыр йөк булып ятты. Зыкыны алган авыр тормыш, торган саен халыкта тирән өметсезлек арттырып, соңгы чиккә илтеп терәде. Икмәк үстерергә кеше юк. Сабан тоткасы урынына эшкә яраклы ир-ат кулында — мылтык. Яңа җирләрдә шәһәр торгызу, ныгытмалар кору эшләрендә генә дә унҗиде меңнән артык халык бил бөгә. Шуның өстенә, налог өстенә яңа налоглар. Кораллы көчләр, ил буе кеше талап, налог җыя. Халык, авыллары белән куптарылып, урманнарга кача, Себер якларына китәргә мәҗбүр була. Бу тормыш авырлыклары алпавытлар белән дворян гаиләләрен дә читләтеп узмады. Күп кенә сәүдәгәрләр таланып бөлгенлеккә төште, күпләре Русиядән качып киттеләр. Кайбер урыннарда халык сәнәк тотып күтәрелде. Андый җирләргә коралды хәрбиләр җибәреп, халыкны канга батырдылар. Моның шаукымы Вишневка авылын да читләтеп узмады. Җыеп алган икмәкнең яртысы белән алты баш савым биясен, дүрт баш сыер малын тартып алып киттеләр. Яз башында ике яшь ирне хезмәткә тарттырганнар иде, тагын өч кеше соратып әмер килеп төште. Иван Егорыч, кирәкле язулар туплап, Тамбовка барды. Анда аның үтенечен хәл итмәгәч, Мәскәүгә китте. Уварово яралыларны дәвалау йортына ярдәм итү үз нәтиҗәсен бирде. Тиешле салымнан гайре җыемнардан азат ителүгә ышаныч кәгазе алып кайтуга ирешә.

Көннәрнең берендә, коралды ике хәрби ияртеп, утарга налог җыючы килеп төште. Семен Иванович өйдә юк чак иде. — Башкаларга караганда сез күпкә бай яшисез, шуна карап салымы да күтәренке булырга тиеш, әгәр фәлән кадәр сум акча белән ике ат бирсәгез, ул салымнан азат итәм диюгә Трифон: «Без тиешле салымны түләдек. Калганын хуҗа үзе хәл итәр. Әлегә ул өйдә юк. Көтегез», — дип акланды.

Семен Иванович, кайтып хәлнең асылына төшенү белән, Әхмәтнәсирне бер читкә чакырып алды: «Ахмет, возьми пару крепких мужиков с ружьем и ждите около амбаров», — диде дә, килүчеләргә әтисе алып кайткан таныклыкны күрсәтеп, сөйләшеп калды.

— Все это филькина грамота, — дип тегеләр төкрек чәчә башлаган иде. — Ну ладно тогда, пройдемте к амбарам. Все богатство у нас там, — дип, амбар янына алып китте. Барып туктау белән, каралтылар артыннан чыгып, дүрт-биш кеше бу адәмнәрне коралсызландырды, аяк-кулларын бәйләде. Икенче көнне, таң белән торып, килмешәкләрне Тамбовка алып киттеләр.

Тамбовның хәрбиләр идарәсе башлыгы Семен Ивановичның күптәнге танышы икән. Тикшерә торгач, бу адәмнәрнең үз башбаштаклыгы белән акча даулап йөргәнлекләре ачыкланды. Идарә житәкчесе, ул да полковник, ныгытып тикшергәннән соң хәл ачыклангач хәбәр итәрбез, дип калды.

Соныннан ишетеп белү буенча, ике хәрбине таяк белән суктырып, житәкчесен Себер жибәргәннәр. Шул хәлдән соң утарга килүче кеше булмады.

Ул ел кыенлык белән узып, икенче ел да артык жинеллек китермәде. Семен Иванович Кропотовны, тәжрибәле офицер буларак, хезмәткә чакырттылар. Әхмәтнәсир дә полковник белән бергә хезмәткә алуларын үтенеп сораган иде. Тикшерү вакытында, безгә, гади сугышчы буларак, сау-сәламәт кеше кирәк, диделәр. Яраксыз дип табып, алмадылар хезмәткә.

**32**

Мең дә жиде йөз дүртенче елның уналтынчы ноябрендә:

«Елгаларда боз кату белән кичектерми генерал Левенгауптка каршы чык!» дип Петр Iдән хат алуга карамастан, фельдмаршал юлга чыгарга ашыкмады. 1705 елның февралендә: «Из-за отсутствия провиантов не имел возможности исполнить Вашу просьбу сиюминутно» — дип юллама жибәрде. Патша белән фельдмаршал арасы киеренке булуга карамастан, гаскәрен жиренә житкереп хәзерләп бетермичә фельдмаршалның бер адым да ясамавын Петр белә. Артык зур стратег булмаса да, жинел генә гаскәрен харап итәргә әзер торган кеше түгел иде фельдмаршал. Сугыш кирәк-ярагы, бер рәттән азык-төлек белән сугышларда катнашып тәжрибә туплаган офицерларга да мохтаж иде ул. Яра алып та хәрәкәт итәргә мөмкинчелеге булган барлык офицерларны чакыртып алып, жиренә житкереп юлга әзерләнде.

1705 елның 12 июнендә, чирдән терелеп аягына басу белән, Петр I, барлык көчләр белән генералитет тупланган Полоцк шәһәренә килде. Кинәшмәдә хәл ителгәнчә барса швед генералы Левенгауптны Ригадан кысрыкларга тиеш иде. Бу мөһим бурыч Шереметьевка тапшырылды. 15 июльдә каралган план буенча атлы драгуннардан гына торган гаскәр, турыдан-туры һөжүмгә күчмичә, әйләнеч юл белән дошманны уратып алып тар-мар итәчәк. Баштарак уңыш урыслар ягында иде. Митава ныгытмасына көтмәгәндә һөжүм ясап, гарнизонны тулысынча диярлек юк итүгә ирештеләр. Алда шведларның төп көчләре белән очрашасы бар иде. Генерал Левенгаупт Мур борыны тирәсендә уңайлы позициядә ныгытма корып урнашкан. План буенча, урыслар Мур борынына турыдан-туры һөжүм итәргә тиеш түгел иде. Урыслар корган хәйләне шведлар да кулланды. Алда торган бер төркем швед атлылары, янәсе, качып китәргә мәжбүр булды. Ике елга якын сугышта катнашмыйча, дошманның хәйләсен аңлап бетермәгән Кропотов, Шереметьевтан рөхсәт сорап тормый гына, шведларны куа чыкты. Аңа ияреп башка полклар да күтәрелде. Шведлар аларны көчле туплардан атып каршы алды, каты бәрелеш башланып китте. Шереметьев, бу хәлне күреп, башка көчләрне дә ярдәмгә жибәрергә мәжбүр булды. Һөжүмгә күчү белән, урыс гаскәре шведлар калдырган алдавыч обозны таларга кереште. Шведлар икенче көнне таң белән, яңа көч туплап, һөжүмгә ташландылар. Унөч пушка белән ун әләмне кулга төшереп, урысларны чигенергә мәжбүр иттеләр. Ул

бәрелештә ике меннән артык кеше үтерелде. Мур борынындагы, җиңелү Шереметьев өчен бердәнбер генә булуга карамастан, аның күңелендә авыр юшкын калдырды. Фельдмаршалдан кисәтү алмаса да, полковник Кропотов, үз ялгышын аңлап, бу хәлләрне авыр кичерде. Бишенче сентябрьдә яңа көчләр туплап, Митава ныгытмасын, үндүртендә Баускны бирелергә мәҗбүр иттеләр. Бауск ныгытмасында илле биш туп кулга төшкән булса, Митавада ике йөз туксан биш тупка баедылар. Аларның йөзгә якыны яңа конструкциядә эшләнгән мортиралар иде. Митава тантанасын бәйрәм итеп өлгермәделәр, патша исеменә Казан сарае җитәкчесе Борис Алексеевич Голицыннан көтелмәгән хәбәр килеп төште. Әстерханда стрелецлар фетнә күтәргән, Мәскәүгә яу белән киләчәкләр, имеш. Петр I өчен бу начар хәбәр иде. Әстерханны югалту — зур югалту. Беренчедән, ул Идел елгасы аша сәүдә юлы: икенчедән, балык тоту, стратегик башка төрле җиһазлар җитештерүче мөһим шәһәр. Анда төрле милләт халкы яши. Дүрт йөз тирәсе әрмән итек тегә, Бохара һәм башка чит ил сәүдәгәрләре, алыш-биреш белән сәүдә итеп, казнага байлык китерә. Петр I, бу яман хәбәрне алу белән, ярдәмчесе Тихон Никитич Стрегнев аша, ике атна эчендә Шереметьевка Мәскәүгә барып җитәргә кушты. Калада булган барлык кораллар белән казна акчасын читкә чыгарырга, һич югы җиргә күмәргә әмер бирде.

Шереметьев бу таләпне теләми генә кабул итеп, егерменче октябрьдә генә Мәскәүгә килә. Бер ай буе Мәскәүдә булып, ноябрь ае урталарында Түбән Новгородта, унсигезенче декабрьдә Казанда пәйда булды.

Казанда кыш уздырырга ниятләп, Головин аша Петр Iдән кыска гына вакытка булса да Мәскәүгә кайтып килергә рөхсәт сорады. Патша аның үтенечен кире кагып кына калмады, гади солдат Михаил Щепотов аның өстеннән шымчылык итәргә билгеләде.

1706 елның 16 гыйнварында Щепотов Казанга килеп, фельдмаршалга патшаның шул әмерен җиткерде. Бу хәбәр фельдмаршалны бик нык кимсетте. Февраль аенда ук Сарытауга, анда озак тоткарланмый Царицынга килде. Бу вакыт эчендә Әстерханлылар Мәскәүгә юлчы юллап, бу хәлне кан коймый гына хәл итүне үтенәләр. Әстерханлылар белән Мәскәү арасында сөйләшүләр баруы Шереметьевка мәгълүм булды. Шуның өстенә Әстерханнан Шереметьевка, Мәскәүдән патша әмере килеп җитмичә шәһәрне камамаска кушып, юллама килде. Мәскәү белән Әстерхан арасында солых төзелеп, хәрби көчләрнең кирәге чыкмый калу Шереметьевның дәрәҗәсен тагы да түбәнрәк төшерәчәк иде. Гади хәрби хәленә калдырылып кимсетелгән фельдмаршал андый түбәнлекне күтәрә алмаячак. Шәһәрне камап булса да, әгәр «Черный ярдагы» шикелле халык иконалар тотып чыгып кан коелмый гына бирелә калганда, Шереметьев өчен бу бүләкләнә алырдай дәрәҗә өстәмәс иде. Төп карарга килеп, Шереметьев шәһәр халкына хат юллады. Тиз арада гына нәтиҗәле җавап алмасын ул белә иде. Икенче көнне үк шәһәр читендәге балчыктан өелгән валга туплардан ут ачты.

Шәһәрдә бар халык та килешү яклы түгел иде. Фетнәче стрелецлар белән тупчылар, каршылык күрсәтеп, җавап уты ачтылар.

Хөкүмәт гаскәрләре өчен бу зур каршылык түгел иде, унөченче мартта шәһәргә басып керделәр. Шәһәр уртасындагы таш ныгытмадагылар, каршылык күрсәтүне дәвам итеп, көчле ут астында, соңгы чиктә бирелергә мәҗбүр булдылар.

Хәрбиләр арасында югалтулар бик аз иде. Егерме кеше үтерелеп, илле өч кеше яраланган иде. Шәһәргә керү белән Шереметьев фетнәчеләрне бастырды. Кулга алынган ике йөз җитмеш өч кешедән бер йөз алтмыш җидесе — стрелецлар. Соныннан, тикшергәч беленде: 504 кеше фетнәче булган. Шуларның 314е җәзага тартылды, калганнарын Себергә сөрделәр.

Шереметьевнын элеккеге унышларын һәм дә Әстерханны азат итүен югары бәяләп, патша ана 2400 кешедән торган Юхотской өлкәсе белән Вощажников авылын бүләк итеп бирде. Әнә шулай фельдмаршал үз дәрәҗәсен саклап кала алды.

### 33

Мур борынында булып алган ялгышлыктан соң, Митава ныгытмасын алу тантанасында катнашкан полковник Кропотов әкренләп элекке хәленә кайтты. Дошман белән күзгә-күз очрашып көрәшергә күнеккән хәрби офицер өчен Әстерхан фетнәчеләренә каршы чыгу күнел кайтаргыч хәл иде. Айлар буе бер шәһәрдән икенчесенә йөри торгач, юл газапларыннан аяктагы җәрәхәт янә сызларга керешә. Сау-сәламәт кеше өчен дә көннәр, атналар буе ат өстендә йөрү жинел хәл түгел. Ниһаять, Әстерханны алып, тынычлыкта калгач, иске ярасы турында Шереметьевка искәртте. Фельдмаршал үзе дә бик талчыккан кыяфәттә иде. «Понимаю тебя, друг сердешный! Сам того же положения. За грехи мои пришла и мне болезнь ножная. Хоть и не был ранен, не могу ходить ни в сапогах, ни в башмаках. Благодарен за твой ратный труд непомерный! Не щадя живота своего помог родине нашей!» — дип, Кропотовны хезмәтеннән азат итте.

Семен Иванович Кропотов, пар ат жигелгән жинел арбада, Царицын аша Сарытауга, Сарытаудан Тамбовка юл тотты. Юл унаеннан Вишневкага сугылырга була иде, Тамбовта язу эшләрен жиренә житкермичә утарга кайтмаска булды.

Май ае урталары. Улы Егорнын әле мәктәп-гимназиядә укыган чагы. Гаиләнең Егорсыз утарга күченеп килмәве дә мөмкин иде. Һәм шулай булды да. Әтисе Иван Егоровичтан башка барысы да шәһәрдә иделәр. Егор укуын тәмамлагач, июнь аенда гаилә тулысы белән утарга кайтты.

Печәнгә төшәргә иртәрәк иде әле. Полковникнын исән-сау әйләнеп кайтуы хөрмәтенә бәйрәм уздырдылар. Авылда үзгәрешләр юк. Игеннәр матур гына күтәрелеп килә, үлән билгә житеп үскән. Озакка сузмый печәнгә төштеләр. Семен Ивановичнын сау-сәламәт әйләнеп кайтуы Әхмәтнәсир өчен дә зур шатлык булды. Полковникны каршы алганда ул: «Слава Аллаху, что вы живы. Я всю време прасил Аллаха, чтубы Вас беда миновал.» — дип, чын күнелдән шатлыгын белдерде.

Печәнгә төшү белән аллы-артлы янгырлар явып узды. Ары-бире йөреп вакытны әрәм итмәс өчен ир-атлар болында куна калып, иртә таннан карангы төшкәнгә тикле печән чаба. Егор да башкалар белән бергә төнгелеккә куна калырга әтисеннән сорап караган иде, әтисе рөхсәт итмәде. Бабасы Иван Егоровичтан үтенеп сорый торгач кына рөхсәт бирделәр.

Беренче төнне хәвеф-хәтәрсез генә, керфек тә какмый елга буенда балык тотып уздырдылар. Тәүлек буе йокламау үзенекен итте. Көнозын иләс-миләс йөреп талчыккан малай, кояш бату белән, кипшенгән үлән өстенә ятып тирән йокыга чумды. Ул төнне Әхмәтнәсир дә тирән йокыда иде. Тан алдыннан Егор кычкырып йокысыннан уянды. Күк йөзе агарып килсә дә карангы иде әле. Әхмәтнәсир сискәнеп анлы-минле бертын каушап калган иде. Төшендә күргәннәрен өндә дип уйлап, мылтык эзләде. Кулына сәнәк сабы эләгү белән сикереп торып: «Бүреләр? Кайда бүреләр?!» — дип саф татар телендә кычкырып җибәрде. Тавыштан башкалар да уянды. Бу вакытта Егор да кычкыруыннан туктаган, төчкерә-йөткерә, печән өстендә ауный иде. Барысы да малай тирәсенә жыелды. Егор тынычланды шикелле. Борынга нәрсәдер керде дип сенгермәкче итте, тагы да аллы-артлы төчкереп алды. Жиргә берәр нәрсә жәеп йокламагач, печән тузаны кергәндер, ахрысы. Зыян юктыр, үтәр диделәр.

Күзгә башкача йокы кермәде. Яктыра башлау белән, ат жигеп, Әхмәтнәсир егетне утарга алып кайтты. Күз алмалары кызарып йөзе бөртенгән малайны күрүгә әби белән әни кеше елаша ук башладылар.

Иван Егорович Әхмәтнәсиргә тарантас жигәргә кушты. Тарантас артындагы бушлыкка бер сарык бәйләп салдылар да өчәүләп Уваровага киттеләр. Юлда барганда тарантас чайкалуыннан малай изрәп йокыга талды. Бәхеткә каршы, Адам Карлович үз урынында иде: «Не волнуйся, молодой человек, разберемся», — дип, Егорга караганда бигрәк тә үз-үзен тынычландырырга теләгәндәй, зурайткыч пыяла аша малайның борынын тикшерергә кереште. Борын эче кызарып бүрткән, тагы да эчтәрәк ни барын күрерлек түгел иде.

— Скорее всего пыльца от сены. Чем ядовитее трава, тем она и полезнее. Но в меру! Ничего страшного, все пройдет, — дип, эшен бетереп, кулын юды һәм бер савытка үлән төнәтмәсе салып малайга сузды.

Адам Карлович биргән даруны ул кушканча кулланып берничә көн вакыт узды. Борын эченең жилсенүе кими төшеп, малай беразга тынычланган да кебек иде. Иген өсте житү белән Егор яңа баштан төннәрен йокламый чиргә сабышты. Утар хужалары бу хәлне иген өстендә куптарылган шул ук үлән, өлгереп килгән башак тузанына сылтадылар. Әхмәтнәсирне дә үзләре белән алып, гаилә шәһәргә күченеп китте.

Шәһәрдә дә малайның хәле үзгәрмәде. Ике-өч көнгә бер үкереп тиберченә, стенага менә башлый. Борын эчендә башланып киткән чир баш чиренә әверелде. Шәһәрдә булган барлык духтырлар да малайны тикшереп, тәгаен генә чирнең нәрсәдән икәнен әйтә алмадылар. Малай ашаудан калып, кибеп, саргаеп бара. Мәскәүгә алып барырга диеп жыенганнар иде, духтырлар дыңкылтык ерак юлда йөртергә рөхсәт бирмәделәр. Иван Егорович, үзе Мәскәүгә барып, алман кешесен, зур белгечне алып кайтты. Бер атна буе малай янәшәсендә утырып, тикшереп, ул да чирнең нәрсәдән булуын ачыклый алмады.

Әче кайгыда янып көз житте. Малай кипкәннән кипте. Тире дә сөяк. Семен Иванович ярдәм эзләп Мәскәүгә барган иде. Октябрь ае азакларында үзе белән бер адәмне ияртеп кайтты. Кунак Аурупадан килгән яһүд профессоры иде. Башта ул малай белән озак кына әңгәмә алып барды. Көннең кайсы вакытында башлана авырту, кай урында, ничек итеп авырта? Нинди дару эчкәч чире жинеләя? Шуннан соң гына, авыз эчен ачтырып, борын тишекләрен барлап, малайны тикшерергә кереште. Өч көн, өч төн буе малай янәшәсендә утырып, ничек кенә тикшереп карамасын, ул да бу чиргә тәгаен диагноз куя алмады. Китәр алдыннан, гаиләдәге барлык кешене аерым бүлмәгә жыеп: «Не знакомое доселе болезнь. Помочь, к сожалению, ничем не могу. Ребенок истощен до предела. Жить ему осталось максимум два, два с половиной месяца. Умрет он не от болезни, а от истощения», — диде.

Бу хәбәрдән соң ни дәрәжәдә салкын канлы Семен Иванович та түзмәде, сөлге белән йөзен каплаган килеш күз яшьләренә ирек бирде. Ана ияреп башкалар елаша. Йөрәккә кан саудырган бу күренештән Әхмәтнәсир дә түзмәде: «Дайте мни Егорошку, пажалысты! Увезу в деревне, на большуй путь готовить буду. Мужыт он ишо жить будит», — дип, хужаларны үгетләде.

Гаилә кешеләре бу үтенечкә тәгаен генә жавап бирер хәлдә түгел иделәр. Төне буе үзара сөйләшеп, киңәшеп чыктылар. Икенче көнне иртән Иван Егорович: «Ладно, Ахмет, забери нашего Егорушку. Вдруг твой Аллах исцелит его. Мы верим тебе! Верим в твою доброту!» — диде күз яшенә буылып.

Малайны тарантаска төреп салып, егет юлга кузгалды. Кайда юыртып, кайда атлатып кына бара торгач, төн урталарында Вишневкага кайтып җиттеләр. «Мы не хотим смотреть, как наша кровушка будет умирать», — дип, гаиләдән берсе дә авылга барырга теләмәде.

Кайтып төшү белән Әхмәтнәсир Трифонга каен утыннарыннан кызу гына итеп мунча ягарга кушты. Юлда тирбәлеп кайта торгач, малай тынычланып йокыга талган иде. Аны саклык белән генә күтәреп өй эченә алып керделәр. Өй эче суык иде. Мунча хәстәрен күрергә килеп җиткән хатын-кызларга өйне дә җылытырга кушылды. Әхмәтнәсир фонарь тотып чормадан кипкән үләннәр, каен себеркеләре алып төште.

Иртәнге якта малайның чире янадан кузгалды.

— Ахмет, помоги! Мне плохо. У меня в голове что-то живое опять трещит, гудит. Помоги, родной!

—Ты только терьпи! Ты будиш здаровый, терьпи родненки! Ты ысначалы кумыз попей. Бане пойдем, там жаркы. Пусле кушайт нужны будит. Что сказал духтыр, знаеш? Кушайт не будиш, умреш ысказал. Кушайт абизательны нады!

Шулай сөйләнә-сөйләнә малайны кыстап кымыз эчерде. Чишендереп юрганга төрде дә күтәреп мунчага алып керде. Эре бүрәнәдән салган өч яклы мунчаның алгы ягы чишенү, уртадагысы юыну бүлмәсе иде. Түрдә кайнар кызу як, чабыну өлеше. Зур-зур лаханнарның берсендә шаулап торган кайнар су, икенчесендә салкын чишмә суы. Тәрәзә аша көн яктысы төшүгә карамастан, егет ике дистә тирәсе шәм кабызып, лаханнар тирәсенә тезде.

— Ты түлке ыслушайся минә и тирпи! Всю будит харашо, Егорушкы! — дип сөйләнә-сөйләнә, малайны түр бүлмәгә алып кереп себерке белән чапты. Юыну бүлмәсенә алып чыгып, кайнар сулы лахан өстенә иелдерде, өстеннән чыпта белән каплады.

— Мне трудно дышать, Ахмет! — дип, малай башын күтәрмәкче иде.

— Жить хочешь, тирпи! Пака ишу трудны, потом лихше будит, — дип үгетләп, малайга башын күтәрергә ирек бирмәде.

Бераздан малайны салкын сулы лахан өстенә иелдерде, башын каплады. Салкын судан соң янадан чабыну бүлмәсенә алып кереп, себерке белән чапты. Ике мәртәбә шул ук хәлне кабатлаганнан соң, хәлсезләнеп калган малайны чишенү бүлмәсендәге тапчанга яткырды, эчәргә кымыз бирде.

— Ахмет, мне хорошо! Этот зверь замолчал. Мне стало лучше.

Ята торгач, малай йокыга китте. Ул йоклаган арада лахандагы үләнле суны кайнап торган яңа суга алыштырды. Бертөрле үләннәрне яндырып, ике бүлмәгә дә ис таратты. Малайны йокысыннан уятып, шул ук гамәлне берничә кат кабатларга мәҗбүр итте.

Узган көзне күпер аша чыкканда бер ат аягын сындырган иде. Төзәлә калганда да эшкә яраксыз булуын исәпкә алып, суярга булдылар. Сум итләрен тозлап, Әхмәтнәсир ачык һавада каклады. Калганыннан, үпкә-бавыр, казылыклары белән бергә тапап, тутырма ясадылар. Кышкы ял вакытында утарга килгән Егор каклаган ат итен ашап караган иде, бик ошады. Бер кисәген шәһәргә дә алып китте. Икенче кат, малайны себерке белән чабып тапчанга яткыргач, шул итләрне кискәләп кайнар суда тотты. Ит йомшара төшкәч: — Накы,папробуй! Ты любиш такой мясы, — дип, малайны ашатырга тырышты. Егор итне авызына алып чәйнәп карагач: — Ого, вкусно! А они что, у тебя еще остались?

— Канишне. Для тибе диржал. Кушай, кушай! Ты же любиш такой мясы, — дип кыстый-кыстый малайга ит ашатты.

Мунча кызуын яңарттылар, суларны алмаштырдылар.

— Ты что, Ахмет? Я устал. Может, на сегодня хватит?

— Нет, не хватит. Пака эты звирь находится у тебя на галавах, не хватит.

Беренче мәртәбә малайның ирен кырыйларында елмаю чаткысы күренде.

Яна баштан себерке белән җилпеп, малайны кайнар сулы лакан өстенә иелдерде. Шулай кабатлый торгач, малай берничә кат кайнар су өстенә төчкерергә мәҗбүр булды. Хәлсез тавыш белән малай кинәт кенә:

— Смотри, Ахмет! Что это такое? Это он, он! Тот зверь, который сидел в носу и трещал! — дип кычкырып җибәрде.

Әхмәтнәсир шәмне якынрак китереп суга иелде. Кан катыш суда ясмык зурлыгындагы таракан иде.

— Я так и думыл, — диде Әхмәтнәсир, өстеннән авыр йөк төшкәндәй хәлсезләнеп, тыныч кына. — У нас в деревне аднаму ребунку в ухы такой таракан чализал был. Бабушкы в ухы тюплий кумыз наливал.

— И что? Вышла таракашка?

— Кәнишне. Там же кушат совсем нет ничего.

Шаркылдашып көлеп кочаклаштылар да сүзне икенчегә борып, малай Әхмәтнәсирдән берәр төрле кызыклы хәл турында сөйләвен үтенде.

Моңа кадәр егет гел сугышта булган хәлләрне генә сөйли иде. Бу юлы ул данлыклы ат карагы Артай турында сөйлисе итте. Ничек итеп Артайның дошманнарын үтереп качып китүен сөйләде...

## 34

Беренче декабрьдә йомшак кына булып кар төште. Йөзләре кызарып, тулыланып килгән малайны җылы гына киендереп урамга алып чыктылар. Ул көнне бала-чага урамда иде. «Кар әбие» әеп, кар бәрешеп, шау-гөр килделәр. Малайның чирдән арынып аякка басуы авыл халкы өчен дә зур шатлык иде.

Әхмәтнәсир юлга әзерләнде. Ул күп итеп кымыз әзерләтте. Бәхеткә каршы бияләр сөт ташламаган иде әле.

Ул елның көзендә гөмбә унган иде. Трифон хатын-кызлардан күп кенә итеп гөмбә җыйдырып тозлатты. Бер өлешен киптерделәр. Кәбестә белән шалкан да унды. Ике кысыр сарыкны суеп, кышлыкка әзерләгән муллыктан өлеш чыгарып, түрле чанага төяделәр. Икенче чанага толып белән төреп Егорны утырттылар. Таң алдыннан Әхмәтнәсир белән Трифон юлга чыктылар. Кар тирән түгел, юл яхшы иде, көн өстендә барып керделәр. Шәһәрдәге йорты каршына атлылар килеп туктау белән өй эченнән өелешеп барысы урамга чыкты. Кропотовлар гаиләсе йөрәкләре кубып мәет көткәннәр иде... Толып эченнән алсу йөзле исән-сау малай торып басуга барысы бергә «ах!» килеп елашып Егорга ташландылар.

— Ты живой, родненький ты наш? Каким чудом! Миленький, хорошенький! Какой же ты у нас молодецкий!

— Это Ахмет! Ахмет меня вылечил! Это он молодец! — Егор үзе дә күз яшен тыя алмады, үксеп еларга кереште.

Әхмәтнәсирне кочаклап алдылар. Барысы да кочаклашып елаша. Читтән күзәтеп торган Трифон да түзмәде, җиңе белән яшен сөртеп алды.

Ул көн Кропотовлар өчен зур бәйрәм иде. Икенче көнне Трифонны кайтарып җибәреп, берничә көнгә генә булса да кал инде дип кыстап, Әхмәтнәсирне шәһәрдә алып калдылар. Шундый зур шатлыктан бераз айный төшеп, берничә көн вакыт узгач, өстәл артында утырганда Иван Егорович сүз башлады.

— Твой Аллах, конечно, тебе помогал. Но твой поступок должен быть вознагражден. Скажи, чтобы ты хотел в награду?

— Ничава мне не нады, Ваше Благородие. Я же не для награды старалсы. Слаубох Егор живой! Это мне бальшой награда.

— Хочешь, мы тебя главным хозяином села поставим. Дом для тебя построим, женим.

— Нет, гаспадин полкоуник. У вас есть харуший хозяин. Трифон свой дилы знает, народым знакум. И дом тоже не нады. У миня свой дом есть. Мать, атис есть. У миня есть свой степь, свой народ. Я их люблю. Я их панимаю, они миня понимают. Последни три, четыре год не с кем на своем языке не говарил. Это мой мамин язык. Я очень ыскучаю свой язык. Если вы самым делы хатите, что-ты добрый делать, отпустите мине домой. Я уже не солдат. Ваевать не бирут. А я дома ишшо успею женитса, детей рожать. Наслетника аставить.

— Ты прав, Ахмет! Я сделаю все, что в моих силах, чтобы выполнить твою просьбу, родной ты мой человек!

Тагын бер көн узып, авылга кайтып китәр алдыннан Иван Егорович Әхмәтнәсирнең кай якта тууын, кайчан ничәнче елда хезмәткә алынуын, ата-бабасы, нәсел-ыруын сораштырып, дәфтәргә теркәп калды: — Ладно, сынок, не волнуйся. Все будет хорошо. С завтрешнего дня начну хлопотать твоего освобождения от службы.

## 35

Егетне авылга озату белән аталы-уллы ике полковник киңәшкә утырдылар. Нәрсәдән башларга, кемгә беренче мөрәҗәгать итәргә, нинди аргумент белән нигезләп егетне хезмәттән арындырырга мөмкин? Булышырга теләк булу бер хәл. Ә эшне уңышлы башкарып чыгу, ул бөтенләй икенче нәрсә.

Икенче көнне икәүләп хәрбиләр бүлеге идарәсенә бардылар. Анда шул ук таныш полковник иде.

— Я даже не знаю, что ответить Вам, господа. В моей практике такого не было. Единственное, что смогу раскрыть одну тайну. По надежному источнику знаю, что сам Петр Алексеевич, со своей свитой, собирается приехать к Меньшикову. Точную дату не знаю. Скорее всего к Рождеству. Ловите момент. Когда он будет отдыхать с обильной горячительной, добр и снисходителен. Дерзайте, господа!

Раштуа бәйрәменә ике атнадан артык вакыт бар иде әле. Эшне озакка сузмыйча Воронежга барырга карар кылынды.

Семен Ивановичны Воронежга озату белән, «На всякий случай», — дип, Иван Егорович Вишневкага юл тотты. Шикләнүе юкка булмаган, биш көн узу белән улы Семен Иванович утарга кайтып төште. Петр Алексеевич Воронежда икән инде. Килү сәбәбе Меньшиков белән очрашу түгел, чире аркасында. Уваровага киләчәк икән. Авыр уйлардан алҗып чире кузгалган. Мактаулы исеме таралып өлгергән шифалы мунчада, сырхаудан арынып, берничә көн ял итәргә имеш исәбе.

Сугышлар Русияне фәкыйрьлек чигенә илтеп терәгән чак. Нарва, Мариенбург ныгытмалары, Нева елгасы буйларын шведлардан яулап алу бер хәл, аларны саклап тотасы бар. Карл XII Русияне тынычлыкта калдырмаячак. Аурупада таяна алырдай ил калмады. Август II шведларга бирелеп, ике арадагы килешүгә хыянәт иткәннән соң, шведларга каршы тору авырлыгы тулысы белән Русия өстенә төште. Бер яртысы Август IIне, икенчесе Станислав Лещинскийны яклап икегә бүленгән Речь Поспалитага да өмет юк.

Карл XII Саксониядә май җыеп балда йөзә. Кай якка юл тотачагы билгесез. Барлык Аурупа илләре дипломатлары швед короле белән дуслык эзли. Шул ук Англия, Австрия, Голландиянең Карл XIIне Испаниягә каршы күтәрелеп, җинел генә мал бүлү исәпләре.

Петр I Меньшиковны ике драгун полкы биреп Речь Посполитасы белән араны якынайтырга җибәрде. Әлегә анардан күңелне тынычландырырдай хәбәр килгәне юк. Ә Азовтан: «Казаклар кенәз Юрий Владимирович Долгорукийны кыйнап үтерделәр», — дигән хәтәр хәбәр килде. Патша өчен беразга булса да онытылып тору, чиреннән арыну кирәк иде. Кайту белән Семен Иванович, ишеткән-белгәннәрен сөйләп, кичектерми юлга әзерләнергә кушты. Тиз арада бер тана белән ике сарык суеп, соңгы булган кымызны, башка төрле азык-төлекне төяп Трифонны Уваровага озаттылар. Мунча кереп чыкканнан соң, өчәүләп, үзләре дә юлга чыктылар. Әхмәтнәсир үзе белән бөтен булган шифалы үләннәрен алды. Беренче мәртәбә кымыз төяп Уваровага баргач, Семен Иванович Адам Карловичка мунча турында искәрткән иде. Сызымына тикле сызып, күрсәтеп калдырды. Озакка сузмый төзеп тә куйганнар. Урынына карата бик кирәкле нәрсә булып чыкты ул. «Березовым веником в парилке вышибают все болезни. Диковинным напитком поят, и раны исчезают на глазах!» — дип дәваланып киткән халык аша, мунчаның даны тирә-якка таралды.

Кропотовлар килгәндә Петр Алексеевич юк иде әле. «Как вы во время, господа! И кумыс кстати! За продукты тоже большое спасибо! Целая орава ртов ожидается», — дип куанып каршы алды аларны Адам Карлович. Воронеж яклап урман юлында хәрбиләр төркеме күренде. Артларыннан аллы-артлы пар ат җигелгән берничә бөркәүле чана пәйда булды. Аларга да атлы хәрбиләр төркеме ияргән.

Кунакларны бил бөгеп каршы алдылар. Бөркәүле чана эченнән башта купшы киемле бер кеше чыкты. Аның артыннан ук, зур якалы толыпка төренеп, патша үзе күренде.

—Добро пожаловать, Ваше Величество! Мира Вам и здоровья!

— Куда пройти, старик?

— Прямо сюда, Ваше Величество.

Петр Алексеевич эре-эре атлап эчкә кереп китте. Башка чанадагылар аңа иярде.

Янәшә өйдән Кропотовларга стряпчий бүлмә күрсәткән иде.Патша белән очрашырга мөмкинлек көтеп ике тәүлек буе шунда вакыт уздырдылар. «Как только появится подходящий момент, я вас информирую», дип, Адам Карлович ышандырган иде, тиз арада гына җае чыкмады, күрәсең. Өченче көнне кичке якта гына, ниһаять, Адам Карлович ашыктырып керде.

Яңа гына мунчадан чыккан Петр Алексеевич, ярым шәрә килеш толыбына төренеп, зал бүлмәсендә утыра иде. Залга узу белән Адам Карлович: «Вот они, Ваше Величество! Наши меценаты Кропотовы!» — дип керүчеләргә күрсәтте.

Кропотовлар икесе дә хәрби киемнән. Үкчәне үкчәгә сугып көр тавыш белән рапорт бирделәр:

— Отставной полковник Кропотов Иван Егорович, Ваше Величество! Участвовал в Крымской и турецкой баталиях. Награжден орденом святого Андрея Первозванного, и земельным уделом с деревней из сорока душ, Ваше Величество!

— Полковник драгунского полка Кропотов Семен Иванович, Ваше Величество! Воевал под командованием Бориса Петровича Шереметьева. Был ранен дважды при взятии Гумолова и Ниеншанца.

Чират Әхмәтнәсиргә житте. Ул гади киемдә иде.

— Капрал Ахмет, сын Салимгарая. Из роды Манаш, Ваш Благароди! Татар-башкирыми памагал, Азов брали. Швидами ваевал. Мнугы крипост брали. Кагда крипост Маринбур брали, ранился. Свой солдат руку ранил.

Шулчак патшага жан ингәндәй булды. Күзләреннән очкын чәчелгәндәй мыегын селкетеп куйды.

— Как свой солдат ранил? Удират хотел?

— Так тучны, Ваш Блгароди! Он хатил лодкы забират и удират. Я лодкы не давал, а он плухы ругался и миня саблем рубил плеча, Ваш Блгароди.

— Лодку не отдавал?

— Нет, Ваш Блгаруди, не давал. Пумыч пришол и мы эты крипост брали.

— Молодец, солдат! Хвалю! Это ты тут кумыс придумал?

— Э нет, Ваш Блгароди. Кумыз давно наш деды придумал. Я тут прусты других учил.

— Татарин?

— Так тучны, Ваш блгароди, татарин.

— Откуда родом?

— Э-э, далика, Ваш Блгароди. Из деревне Тархан. Степь.

Шулчак Семен Иванович алдан әзерләп куйган дәфтәрне Петр Алексеевичка сузды.

Патша язуны укыганда ара-тирә егеткә күз ташлап алгалады. Укып чыгу белән Семен Ивановичка.

— Почему этот воин не был представлен к награде? — дип сорау бирде.

— Не единожды был представлен к награде, Ваше Величество. Просто мы забыли упомянуть их в списке, Ваше Величество. За инициативность и отвагу при взятии Азова был присвоен звание «капрал». В честь победы над турками участвовал на параде в городе столице Москве. Был награжден деньгами в сумме двадцать пять рублей серебром. За взятие Маринбурга тридцатию рублями серебром, Ваше Величество.

— Не один он получал деньгами, полковник. Пожадничали?

— Виноват, Ваше Величество! Мы как раз и пришли по этому поводу к Вам, Ваше Величество! Ахмет заслуживает награду существенную. Ахмет славный воин. Будучи раненным просился на службу в армию, но из-за серьезного ранения ему в этом отказали. Он на днях спас моего сына, Ваше Величество. Иноземные лекари не смогли вылечить. В последний раз иноземец-профессор указал день кончины моего сына, а он жив и здоров. Ахмет его спас, Ваше Величество!

Тавышы карлыгып, полковник туктап калды. Үзалдына сөйләшкәндәй патша карашын янадан дәфтәргә күчерде.

— Вы просите солдата отпускать домой, на родину... Ну что же, я не против. Такие люди нам полезны везде. Пока занят со шведами, рука не доходит установить порядок на своих окраинах. Башкиры бузят. И с татарами хлопот не мало. Его не просто так отпускать, полковник, а всеми почестями и правами. В Казань снаряжается обоз Саратовскими и прочими боярами. Вам подготовят депешу на имя Урусова Юрия Семеновича. Поедете в Москву, старайтесь до марта месяца поспеть, полковник.

А тебе, солдат, спасибо душевное, за травы чудные и напиток бодрящий! Я думаю, ты не посрамишь наше доверие у себя дома!?

— Никак нет, Ваш Блгароди! Вы добрый человек, Ваш Блгароди! Спасибо большой!

— Не скажи, солдат, не скажи...

**36**

Семен Иванович Мәскәүгә үзе генә барып кайтмакчы иде. Урусов четерекле кеше, көтелмәгән сораулар туарга мөмкин дип, Әхмәтнәсирне дә үзе белән алырга булды. «Майламый булмас», — дип, үзләре белән бер түшкә сарык, бер капчык он, атка солы алып, төн уртасында юлга чыктылар. Рязаньда бер төн кунып, икенче көннен кичендә Мәскәүдә иделәр. Урусов эш урынында юк иде, берничә көннән булырга тиеш, көтегез диделәр. Патша әмере белән килүне раслаган язу булганлыктан, Әхмәтнәсирне аты-чанасы белән Кремль сарае кәнүшниенә, ә полковникны махсус торакка билгеләделәр. Буш вакытта Мәскәүне күреп килергә егет полковниктан рөхсәт сорады. «Смотри, Ахмет, далеко не ходи, заблудишься», — дип, Семен Иванович егетне кисәтеп, рөхсәтен бирде.

Мәскәү урамнарында халык күп түгел. Кая карама, хәерче. Күбесе хәрби киемнән. Кем кулсыз, кем аяксыз.

«Бу кадәр ташны ничек итеп шулай өеп бетерә алдылар икән?» — дип, катлы-катлы өйләргә исе китеп йөри торгач, бер хәерче күнелен үзенә җәлеп итте. Бу адәм башкалардан өс киеме белән аерылып тора иде. Өстендә чапан, башында йон тукыма кыргыз калпагы. Аягында иләмсез зур күнитек. Заманында Әхмәтнәсир дә швед хәрбие аягыннан салдырып алып шундый итек кигән иде бит... Бу мөселман бәндәсе булырга тиеш, бер-ике тиен акча бирим әле дип янәшәсенә килде. Йөзен сирәк кенә булып сакал-мыек баскан хәерче башын күтәрде.

— Ыспасибы, дубр чәлауик.

— Йә Хода! Йомахужа, бу синме?!

Өмет чаткылары сүнгән тоньк карашын төбәп бертын сүзсез торган хәерче:

— Моя кушет хучет.Моя дулгы не кушал», — диде калтыравык тавыш белән.

Күзләре аныкы! Шик юк, бу чынлап та Йомахужа иде.

— Йомахужа, бу мин, Әхмәтнәсир! Син нәрсә, оныттыңдамы? Без синең белән Азовны алдык. Вишнүвкә авылы, палкауник Крупытыв... исенә төшер!

— Ә-ә бу һинмени, Әхмәт?! Танымаймын, дускай. Нәмәкәй кылып йөрәйһен монда? — Корычтай сенерле бармаклары белән Әхмәтнәсирнең кулын кысты. — Минем хәлдәр хөтө, туган...

— Ярар, ярар соныннан. Соңыннан сөйләрсең. Киттек минем белән, дускай! Ашатам, эчертәм үзеңне. Баргач аңлашырбыз.

Егет Йомахужаны кәнүшнигә ияртеп барып тамагын туендырды. Өлкән офицер аша белешеп, бер бүлмәдә юындырды. Ике тәңкә көмеш акча биреп, өс-башын карады. Бераз хәл кереп ял иткәч, башыннан үткән хәлләрен сөйләтте.

Нарва урманнарында шведларның авангард көчләре белән бәрелешкәннән соң яра алган хәрбиләр обозын озатырга билгеләнгән төркем, Нарвага кереп тормый гына Псков ягына юл тота. Яралыларны тапшырганнан соң озата килүче төркемне кенәз Репнин гаскәренә кушалар. «Төньяк» сугышында Репнин житәкчелегендә көрәшеп батырлыклар күрсәтә.

— Бүләкләп утыз тәнкә көмеш биргәйнәр ине. Ярты елдык хезмәт хакын түләнеләр», — диде Йомахужа монсу гына итеп.

Биленә бәйләп куйган акчаларын талап алмакчы булалар. Бу турыда өлкән офицерга әйтеп, теге урысны таяк белән суктырттыра. Күпмедер вакыт узгач, акчаларын барыбер урлата. Кем эше икәнен белә. Тик ул акчаларны ул кешедән таба алмыйлар. Нахак яккан өчен егетнең үзен җәзага тарталар. Бик каты кыйныйлар, ике ай артыгы белән рәткә керә

алмый җәфалана. Шуннан соң ана көн бетә. Туган якларга кайтып китәргә исәбе, тик бер тиен акчасыз кая бара аласын ди...

Йомахуҗаның табылуы полковник күнеленә дә хуш килде. «Ты хорошо сделал, Ахмет! Мы его с собой возьмем», — диде.

Әхмәнәсирнең: — Ул монда прпайдет, мин аны үзем белән туган якларга алып китәр идем. Он же ужы не салдат. Пра ево тоже Урусова праси пажалыста», — дигән үтенечкә каршы полковник: — Син үзең буласың бит Урусовта, курыкма, сора, кире какмас, минемчә», — дип, егетне тынычландырды.

Өч көн дигәндә аларны Урусов бүлмәсенә чакыртып алдылар. Егет керү белән Юрий Семенович аны таныды. — А, это ты, земляк! — дип, ачык йөз белән каршы алды. Шунда ук эшне хутка җибәрде.

Икенче көнне Әхмәтнәсирне башка урынга чакырып керттеләр. Ул Йомахуҗаны да ияртеп килгән иде, анысына ишек төбендә көтеп торырга куштылар.

Бүлмәдә ике кеше иде. Берсе, егет керү белән аны-моны сорашып тормыйча, төп сүзгә күчте.

— Вам возлагается ответственная миссия. В последнее время в тех краях, где вы родились, идут волнения среди кочевников. Вам надлежит выяснять их намерения. Государь дает вам право и полномочия дать волю беглым и присоединить их к ратным делам во славу нашего Отечества. Вы получите из казны деньги серебром в сумме десять тысяч рублей. Часть денег потратите для приобретения лошадей и телег. Часть — для снабжения обоза провиантом и снаряжениями. Вас будут сопровождать дюжина солдат верхом на лошадях. Вы должны будете контролировать при сборе налогов, организовать охрану караванов. Повторяю еще раз — контролировать! Ежели кто препятствовать будет, составлять письменную депешу. В дальнейшем вам присудят жалование по возможности и по вашему усердию. Вопросы какие будут?..

Вәгазь укыган мулла шикелле бертөрлексез сөйләгән бу адәмнең сүзләрен Әхмәтнәсир аңлап та, эчтәлегенә төшенеп тә бетә алмады.

— Вапрус кәнишне ест, Ваш Блгаруди. Ну түлке я не савсим понил, что вы говорил. Вы, пажалысты, всю иты на бумагы пишите. Патум буду читат как коран и панимать.

— Хорошо. Какой вопрос хотели задать?

— Тут нашулсы зимляк. Он савсим балнуй и тущи. Он самнуй Азов брал. Ә тәпир ваеват не мужет, балной... Чтубы ево самнуй отпустили. Он харуший чалауик.

Бүлмә хуҗасы өстәлдәге кыңгырауны алып шалтыратты. Ишек катында хәрби күренү белән: «Кто там, пропусти его!» — дип әмер бирде.

— Йомахуҗа, Ваш Блгаруди... — Ике күз дә борыны гына утырып калган нурсыз йөзле Йомахуҗа тотлыгып калды.

Шунда Әхмәтнәсир ярдәмгә килде.

— По урыски Хаджа, сын Йомагол, Ваш Блгаруди. Ыснaчалы наш камандир был Куфтерев Кәнстәнтин Диминтыч. Ишу раншы стулник Туренев был. Патум наш нәчәлникым ыстал палкауник Семен Иваныч Крапутов, Ваш Блгаруди. Пусле ыс ранинымi папал другой камандир. Кенәз Рәпнинга, Ваш Блгаруди.

— Я понял вас. У него где бумага, удостоверение его личности?

Шулчак аңга килгәндәй Йомахуҗа үзе сүзгә кушылды.

— Ест, ест, Ваш Блгаруди, бумагы ест, — дип, итек балтырыннан төргәк чыгарып бүлмә хуҗасына сузды.

Тир белән чыланып кан таплары төшкән кәгазьне барлап чыгып, бу түрә башын чайкап куйды.

— Все понятно, хорошо. Его тоже включат в список. Еще есть вопросы?

— Никак нет, Ваш Блгаруди!» — дип, егетләр бүлмәдән чыктылар.

Мәскәүдә Раштуа көннәре иде. Өчәүләп кибетләрдә йөреп, өйдәгеләргә тәм-том, прәннекләр, лампачилар сатып алдылар. Кремль тирәсен карап-йөреп чыктылар. 1707 елның 11 гыйнварында, кирәкле язулар белән 10 мең сум акча алып, Тамбов ягына юл тоттылар. Сирәк кенә юл җаенда очраган авылларда тулы тынлык. Анда Гайсә пәйгамбәрнең туган көнен бәйрәм итүләр сизелми иде. Ак карга төренгән кырлар, урманнар иксез-чиксез кинлектә тынып тирән уйга талган.Сирәк кенә очраган почта ямшикләреннән башка юлда кеше заты күренми. Шулкадәр җире булып та бөлгенлектә яшәгән урыс, кеше талап, кан коеп, чикләрен киңәйтә, зурайта. Кемнәрдер тир түгеп тә юклыкта яши, ә кемнәргәдер көтмәгәндә генә байлык ишелә... Аңламассың бу дөньяны...

Авылга кайтып җиткәнче егет керфек какмый тирә-якны күзәтте, ул тирән уйда иде.

## 37

Җигүле атлар сатып алып булмасмы дип Кирсанов авылына барганнар иде, кыенлык белән сатулашып ике җигүле, камыты-ние белән җигүсез генә өч ат алып кайттылар. Кропотовлар да дүрт җигүле ат бүләк иттеләр. Шулар өстенә җиде капчык он, биш капчык солы белән өч капчык арпа ярмасына да акча алмадылар. Калган җигүле атлар белән башка кирәк-яракны Царицында алу юньрәк дип һәм, иртәрәк юлга чыгу хәерле булачак дип, февраль ае башларында ук җыенып юлга чыктылар. Семен Иванович белән Трифон обозга барып кушылганчыга кадәр озата барасы иттеләр.

Царицында яз иде. Кар җепшек, урыны-урыны белән сулар җыелган. Вакыты чыгып барганга күрәсең, чана табуы кыен булмады. Баштагы берничә көндә шәһәр базарында күз төшәрдәй атлар гына юк иде. Шимбә базарына калмыклар бер көтү ат куып алып килделәр. Атларны Әхмәтнәсир үзе сайлады. Баштарак ул дүрт-биш баш ат алырга уйлаган иде. Уптым ун баш алсаң, бәясен төшерәбез дигәч, ун итеп алды. Обоз тупланган җирдә азык-төлек табуы читен, табылса да бәясе арзан түгел, дип, шунда ук атларга азык, үзләре өчен он, ярма сатып алып, чаналарга төяделәр. Төн җитеп бераз тындыра төшкәч, юлга кузгаласы көнне Семен Иванович Әхмәтнәсирне зур гына бер кибеткә алып керде. Анда тимердән эшләнгән кирәк-ярак, җиһазлар сатыла иде.

— Семен Иванич! Как вы дагадался? — Егетнең күзе йөгерде. — Это нады, а эты патум нады будит, — дип, ун аркылы пычкы, ике дистә чалгы, бишәр-бишәр бәйләм балта, урак сатып алды.Такта яра торган дүрт озын пычкы белән дүрт дистә көрәк, егерме сәнәк һәм ике бәләкәй, бер зур казан да аласы итте. — Я бы всю лавкы купил, если тяжила не был, — дип егет алган әйберләренә шатланып бетә алмады.

Йөкләр җинел түгел, юллар да начар. Төнгелеккә чыератып җибәрүгә дүрт атка атланып, җигүле унөч йөк белән Сарытау ягына кузгалдылар. Сарытауга якынайганда юллар аруланды. Кар алай ук баткак түгел иде әле. Февральнең 22сендә Сарытауга барып керделәр. Иртәләп килүләре бик вакытлы булган. Юллар бозылганчы кузгалырга ниятләгәннәр. Обоз тупланып яткан урында, Семен Иванович кирәкле кешене табып, Мәскәүдән алып кайткан юлламаны күрсәтте. Ул адәм Әхмәтнәсирләр обозына ун атлы гаскәрине беркетте.

Икенче көнне таң белән, обоз Идел елгасы аша юлга кузгалды.

Кышкы юл тигез һәм такыр иде. Түбән таба салулап төшәсе, үрләр менәсе дә юк. Чаналарда йөк барлыгын тоймагандай, башларын чайкап, атлар жинел генә элдерә бирә. Дистә чакрымга сузылган обоз алдында ике дистә тирәсе бөркәүле чана белән өч йөз кешедән торган атлы гаскәр бара. Әмәтнәсирләрне соңгы рәткә куйганнар иде. Аларга да ун атлы гаскәри ияргән.

Ак жәймә өстенә сузып салган чәч толымы шикелле боргалана-сыргалана сузылган обоз, төннен беренче яртысында Балакайга барып житте.

Привал...

Вишневкадан китәр алдыннан, юлда пешеренеп булмас дип, бер түшкә сарык ите пешереп куйганнар иде. Бу бик урынлы булды.

«Ыслужбы ыслужбый, ә кәрмитсы нады», – дип Әмәтнәсир гаскәриләре алдына ит турады, ике түгәрәк ипи кисте. Атлар башына махсус янчыкларга солы салып элделәр. Өч сәгать вакыт узып та өлгермәде, «Трогай!» – дигән әмер йөгереп узды.

Икенче көннен төш вакытларында алар «Хвалынск» ныгытмасында иделәр. Анда халыкны биш сәгатьлек зур ялга туктаттылар. Яр буенда коры-сары жыеп казаннар астылар. Өсләренә чыпта ябып, тугармый гына атларга солы бирделәр. Күпмедер вакыттан соң обоз житәкчесе Әхмәтнәсирләр төркеме янына тукталды. Янәшәсендә ат менгән тагын бер адәм бар. Жентеклэбрәк карагач, егет аны таныды. Мәскәү бүлмәсендә сүзгә катнашмый тын гына утырган кеше иде бу.

— Наш друг и благожелатель, Винниус Витсен, из Амстердама, – диде обоз житәкчесе.

Сүз уңаенда шунысын әйтеп узарга кирәк, Аурупада Русиянен ышанычлы таянычы булган илләр юк түгел иде. Әйтик, Нидерланд илендә яшь Петр I дингезче һөнәренә өйрәнде. Нидерланд белгечләре ярдәмендә дингез кораблары төзелде, башка өлкәләрдә дә күп кенә булышлыклар тиде. «Төньяк» сугышы вакытында корал һәм матди яктан ярдәм итеп торды. Амстердам бургомистры Николас Витсен Русия халкын өйрәнеп: «Северная и Восточная Тартария», – дигән исем астында китап чыгарды. Күп кенә Нидерланд белгечләре һәм сәүдәгәрләре, Русиягә килеп урнашып, хужалыкны торгызуда, жир асты байлыкларын өйрәнеп заводлар төзүдә катнаштылар. Шулар арасында жир асты байлыклары белгече Николас Витсен дә бар иде. Урал ягында чуен, корыч житештерү заводларына нигез салуда күп көч түккән шәхес иде ул.

Заводлар төзер өчен жирләрен яулап алу нәтижәсендә төньякта яшәүче башкорт кабиләләре баш күтәргән, «Ак патша»га каршы чыккан чор иде бу.

Ара-тирә туктап, атларны ашатып-эчертеп, ял иттереп бара торгач, Самарага життеләр. Инде Әхмәтнәсирләр обозны үз якларына борырга тиеш иде. Юлны төгәл белмәгәнлектән, озата баручы кирәк иде. Белешә торгач, андый кеше табылды. Жиде-сигез йөктән торган обоз белән бер сәүдәгәр ике көннән Богатое авылына юлга чыгарга тиеш булган. Обоз житәчесе, Әхмәтнәсир белән таныштырып: «Этот человек от самого царя!..» — дигәч, сәүдәгәр иртәгә үк юлга чыгарга ризалыгын белдерде.

Бик иртә кузгалдылар. Богатоега кадәр юл тапталган, йөрелгән иде. Богатоеда төн уздырып чыккач бару әкренәйде. Аннан ары елга өстендә юл юк иде. Урыны белән ике ярны тигезләп кар өйгән. Житмәсә, барган саен елга тарая бара, урыны белән кар астына су чыккан. Көн буена барлыгы биш-алты чакрым юл үтелә. Жылытып жибәргәнлектән ерганаклар күренгәли башлады. Сөзәк ярга чыгасы иттеләр. Берничә чакрым ара үтү

белән алда куе агачлык очрап киредән елгага төшәргә туры килде. «Сукыр күз белән» вакыт әрәм итмәс өчен, төнгелеккә туктап ял иткәннән соң, берничә атлыны Әхмәтнәсир алдан җибәрәсе итте. Алдарак бозны су юган, бөтенләй дә үтәрлек түгел икән. Бер атлы суга баткач аны көч-хәл белән коткарып калганнар. Әйләнеп кайткан арада ул бик каты өшегән. Әхмәтнәсир үз киемен салып биреп, аны бераз жылыткандай итте.

Богатоедан Бозаулыкка житкәнче төгәл биш тәүлек вакыт узды. Шул вакыт эчендә табигать күзгә күренеп үзгәрде. Кая карама гөрләвекләр ага, агач башларында кара каргалар шаулаша.Әхмәтнәсир Бозаулыкта бер-ике көн тоткарланып, атларны ял иттермәкче иде. Юллар начар. Ташу сулары кузгалса, бөтенләй дә ерып чыгып булмас. Атлар да талчыкты, өшәнде. Төнгелеккә чиратып җибәрү белән юлларын дәвам иттеләр. Бозаулык тавын менгәч, юл аруланды. Башка урында тукталып тормадылар. Көн урталарында эретә башлагач, урман эчендә туктап, кичкә кадәр атларны ашатып, үзләре дә тамак ялгап, төнгә кадәр ял итеп алдылар. Кече Кинәле елгасына ташу төшмәгән иде әле. Ул тирәләрдә кар да артык нык эремәгән. Башкача тукталып тормадылар. Мартның егерме икесендә Әхмәтнәсир үз якларында иде инде. Туып-үскән дала аны колакны тондырырлык тирән тынлык белән каршы алды.

Заманында шау килеп торган тирмәннәр урынында бушлык, кайчандыр кешеләр яшәгәнен исбат иткәндәй, ара-тирә казык башлары, жир өемнәре генә утырып калган. Көннәр жылытып жибәрүгә карамастан, дала өстендә күзне камаштырып ак кар ята. Кар катламы калын түгел. Кай якка барасың килә, шул якка юл тот, кыенлык юк.

Атасы Сәлимгәрәйнең Әсәкәйгә китеп урнашуын ишеткән иде. Солтанголның яшәгән жирен эзләүдән файда юк. Тапкан очракта да ни дип әйтер, нинди кинәш көтсен? Нинди йөз белән каршы алыр әле ул?.. Әхмәтнәсир Әсәкәйгә баруны хуп күрде. Яхшымы, начармы, атасы шунда. Тора-бара жайланыр, урнашыр.

## 39

Сәлимгәрәй аны кочагын жәеп каршы алды. Шатлыгыннан күзенә яшь бөртекләре бәреп чыккан иде.

— Һәй, улым! Пәхливаным! Мин бит сине күрми үлеп китәрмен диеп курыккан идем!

Яше артык зур булмаса да Сәлимгәрәй картайган, чәченә чал кергән. Тавышы да картларныкы шикелле карлыккан. Анасының да йөзе жыерчыкланып бара. Чәче агарган. Оялып кына бер читтәрәк ике бәләкәй малай ят абыйны күзәтәләр. Мәскәүдә үк кесәсендә саклап кайткан лампачиларны балаларга сузды Әхмәтнәсир.

— Энекәшләр зуп-зур икән инде. Исемегез ничек?

Оялудан дәшми торган малайларга анасы ярдәмгә килде.

— Булат белән Нигъмәт. Бу сезнең абыегыз. Атагыз сөйләгән Әхмәтнәсир абыегыз шушы була инде, балакайларым.

Ул көн урнашып-танышып узды. Икенче көнне аталы-уллы икәүдән-икәү калып, озак кына гомер, тормыш хәлләре турында сөйләшеп уткәрделәр, Әхмәтнәсирнең кайту сәбәпләре аңлашылды... Моннан өч ел элек бу якларда зур күтәрелешләр булган. Атасының сөйләвенчә, башта татарлар белән башкортлар арасында гауга купкан. Аннан ары бергә кушылып урысларга каршы күтәрелгәннәр.

— Сине патша хезмәтенә озатканнан соң ике ел вакыт узу белән, урыс гаскәриләре килеп ярты көтү атыбызны талап алып киттеләр. Шунын өстенә акчалата ясак даулыйлар, жәнлек тиреләрен бирүне йөкләделәр,

— диде Сәлимгәрәй, узганнарны исенә төшереп. — Без аучы түгел. Умарта да тотмыйбыз. Бөтен белгәннәре: «Бир дә и всю!» Икенче елны килеп тагын ике дистәгә якын атны, кәҗә-сарыкларны тартып алдылар. Бер безне генә түгел, бөтен тирәне таладылар. Башка чара калмагач, халык күтәрелергә мәҗбүр булды. Күпме егетләрне патша хезмәтенә алып киттеләр. Соңгы килүләрендә халык күтәрелеп чыгып, урыс түрәләрен куып җибәрде. Артларыннан ук, алты мең гаскәр ияртеп, Казаннан Сергеев атлы башкисәр килеп житте. Авылдан авылга йөреп, күп кенә кешене асып-кисеп, мәсхәрәләп, халыкны канга чумдырдылар. Күпме ир-атны кулга алып, үзләре белән алып киттеләр.

Әлегесе көннәрдә дә тынычлык юк. Татарлар белән башкортлар гына түгел, барлык милләт-халыклар патшага каршы.

Әсәкәй малае Алдар белән Көсүм Түләкаев гаскәр җыя. Урыс авыллары, ныгытмаларына һөҗүм итеп, бу җирләрдән урысларны куып җибәрү уйларында. Белмим, соны ничек булып бетәр, улым, тик син бу эшкә тыкшынма. Язуыңны беркемгә дә күрсәтәсе булма! Халык кызу хәзер. Аны-моны аңлашып тормаслар, бәреп үтерерләр. Бу урысларны да юккарак ияртеп кайткансың, улым.Син аларга аңлат, чыгып, күренеп йөрмәсеннәр, өйдә генә утырсыннар. Тора-бара күз күрер.

Сәлимгәрәйнең өе бурадан салынган. Үз гаиләсе өчен иркен генә булса да артык кеше яши алырлык түгел иде. Кардан арчылып килгән йорт янәшәсендә тирмә кордылар. Идән урынына ике катлы итеп сыер тиреләре җәеп, өстен зур келәм белән каплагач, хәрбиләр күңеленә хуш килде. «Кирәге чыгар бер дип абзар салдырган идем, шәп булды әле», — дип сөйләнә-сөйләнә йорт хуҗасы улы алып кайткан байлыкны сараена куйдырды. Әзме-күпме мал-туары да бар иде Сәлимгәрәйнең. Йорттан ерак түгел битләүдә, киртәләр белән тотып алынган ачык һава астында дүрт ат, унлап сыер малы һәм ике дистә тирәсе кәҗә белән сарыгы. Кышкылыкка әзерләнгән печән өеме төбенә төшкән, маллар үшән. Улының уен белгәндәй ата кеше үзенекен тукый торды: «Бу малларны тотарга да кыен хәзер, улым. Булышыр кешебез юк. Егет-җилкенчәкнең кайсыларын патша хезмәтенә алдылар, кайсылары Алдар белән китте. Карт-коры үлеп бетте. Печән әзерләргә кеше калмады. Бу малларны да әкренләп бетерергә дип тора идек әле.»

Ни өчендер карт икенче улы Солтангол турында искә алырга ашыкмады.

— Солтанголның хәле ничек? Үзенә аерым нигез корган дип ишеткән идем, — дип, Әхмәтнәсир үзе искәрткәч кенә, ата кеше кулын селтәп куйды:

— Аерылыштык без аның белән, улым. Элек тә ул миңа карата битараф, салкын иде, анасы мәрхүмә булгач, бөтенләй дә суынды. Бу малларның яртысы анамныкы иде дигәч, ал, ал, улым, барысын да ал, дип, көтүләрне аңа бирдем. Моннан әллә ни ерак түгел, тау итәгендә нигез корды. Маллары белән халыкның да күп өлеше аның янында калды. Аралашкан юк. Бабасы Артай ике араны якынайтырга тырышып карады, тик рәт чыкмады. Хәерле булсын, яши бирсеннәр, үпкә тотмыйм.

Артай сүзен ишетү белән егеткә җан ингәндәй булды.

— Артай дисеңме?! Әле ул исәнмени?

— Исән, исән. Эт каешы кебек кешегә ни булсын, Богырысланда яши. Үз тирәсенә башкисәр ат каракларын җыеп тик ятмый ул, улым. Син нәрсә, аны беләсеңме әллә? Ә, әйе, беләсеңдер. Ул сине очратканын сөйләде бугай...

— Ничектер очрашасы иде үзе белән.Бик картайгандыр инде. Солтангол янына да барып хәлен белешәсе килә.

— Ярар, улым. Ташу сулары төшкәнче ат менеп барып кайтырбыз Богырысланга. Минем дә аның белән сөйләшәсе сүзләр бар иде. Тик син бу язуың турында сүз ычкындыра күрмә, зинһар! Яшә, күнек. Син акылсыз кеше түгел, кай якка тәртә башын борырга кирәкне тора-бара үзең үк төшенерсең.

Шулчак өйгә Бану керде.

— Улым, сине дәшәләр. Салкын тигән теге хәрбинең хәле авырайган ди бугай.

Елгада батып чыккан хәрби ютәлли иде. Әзме чыланып салкын тидергән чаклар, узар әле дип ничектер аңа артык игътибар ителмәде бу соңгы көннәрдә. Дөресен генә әйткәндә, хәрбиләр белән якыннан гына танышырга вакыт та булмады. Суда баткан кеше башкалардан олырак иде. Шуның аркасындамы, башкалар аңа буйсына, аның сүзен тыңлыйрак төшә иделәр. Исеме дә ничектер урыс исеменә тартым түгел: «Шаблан». Китәр алдыннан обоз житәкчесе белән нәрсә турындадыр шактый вакыт әңгәмә корып алды. Гади солдатка охшамаган иде ул. Аз сүзле, уйчан йөзле.

Әхмәтнәсир тирмән эченә кергәндә Шаблан буылып-буылып йөткерә иде. Йөткергәндә авызын каплаган сөлгедә кан таплары күренә. Егет керү белән, ул башкаларга ым кагып, чыгып торырга ишарә ясады. Кызарынып-бүртенеп ютәленнән арына төшкәч, гырылтык тавыш белән җөмләсен бүлә-бүлә сүз башлады.

— Ахмет, мне пришел конец.

— Мы тибе личить будем, всю прайдет.

— Не перебивай меня, Ахмет! — Шулчак көтмәгәндә ул саф татар теленә күчеп, сүзен дәвам итте. — Мин үз хәлемне беләмен. Миңгә күп калмады, дускай. Мин элек тә чирле идем. — Чирле янә буылып йөткерергә кереште, хырылдый ук башлады. — Мин синең өстән шымчылык итәргә тиеш идем. Мәскәүдә чакта синең турыда күп кенә белешмәләр алдым. Син башкалар кебек түгел, син яхшы кеше.

Тагын бертын ютәлләп алганнан соң янадан урыс теленә күчте. «Богу угодно кого защищать... Не бойся этих ребят. Живи по своим правилам. Похорони меня где-нибудь подальше и разравняй землю. Чтоб не одна душа не могла знать!»

Кичке якта тирмән эченнән ютәл ишетелмәс булды. Бу бәндәнең серен ачканына караганда, кыска гына вакыт эчендә чирләп үлеп китүе, соңгы теләге тетрәндерде егетне.

Ат жигеп хәрбиләрне утыртты да килгән яклап тау битендәге таллыкка юл тотты. Карны ачып коры-сары белән учак кабызды. Дөрләп янган учакка утын өсти-өсти жирне бераз эретә төшкәч, учакны читкәрәк этәреп казырга керештеләр. Төннең икенче яртысында кабер әзер иде. Көн туганны көтеп тормадылар. Таң ата башлауга алып килеп жирләделәр, өстен тигезләп кар өйделәр. Әнә шулай Әхмәтнәсир узган гомеренең бер өлешен жиргә күмде. Калган өлеше ничек булып бетәр, анысы Ходай кулында иде.

## 40

Кыш күпме генә китмәскә теләмәсен, яз үзенекен итте. Соңгы берничә көн эчендә күзгә күренеп жир өсте үзгәрде. Кояш нурларыннан гайрәт алып, көньяктан искән жил, шагыйрь әйтмешли, жиргә ятып кар ашый. Бер-берсе белән ярышып гөрләвекләр ага. Кардан арынып кипшенгән калкулыкларда яшелләнеп чирәм шытып килә. Талларның да бөреләре бүрткән, яфрак ярырга әзер.

Иртә таңнан торып, ат менеп Сәлимгәрәй белән Әхмәтнәсир Богырысланга киттеләр. Үзән аша йөрерлек түгел әле, тау аша гына барырга

мөмкин. Көннең икенче яртысында алар Богырысланда иделәр. Тау астындагы кечкенә инеш кабарып бүрткән, боз өстенә көрәнсу болганчык су чыккан.

Бер-берсенә сыенышып утырган каралты-куралар ишәйгән. Элекке кебек ялгыз урам гына түгел. Аерым бер калкулыкта да каралтылар торгызганнар. Шулар арасындагы кечкенә бер хөҗрә Артайның торагы икән.

Артай өендә иде. Сәлимгәрәйне күрү белән:

— Сәлимгәрәй туган! Нинди җил ташлады сине бу баткак чорда?! — дип, кулын җәеп ачык йөз белән каршы алды. Әхмәтнәсирне танымады.

Кызып сөйләп киткән җирдән Сәлимгәрәй:

— Бу кешене таныйсыңмы? — дип, йорт хуҗасын сүзеннән бүлдерде.

Шунда егет ягына күз ташлап, өйдә тагын бер кеше барлыгын яна гына күргәндәй:

— Ә мин аны элек күргәнем бар иде дип беләсеңме? — дип, сорауга сорау белән җавап биреп, Әхмәтнәсирне дикъкать белән баш-аяк барлап чыкты. — Танымыйм бит туганкаем, хет үтер, танымыйм...

— Картлыгың житкән икән, Артай. Синең улыңны очраттым, ул мине үлемнән алып калды дип үзең үк мина сөйләгән идең түгелме? Андый кешене хәтердән чыгарып ташларга ярыймы?!

— Кит, булмас! Кем диден әле... Әһә... әйе... Әхмәтнәсир!? — Ни әйтергә белми каушап калган Артай, — синмени бу, балакаем!? — дип, егетне кочып ук алды. — Мин бит хәзер сиксәнгә якынаеп килгән кеше, туганкайларым. Хәтер начар, тешләр юк, колак ишетми. Егерме биш ел узып та киттемени, балакаем?! Ни хәлдә? Исәнлегең ничек? Утыр, сөйлә!

Артайның үзен дә танырлык түгел иде. Колак артларында сирәк кенә озын чәч бөртекләре, сакал-мыегы ап-ак. Бер як күз алмасы кырыена ак төшкән. Урынында утырып кипкән карт имән кайрысы кебек битекулы җыерчык. Хәрәкәте генә артык үзгәрмәгән. Шулай ук житез. Кул бармаклары да бөркетнеке шикелле нык, көчле.

— Егерме биш ел ук түгел, ага. Тәгәл яртысы гына узды әле, — дип, аклангандай, егет өстән-өстән генә башыннан узганнарны искә төшерде. Ничек итеп җәрәхәт алып хезмәткә яраксыз булып калуын, полковник малаен дәвалаган өчен ирекка җибәрүләрен әйтеп узды. Патшаның үзе белән очрашып, шул кылган гамәлләре өчен Указ белән Булат абзасының җирләрен бүләк итеп бирүләрен ишетү белән, Артай урыныннан сикереп торды.

— Бөркет икәнсең, егет! Ник син минем оныгым булып тумадың икән! Патшаны күрдем дисең, ниндирәк ул? Канэчкеч явыз диләр, дөресме? Андый булса, синең хезмәтеңне санга сугып, шундый зур бүләк биргән булыр идеме?!

— Ул кадәресен белмим, ага. Мин хезмәткә барганнан бирле гел сугыш та сугыш. Ул кадәр гаскәрне, ул кадәр атларны туендырып торыр өчен генә дә күпме мөлкәт кирәк. Урыс халкы арасында да шул ук кыенлык, ачлык, ялангачлык. Кырыслыкка кырыс, патша, анысы хак. Каракларны таяк белән суктыралар. Зуррак җинаять кылучыларны асалар, кисәләр. Авылларында хәзер халык та калмады. Урманнарга, ерак Себер якларына качып китәләр. Кайда да шул ук бер хәл. Түрәләрдән тора барысы да. Берәүләре актык азыгыңны тартып алып баерга, үз хәлләрен яхшыртырга тырыша. Кем гакыл белән уйлап эш кыла,үз кешеләрен рәнжетми, галеллектә яши, андый урыннарда тәртип, муллык.

Егет Кропотовлар гаиләсен искә алып узды.

Сөйләшкән арада Артай чәй куйды. Бер генә тынга дип күршеләренә кереп, катлама алып чыкты. Тышта караңгы төшкән иде инде. Мин бит бу

өйдә йоклыйм гына. Чәйдән гайре аш хәстәрен күргән юк, дип, кунакларны күршеләренә алып керде. Катлама артыннан кергәндә кисәтеп куйган, күрәсең, күршеләре табын әзерләгән иде. Аш пешергәннәр, чәй янына коймак куйдылар. Чүлмәк белән каймак, бал да бар иде.

— Аллага шөкер, азыктан зарланган юк. Күршебез сау-сәламәт була күрсен, бездән теләк шул! — дип, күрше хатыны көр тавыш белән кунакларны ашарга кыстады.

Чәй артында утырганда Артай:

— Әсмабикә, син кунакларга урын әзерләрсең. Минем алачыкта йокларлык түгел, шайтаннар да качып бетте, — дип, янә сүз катты.

— Йорт хуҗасы кайда, күренми? — диде Әхмәтнәсир.

— Йорт хуҗабыз үлде. Биш ел элек урыслар кыйнап үтерде мәхлукне, — диде хатын, берни дә булмагандай. — Күршем әйбәт, авыр хәлдә калдырмады. Бу кыен заманда ни эшләр идең берүзең генә, — дип өстәп куйды.

Хуҗабикә артык олы күренми, илле тирәләрендәге таза хатын. Артай җаен тапкан, югалып калмаган, тол хатынны ялгыз яшәтми икән.

## 41

Әхмәтнәсир йокысыннан уянганда өйдә кеше заты юк иде. Бертын һични аңлый алмый торды. Өстәл өстендәге нигъмәтләрне күргәч кенә кайда булуын исенә төшерде. Атасы уятмый чыгып киткән. Шулчак алгы яктан хуҗа хатын килеп чыкты.

— Уяндыңмы, апаем?

— Картлар кайда?

— Таң атмас борын атаң Артай янына кереп китте. Ашарга әзер, хәзер чакырам үзләрен.

— Юк, юк, кирәк түгел! Үзем чакырам.

Егет кергәндә ике карт ни турындадыр кызып-кызып бәхәсләшә иделәр.

— Әнә, үзе дә керде. Әйдә, уз!

— Хуҗа апа ашарга дәшә, өстәл әзер.

— Табын качмас, өлгерер. Утыр! — Егетнең атасы икеләнеп кенә сүз башлады. — Артайга серне ачтым, улым. Ул безгә чит кеше түгел. Чыгар дәкүминтенне, күрсәт үзенә.

— Юл капчыгында алар, күрше өйдә. Табында күрсәтермен.

— Табында тамак туйдыралар, энем. Бар, алып кил! — диде Артай җитди генә.

Язулар күн янчыкта иделәр. Алып кереп егет укып бетерү белән Артай:

— Имзасы бармы, имзасы? Мөһере дә куелганмы? — дип сорады.

— Имза куелган. Мөһере дә бар.

— Кая әле, бир, карыйм! — Язуны борын төбенә китереп, читкә сузып карый торгач, тагы да җанланып китте. — Сез беләсезме бу дәкүминтнең бәһасен?!! Бу язу белән дөньяны әйләндереп ташларга була! — Шунда ук ярым пышылдауга күчте. Атаң дөрес фикер йөртә, улым. Халыкка бу турыда белдерергә ярамый әлегә. Төрле кеше бар дөньяда. Урыс шымчысы дип уйлап хур итеп куюлары да мөмкин. Ашап алыйк. Аннан соң бер урынга барып килербез.

Кояш баешы яклап, Бөгелмә юлы калкулыгында таштан өеп салган өйләр барлыкка килгән икән. Аннан ерак та түгел мал базары. Тик анда бу көнне кеше-мазар, маллар да күренми иде. Асты таш, өсте агачтан бурап салынган ике катлы йорт янәшәсендә туктадылар. Капканы кораллы сакчы ачты.

— Што хотим?
— Иты я, Артай. Хәзәенне хәтим.
— А эти хто такие?
— Мой люди.
Килүчеләрне юан гына урыс каршы алды.
— Што случилось, Артай?
— В густи пришол.
— С утра в гости не ходят.
— Харуший густ на вриме не глядит, гаспадин харуший. Раны пришул, раны ушул. Дилы ест.

Аскы каттагы бүлмәгә уздылар. Йомшак утыргычка утыру белән Артай төп сүзгә күчте.

— Ызнаеш кава тибә привол? Чәләүик ат самава, Ак падишаха! Ат саря! Паказивай синок дәкүминт гаспадину. Катурий уруски нәписан!

Йорт хужасы язуны укып чыгып әйләндергәләп карады: — Што, по-другому написанное есть ешшо?

— Ест, гаспадин, ест, по-мусулмански написанный ест.

Урыс икенче язуны да алып як-ягын барлап чыкты.

— А тут што написано?

— Што пирви написан, гаспадин. — Шунда гына Артай иптәшләре ягына борыла төшеп, йорт хужасы белән таныштырасы итте.

— Иты чәләүик галава Богырыслан. Әртими Иваныч. Он умный, харушый чәләүик.

Артемий бертын уйланып торганнан соң, күлмәк якасы муенын кыскандай, башын чалшайтып куйды:

— Серьезный документ. За какие заслуги удостоили такую честь?

— Ыслужил хараша. Вирный челавиком был. Такуй дакумент зря ни дают. Ни нады пустуй слава гаварит, гаспадин. Тибе вот зачим такуй пуст дала? Ызничит заслужил, как ты сам гаварил адин раз.

Богырыслан Хужасына тагын бер язу күрсәттеләр. Анысында, Булат Манашев жирләрен Ахмет Салимгерей углы исеменә теркәү, бу эштә урындагы түрәләргә ярдәм итү тиешлеге язылган иде.

Түрә язуларны озак кына карап, барлап чыккач, башын күтәрде, тагын бер кат муенын сузып куйды.

— Хорошо. Будем помогать по силе возможности. Эти места западнее, за бугром. Но там много разных беглецов и варнаков.

— Ты пакажи иты мисты. Ми ыс ним сами ладит будим.

— Хорошо, Артай.

Бу очрашу шуның белән тәмам булды.

— Сый-хөрмәтең өчен зур рәхмәт, Артай, якты күздә китәргә кирәк, — дип, аталы-уллы Әсәкәйгә кайтып киттеләр.

Әхмәтнәсир өчен өйдә күңелле яңалык бар иде. Йомахужа чиреннән арынып аягына баскан. Баеп барган кояш нурларына күзен кысып нигез өстендә утыра.

Мәскәүдән кайтканда ук хәле начарланган иде. Вишневкада мунча кереп бераз дәвалагач, жинеләйгән сыман булды. Аннары тагын яңадан авырайды. Ат өстендә бара алмагач, төрендереп чанага утырттылар. Әсәкәйгә кайтып житкәнче тын да чыгармады. Үлмәгәндер бит инде дип Әхмәтнәсир берничә кат Йомахужаны барлаштыргалады. — Түз, якташ,түз. Кайтып жылыга эләккәч үтәр барысы да. Ирекка чыккач кына алай тиз бирелергә ярамый дип күңелен күтәрергә тырышты.

Халык ишле булгач, он, ярма белән генә чыгышып бетәрлек түгел, ит кирәк иде. Алып кайткан атларның берсен көтүдәге яшь елкыга алмашып,

ат суйдылар. Фуражга көч килмәсен дип атларны чирәмгә чыгардылар. Көннән-көн кыздырган кояш җылысы үләннәрне яхшы гына күтәреп килә иде, анысы әйбәт булды әле.

Көннәр шау-шусыз әкрен генә узды, сукмаклар төште. Ташу суларыннан Кинәле елгасында боз күтәрелде. Шундый көннәрнең берендә ат менеп Артай күренде. Күнелгә ятышлы яналыклар алып килгән. Артемий белән очрашканда Әхмәтнәсир хәрбиләре турында да сүз булып алган иде: «Пускай срочно прибудут!» — дигәннәр. Җир турында да уңай җавап бар икән.

Артайның ниятендә өчәүләп Солтангол янына барып кайту иде. Икенче көнне ат менеп китеп тә бардылар.Тау итәгеннән уратып бара торгач, алда каралтылар күренде. Кинәле елгасы буенда бер көтү мал утлый. Абалап өреп аларны бүре баса торган берничә эт каршы алды. Кулын алга сузып Әхмәтнәсир: «Алабай, Алабай», — дип караган иде, эт аны танымады. Кайчандыр егет белгән Алабай юк иде шул анда. Сәлимгәрәй: «Алабай бик карт булган, күптән икән инде анын үлгәненә», — диде.

— Әссәламәгаләйкүм, Азамат! Сау-сәламәт кенәме, Гөлминиса әби! — дип, очраган кешеләр белән исәнләшеп, Солтангол катына уздылар. Юан агачлардан бурап салган зур гына өй. Түбәсен камыш белән япканнар. Тирә-ягында алачыклар. Уратып алган йорт уртасы Артай түбәсе шикелле такыр. Ишек алдында берничә хатын-кыз. Берсе гөбедә май яза, берсе ишегалдын себереп йөри.Нигез өстендә бөршәеп олы гына карт кояшта җылынып утыра.

Килүчеләрне күреп алу белән йорт себерүче өй эченә кереп китте. Бераздан, өстенә кытай атласыннан теккән аллы-гөлле чәчкәле халат киеп, хуҗа күренде. Килүчеләрне сүлпән генә барлап алды.

— Ә, дәү ата... Сау гынамы?

— Сау, улым. Әлегә исән-сау. Ә бу кешеләрне танымыйсынмы?

— Ник танымыйм, таныйм. Сәлимгәрәй бай...

Карашын егет ягына күчереп тынып калды.

— Әхмәтнәсирме дип әйтим... Ник бик иртә кайттын? Җибәрделәрме, әллә качтынмы?

Атыннан төшешли, Артай кычкырып ук салды.

— Агач тел! Үз туганынны шулай каршы алалармы?! Кяфер кешесе дә кунакларны болай каршыламый! Анаң мондый түгел иде, атаң да мәрхәмәтле зат! Кемгә охшап тудын син, хайван?!

Артайның сүзләренә колак та салмагандай, Солтангол тыныч кына:

— Йорт уртасында шаулашмаек, узыгыз өй эченә, — дип, хатыннарның берсенә баш кагып нидер әйтте.

Уздылар. Төрле келәмнәр белән төрелгән өй эче бик ямьле. Өем-өем юрган-мендәрләр. Урта бер төштә кызыл агачтан эшләгән өстәл. Урындык заты күренми. Керүчеләр дивар кырыена йомшак паласка чүмәшеп утырыштылар.

— Нигез иминлегенә дога кылып алыйк бер...

Шунда ук, Артай сүзгә килмәсен дигәндәй, Сәлимгәрәй сөйләшүне тыныч агымга борды.

— Малларын артык өшән күренми әле, улым. Кышны бик авыр чыкмагансыз.

Атасының тел төбен аңлап, Солтангол җавапсыз калмады.

— Ходайга шөкер, кыш бу елны бик авырга килмәде. Кар сон ятты, артык күп яумады.

Шулчак өй эченә кәсәләр белән чәй керттеләр, өстәлгә кипкән кәҗә сыры куйдылар.

— Сез мина карамагыз, эчегез. Без күптән түгел генә чәйләп алган идек,

— дип, хужа карашын Әхмәтнәсир ягына борды. — Патша хезмәте ничек узды? Исәнлекләр ничек?

— Әлхәмдүлиллаһи, исәнлек әлегә зарланырлык түгел. Сонгы сугышта яра алган идем, сун як кулбашыма. Вакыт-вакыт искә төшергәли, күнегеп барам инде.

— Кемнәр белән бара сугыш? Туктарга исәбе юк бугай?..

— Баштарак төрекләргә каршы сугышып, Азов ныгытмасын алдык. Берничә елдан, «Төньяк» сугышы, ягъни шведлар белән сугыш башланып китте. Күп кенә ныгытмаларны алуда катнашырга туры килде.

— Безнен якларда да тыныч түгел. Талау өстенә талау, кан коюю.

Ниһаять, Артай да сүзгә кушылды.

— Ул кыенлыклар әле сина кагылганы юк, олан. Канат астында яшисен. Тәкәбберлегенне жинмәсән, канатынны каерып куюым да бар. Хәзерге заманда туганнар белән дошманлашып яшәргә ярамый. Ата-ананы рәнжеткән кеше тәмуг кисәве булып яначак. Ишетсен колагын!

Кунаклар озак тоткарланмады.

— Берәр төрле әйтәсе сүз бар идеме әллә? — дип сорап куйды Солтангол.

— Бар ие улым, бар ие. Әйткән сүзләремә колак салмасан, япа-ялгыз калачаксын, кара аны! Әйтәсе сүзне икенче килүдә әйтербез! — дип, Артай атына йөгән уйнатып урыныннан кузгалды.

## 42

Бөтен жир яшеллеккә чумган май ае урталарында, урман сулары төшеп, уйсулыкларны басты. Әхмәтнәсирнен тизрәк үз жирләрен күрәсе килгәнлектән, Йомахужа белән икәү, хәрбиләрне ияртеп, Богырысланга барган иделәр. Инешләрен су басып, үтеп чыгарлык булмаганлыктан, бүленеп калдылар. Әсмабикәнен сый-хөрмәтендә берничә көн тору белән егет түзмәде, Артай ярдәме белән озата баручы кеше табып, Йомахужа белән өчәүләп тан атуга юлга чыктылар. Тау итәгеннән урап берничә чакрым юл үтүгә алда каралтылар күренде. Биш-алты йорттан торган урыс авылы иде бу. Озата баручы әйтүенчә, Благодаровка икән. Урман аша үтеп тауга күтәрелделәр. Кемнәрдер бу тирәләрдә йөрештереп караган, күрәсен, сукмак шикеллерәк нәрсә бар иде. Кәрлә имәнлек катыш усак урманы арасында кин генә аланлыклар да очрый. Тирән тынлыкка моң өстәп кошлар сайрый, чәчәктә утырган миләш агачларында умарталар мәш килә. Берничә көн рәттән суытып жибәргән иде. Бүген көн мәрхәмәтле. Дала тормышын сагынып, шундый урманлы тормышка күнеккән егеткә бу күренеш узган елларын исенә төшерде. Тын гына ат өстендә чайкалып бару аны Вишневка авылы якларына алып китте.Андагылар ни хәлдә икән? Андагы инешне дә су баскандыр инде... Егорнын хәле ничек икән?.. Янабаштан чирләп китә күрмәсен инде, Ходаем!..

Тора-бара тигезлек бетеп сукмак түбәнлеккә төшеп китте. Алда урман куерды.Колач житмәс имәннәр, усак катыш каен агачлары. Әкренләп урман сирәгәя барып, алда таллыклар барлыкка килде. Таллар су эчендә. Артка чигенеп, унга борылдылар. Ул тирәдә кыргый жанварлар эзеннән башка юл юк иде. Шактый гына ара узгач, алда калкулык күренде. Шәрә калкулыкка күтәрелеп кояш баешы ягына күз ташлау белән алларында хәйран күренеш ачылды. Күз күреме арада үзәнлек су астында калган. Богырысланда алган белешмә буенча Тәрәгәл белән Саураш елгалары кушылган үзәнлек иде бу. Әнә, еракта, ике елга арасында чөй шикелле ерып кергән тау. Тау итәгендәге таллыклар арасыннан тасма кебек сыек кына төтен күтәрелә. Ул тирәдә кеше заты бар иде, күрәсен — ташландык урынга охшамаган. Килгәндә

үк үзәнлек ягыннан кошлар шау-шуы ишетелгән иде. Менә кайда икән ул кошлар дөньясы! Дәрья суыдай җәелеп яткан уйсулыкны шау китереп кошлар каплап алган. Нинди генә кошлар юк иде монда! Балачакны хәтерләткән казлар кангылдавы, тамаклары карлыкканчы бакылдаган үрдәк тавышлары егетне бала чагына алып кайтты. Җылы яклардан кайтып килгән киек кошлар ул туып-үскән тирәдәге күлләвекләрдә туктый иделәр. Хәл җыеп, тамак ялгап алып, дәррәү күтәрелә иделәр дә, каядыр шушы якларга көтү-көтү очып китә иделәр. Менә кайларга ашыкканнар алар. Әнә, алар килгән яктан, гыж-гыж һаваны ярып, бер төркем аккошлар баш очыннан гына узып китте. Су өстендә буш урын эзләгәндәй очып әйләнеп, тәпиләрен алга сузган килеш, суга төштеләр. Суга төшү белән берсе, канатын җилпеп, туган якларын сәламләгәндәй сузып-сузып кангылдап алды. Казларныкына охшаш булуга карамастан, аккош тавышларында ниндидер аерым мәкам, йөрәкне чеметеп алган моң, сагыш. Егет тә бит шушы киек кошлар шикелле талпынып туган якларына кайтты. Аның күңелендә дә шул ук моң-зар. Әссәламәгаләйкүм, ата-бабалар җире! Җәннәт түрен хәтерләткән кыргый төбәк! Бу тамашаны йөрәге аша кичерү үзе бер тантана, бәхет иде!

### 43

Язгы сулар үз ярларына төшә башлау белән җирле халык арасында шау-шу, җәнҗал купты. Авыллардан авылларга йөреп урыс гаскәриләре кеше талый, ясак җыя. Шуның өстенә елга буйларындагы уңдырышлы җирләрне урысларга тарату эше дә янабаштан зур колач алды. Гомер-гомергә мал асрап көн күргән дала халкына җәйләүләрне кысканнан-кыстылар. Алай ярамый, монысы ярамый. Юк-барга да ясак түләргә кирәк. Мөселманнарның гыйбадәтханәләренә ясаклар салып, урыслар яңа җирләрдә чиркәүләр торгыза. Богырыслан белән Әсәкәй тирәләрендә тынычлык иде әле. Төньяк-көнбатыш өлкәләрдән татар, мишәр, башкортлар белән бергә чуаш, мари, удмуртлар, талаудан гаҗиз булып, бу якларга агыла башлады. Әсәкәй улы Алдар Тарханлыларга һөҗүм итеп, патша яклы бай түрәләрне үтергән. Түләкәй улы Көсүм белән кушылып урыс авылларына һөҗүм башлаганнар, үз тирәсенә халык җыялар, имеш. Уфага һөҗүм итү ди исәпләрендә. Шул ук вакытта, Себер һәм Кырым татарларына, казакъ белән каракалпак, чыңгыз кабиләсеннән булган җөнгер түрәләреннән ярдәм сорап юлчылар җибәргәннәр.

Көннәрнең берендә Богырысланнан Артай килеп төште. Бик талчыккан, житди кыяфәттә иде.Килү белән Сәлимгәрәйгә тиз арада аксакалларны җыярга кушты. Табын корып тормадылар. Авыз кипкәндә кабып куйгаларга дип чәй генә өлгерттеләр. Көттереп дигәндәй Әсәкәй карт та килгән иде.

Сүзне Артай башлап җибәрде.

— Туганнар, яшерен-батырын түгел, эшләр начар. Һәркайсыбыз аңлый, урысның тамгысы көчле. Халык юк-бардан гына күтәрелмәде, аңысы хак! Без сезнең белән зур тормыш юлы узган кешеләр. Заманында мондый хәлләрне баштан уздырырга туры килде безгә дә. Әйе, күзне кан баскан, зиһен буталган! Әйе, урыс азды! Ә урысның кайчан мәрхәмәтле булган чагы бар иде? Азагы ничек бетәчәк? Күптән түгел генә узган елларны исегезгә төшерегез! Безнең тирәләргә ул кара козгынның канат очы гына кагылып узды, ә дәһшәте сизелерлек иде...

Карашын үзалдына төбәп тын гына утырган Әсәкәй карт телгә килде.

— Ә син нәрсә тәкъдим итәсең? Аякларын бәйләп ташлаган сарык бәрәне шикелле үлем көтеп ятаргамы?

Артай бер йотым чәй эчеп куеп, тынычлана төшкәндәй булды.

— Юк, туганнар. Хикмәт шунда, без сарык малы түгел, без адәм балалары.

Ходай Тәгаләдән безгә ан, зиһен бирелгән. Безгә төптән уйлап, гакыл белән эш итәргә кирәк.

Шул ук Әсәкәй, тавышы кырысланып калтырана төшкән килеш:

— Баш иеп каршысына барыргамы? Заманында башны идек. Билне дә бөктек, артын да үптек! Ә нәрсә бирде?! Бар, әнә яшьләргә сөйләп, аңлатып кара! Давылны урыс үзе кузгатты. Аны хәзер жинел генә туктатырлык түгел, – диде дә тынды.

— Аңлыйм, туганкаем, тик...

— Мин сиңа туган тиешле кеше түгел!

Әңгәмәнең зурдан кубуын тоеп, Сәлимгәрәй картларны тынычландырырга ашыкты.

— Кызып китмик әле, агайлар. Без барыбыз да бер каннан, мөселманнар. Атабыз Адәм, анабыз Һава балалары. Артайны мин күптәннән беләм. Малай чагымнан ук. Заманында Степка Разин кулы астында безгә аның белән урыс патшасыннан хаклык дауларга туры килде. Бөтен ил кузгалган иде бит. Ә нәрсә белән бетте? Тыныч кына тыңлап бетерик Артайны. Буш сүз сөйли торган кеше түгел ул.

Артай ашыкмый гына кесәсеннән дүрткә бөкләнгән язу чыгарып, ишек катындагы Әхмәтнәсиргә сузды.

— Мә, улым, син укый беләсең аларча, укып чык. Калганын үзем тәржемә итеп аңлатырга тырышырмын.

Егет башта язу өстеннән күз йөгертеп узды. Хәрефләр тигез, аңлаешлы язылганлыгын күреп, мәкам белән укырга керешге.

«У нашего великого государя земли много безсметно, и вам ворам нас и земли своей никогда не отдаст. А как великий государь наш гнев свой государев положит на тех ханов и салтанов... что... на нас идут, и он не токоме ево государевой земли взять, ни и в своих землях места не сыщут; не токомо степные кочевальники, но и каменных городах ево государевы неприятели не успевают искорены бывают, а он, великий государь наш, в полной силе и богатстве».

Хатны укып бетергәч, беразга тынлык урнашты. Тынлыкны шул ук Әсәкәй карт бозды.

— Әз булса да урыс телен сукалыйм. Бу юлламада безне караклар дип атаганнар. Шуның белән нәрсә әйтергә теләден, Артай?

— Әйе, андый сүз бар юлламада. Тик ул сүз безгә карата әйтелмәгән. Аның мәгънәсе башкачарак. Ишетеп белүемчә, чит төбәктәге ханлыклардан ярдәм сорап юлламалар жибәртелгән. Кем генә килеп яклар, кан кояр икән безнең өчен? Андый хәл чыңга ашса да ирекле була алырбызмы? Ничәмә йөз еллар буе Чыңгыз ханлыгы кулы астында булдык. Әллә безнең халыклардан ясак түләтмәделәрме? Урыс бит башта безне кысрыкламады. Дистә еллар буе аның барлыгын да белми яшәдек. Ә тәртип дигән нәрсә, тынычлык бар идеме? Шул ук сез ярдәм сорап өмет иткән кыргыз, каракалпаклар тынгылык бирмәделәр. Малларыгызны көтүләре белән куып алып китә иделәр. Каршы торганнарны аяусыз килеш үтерә иделәр. Ярдәм итеп урыстан арындыра алганда да безгә бәхет инмәс, туганнар. Малларыбыз белән бергә жирләребезне тулы килеш тартып алып, безне юкка чыгарачаклар. Әлегесе вакытта урыс төньяк биләмәләрен кинәйтә. Төрекләр белән тынычлык урнаштырган, төньягында да әкренләп жайга керер. Ул сугышлар гомер буена сузылмас, бетәр бер. Урыс үзе дә анга килер, карашын йомшартыр. Тик әйтәсе килгән кинәшем бу турыда түгел. Болары тик минем хыялым гына. – Артай тагын бер мәртәбә чәй йотып куйды. Сүзен бүлүче булмады. – Юлламадагы «карак» сүзе әнә шул, без ярдәм көткән кабилә ханнары турында бара, туганнар. Урыс та бит шул ук безнең

кебек адәм заты. Безгә кирәк булган әйбер аңа да кирәк. Кычкырышудан, янаудан файда юк. Урыс түрәләренең салпы ягына салам кыстырып, гакыл белән эш итәргә кирәк. Алар халкы майлаганны ярата. Ә кем яратмый? «Жилдән» килгәнне без үзебез дә читкә типмибез. Майламаган көпчәк тә начар әйләнә, озакка чыдамый. Богырыслан түрәсе башсыз кеше түгел, безнең хәлләрне аңлый. Әгәр бездә маллар юк икән, ул аларны ничек итеп ала? Ә бездә мал-мөлкәтнең күпме икәнлеген ул каян белә?.. Аңлыйсызмы? Аның өчен бу тирәләрдә тынычлык булу кирәк.

Әсәкәй сүзләрендә дә хаклык юк түгел. Давылны туктатып булмаса, аны башка яккарак өдереп җибәрү кирәктер. Урал якларында чуен-корыч чыгарыр өчен җирләрне тартып алалар.Андагы халык мал асрамый, аучылык белән көн күрә, ау өчен аларга урын җитәрлек. Һич югы тимерчелек белән шөгыльләнсеннәр. Ә без монда үз хәлебезне үзебез җайларга тиеш. Менә шулай, туганнар. Уйлашыгыз, киңәшегез. Әгәр теләгегез бар икән, тәнемдә көч бар вакытта ике арада арадашчы була алам. Әнә яшь егетебез патша хезмәтеннән кайтты. Гакыл белән эш йөрткәне өчен, күндәм булганы аркасында аны Ак патша җир биләмәләре белән бүләкләгән.Алып кына калмый, бирә дә белә икән. Кулында көчле язуы да бар. Ул юлламаны гакыл белән кулланганда тормышларны җайга салырга була, туганнар. Азагын уйлап эш итәргә кирәк.

— Сәлимгәрәй энекәш, хатын-кызлар самавыр янартсын әле. Үзем белән бераз бал да алып килгән идем, чәй эчеп алыйк. Аннан ары асыл киңәшләремне әйтермен, ачысы серем дә бар, — дип, Артай сөйләвеннән туктап калды.

Олылар баллап чәй эчтеләр, Артайның киңәшләрен уртаклаштылар. Богырысландагы урыс түрәсе Артемий үзе Артайдан халык белән уртак тел табуын сораган булып чыкты. Кай өлкәләрдән сорау була, шунда җибәрәчәкләр икән үзләрен. Артай ачкан сер шул, Артемий Казанга: «Слава Богу, у нас пока спокойно. С населением в ладах», — дип хат юллаган. Тора-бара да тынычлык сакланса, гаскәриләр бу якларны читләп үтәчәкләр ди. Картлар бу фикерне хуплады. Малларны ничек итеп саклап калу турында да Артай үз фикерен әйтте: «Көтү-көтү мал асрап булмый хәзер, җәмәгать. Аның үз авырлыклары да җитәрлек. Кышкы чорда вакыты белән күп маллар ачтан үлә. Безгә иген игә башларга кирәк. Иген булганда мал асрау да җиңелгә төшәчәк. Малсыз җир эшкәртеп, иген игеп булмый дип атларыбызны бирмәскә бер сәбәп булачак. Берничә гаилә Урал якларыннан килгән. Тимер эшкәртү эшләрен беләләр. Корал ясыйлар дип ул яктагы башкортларга тимерчелекне тыйганнар. Әгәр без монда, үзебездә балта, сабан төрәннәре эшкәртсәк, каршы килүче булмас. Курыкмыйча башлап җибәрергә кирәк, Ходайга тапшырып.

Кичкә кадәр сузылган җыен шуның белән тәмам булды. Әсәкәй карт үзе дә әлеге киңәшләр белән килешә иде булса кирәк, башкача каршы сүз какмады.

## 44

Әхмәтнәсир үз хәрбиләрен Богырысланга илткәннән соң да тирмәнне сүтмәделәр. Егет белән Йомагол шунда төн уздырды. Ул көнне Артай егетләр янында куна калды. Кичектерми егеткә үз җирләрен күреп кайтырга киңәш бирде. Өч атнага якын элек күнелен җилкендергән кичерешләр егеткә инде тынгы бирми иде.

Еракта тау итәгендә төтен күренүе аны уйга салды. Кемнәр? Кай яктан анда барып эләккәннәр? Благодар тавы аша сукмакны кемнәр салган? Эшне озакка сузмыйча, Йомагол белән икәү Артайга ияреп икенче көнне

үк Богырысланга киттеләр. Куна калырга туры килсә дип берничә күлмәк азык, балта белән мылтык та алдылар. Карт иярмәс булды, сез башта йөреп, барлап кайтыгыз, икенче юлы мин дә барып чыгарга тырышырмын, диде.. Бу юлы егеткә күпләп озатучы кирәк тә түгел иде.

Җәйнен үз фасылына кереп килгән чагы. Бигрәк тә аста, үзәнлектәге таллыклар арасында бу чор көчле сизелә иде. Бер-берсе белән ярышып сандугачлар сайрый. Бер-берсенә хәбәрдар булып кәккүкләр ухылдавы да үзенә күрә бер серле моң. Урман аша сузылган сукмак таллар арасыннан алга әйдәде. Шаулап аккан инеш буена килеп чыктылар. Сукмак туп-туры сөзәк ярга илтеп терәде. Ул урында яр аралары киң һәм ике якта сөзәк. Ашыкмый гына суга керделәр. Сай икән. Икенче ярга чыгып куаклар арасыннан бара торгач, юл унга борылды. Бер чакрым тирәсе ара узу белән алда ачыклык күренде. Сул кул яклап камышлык. Күлдән шарлап су агып чыга. Чынлап та бу юлны кешеләр салган икән. Сукмак арасындагы сазлык өстенә чыбык-чабык түшәп, агачлар ыргытканнар. Җайдаклар да үткәндер — тояк эзләре бар. Уң яклап киң болын. Матур гына булып үлән күтәрелгән. Бу тирәләрне язгы су басканлыгын күрсәтеп, анда-санда куаклар төбендә төрле чүп-чар, ташкын юшкыны утырып калган. Такырларны үтеп бара торгач, юл сизелерлек булып үргә күтәрелде. Алда артык куе булмаган урман. Агачларнын күбесе карама, усак белән ялбыр имәнлектән тора. Тау белән тигезләшүгә сукмак икегә аерылды. Юлчылар туктап калдылар.

— Кай сукмак белән китәбез, Йомагол?

— Белмәем һул, Нәдир. Тау ягына бараек булмаһа. Унда торак бар бугай.

Тау ягына киткән сукмак әкренләп тарайды. Егетләргә, атларыннан төшеп, җәяү барырга туры килде. Аяк асты юеш, тайгак. Язгы судан бу тирәләр кипшенеп өлгермәгән иде әле. Кыенлык белән карагайлык арасыннан бара торгач, сукмак инеш ярына илтеп чыгарды. Яр буйларын куе таллык баскан, ары юл юк. Сулга борылып атлый торгач, инеш аша салган басма күренде. Элмә кайрысы белән берничә җирдән бәйләп ике бүрәнә салганнар.

— Нәрсә эшлибез, Йомагол? Борылып кире китикме, атларны бу ярда калдырып җәяү йөреп киликме?

— Юк, Нәдир, кире китмәйбез. Атлар калып торгайны, аларга нәмәкәй булыр?

Атларны яр буенда калдырып, егетләр бара-бара ачыклыкка килеп чыктылар. Сөзәк кенә тау итәге иде бу. Һавада башны әйләндерерлек тау үләне белән кукы чәчәге исе. Сап-сары тузганак чәчәкләре өстендә гүелдәп бал кортлары оча. Елга буендагы биек таллыкта кара каргалар шаулаша. Кайдадыр еракта тотлыга-тотлыга сакау кәккүк, бу гүзәллеккә тагын күпме вакыт калганын санап, аваз сала. Атлый торгач, сукмакка чыктылар. Елга яклап кырын салган юл тауның уң як итәгенә сузылган. Әнә, алда яртылаш җиргә казып салынган алачык күренде. Ишек ачык, ә хуҗасы күренми. Җирдә эре-эре балык тәңкәләре сибелгән.

## 45

Мылтыклары булганлыктан хөҗрә хуҗасын өркетмәс өчен «Әссәламәгаләйкүм!» дип кычкырып, ишек катына килеп туктадылар. Сәламне алучы булмады. Хуҗасыннан башка гына өй эченә керергә арусынмыйча тирә-якны барлап чыктылар. Бер читтәрәк акташтан өеп ясалган учак. Ике ягында таган казыклары. Йомахуҗа, таяк алып, учак көлен актарып карады. Сүнеп бетмәгән күмерләр бар иде, кисәү башларында

ут телләре кабынды. Учак хуҗасы ишетсен дигәндәй, тавышын күтәрә төшеп, Йомагыл:

— Нәмәкәй уйлайһын? Бу бәндә касып киткәйнеме, әллә яр буенда балык аулыймы? — дип сөйләнеп алды.

— Белмим, дускай. Ни дип качып китәр икән? Без бит юлбасарлар түгел. Балык тота торгандыр. — Исенә нидер килгәндәй. — Учакка утын өстәргә кирәк. Сүнсә, утсыз калуы бар, — дип, учакка утын салды. Тере күмерне көл белән каплый төшеп саклау гадәтен егет белә иде. Мондый җирдә утсыз калу — ул зур югалту. Юккамыни ишек саңагына каен тузлары кыстырып куйганнар.

Йомахуҗа түбәнрәк төшеп бер кочак коры-сары күтәреп менде. Эрерәкләрен балтасы белән чапкалап, учакны янартты. Шул вакыт тау борылышы артыннан ниндидер адәм күренде. Бер кулында зур булмаган казан, икенче кулында озын таяк иде. Уртача буйлы, киң җилкәле, яше утыз-утыз биш тирәсе булыр. Өстендә иске чикмән. Чикмән итәген өскә кайтарып бәйләгән. Ямаулы киң ыштан балагын киндер белән урап, аягына чабата кигән. Чабата табанында өч бармак калынлыгында күтәртмә. Башында керләнеп каткан кәләпүш. Кояшта янып каралган йөзен сакалмыегыннан аерырлык түгел, бер төстә. Каш астыннан сөзеп карап, учак янына килеп басты. Егетләр нинди телдә сүз катарга белми тынып торган арада, кулындагы таягына сулы казанын элеп, казык башына урнаштырды. Шунда ук көтмәгәндә:

— Ни югалттыгыз бу тирәләрдә, нинди җил ташлады? — дип, саф татар телендә сорау бирде.

Әхмәтнәсир, җинаять өстендә тотылгандай:

— Күреп китәсе килде. Бик матур урын икән... — дип куйды.

Ярдәмгә Йомахуҗа ашыкты.

— Бу тирә Булат Манашов биләмәсе. Син үзең кем монда? Без сиңа дошманлык кылмайбыз, ә син ник болай сөйләшәсен?! Караскы!

— Кызма әле, дускай. Без бит аның таныш-белешләре түгел. Кочак җәеп каршы алсынмыни? — дип, егет Йомахуҗаның җиңеннән тотты. Шунда ук үзләрен таныштырып та узды. — Мин Манаш ыруыннан булам. Әхмәтнәсир Сәлимгәрәй улы. Ә бу — минем якын кардәшем Йомахуҗа, Йомагол улы. Патша хезмәтендә бергә унөч ел хезмәт иттек. Ә сез кем буласыз, кардәш? Исемегез ничек?

Җавап бирәсе урынга бу адәм:

— Тозыгыз юкмы? Тозым бетте, — дип куйды.

Егетнең йөзенә елмаю чыкты.

— Йомахуҗа, тоз синең капчыкта булырга тиеш, чыгар.

— Ни атлы булуын әйтмәсә тоз бирмәймен, — дигән булып, йомшара төшкән башкорт егете капчыгыннан тоз чыгарды. — Тозның бәһасе күпме икәнен беләсеңме? Мә, ал. Без саран түгел.

Учак хуҗасы бер чеметем тоз алып авызына капты, иренен ялап куйды.

— Тозсыз кыен шул. Ашаган азыкның тәме юк. Гел генә балык та туйдырып бетерде. Минем исемем Латыйп. Сунарчы мин. Балык тотам.

Иптәшенә учак хәстәрен йөкләп, егет суга китте. Тау итәген урап аска төшүгә, алдында киң болын ачылды. Күптән түгел генә судан арынганга, күрәсең, үләннәр яна күтәрелеп килә иде әле.

Әхмәтнәсир башта кулын юып теш сындырырлык салкын су эчте. Су искиткеч тәмле иде. Битен чылатып, тагын бер мизгел тирә-якны карашы белән айкап-барлап чыкты. Өлешенә тигән җир бу кадәр җанга ятышлы урында булыр дип уена да килеп кермәгән иде бит. Нәрсәдән башлап

җибәрергә дә, ничек итеп кулланышка кертергә бу хәтлек җирне?.. Атасы олыгаеп бара, Солтанголның үз белмәсе бар. Кемгә таянырга була? Артайның да комы коелган. Кинәш бирүен бирер дә...

Уйланып бертын утырганнан соң казан тотырып су алды. Төшкәндә сизелмәгән, сөзәк ярыйсы гына текә иде. Теге адәм үзе белән юкка гына таяк алмаган икән. Килеп җитмәс борын, үз җирем итеп, комнан бау үрә башладым бугай, дип егет үзалдына елмаеп куйды. Кем ул Котлыгыш, аның монда ни катнашы бар, ул карт янына барып белешергә, аңлашырга кирәк...

Йомахуҗаның учагы әзер иде. Алып килгән суның яртысын чәйнеккә салып, казан элделәр.Капчыкта каклаган иттән башка бер төтәрәм сарык ите дә бар иде. Кычыткан белән төреп салган ит төсен җуймаган.

— Балык туйдырды диделәр бит, сал яртысын, саранлашма, — диде егет, Йомахуҗаның итне өч кисәккә бүлеп ятканын күреп.

Шул арада Латыйп каяндыр кыр суганы белән тәмләткеч үләннәр җыеп килгән иде. Тирә-якка хуш ис таратып балык шулпасы өлгерде. Вакыт әле иртә иде. Башта балык ашы ашап, итле ашны кичке буйда ашарга булдылар. Табында төрле сораулар биреп, егет балыкчыдан күп кенә нәрсәләр белеште. Иптәше бүген килә калса, Латыйпның үзе белән Котлыгыш якларына барып килергә килешенде.

Латыйпның иптәше караңгы төшәр алдыннан гына килде. Ят кешеләрне күреп, инеш буендагы таллар арасыннан, шактый гына вакыт читтән күзәтеп торган. Икесенә генә таныш булган ишарә белән Латыйпны чакырып алып, хәлнен асылына төшенгәч кенә чыгасы иткән.

— Заманы шундый, төрле кешеләр очрый урманнарда, — диде Латыйп, агайне белән таныштырганда. — Астанай бу. Тоз, ярма алып килә алмасмы дип Котлыгышка барган иде, үзләре дә балык белән тамак туйдырып торалар икән. Бу чорда, җәнлек тиреләре булмагач, урыс сәүдәгәре кирәк-ярак алып килми шул. Күзгә кадәрле ничек тә түзәргә туры киләчәк. Узган көзне тоткан кондыз тиреләренең дә күп өлешен, ясакка дип, бушлай алып киткәннәр иде, бу елның көзендә ни булып бетәр, билгесез.

— Менә сиңа аулак урын, — дип куйды Әхмәтнәсир үзалдына. Шунда ук Латыйпны тынычландырырга ашыкты.

— Кайгырмагыз, агайлар, җайланыр. Котлыгыш картны күреп кайтыйк, аңлашыйк, аннан ары күз күрер.

Ашны җылытып ашап, төнгелеккә әзерләнделәр. Әхмәтнәсир белән Йомахуҗа ачык һавада гына йокларга булдылар. Хөҗрә эчендә тынга капланган тынчу ис, урын да кысрык иде.

Латыйпның әйтүенчә, барасы җир якын түгел, берничә урында тау менеп тау төшәсе, урманнар аша үтәсе бар икән. Шуның өчен таң белән юлга чыгарга карар кылынды.

**46**

Юл җиңелдән булмады. Сөзәк калкулык аша шактый гына ара узгач, тау битенә килеп чыктылар. Тау асты битләвегендә елгачык буйлап бер дистәгә якын каралты-кура бөршәеп җиргә сеңгән.

Тулы тынлык. Кеше заты күренми. Шул тынлыкны бозып кырый йортта абалап эт өрә башлады. Ул бәйдә түгел иде. Эт өргән тавышка өй эченнән бер адәм чыкты. Озын, таза гәүдәле. Җыйнак сакал-мыегын чал баскан. Алтмышлар тирәсендәге олы кеше иде бу.

— Әнә, үзе, — диде Латыйп, ияге белән карт ягына ымлап. — Котлыгыш бабай.

Кычкырып сәлам биреп исәнләштеләр. Йөгәнне кулдан ычкындырмый гына бер аякка тезләнеп дога кылдылар.

— Йортыгыз имин булсын, бабай! Сау-сәламәтлек сезгә барчагызга да.

— Амин, шулай була күрсен, әйдүк, узыгыз!

Йөгәнне казык башына бәйләп өй эченә уздылар. Өй эчендә артык зур муллык сизелми.Мич алды бүлмәсеннән әби күренде.

—Карчык, чәенне жылыт, кунаклар килде безгә. — Егетләр алдында бераз акланып та алды. — Сый-хөрмәт юк инде, туганнар.

— Хафаланмагыз! Хәлләрегезне беләбез, бабай. Чәегез булса, безнең үзебез белән бераз бал, икмәгебез, катлама бар. — Йомахужа ягына баш ымлады, — бар, алып кер капчыгынны.

Саклык белән генә башланып киткән әңгәмә чәй эчә-эчә әкренләп үз агымына керде. Әхмәтнәсир бу тирәдәге жирләрнең урыс патшасы әмере белән үзенә бирелгәнен дәлилләп, түш кесәсендәге язуын укып чыкты. Котлыгыш карт, сабыр гына тыңлап утырганнан соң:

— Менә ничек икән... — дип, тарихка ачыклык кертәсе итте. — Син чынлап та безнең токымнан икәнсең, олан! Бу жирләр борынгы бабабыз Гали бай жирләре. Заманында аның өч хатыны булган. Беренче хатыны нугай кызы, икенчесе мишәрләр токымыннан. Ә өченчесе, мөселман динендәге чуаш кызы була. Безнең бабабыз Манаш әнә шул өченче хатыннан. Явыз патша Иван Казанны алганнан соң, башка туганнарына караганда, урыска карата күндәмлек күрсәтеп, бу жирләрне үзенә теркәтә. Дүрт малаеның берсе Булат урыс патшасына хезмәт иткәндә үтерелә. Икенче улы Килемхан, башкорт кызына өйләнеп, Тархан ягында яши торган була. Шунлыктан Булатның Кинәле елгасы башындагы дала жирләре, мал-мөлкәте белән, аңа кала. Минем атам Сөләйман сәүдәгәр бу жирләрдә сунарчылык, тире эшкәртү, бал жыю шикелле эшләр белән көнен күрә. Хикмәт шунда, олан, туганнар арасында бердәмлек булмый. Шунын аркасында без аерым яшәдек, берберебезнен тормышы, кайгы-хәсрәте белән кызыксынмадык.

Гали бабабыз туганнарының бер өлеше урыска каршылык күрсәтеп һәлак була. Исән калганнарынын да оныклары бүгенгесе көндә дә качып яшәргә мәжбүрләр. Шуларнын берсе Гали әлегесе көндә Сарбах чокырында көн күрә.

— Туганнарның аралаша алмавы әллә әбиләребезнең төрле милләттән булуы аркасындамы икән? — дип, Әхмәтнәсир үз язмышын мисал итеп китерде. — Минем дә ир туганым бар. Исеме Солтангол. Ул атамнын беренче хатынынннан туган бала. Солтанголның анасы нинди милләттән булуын тәгаен генә әйтә алмыйм, минем анам нугай кызы. Арабыз ике ай тирәсе генә булуга карамастан, туганым белән аралашып үсмәдек. Бала чактан ук көнче иде. Ир уртасы булып килгәндә шул көнчелеге хөсетлеккә әверелгән, күрәсең, атабызга карата да шәфкать нуры калмаган үзендә. Бу бик кызганыч хәл. Бик тә аңлыйм сезне, бабай! Бер-беренә терәк булу житешми шул туганнар арасында! Гали кардәшебез турында ачыклык кертсәгез иде. Еракмы ул Сарбах дигән урын? Очрашып танышу мөмкинлеге килсә, бик тә мәслихәт булыр иде.

Котлыгыш картнын йөзе балкып китте.

— Мин үзем дә бу хакта уйлап куйган идем. Андый мөмкинчелек биргәннәр икән, кулланмый калу гөнаһ булыр, улым. Өченче кышны кышладылар чокыр төбендә. Килгән чорны маллары да ишле генә иде, яртылаш малларын югалттылар. Бүреләр үрчегән, шулар тынгылык бирми үзләренә. Барабыз, улым, барабыз! — Котлыгыш карт тәрәзә өлгесе аша тышкы якка күз ташлап алды. — Соңгарак калдык, бүген барып булмастыр. Иртәгә иртүк торып кузгалырбыз.

Битләү аланынын аскы рәтендә, бер-берсе белән янәшә, жир асты каралтылары. Өсләренә түгәрәк агач төзеп, жир белән каплаганнар.

— Болары — маллар өчен, — диде Котлыгыш карт, каралтылар янәшәсеннән узганда.

Өске яклап, озын гына бер рәттә, яртылаш жиргә казып, өсте бурап эшләнгән тораклар. Түбәләрен шулай ук ике кат бүрәнә белән томалап, өстенә балчык салганнар. Арт яклап килгәндә бу торакларны күрерлек түгел иде. Аланның түр башында берничә кеше җыелган. Агач ботагына мал түшкәсе элеп, тиресен тунап ята иделәр.

— Аллаһы ярдәм бирсен, туганнар! Малыгызның ите тәмле булсын! — дип, килүчеләр төркем янәшәсендә тукталды.

Урта буйлы, чәченә чал йөгергән илле яшьләр тирәсендәге сөйкемле генә кеше, танышын күреп:

— Менә, тагын бер тананы яраладылар. Сарай түшәме астындагы тар ярыктан кереп, малның арт аяк сенерен тешләп өзгән, явыз. Качып китә алмады, сәнәккә элдек үзен. Әнә, сарай янәшәсендә ята гәүдәсе, — дип, карашын ят кешеләр өстеннән йөгертеп узды. — Кунаклар алып килдеңме? Сизенгәнсен казан эләсен.

Шул арада, жир асты мәгарәләреннән үрмәләп чыгып, халык җыелды.

— Яхшы хәбәр белән килдек әле, Гали туганым! Менә тагын бер кан кардәшебез, туган кешебез табылды!

— Бирсен Ходай! Амин, шулай була күрсен! — дип, Гали атлы ыру башлыгы тананың түшен ачып, үпкә-бавырын, йөрәген суырып чыгарды. Үпкәсен янәшәсендәге үсмергә сузып: — Мә, монысын көчегенә бир, — диде. Түш итен кисеп алып, боларын казанга салыгыз дип әмер биреп, янәшәсендәге хатын кулындагы комганнан кулын юды, сөртенде. — Әйдәгез, туганнар, аш өлгергәнче сөйләшеп алыйк, — дип, кунакларны өске яктагы озын өстәл артына әйдәде.

Жиргә казып утырткан зур агач өстәл янәшәсендә ике яклап эскәмияләр тора иде. Утырышып дога кылдылар, хәлләрне белештеләр. Котлыгыш карт кунакларны якынча таныштырып, килү сәбәбен әйтеп узганнан соң, сүзне Әхмәтнәсиргә бирде. Егет, нәрсәдән башларга белми бертын уйланып алгач, ялгыш сүз ычкындырып бу кешеләрне рәнжетә күрмим дигәндәй, саклык белән сүз башлады.

— Дөресен генә әйткәндә, туганнар, мин сабый чактан атасыз үстем. Туганыгыз Сәлимгәрәй мине патша хезмәтенә китәр алдыннан гына үз баласы итеп таныды. Гөнаһлы була алмыйм, ул мине юклыкта үстермәде. Үземне ятим итеп тоймадым. Патша хезмәтенә дә мин зур теләк белән бардым. Дөнья күрәсем, үз-үземне сынап карыйсым килде. Бәхетемә күрә, юлымда гел яхшы кешеләр очрады. Күнелемнең ихласлыгын аңлап, миңа да тиешлесен түләделәр. Күп кенә авырлыклар кичерергә туры килсә дә зарланып телгә алырдай сәбәп тапмыйм. Күңелем түрендә бер генә китек калдырган нәрсә шул — мөселманнарга каршы сугышта катнашкан елларым. Анда да мин нәселемә тап төшәрдәй гамәл кылмадым, мөселман гаскәриләрен дошманым итеп күрмәдем. Жанымны алырга дип өстемә ябырылганның жанын алдым, яралы кешегә кулымны күтәрмәдем. Кырым ханы Нуретдинне яралы килеш әсир алганда да, җаен табып, иреккә җибәрттердем. Кяфер урыслар арасында да шәфкатьле, итагатьле кешеләр булуына инандым. Иелгән башны кылыч кисми дип яшәмәдем, ялагай булмадым. Ярдәмгә мохтажларга, нинди мәсһәб, нинди диндә булуларына карамастан, ярдәм кулымны суздым. Аллаһының кодрәте белән күнелемнең керсезлегенә инандылар, чит күрмәделәр. Ходайның рәхмәте белән, узган елны бер баланы үлемнән йолып калу бәхетенә ирештем. Чит илләрдән килгән духтырлар, ярдәм итә алмыйча, балага ике ай гомере калуын әйтеп киттеләр. Ә ул, Әлхәмдүлиллаһи, бүгенгесе көндә дә сау-

сәламәт, исән. Кылган гамәлләрем риядан булмады, бүләк өмет итмәдем. Кылган изгелекләр югалып юкка чыкмый икән. Изгелек күрсәтеп, мина ирек бүләк иттеләр. Бу жирләрне дә мин сорап алмадым. Әле анын бәясен түлисе бар... Туган илемдә булсам да мин әлегә кеше кешесе. Мин сезнең ярдәмгә мохтаж, туганнар. Бу жирләрнең элек-электән ата-бабаларыбыз биләмәләре булуы — минем өчен зур яналык һәм әлеге хәбәр мине чын күнелдән шатландыра, өмет уята. Бүгенгесе көннән сез — качаклар түгел! Минем исемгә аталган кодрәтне кулланып яңа тормыш башлау мәслихәттер, туганнар. Сүземнең ахрында шуны өстәп әйтәсем килә. Урыс көчле. Алар күп. Бүгенгесе көндә аны көч белән сындырып булмый. Яңа юл эзләргә, яраклашырга кирәктер. Ә анын өчен бердәм булу кирәк. Эт өрә, кәрван бара, дигән әйтем бар. Эт булып өрүдән, теш ыржайтудан файда юк. Эт өрүенә карамыйча кәрван булып юлны дәвам итәргә, ныгырга кирәк. Күрегез әле, тирә-якта күпме байлык! Шуңа карамастан, жир астында яшәп, юклыкта жәфа чигәбез, туганнар! Урысның да күпчелеге юклыктан интегә. Үз бәхетебез үзебезнең кулда. Урыс көнләшерлек итеп яшәргә кирәк!

Сүз барышында өстәл артына тагын берничә ир-ат килеп утырган иде. Тын да алмый егет сөйләгәнне тынладылар, вакыт-вакыт килешкәндәй башларын кактылар. Бер мизгелгә тулы тынлык урнашты. Барысының да карашы Гали ягына төбәлгән иде. Ул ни әйтер?

— Эчендә булганнарны яшермичә ачып салуың өчен рәхмәт сиңа, туганкаем! Сүзләреңдә хаклык күп, шигебез юк. Тормыш бит ул бик күп катлы, катлаулы. Син бер катламын күргәнсең, ә безгә анын тирәнрәк катын татып карарга туры килде. Заманында бабаларыбыз урыс белән алыш-биреш, сәүдә иткән, начармы-яхшымы, үз тормышлары белән көн күргәннәр. Дине, теле ят булуга карамастан, дошманлашмаганнар, бер-беренә тәмгыларын сузмаганнар. Кем беренче булып шул тынычлыкны бозды? Кем безнең илгә яу белән килде? Явыз Иван килде! Ул беренче бозды тынычлыкны! Анысы хәерле булсын, жиңелдек. Ясак түләдек. Хатын-кызларыбызны хурладылар, түздек. Ул гына житмәде, канны эчәргә, динебездән яздырып, безгә хас булмаган ят кануннар тагарга кереште. Адәм баласының үз теләгенә карап түгел, канын коеп, көчләп! Син ул мәхшәрнең бер генә мизгелен күрсәң икән, туганым! Йөрәгенә кан савып, тилереп үлгән булыр иден! Шунын бер генә очрагы...

Чулман елга аша басма салып, басма уртасына түшәм кордылар. Түшәм астында зур тишек. Ике яклап кораллы ике башкисәр, янәшәдә зур сакаллы поп, кулында тәресе. Меңләгән кешене ярга куып китереп, басма аша уздыра башладылар. Гайсә динен кабул иткәннәрне, муеннарына тәре тагып, икенче ярга уздырдылар. Кем үз диненнән ваз кичәргә теләми, башын кисеп, шундагы тишек аша суга ыргыттылар. Берничә көн эчендә каннан кызарган елга, мәетләрдән буылып, ярларыннан чыкты. Бүртенеп кабарган мәет исеннән дистә чакрымнар тирә-юньдә тын алгысыз иде. Әлегесе заманда да ул тирәләрдә мәет исе. Бабалардан мирас булып калган үз жиребездә күселәр шикелле жир тишегендә качып яшәргә тиеш түгел без. Моның белән дә килешәм, туганкай! Күнеленнең ихлас булуына ышанам, шунын өчен фикеренне кабул итәбез. Туганнар туганнар белән, бер-беренә ярдәмләшеп, аралашып яшәргә тиешләр! Хаклык синен якта! Эзләп-табып килүең өчен Аллаһынын рәхмәтендә бул, туганым!

Гали, урыныннан күтәрелеп, Әхмәтнәсирне кочагына кысты. Котлыгыш картның күзендә яшь иде.

— Амин! Шулай гына була күрсен иде, Ходаем! Картлык көнемдә мондый хәлне күрүемә бик шатмын, балалар!

Туганнарның үзара килешүе тискәре хис уяткандай, каяндыр өске яклап, калын урман арасыннан, сузып-сузып бүре улаганы ишетелде. Аның тавышында моң-зар, тирән сагыш иде.

47

Яңа урында хыялланып ике тәүлек вакыт уздырганнан соң, Әхмәтнәсир белән Йомахужа Богырысланга кайттылар. Анда аларны начар хәбәр көтә иде. Минзәлә тирәсендә җанҗал кубып, Әлмәтне, Бөгелмәне аякка бастырганнар. Тирә-яктагы авылларны ватып-җимереп, талап, дәһшәтле көч өермә шикелле кубып, Уфа якларына юл алган. Шул өермәнең бер өлеше — фетнәчеләр, Богырысланга килеп котквы салганнар. Урындагы халыкның бер өлеше алар яклы икән. Йөзе качкан Артай:

— Вакытында кайтып өлгердегез, мәхшәр бездә. Глава тирәсенә халык җыелган, шунда барырга, аңлашырга кирәк! — дип, хафаланып каршы алды үзләрен.

Алар барганда шактый гына халык җыелып өлгергән иде. Ике дистәгә якын коралл хәрби мылтык төзәп халыкка каршы баскан. Глава урыс телендә нидер аңлатырга газаплана. Торган арба өстенә басып Артай, барлык көчен туплап, тавышын эшкә җикте.

— Җәмәгать! Туганнар! Тынычланыйк әле! Тыңлагыз әле дим!

Шау-шу бераз кими төшсә дә, сүз ишетерлек түгел иде әле. Әхмәтнәсир, янәшәдә торган хәрбинең мылтыгын алып, өскә атып җибәрде. Халык тынычлангандай булды. Артай, карлыккан тавыш белән кычкырып, сөйләвен дәвам итте:

— Хәлегезне аңлыйм,туганнар! Бөтен ил шушы хәлдә. Урысның үз өендә дә шул ук хәл. Гомер буена кыеңлыкта яшәдек. Мин белгән заманда гына да күпме баш күтәрү, кан коюлар булып алды. Йә, тормышыгыз аруландымы? Заманында данлыклы Степан Разин белән иңгә-иң сугышкан кеше буларак әйтәм, фетнә куптарып кына фәкыйрьлек тишеген ямап бетереп булмый, туганнар. Арагызда олылар бар. Алар онытмагандыр әле ул фетнәнең ни белән беткәнен.

Яңабаштан шаулаша башладылар. «Нәрсә әйтмәкче буласың? Без үлемнән курыкмыйбыз! Ачтан ятып үлгәнче, байларның бугазларын чәйнәп, йортларын утка тотып үләбез!..» «Сөйләп бетерсең! Дөнья күргән кеше ни әйтер?!»

Халык башкача тынычланырга теләмәде. Көн кичкә авышып кояш тау артына төшкәнче шау-шу, гауга дәвам итте. Артай халыкны сүз белән генә аңга китереп булмасын аңлый иде.

Караңгы төште. Бер төркем фетнәче глава йорты тирәсендә калып учак кабыздылар. Икенче төркем инеш буенда урнашып казан элде. Ул төн, хәвефле булуга карамастан, шау-шусыз узды. Таң алдыннан глава йорты тирәсендә әз-мәз генә кычкырышып алулар булды, озакламый аңысы да тынды. Таң атып килгәндә балык тотарга дип су буена төшкән бер карт җирдә аунап яткан күп кенә мәеткә тап булды. Глава йорты тирәсендәге мәетләрне алып китеп өлгергәннәр иде инде. Фетнәчеләр кабызган төнге учак зураеп китми генә, пыскып янып сүнде, көлгә әйләнде. Богырыслан тарихына ул төн: «Небольшая группа людей, около полсотни голов, все ночь буянили, и к утру исчезли восвояси», — дигән берничә юллы сүз белән кереп калды.

Шул көннәрдә, Тархан Габдулла, Шарлык якларыннан да яман хәбәрләр килде. Башкорт белән татарларга кушылып мишәр, чуаш, мари, удмурт, мордва халыклары да купкан. Әсәкәй малае Алдар белән Түләкәй Көсүме җитәкчеләре икән.

Богырыслан, Әсәкәй тирәләрен ул дәһшәтле өермә әлегә әйләнеп узды. Киләчәктәниләр буласы билгеле түгел иде әле. Бу хәбәрләр Йомахужаны хафага салды. Ул бит Урал якларыннан. Анда аның туган-тумачасы, ата-анасы яши. Алар ни хәлдә икән? Үзара киңәшләшкәч, туган якларына кайтып килергә булды. Атның җиллесен генә сайлап, азык алып, юлга кузгалды. Әхмәтнәсир, зур казан белән такта яргыч пычкыларын, чалгылар алып, Гали янына барып кайтты, бәладән баш-аяк, талап алулары, урлап китүләре мөмкин. Атасы Сәлимгәрәй дә малларын шунда куды.

Кире китәр алдыннан Котлыгыш карт килеп төште. Бик өшәнгән, йөзе борчулы. Ясак таптырып Куратгаудан килгәннәр. Бөтен йортларны тентеп, шау-шу куптарып, тагын ике көннән киләбез дип, өркетеп киткәннәр.

— Ни генә эшләргә инде, туганнар! Яшәргә мөмкинчелек калмады бит! — дип ах итте карт. Карчыгы артыннан Гали кеше җибәртте. Үз чиратында Әхмәтнәсир: «Хафаланма, бабай, хәл итәрбез», — дип юатып киткән иде, Богырысланда хезмәт иткән хәрбиләрен алып, ике көннән килеп тә житте. Ясак җыючыларны Котлыгыш авылында каршы алдылар. Ике кораллы адәм белән зур сакаллы поп һәм зур корсаклы ясак җыючы килгән. Мондый очрашуны алар һич тә көтмәгән иде, күрәсең, поп озак кына, тирә-ягыннан чебен кугандай, чукынып алды. Ясакчы бөтенләй дә телсез калган иде. Әхмәтнәсир тыныч кына кесәсеннән мөһерле язу чыгарып, ясакчыга сузды һәм басынкы тавыш белән сүз башлады.

— Эты дакумент ат самава царя, Питр Аликсейча. Тут я хәзәин. И ясак сам сабираю. Ви должен Бугырыслан, Әртимий пәдчинәтсе. Зачим вас там я ни раз не видал? Куда ясак даюш? Сибә забираеш? Мы иты будим прәвирәт. Ә тәпәришше ыштуб ваш духы тут нибыл! Панял? Бумагы пасматрил? Аддай!

Ясак жыючы нәрсәдер әйтергә дип авызын ачкан иде, егет тавышын күтәрә төшеп:

— Ышто, не панятны гаварил? Тибә ишшо пататарски әбияснит нады?! — дип, тегене кырт кисте.

Ясак таптырып Котлыгышка башкача килүче булмады. Шулай да, ул очрашуның дәвамы әле алда иде. Эзсез генә югалмады ул сөйләшү.

**48**

Бу вакыт эчендә Алдар белән Көсүм, көзгә кадәр үз тирәләренә сигез мен чамасы халык җыеп, Уфага һөҗүм итәләр. Уфа гаскәрләрен тар-мар итеп, тирә-якны утка тоталар.

Кенәз Хаванский кулы астында Казаннан зур көчләр килә. Көч белән генә алдырып булмагач, аерым килешүләр, ымсындырулар белән, фетнәчеләрнең бер өлешен капма-каршы бастыруга ирешәләр. 1708 елның башында Көсүм, каршылыклар белән булса да, урысларга буйсына. Башкортларның көнбатыш өлкәләрендә фетнә бастырыла. Әсәкәй улы Алдар, үз кешеләрен көнчыгыш өлкәләргә алып китеп, каршылык күрсәтүен дәвам итә. Ике елдан артык төрле төштә талап, яндырып йөри торгач, урыслар аларга каршы Әюк ханны бастыра. Әюк хан кулы астындагы дүрт меңлек калмык гаскәре Алдарны җиңә. 1711 елны фетнә тулысы белән бастырыла. Бу күтәрелеш нәтиҗәсендә патша урындагы халыкларның күп кенә сорауларын канәгатьләндерергә мәҗбүр була.

Туган якларына кайтып киткән Йомахужа шул гомер эчендә, ике дистә җигүле йөк белән ыруын төяп, бу якларга килә. Ике дистә йөкнең күбесендә тимер-томыр, тимерчелек җиһазлары, өрге учагы өчен күп кенә кокс, ташкүмер... Алар килгәндә Гали авылының тавы буенда дистәләгән йортлар калкып чыккан була инде. «Күчену» (Күч юлы) яклап җирләрне агачлардан

арындырып, шул елны икмәк чәчәләр. Агач ботаклары, куакларны яндырып көлен сипкән жирдә шаулап иген уна. Дөньясында кан коюлар барганда Гали авылы тернәкләнә, әкренләп аякка баса.

1707 елның көзендә Әхмәтнәсирне өйләндерәләр. Башта Әсәкәйдән кыз соратып карыйлар. Сәлимгәрәй малае урыска өйләнеп кайткан, моенында тәресе генә юк, андый кешегә бирергә кыз үстермәдек, дип, кире кагалар. «Кәжә мал түгел, хатын-кызга кытлык заман түгел!» — дип, Тарханнан кыпчак бае кызын алып кайталар. Хатыны, гәүдәгә зур булмаса да, аякка нык була. Ел саен бер-бер артлы бала таба. Житмәсә, барысы да малай. Өйләнеп тора башлау белән Галигә килеп нигез кормакчы булалар. Гөрләтеп урман кисеп, такта ярып, йортны аякка да бастыралар. Тик анда калу нияте тиз арада сүрелә. Дала кешесе булгач, хатынына да, үзенә дә сазлыклы, черкиле ул һава ошамый. Башта Әсәкәйдә, атасы йортында кыш уздыралар. Андагы халык белән ара салкын булганлыктан Тарханга, бабасы янәшәсенә барып тирмән коралар. Әкренләп йорт торгызалар. Башкортстаннан килгән Йомахужа кавеме тау итәгендәге елга буена нигез сала, тимерчелек белән шөгыльләнә, мал асрап көн күрә. Ул урам «Башкорт урамы» дип атала. Күченеп килгән елның көзендә, сыкылап яңгыр яуган чорда, Галинең анасы гүр иясе була. Янәшәдә генә, Башкорт урамы белән тау арасындагы бушлыкта жирлиләр. Шул көннән алып тау исеме «Әби тавы» булып телгә кереп кала, тора-бара онытылып, кулланыштан төшә. Ул тау итәге киләчәктә авыл зиратына башлангыч бирә.

Күченеп килгән елны Гали, чуаш кардәшләрен эзләп табып, гаиләләре белән үз янына елыштыра. Үн ел тирәсе элек чуаш кардәше Арсай, Гайсә динен кабул итеп, Котлыгыштан ерак түгел елга буеннан жирләр алуга ирешкән була. 1707 елның язында, ташу сулары күтәрелеп, жирләре су астында кала, мал-мөлкәтен югалта. Кураткауга барып попка мөрәҗәгать итеп карый. Поп: «Стало быть, богу так угодно было. Молись! Молись и терпи! Бог терпел и нам велел!» — дип, йөзен борган.

Арсай, агач эшен, бура бурау, такта яру эшләрен белә. Шуның аркасында, диненнән язуына карамастан, туган кардәшен канаты астына сыендыра, жирләр бүлеп бирә. Чуашларның күбесе киредән ислам диненә кайта, Гали авылында нигез кора. Арсай, урысларның үч алуыннан куркып, Гайсә динендә кала. Тора-бара Гали ана тау итәге буйлап өске яктан, өч-дүрт чакрым ары жир биреп, бүлеп чыгара.

Арсай чуашлар арасында Ыросай, икенче төрле әйткәндә, Ыра — яхшылык, изгелекне аңлата. Русчалап әйткәндә «добро» аңлатмасы ята. Гали авылы янәшәсендәге Ырсай, (Рысайкино) авылына әнә шулай нигез салына. Заманында ул авылда нигез корып ишәйгән халыкта өч төрле дин була. Мөселманнар, христианнар һәм мәжүсиләр. (Күп еллар узгач, ислам динендәге Акмулланы кысрыклап, авыл очындагы чокыр буена куып чыгаралар.)

**49**

1711 елның көз аенда Артай дөнья куя. Тагын бер елдан соң, язгы сусыл вакытында, Әхмәтнәсирнең атасы Сәлимгәрәй дә бу дөньядан китеп бара. Артайга сиксән бер яшь булса, Сәлимгәрәйгә алтмыш тугыз гына тулган иде әле. Аллы-артлы иң якын кешеләрен югалтып, Әхмәтнәсир бер терәксез кала. Бу вакытта ул үзе дә ир уртасы кеше, дүрт бала атасы.

Атасының кырыгын уздырып, атна-ун көн узмады, Казаннан Богырысланга бер төркем тикшерүчеләр килеп төште. Тикшерүнең төп сәбәбе, ясак жыю белән берргәттән, фетнә вакытында булып узган гамәлләрне ачыклау иде. Әхмәтнәсирне Богырысланга чакыртып алдылар.

Күнеле сизенгәндәй, ул Мәскәүдән алып кайткан язуларын да алды. Ул килгәндә тикшерүнең кызган чагы иде инде. Тирә-яклардан да куркытылган халык җыелган иде. Барган көнне Әхмәтнәсирне иртәгә, фәлән вакытка килерсен дип кайтарып җибәрделәр. Төнне ул Артай күршесе Әсмабикә өендә уздырды. Әсмабикә шул ук көләч йөзле, киң күнелле хатын иде. Артайның үлемен бик авыр кичергән. Бик тә гакыллы, итагатьле кеше иде мәрхүм дип, Артайны искә алып, балавыз сыгып алды. Әхмәтнәсиргә килгәләп йөрергә, онытмаска кушты.

Әхмәтнәсир, соңга калмыйм дип, идарәгә әйтелгән вакыттан алдарак барды. Аны көтәләр иде инде. Бүлмә эчендә биш-алтылап кеше бар. Кәҗә сакаллы ябык кына бер карт, исемен-ниен сорашып, сораулар яудыра башлады. Кем, каян, нинди эш белән шөгыльләнә? Әхмәтнәсирнең урыс теле какшау икәнен күреп, үз телегез белән сөйләгез, аңларбыз, диде. Әхмәтнәсир, керү белән кесәсендәге язуларның кайчан, ни өчен бирелгәнен, соңгы елларда булып узган вакыйгалар, ул чордагы кылган гамәлләрен сөйләп узды. Аның сөйләгәннәрен кәҗә сакаллы карт өстәл артында утыручыларга тәрҗемә итеп барды. Шул вакыт арадан берсе:

— Ясак җыюда катнаштыңмы? Җыелган ясакны кая, кемгә тапшырдың? — дип куйды. Көтелмәгән бу сорау Әхмәтнәсирне бер мәлгә уйга калдырды.

— Мин ясак җыймадым, — диде каушап.

— Сезгә бирелгән бу юлламада, акка кара белән: «Способствовать по сбору налогов, ясак», — диелгән. Ә сез, ясак җыюда булышыр урынына, киресенчә, каршылык күрсәткәнсез.

— Мин андый очракны белмим, әфәнде.

— Хәтерегез начар! Котлыгышта ясак җыючыларга кем каршы төште? Кем корал белән янады? Оныттыгызмы?

Шулчак бүлмәнең караңгы бер почмагында бөршәеп утырган поп торып басты.Кара кием өстенә таккан зур тәресен рәтли төшеп, бүксәсен киерде. Гәүдәсенә тәнгәл килмәгән хатын-кыз тавышы белән телгә килде.

— Быстро забыли, молодой человек, как вы нам угрожая усердствовали во благих намерениях наших по сбору дани, во славу нашего отечества.

— Без беркемне дә өркетмәдек, безнең уебызда андый нәрсә юк иде, — дип, Әхмәтнәсир күпме генә акланмасын, попның сүзе өстен чыкты. Әхмәтнәсирне кулга алып, аны таш сарай базына яптылар. Базда бер дистә тирәсе кеше бар иде инде. Тын алгысыз тынчу һәм юеш  баз эчендә ике көн утырганнан соң гына чыгардылар. Идарә башлыгы Әртими:

— Комиссия китте, Аллага шөкер, котылдык! Син молодец, артык сүз ычкындырмадың. Шул вакытта синең белән Котлыгышта булган хәрбиләр сине яклап чыктылар, ул беркемгә дә начар сүз әйтмәде, өркетмәде диеп бардылар. Син азат! Вакытлыча кыенлык тудырган өчен гафу ит безне, — дип калды.

Идарә башлыгының хафалануы юктан гына түгел иде. Җыелган ясакларны аңа биреп бардылар бит. Гали дә үз ясагын вакытында түләп килде. Шуны аңлап, Әхмәтнәсир сүзне куертмады. Кемнәрдер килә дә китә, аңа монда яшисе бар. Кулга ияләштергән түрәне чумдырудан файда юклыгын ул яхшы аңлый.

Чыгу белән Әсмабикә йортына барды. Хуҗа хатын аны:

— Һәй, иркәм, куркыттың бит! Күп кешене кулга алганнар, кыйнаганнар, кемнәрнедер Себер җибәргәннәр имеш, дип сүз ишеттерделәр. Килми торгач, әллә сине дә хур иттеләрме икән дип йөрәгем алынды, — дип, хафаланып, каршы алды. — Исемдә чагымда тапшырып котылыйм әле, дип идән асты базыннан зур гына бер төргәк чыгарды. — Менә, иркәм, Артай моны сиңа тапшырырга кушып калдырды.

— Нәрсә монда?

— Ач, ач төргәкне, үзен күрерсен.

Әхмәтнәсир киндер чүпрәкне чиште. Төргәк эчендә авыр гына күн янчык белән хәлвәдән бушаган калай тартма иде. Тартма тулы төрле зиннәтле бизәнү әйберләре, асылташлар белән уеп ясалган йөзек, балдаклар. Янчык эчендә тагын ике төргәк бар икән. Бер төргәктә алтын, икенчесендә көмеш тәнкәләр иде.

— Ник бирәсе иттегез, үзегезгә генә алмадыгыз?

— Бәладән баш-аяк, иркәм! Мин бу әйберләрне куллана белмим. Белгән хәлдә дә ул әйберләр сина аталган. Берәрсе сизеп үтереп чыкмагайлары дип йөрәгем алынып яшәдем. Артай үләр алдыннан, башкача жан аткан кешем юк, Солтангол безнен каннан булса да туган жанлы кеше түгел; карап торган бер якын кешем — Әхмәтнәсир; намазлык өстендә чакта минем исемне дә телгә алгаласын, мин ана ышанам; бу төенне үз кулын белән ана тапшыр, диде. Шикләнмә, иркәм, ул мине дә ким-хур итмәде. Алланын рәхмәтендә булып, яткан туфрагы жинел булсын, Сират күперләрен жинел генә кичәргә язсын, Раббым!

Әхмәтнәсир Тарханга кайту белән зур гына итеп мәжлес жыйды. Әрвахлар исеменә Коръән чыгарып, муллага алтын, картларга көмеш, яшьләргә бакыр тәнкәләр өләшеп чыкты. Икенче көнне үк елкы сатып алып чалдырды, итен карт-коры, ятимнәргә таратты.

**50**

Тикшерүләр булып алганнан сон күп тә үтми Әртимийне урыныннан алып икенче кешене куйдылар. Шул барудан сон түрәләр белән башкача аралашмады Әхмәтнәсир. Гали янына барып хәлләрен белгәләде, кулыннан килгәнчә ярдәм итте. Сонгы баруында, ул-бу була калса дип, балалары исеменә жир бүлеп бирү турында сүз кузгатты.

Гали ана:

— Әнә, Күчү юлы унаеннан урын бүлеп куйдык. Яна урам ачабыз. Алар өчен генә ин жайлы, коры урын. Теләмиләр икән, үзләре сайлап алыр ошаган урыннан, — дип, икеләнергә урын калдырмады.

Байлык артыннан кумады ул. Кирәк каләрле генә мал тотты, гаилә хәстәрен кайгыртып балалар үстерде. Хатыныннан уңды. Ул унжиде ел эчендә тугыз малай белән бер кыз табып бирде. Кыз үзе генә дә тугыз малайга торырлык иде.

1720 елны Богырысланга барып, Патша хезмәтендә булуымнын вакыты чыкты, егерме биш елым тулды, минем өстән бу йөкләмәне төшерегез, дип гозерен белдерде.

В этом деле мы не уполномочены. Вы и так давно службу не несете, дип жибәрделәр.

1725 елны анасы алтмыш жиде яшендә гүр иясе булды. Шул елны Петр I дә үлгән икән дип хәбәр тараттылар. Әхмәтнәсирнен күз алдына мыегы биеп торган, үтәли карашлы, арыган йөзле һәм биек гәүдәле патша кыяфәте килеп басты. Ул бит Әхмәтнәсирдән барлыгы берничә яшькә генә олырак. Шундый адәмнен үле гәүдәсен күз алдына китерү дә кыен шул. Әхмәтнәсир өчен бу чын-чынлап кайгылы хәбәр булды. «Рәхмәт сезгә! Сез яхшы кеше!» — дигән сүзләренә каршы: «Не скажи, солдат, не скажи...» дигән сонгы сүзләре әле дә анын колагында янгырый.

Ул елларны бу тирәләрдә урыслар ишәйде. Урыны-урыны белән авыллар торгызалар, елга буйларындагы яхшы жирләрне сайлап алып, нигез коралар. Күп кенә урыс гаиләләре күченеп килгәч Богырыслан кинәйде, үсте. Сәүдә юлы өстендә дә урыс авыллары барлыкка килде.

Онытылып беткән хәлләрне искә төшереп, Әхмәтнәсирне тагын Богырысланга чакыртып алдылар. »Почему препятствовал по сбору налогов в казну? По какому праву раздавал земельные угодия?» — дигән шул ук бер сорау иде аларның телендә. Кызганычка каршы, Мәскәүдән алып кайткан язуының мөһер куйган өлеше, тирдән чыланып булса кирәк, төсен югалткан иде, бер кат утырып чыккан шул ук базга ябып куйдылар. Элеккеге түрә ярдәмчесе аша ул Казаннан тикшерергә зур урындагы кеше киләчәген, шуның аркасында элеккеге шикаятьләр буенча чистарыну ниятеннән, аны гаепләп Себер җибәрәчәкләрен белде. Мал-туарын тартып алулары да ихтимал икән.

Дымлы базда ятып бер атна тирәсе вакыт узгач, сорау алырга дип күрәсең, өскә алып менделәр. Бүлмә эчендә хәрби киемнән бер адәм бар иде. Чәчләренә чал ингән, сакал-мыек баскан, хәлсезлектән бөкрәя төшкән зур гәүдәле тоткынны күреп, хәрби урыныннан кутәрелде. Күзләренә туры караган килеш якынаеп, ике кулы белән аның җилкәсеннән тотты.

— Ахмет, это вы?

— Да, Ваш Блгаруди. Ахмет, сын Салимгарай.

— Родной ты мой человек! До чего тебя довели! За что?!

— Не магу знайт, Ваш Блгаруди. Не адин раз инде, шту ты гәвәрәт не панимай.

— Вы что, не узнаете меня? Это я, Егор. Егор Семенович Кропотов! Человек, которого ты спас когда-то! Забыл?

— Зрәем, желаем, Егор! Тәпәришше узнал.

Егор Семенович аны кочып алып урындыкка утыртты. Хәл-әхвәлләрен сорашты. Өстәл өстендәге язуны алып укыды:

— Тут о Вас всякую чушь настряпали. По этим доносам, не только в Сибирь, под расстрел можно угодить!

Әхмәтнәсирнең үз исеменә бирелгән җирләренә башкаларны урнаштырып, үзе башка җирдә яшәп ятуын, берничә баш сыер белән ике-өч аты, унлап баш сарыгы булуын белеп алгач, купкан ярсуын көч-хәл тыеп калды:

— Каналья! Тут пишут, что Вы присвоили госимущество и разбогатели за счет сбора налогов.

Хәрби тикшерүче полполковник (подполковник) Кропотов Егор Семенович, 1726нчы елны, Казаннан Уфага барышлай, Әхмәтнәсирне күрү теләге белән, Богырысланга сугыласы иткән иде. Аның киләсен үзләренчә аңлап, түрә шымчылары Богырыслан түрәләрен алдан кисәтеп өлгерде. Шуның аркасында, чистарыну ниятеннән кадим заманындагы шикаятьне табып, Әхмәтнәсиргә бөтен чүп-чарны өеп, судан коры чыкмакчылар иде. Аларның бу тырышлыгы кире нәтиҗә биреп, Кропотов килеп китүгә бер ай тулмас борын, өстән икенче — тагын да зур тикшерү килеп төште. Түрәләрнең нинди дәрәҗәдә булуларына карамастан, хөкемгә тарттырдылар. Ясак урлап баеган мөлкәтләрен тартып алып урыннарыннан кудылар. Илне алда тагы да зур үзгәрешләр көтә иде. Тагын берничә елдан, 1730 еллар башында, татар-башкорт өлкәләрендә тәртип урнаштыру ниятеннән, урыс патшалыгы йөзен тулысы белән бу якка борды.

1734 елны, югары дәрәҗәдәге Оренбург экспедициясе җибәртелеп, Ор елгасы буенда яңа шәһәргә нигез салынды. Аңа Оренбург дигән исем бирелде. Бөгелмә белән Богырыслан, слободага әйләнеп, шәһәр статусы алды. Бозаулыкта зур ныгытма төзелеп сәүдә юлына надзор куелды. Шул чорны, яңа урам ачып, Әхмәтнәсир балалары Гали авылында нигез кора башлады. Саураш елгасы буендагы җирләр дә шул ук балалар исемендә иде. «Бер үк малдан ала да туа, кола да туа», — дигән борынгылар. Әхмәтнәсирнең

булдыклы балалары арасында бер булдыксызы да булган икән. Минегани исемле кече малай аракы эчеп хатын-кызлар белән буталырга, эшләми генә матур тормышта яшәргә яраткан. Саураш үзәнлегендәге җирләрен бер чирек көмешкә белән бетле тунга сатып җибәргән. Соңгы чиктә шәрә калып, кышкы салкында катып үлгән. «Гани җирләре» дип аталган ул урында чуашлар нигез кора. Хәзерге заманда ул авылның исеме, «Ганкино земли» сүзеннән чыгып, Ганкино авылы исемен йөртә. Араларында Насыйровлар, Манашевлар, Шәвәлиевләр, Ганиевләр, Алтынбаевлар, Фәйзуллиннар, Төхвәтуллиннар, Муллабаевлар, Нәбиуллиннар, Минһаҗевларның барлыгы тарихи хакыйкать.

Гали белән Әхмәтнәсир бабаларыбыз дөнья куйганнан соң, шул ук җир аркасында гауга куба. Карт Йомахуҗа гаиләсе белән үз якларына кире күченеп китәргә мәҗбүр була.

Ил буенча хәер сорашып йөреп, авылга килеп эләккән төрле милләттәге хәерчеләр дә Гали авылында тормыш корып, Ислам динен алды, татарга әйләнде. Ата-бабалардан калган риваятьләр буенча, Гали авылында яшәүчеләргә ундүрт милләт каны кушылган. Кыпчак, кыргыз, башкорт, казах, уйгур, ногай, үзбәк, мишәрләрдән тыш, чуаш, мари, мукшы, хохол, урыс милләтләре каны да бар аларда. Балалары саф татар телендә сөйләшә, кер төшмәс пакъ Ислам динендә. Мәчетләрне җимергән иң авыр елларда да, өч мәхәлләнең икесен саклап калдылар. Әлеге вакытта юк ителгән мәчет урынына таштан яңа гыйбадәт йорты торгызып, искеләрен яңартып, өч мәчетебез гөр килеп эшләп тора. Динен югалтмаган, эшкә оста, уңган халкым яши анда. Ул минем бабам җирләре, туганнарым җире. Кызганычка каршы, мәрхүм атам казанга сыймаган кабырга булып, минем өчен дә яшәү мөмкинлеге калмаганлыктан, туган авылымны калдырып, чит җирләргә китәргә мәҗбүр булдым. Шуңа карамастан, җаным-тәнем, йөрәгем белән мин Туган ягымда. Бу табигый хәлләр. Күпме безнең нәсел кешеләре читят җирләргә китеп нигез корды. Мин әле бәхетле! Борынгы бабаларыбыз яшәгән Татарстан җирендә гомер итәм! Борынгыдан килгән риваятьләр буенча аларның төп чыгышлары Казан өязе, Зөрәй юлы өстендәге Чаллы җирләреннән. Без барыбыз да бер каннан, бер токымнан! Безнең ДНК бер, туганнар!

## Соңгы сүз

Әсәрне укып чыккач: «Өч гасыр элек булып узган хәлләрне автор каян белеп бетергән, әсәрдә хаклык бармы?» — дигән сорау туачак. Бу табигый хәл.

Балачагымнан, атам аша һәм башка олы яшьтәге бабайлардан ишеткән риваятьләргә таянып язылган әдәби әсәр бу. Кышкы озын төннәрдә күрше-тирә, туганнар һәм ыру-кардәшләр очрашып кич утырганда, төрле мажаралар, авылыбыз тарихына кагылышлы хәлләр турында сүз чыга иде. Инәкәй мәрхүмә коймак пешерер иде. Мич башында таратып киптергән көнбагыш чиртеп, башларыннан узган хәлләрне сөйләрләр иде. Ата-бабаларыбыз язмышын, көнкүрешен һәркем үзе белгәнчә, үзе ишеткәнгә таянып фараз кылыр иде. Кемнәр генә килми иде безгә! Шулар арасында Муратов Зәки абый белән хатыны Рәшидә апа, Тархан якларыннан килеп урнашкан Нургали абзыйларның (Таз Нургалие) сөйләгәннәре күңел түрендә уелып калган. Муратов Зәки абый, авыл мәктәбендә завуч булып та, колхоз идарәсендә дә эшләгән белемле һәм бик сабыр, интеллигент кеше иде. Авыл тарихы белән төптән кызыксынган шәхес иде. Хатыны Рәшидә апа, чыгышы белән Тамиян якларыннан, авылыбыз мәктәбендә тарих укытучысы булып эшләде.

Утызынчы еллар тирәсендә, авыл советы бинасы янып, авыл тарихы язмалары юкка чыккан. Шул язмаларны искә төшереп, янасын язалар. Сугыш чорында анысы да юкка чыга. Зәки абый, күп еллар буе эзләнүләр алып барып, ул язмаларның Әсәкәй, Тархан якларына китеп эзе югалуын ачыклый. Бүген кемдә дә булса ул язмалар саклана торгандыр, бәлки бер заман калкып чыгар дигән өмет бар.

Ишетеп белүем буенча, безнең Насыйр бабай, патша хезмәтенә алынып, унбиш ел тирәсе хезмәттә була. Ул чынлап та ялчы анадан туып ятимлектә үсә. Бай хатыны, үз баласын егерме биш елга патша хезмәтенә җибәрәсе килмәгәнлектән, иренә ялчы хатын белән үз баласын таныpга рөхсәт бирә. Шуның аркасында патша хезмәтенә Насыйр бабайны җибәрәләр. Риваятьләр буенча, башкорт атлы гаскәрләре белән ул төрекләргә каршы яу барган. Таза гәүдәле бабам, балачактан кызыксынучан, эшкә яптәш булып үсә. Шифалы үләннәрнең серләрен белә. Кымыз ясау, тире игү һәм уктан ату һөнәрләрен үзләштерә. Кышкы озын төннәрдә хатын-кызлардан да остарак итеп оек бәйли торган була.

Төньяк сугышында катнашып яра ала. Соңгы берничә елын өлкән офицер утарында денщик булып хезмәт итә. Бай малаеның борынына каты кыр тараканы кереп чиргә сабышуы, төрле дәвалаучыларның бу чиргә дөрес диагноз бирә алмый үлем юраулары, бабамның ул баланы үзенчә дәвалап, үлемнән алып калуы, чынлап та, булган хәл. Бу турыда атам сөйләгәннәрнең барысы белән дә әлбәттә килешеп бетә алмыйм. Кызу мунчада берничә көн себерке белән чабып, кайнар һәм салкын сулы лаканнар өстендә каплап торуы хактыр. Шәмнәр дә кабызгандыр. Атам сөйләве буенча, каты таракан суда үз шәүләсен күреп, аталану ниятеннән борыннан сикереп төшкән, имеш. Мона ышана алмыйм. Кайнар пар астында чабынып, кайнар су өстендә томалап тоту нәтиҗәсендә үлеп төшәргә мөмкин. Анысы хаклыкка туры килә. Ничек кенә булмасын, таракан эрен белән төшә. Кышның соңгы аенда, малайны аякка бастырып, Раштуа бәйрәме алдыннан шәһәргә алып кайта. Бәхиллэтү йөзеннән ана ирек бирүләре дә мөмкин. Шуңа ияртеп, җир биләмәләре бирү, күп кенә акча белән обоз торгызып, ун кешедән торган хәрбиләр карамагы астында озату өчен, минемчә, ул гына аз. Һәрхәлдә, бабамның патша хезмәтендә күрсәткән башка төрле гамәлләре дә булган. Бу очракта мин бабам урынына үземне куеп карадым. Аның белән бергә Азов ныгытмасын алуда катнаштым. Шереметьев белән күзгә-күз очрашып, шведлар белән сугышта ныгытмалар алдым.

Өч ел буе ил чигендә хезмәт итү дәверендә, миңа эчке эшләр министры Семичастный белән күзгә-күз очрашырга туры килгән икән, нигә ул патшаның үзе белән очрашмаска тиеш? Петр I дән ул бары өч яшькә генә кече була. Күнеле дөреслектә булган кеше ник әле каушап калырга да, шаулатып җавап бирмәскә тиеш?! Мин үзем шундый идем. Өч ел буе Армия сафларында хезмәт итү чорында ике мәртәбә унбиш көнлек ялга кайтып китү бәхетенә ирештем. Ялагай булмадым, булдыклы идем. Чөнки мин бабам каныннан!

Авылым тарихы турында язу ниятем күптәннән бар иде.

2011 елның гыйнварында авылым мәктәбендә «Галинең асыл затлары» дигән кичәгә чакырып алдылар. Авылдашларыма карата иҗат иткән җырым да бар иде, бик теләп катнаштым. Шул очрашу кичәсендә, «Сохраняя вековые традиции» дигән исем астында, авыл тарихының дүрт йөз еллыгына багышлап чыгарылган китап бүләк иттеләр. Авылым тарихының башлангыч чорына бу китапта барысы бит ярым урын алган. Шуна карамастан, бу язма миңа көчле этәреш бирде. Чаллыга кайту белән

эзләнү эшләре башлап җибәрдем. КамАЗ китапханәләреннән, унҗиденче, унсигезенче гасырны тасвирлаган китаплар яздырып алдым. Янәшәбездә генә булган мәктәп китапханәсеннән, Петр I турында язылган китаплар яздырып алып, уку залында утырып башка китаплар белән танышып чыктым.

Авылым тарихын тасвирлаган автор Гайнанова Лилия ханым белән бәхәскә керү теләгем юк. Ул ханымның бу эшкә күпме көч куйганын, нинди зур хезмәт башкарып чыга алганын аңлыйм һәм, чын күңелдән хөрмәт итәм! Элекке заманда кемнәр язган тарихны диген сорау туа. Күп очракта аны, бүлмә эченә бикләнеп, кешеләрдән ишеткән хәбәрләргә таянып, дьяклар язган. Чыңгыз хан бу очракта елъязмачыны үзе белән ияртеп йөртеп, булып узган хәлләрне яздырган. Шуңа да карамастан, тарихны тулысы белән ачыклап язучы кеше юктыр. Һәр язучы үз фикереннән чыгып, үзе аңлаганча тасвирларга тырышкан. Бер үк чор турында төрле авторлар язган китаплар белән танышырга туры килде. Бер үк хәлне һәркем үзенчә тасвирлаган. Бер уңайдан, кайбер тарихчылар фикере белән килешмичә, үз фикеремне әйтеп узу урынлы булыр дип уйладым.Борис Петрович Шереметьевка карата, патшаның мин-минлеге аркасында кылынган кайбер хаталарны аның өстенә аудару белән килешеп бетмим.

Әсәрдә тасвирланган геройларны үз исемнәре белән атап, шәһәр, ныгытма исемнәре, даталарын ачыклап, тарихка таянып язарга тырыштым.

Кызганычка каршы, әкренләп тамырлар онытылып, аралар өзелеп бара. Узган гасыр башында гына да әле, Әсәкәй, Тархан, Тамиян яклары белән аралашу, кыз бирү, кыз алу йолалары бар иде. Анам ягыннан әбекәйнең чыгышы Әсәкәй Солтанголыннан. Элеккеге заманда йөз-ике йөз чакрым ара, ат җигеп йөрүгә карамастан, зур ара саналмаган. Безнең бабайлар, Бөгелмә, Әлмәт якларына, Сорочинск базарларына кадәр йөргәннәр. Сүземне түгәрәкләп шуны әйтәсем килә, риваятьләргә таянып язылган минем эчке халәтем, күңел җимешем бу. Якынча гына булса да авылым тарихына ачыклык кертү иде теләгем. Тарихны якынрак белгән бабайлар күптән бу дөньяда юк. Мин үзем дә җитмеш яшьлек бабай. Үз сүземне әйтми мин дә китеп барсам, эзләр бөтенләйгә югалачак. Ана телендә белем алмаган хәзерге буын балаларына бу язмалар бәлкем кирәк тә булмас. Тора-бара тормыш үзгәреп үз тәртәсенә керер, халык аңга килер, диген өметтә калам. Җан азыгы булмаган җирдә акчаның, байлыкның бәрәкәте, тормышның кызыгы, яме юк! Бу бит көн кебек ачык хәл, туганнар.

Хәнәфи
Бәдигый

## ВАКЫТНЫҢ ЮК БАШЫ, АЗАГЫ

### Безнең сүзләр

Таралса да татар кыйтгаларга,
Сибелсә дә төрле төбәккә.
Сүзләребез уртак ядкарь булып
Уелганнар һәрбер йөрәккә.

Әллә сезме безнең Туган ил һәм
Ашкынулы хисләр Ватаны?
Әллә сезме безнен барыр юл һәм
Киләчәкнең туар ал таңы?

Тик сез генә безнең чын тарихны
Туры юлдан алып барасыз!
Тик сез генә безнең күңелләрдә
Якты йолдыз булып янасыз!

Энҗе-мәрҗән булып бизәгәнсез
Данлы төрки телнең нигезен!
Ия дигән бер сүзебез иңли
Кыйтгаларны, океан-диңгезен!

Ике йөздән артык барлык илнең
Һәр дүртенчесенә ия син!
Австралиясеннән башлап,
Урагансың Япониясен!

Уйгур, рун, гарәп, латин, кириллда
Тирән уелып калган эзләрең!
Кол Галиләр, Тукай, Җәлил булып
Балкытасың дөнья йөзләрен!

Хәнәфи БӘДИГЫЙ (1941) – *шагыйрь, галим; «Күңел ялкыны», «Яшел чирәм», «Тормыш фасыллары» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Көзге гамь

Зәңгәр күзле күк гөмбәзе
Сокланып карый көзгә.
Алтын-сары ак каеннар
Кулъяулык болгый безгә.

Бар иде минем дә сиңа
Сокланып туймас чаклар.
Мәңге сүнмәс кебек иде
Без кабызган учаклар.

Биек булса да күк йөзе,
Түбәләргә тоташкан.
Көзнең зәңгәр гөмбәзеннән
Моң агыла тоташтан.

Саргылт буранга уралып,
Мин атлыйм көзгә табан.
Синең яшь җилкенчәк күңел
Җәй кочагында һаман.

Җәелсә дә җир өстенә
Томанлы көзге салкын,
Җылыта күңелне синең
Кулъяулыктагы ялкын.

Зәңгәр күзле күк гөмбәзе
Сокланып карый көзгә.
Ак каеннар, җилфердәшеп,
Кулъяулык болгый безгә.

## Юк

Саргаеп коела яфраклар,
Түшәлеп туган җир өстенә.
Кәүсәгә сарылып, әйтте җил:
— Язмыштан берәр зат өстенме?

Бар белән юк булу арасы,
Һәркемгә шул юлдан барасы.
Килгәнне-киткәнне хәтерли
Туган җир һәм адәм баласы.

Вакытның юк башы, азагы,
Мәңгелек битараф һәркемгә.
Яфракмы, тәлгәшме, кәүсәме,
Язмыштан узмыш юк беркемгә.

## Көзге уҗым басулары

*... сизелми дә җиткән көз дисең.*
*Үзең әле һаман кырлар буйлап*
*яшеллеген җәйнең,*
*яшеллеген җәйнең әһлисең.*

М.Галиев.

Хәтерләтә яшьлектәге язны
Көзнең хәтфә уҗым басулары.
Җилфер-җилфер итеп дулкынлана
Онытылган йөрәк ярсулары!

Зәңгәр күзле туган ягым минем,
Керфекләрең—уҗым басулары!
Сүрелмәслек ялкын салган икән
Язның ярсып аккан кар сулары!

Күзләремне тутырып карыйм сиңа,
Туган ягым уҗым басулары!
Күпме карасам да, үткәндәге
Сөю-сагышларым басылмады!

Күзләр саен язлар булып кайта
Яшел хәтфә уҗым басулары.
Хәтерләтә яшьлектәге язны
Онытылмас йөрәк ярсулары.

## Тумыштан

Бу дөньяда мин Ходайдан башка
Беркемгә буйсынмыйм.
Кануннар да Коръән сүзе түгел,
Һич табынмыйм, сынмыйм.

Минем өчен Канун — Коръәндәге
Йөз дә ундүрт сүрә.
Алар Ходай сүзе, кануннардан
Өстен шуңа күрә.

Үз бизмәне белән һәрбер хаким
Яза үз фәрманын.
Дәүләтенең һәм яраннарының
Кушып дәрт-дәрманын.

Тәртип, әдәп өчен кануннарны
Үтим фәкать тыштан.
Аятьләргә җаным-тәнем белән
Буйсынам тумыштан.

## Күңел!

Шигърияттә сүзне авызлыклап,
иярләүчеләрдән түгел.
Гөлбостанда кәрәзгә бал җыеп,
нечкәләнгәннәрдән күңел.
Аратага куып кертеп сүзне,
дагалаучылардан түгел.
Бисмилла әйтеп, сүзгә башны иеп,
догалаучылардан күңел.
Шигырьдәге сүзне тартыштырып,
дошманлаштыручы түгел.
Берсен-берсе аңлап, зурлап, санлап,
туганлаштыручы күңел.
Максатым да язганнарым белән
фәкать шаккатыру түгел.
Үзем мактасам да, башкалардан
Көтмим, өмет итми күңел.
Сүзләремнең хокукларын кысып,
Изеп яшәтүче түгел.
Империя түгел, үзе хуҗа
Ирек, хөрлек сөйгән күңел!



## Фәнзаман Баттал

# ХИКӘЯЛӘР

## Дөньяның асты өскә киләчәк!..

*Бу күңелсез кыйссаны нерв җепселләре нык булмаган кешеләргә, бигрәк тә хатын-кызларга укымаска киңәш итәм.*

Автор

Фатирыма атна саен диярлек кереп чыгарга күнеккән якын танышым Мирза юкка чыкты...

Әйе, әледән-әле килә иде үзем кебек үк кырыгына таба баручы тәбәнәк гәүдәле шушы сазаган буйдак. Һәр килүендә, монсу гына тавыш белән бер җөмләсен кабатламый калмый иде:

— Өйләнер идем дә, парин, хәзерге хатын-кызның тугрылыгына ышанмыйм мин... Типтерәләр алар... Нык аздылар...

Әнкәсенең сүзен дә еш искә төшерә, башлы-күзле булу турында сүз чыккан саен:

— Алай-болай өйләнә калсаң, улым, чибәрлегенә алданма, сакланган кыз тап! — дия икән. — Бөкре булса-булсын, саф кыз булсын, ыштубы!

Туктале, тукта... Әллә соң, берәр саф кыз табып, өйләнеп җибәрде микән?! Булыр-булыр... Андый дусларны да күрмәдем түгел: өйләнгәч үк ахирләреннән качып йөриләр. Дөресрәге, кәләшләрен күрсәтмәскә тырышалар... Көнләшәләр, сабакылар...

Хәер, телефонының нумирын блокнотыма үзе язып куйган иде бит бер килүендә... Яле, чылтыратып карыйк! Нишләп ята микән?

Бер генә түгел, атна буена көндез дә, хәтта төн уртасында да чылтыраткаладым — үзе дә юк, сүзе дә юк... Инде тагын да бер чылтыратып карагач, кулымны селтәдем дә, кәмпүтер яныннан кузгалып, электрон сигаретны тарта-тарта балконда укып утырыйм әле ичмасам дип, электрон китап та алдым кулыма. Бетмәс монда хәбәр дә бирмичә югалып торучы килде-китте дус-ишләр...

Ләкин балкон ишеген ачасы урынга фатир ишеген ачарга тиеш булдым: нәкъ шул мизгелдә ишек кыңгыравы сайрап җибәрде. Барып ачсам, ни күрим,

Фәнзаман БАТТАЛ (1939) – *язучы; «Сакалыңа ут капса...», «Сигезенче оҗмах», «Безнең сурәт» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

ниндидер япун басып тора. Сокура агачы сурәтләре белән бизәлгән күлмәк кигән, муенында иероглифлар белән чуарланган галстук, ә күзләрен, дөресрәге, йөзен чем-кара кысалы, көрән пыялалы зур күзлек каплаган. Өскә күтәрелгән авызы түгәрәк кашык кебек йоп-йомры булып ачылган. Иреннәрен ертырдай булып алга калыккан тешләре ыржаеп тора. Ә үзе кет-кет көлә, чукынмыш. Хәтта чәче дә керпе энәләре кебек тырпаеп тора монын. Япун гына түгел, самурайның үзе бу, мәлгунь!.. Житмәсә, түшенә зур шоколад хәтле смартфон дигән нәрсәкәй асып куйган. Кулындагы дипломатына да япун гербы ясалган. Тфү!

Ишекне гөпелдәтеп ябам гына дигәндә, теге адәм саф татар телендә әйтеп өлгермәсенме!

— Әллә танымыйсыңмы? Мирза бит мин!

Йа, ходавәндә, нинди генә модалар белән саташмый бу замана бәндәләре... Әле яшь булса, бер хәл иде. Әйткәнемчә, ике-өч елдан кырыгына житәчәк бәндә бит инде бу, адәм тәганәсе! Ул аяк савытын сала тора, ә мин кыланчык маймылны күзәткәндәй аңа текәлеп торам...

Залга үтеп, кара-кашы утырышкач, ниләр кылып йөргәнен сөйләп бирде бу. Чыннан да ай буе Япониядә, хәтта Токионың үзендә кунакта булган икән. Шунысы да искә төште кинәт: сөйләгән иде бер, Мәскәүнең Ломоносов университетын тәмамлауга ук пләмәшен, ягъни мәрхүм абыйсының улын бер япун эшмәкәре үзенә ияртеп киткән иде өч-дүрт ел элек, дип. Шунын заводында төрле-төрле электрон аппаратлар ясап яталар икән. Пләмәше, хак булса, шунда баш инженер икән хәзер.

— И малай, ниләр генә уйлап тапмыйлар ул япуннар!..

— Анысын монда ятып та беләбез, — димен тегенә, ис китмәгәндәй. — Менә мин дә яна кәмпүтер алдым. Үзе бер могжиза! Эче тулы электрон! Менә монысы электрон сигарет. Өстәлдә ятучы китабым да — электрон китап. Әнә, үзен дә күрәсен, Казанда да тыкрык саен видеокамералар күзәтеп тора. Ә инде синең пләмәшең укып киткән Мәскәүдә йөз илле меңгә якын икән хәзер андый камералар. Берәр куаклыкка кереп, пес итә башлауга ук полиция дәррәү килеп житә...

Мин берәмтекләп саный, сөйли яки күрсәтә торам, ә ул һәр жөмләмнән соң чыраен чытып һәм, шөпшә кугандай, кулларын селтәштереп, «пүчтәк, пүчтәк, барысы пүчтәк» дип утыра. Нәтиҗәсен дә ясап куйды мин сулыш алган мизгелдә:

— Япуннар өчен бу элекке ачышлары борынгы иске чабаталар инде... Алар хәзер дөньяның астын өскә китерердәй өр-яңа нәрсәләр уйлап тапканнар! Ләкин кайберләрен сер итеп саклыйлар...

Ул арада кухнядагы чәйнүгемнең әче итеп сызгыруы ишетелде. Мирза, шуны гына көткәндәй, дипломатын кулына алып, ача башлады:

— Әйдәле, чәенне эчик. Япун кучтәнәчләре дә бар монда... Алар эчеп кәефләнә торган саке дигән аракы да бар. Фатирың артык жылы, тамак кибә башлады...

Өстәл янына утырыр алдыннан галстугын салды, тары бөртегедәй вак күзәнәкле чылбырга таккан күзлеген колакларыннан ычкындырып, күлмәк кесәсенә шудырды. Өстәлдәге ризыкларга карый-карый чәй йоткалый һәм йоткан саен көлә. Ә карашы, муены борылмый торган кешенекедәй, мина төбәлгән.

Шуннан әйтеп куя бу:

— Шәп типтергәнсен мин киткәч. Шә-әп!!! Әйт-те-лә-әр!.. Мин белгән Сәлимә-Сәкинәләрең, Роза-Венераларың өстенә сары чәчле... нәрсә диләр әле андыйларны... әйе, блондинка диләр... ябь-яшь маржушка да китергәнсен... Исеме Ольга икән, шулаймы?..

Кинәт акылымның — дертләп, гәүдәмнең сискәнеп куюын тойдым.

Нишли бу адәм, ә?! Әйе, Мәскәуский базарда танышкан идем Ольга белән. Ул да өч мәртәбә килде. Ләкин бит ул каранглы төшеп беткәч, урамда кешеләр түгел, этләр дә калмагач килде. Ә бу «сөй-лә-де-ләр» дип утыра... Ольганы бит киткәндә дә күрүче булмады. Ни өчен дигәндә, ирем төнге сменадан кайтуга мин үз ятагымда булырга тиеш, дип, иртүк чыгып китә... Кемнәр сөйләгән булырга мөмкин мона?! Әле бит ул Казаннын аргы читендә яши. Күргән суратттә дә кем танысын аны безнен ишек алдында? Житмәсә, үзенен әйтүенә караганда, бу «самурай» Казанга кичә генә кайтып төшкән...

Акылымны җыеп, нәрсәдер әйтергә теләгән идем Мирзага, кытаклый-кытаклый кабат көлә башлады:

— Карале, Самат, әле кичә генә, шампанскийны йоттырган саен Ольганын авызына тыга-тыга тешләттергән шоколадынныn яртысы калган икән бит!

Валлаhи дип әйтәм, башым уйлаудан туктады сыман. Каян белгән, каян кинодагыдай күреп торган Мирза дигән бу шайтан безнен ниләр кыланганыбызны? Тәрәзәләр дә калын пәрдәләр белән капланган иде бит югыйсә...

Мирзанын элеккечә юаш та, монсу да тавышы керә башлады колакка:

— Үзеннен ирлек куәтенне саграк исраф ит әле син, Самат! Безнен бит әле саф кызларга өйләнеп, балалар үстерәсебез дә бар... Патроннарынны атып бетерергә ашыкма. Безнен чын «революцияләр» алда!

Үземне, урыслар әйтмешли, «подопытный кролик» итеп тоя башлаган идем инде бу татар самурае алдында. Ләкин, аләмчә тавышын ишеткәч, зиhенемнен ачыла баруын тойдым hәм ана:

— Табарсын, бар, эзләп кара саф кызларны! Әле кичә генә гәҗиттән бер хәбәр укыдым. Баксан, аларнын кырык ике проценты мәктәпне тәмамлаганчы ук «мәхәббәт уены» белән гарык булганчы маташа икән... Мирза, көтмәгәндә, тамаша залындагы сыман кул чаба башлады.

— Браво, Самат! Димәк, илле сигез проценты исән! Хәер, урта мәктәпнен сонгы сыйныфын тәмамлап чыгучылар арасында да бардыр сакланып калганнары! Шулар арасыннан сайлыйбыз кәләшләрне!

— Барысын да чишендереп карапмы? — дип, мыскыллы карашымны төбәүгә дә исе китмәде Мирзанын.

Ул кабат кул чапты:

— Күзләренә бер-ике мәртәбә генә карап алабыз, туганым! Барысы да шик калмаслык булып ачыклана. Егетләрнен якасын да иснәп карамаганнарын аерып алабыз да, шул ук авылнын мулласыннан никах укытабыз! Әйе-әйе, авыл мәктәбеннән, чыгарылыш кичәсендә үк сайлыйбыз шәпләрен! Авыл кызлары, барыбер, сакланганрак булырга тиеш.

— Бик ансат икән! — дип, дивана бәндәдәй шаркылдап җибәрүемә Мирзанын күзе тонды, теле тотлыкты. Ә мина сүземне әйтеп бетерү өчен форсат туды. — Алдым, салдым, кайттым киттем, дисен инде, алайса, ә?! Бик ансат икән өйләнү. Ә син ул кызлардан егерме яшькә зуррак икәненне, керпедәй чәченә кырау төшә башлаганын беләсенме сон?

— Пүчтәк ул егерме яшь! Әнә, минем әти-әнидән утыз яшькә өлкәнрәк. Туарга да, үсәргә дә өлгердек, Ходайга шөкер. Алты бала үстек! Кызларнын башы янача эшли хәзер. Казан уртасында өч бүлмәле фатирым бар, ай саен бер атлык, ике сыерлык акча эшлим, дисән, үзләре шундук риза була, ата-аналары ашыга-кабалана хәер-фатиха бирә.

— Шуннан сон инде, яшь хатыным кемнәр белән чуала икән, дип, шикләнеп яшисен генә кала, шулаймы? Мирза, телсез hәм хәлсез калгандай, авызын да, күзен дә ачып, хәсрәткә калган кыяфәт белән мина текәлде дә, кара күзлеген кия-кия:

— Их, Самат, Самат!.. — дигәч, тагын тынып калды. Авыр сулап куйды... Хәтта миңа аның әнә шул сулышы да кайнар сыман тоелды. Ниһаять, салмак кына сүзен дәвам итте. — Мин бит, Самат, беренче җөмләләремне ишетүгә үк башка сораулар бирә башларсың дип уйлаган идем... Ягъни, синең нинди хатыннар белән ничә мәртәбә яткан-торганыңны төгәл әйткәч үк, син миңа: «Боларны каян беләсең?» дип, изүдән эләктереп сорарга тиеш идең, минемчә... Инде хәзер мин сиңа япуннардан алып кайткан гыйлемемне үзем аңлатып бирергә тиеш булам. Иң элек сиңа берничә сорау бирәм. Ләкин син аларга җавап бирмә, минем йөземә генә карап утыр. Әйт әле, үткән җомгада син банкка күпме акча илтеп салдың? Әйтмә, үзем әйтәм... 125000 салдың. Ай ахырына кадәр яшәү өчен күпме калдырдың? Җавап бирмә... 17000 калдырдың. Дәшми тор... Кичә, теге Ольга киткәч, нишләдең? Во, дөрес! «Акчарлак» гәҗитен актаргалап яттың да, шуннан кроссворд табып, чишә башладың... Сүзем бетте! Кайда хата җибәрдем? Әйтеп бирсәң дә ярый хәзер...

— Барысы да дөп-дөрес, — диюдән башка сүз тапмадым. Аптыраудан гаҗиз булып утыра торгач, тормозланып беткән акылымда бер-ике сорау туды:

— Ләкин син аларны каян белдең? Күрәзәчелек һөнәренә өйрәнеп кайттыңмыни?

— Юк, электрониканың өр-яңа ачышы бу! Миңа центильоннан да ким булмаган бихисап электроннар ярдәм итә бу очракта.

— Анысы... синтиллон дигәне... нәрсә була?

— Центильон ул — 1ледән соң алты йөз ноль тезелеп торган сан була. Алар ярдәмендә минем өчен һәр кешенең маңгаенда шырпы кабының күкертле ягы кадәр генә экран ачыла. Менә шуннан мин һәр кешенең уйларын да, серләрен дә, нинди гамәлләр кылганын да кинодагы кебек күреп, ишетеп торам... Ә син?!

Соңгы сүзен әйтүгә үк Мирза шүрәле кытыклагандай эче катып көлә башлады. Үзе көлә, үзе сулыш алган саен нәрсәдер әйтергә тырыша:

— Ә син?! Нәрсә... дидең әле... бая... яшь кызларның ... барысын да чишендереп карыйбызмы дидең... Көлдереп үтерәсең бит, парин. — Аннары әңгәмәдәшем күктән кинәт кенә җиргә сикереп төшкәндәй, сорау бирде:

— Әнә, лампочкаларың балкып яна. Электр чүтчигең бармы?

— Бар, әлбәттә...

— Суны исәпләп бара торган чүтчигең дә бардыр?

— Өч-дүрт ел элек куйдырдым...

— Төгәл үлчиләрме? Күпме киловатт яки ничә кубметр сарыф ителгәннәрен күрсәтеп торган цифрлары әйбәт күренәме?

— Ап-ачык күренеп тора.

— Менә шулай, брат! Хатын-кызларның маңгаенда да шундый ук чүтчикләр бар! Әйтик, кайда барган, нәрсә алган, кемгә ни биргән, бирсә, ни өчен һәм ничек биргән, нәрсәләр күргән — барысын да әнә шул маңгайларындагы экран теркәп бара. Үзеннең дә ишеткәнең булгандыр гыйлем картларның:«Язмышың да, гамәлләрең дә маңгаеңа язылган», дигән сүзләрен. Хак икән ләбаса! Япуннарның өр-яңа ачышлары арасында шундые да бар. Ике иңеңдәге ике фәрештәнең барлык гөнаһ-савапларыңны теркәп баруына да ышанмый булмый хәзер, әфәндем! Кешеләрнең нинди ният белән йөрүенә кадәр белеп була. Менә мин дә телевизор караштырып утырам бит кайчак. Теләсә кайсы ил башлыгының мәкерле уйларын һәм киләчәккә нинди провокацияләр әзерләп ятуын да беләм.

Дөрес сөйләвенә шигем калмаса да, куеныма шүрәле кергәндәй тоелды, кытыкланып көлә башладым.

— Соң, Мирза дустым, андый кеше икәненне белсәләр, бәреп кенә үтерәчәкләр бит сине!

— Ә кем белсен аны?!

— Мина сөйләп утырасын ич! Миндә дә тел бар, минем дә әләкләвем ихтимал, хәтәр оешмага барып...

Мина кушылып, Мирза да көлеп куйды:

— Пажалыста, сөйлә! Акылы ычкынган икән монын дип сары йортка тыгарлар да куярлар — ирешкәнен шул булыр... Чөнки мин үзем дә шулай диячәкмен аларга. Бер әкият сөйләгән идем ул ахмакка, ышанган икән, дип, шаркылдап көләчәкмен. Чөнки мин белгән серне чишәрлек бәндә табылмаячак.

—Туктале, тукта... Бары тик берүзен өчен уйлап тапканнармыни ул хикмәтне?!

— Әйе... Хәзергә ул дүрт кенә кешедә. Берсе — миндә, икенчесе — аны әзерләп чыгаручы завод хуҗасы Ката-Яма дигән капиталистта, өченчесе минем пләмәштә...

Мирза, тотлыккандай, сүзсез калды. Сагайган сыман як-ягына каранды... Аннан соң гына авызы ачылды:

— Дүртенчесе Обамада икән... — дип өстәде ул ярымпышылдап. — Ката-Яма, яна ачыш әзер булуга ук, Америкага барып, ничек, нинди очракларда файдалану ярашлы булыр икән бу галәмәтне, дип кинәшкән анын белән... Тегесе, нәрсә икәнен анлап бетергәч, әйткән мона, әгәр дә яна Хиросима һәм Нагасаки теләмәсәгез, сер итеп саклагыз бу гамәлегезне, ыштубыты, дигән. Чөнки бу нәрсә дөньяга таралса, Жир шарын атом бомбаларына караганда да ныграк жимерәчәк, дөньянын астын-өскә китереп бетерәчәк, жәмәгатьчелекне пыр туздырып, глобаль революциягә илтәчәк, дигән. Ә инде үзенә биргәнен алып калган, бу нәрсә мина демократияне тыйган мәкерле диктаторлар белән сөйләшкән чакта кирәк булыр, дип тә өстәгән... Тагын... заводнын расхутларын, керемнәрен капларлык капиталны тынычлык фондыннан түләттереп торачагына вәгъдә биргән... Өч елга килешү төзегәннәр.

Дөресен әйтим, күнелемә шом йөгерде, хәтта куркыныч булып китте ул текемләп сөйләгәндә. Хәтәр нәрсә эләккән икән бит Мирзага, анлатканы хак булса!.. Шулай да шигемне әйтми кала алмадым.

— Ә син причум монда? Бик серле ул нәмәкәй синен кулга ничек килеп керде? Ин куәтле дәүләт житәкчесе белән тигезләнгәнсен ләбаса! Алланын кашка тәкәсе түгелсендер бит?

— Анысын Ката-Яма үзе бирде. Бу ачышта синен пләмәшнен өлеше галәмәт зур, шуна күрә әткәседәй якын кешесенә бирү гөнаһ булмас, дип тапшырды...

— Барыбер ышандырмый! Синен тузга язмаган фантазиян генә булырга охшый бу, брат!

Учы белән өстәлгә чәпәп, Мирза җәһәт кенә урыныннан кузгалды:

— Сүз боткасы үземне дә туйдырды, тынчу була башлады. Әйдә, урамга чыгыйк әле. Мине озатып жибәрерсен... Озатканчы, хаклыгымны да исбатлармын.

Мин киенә башлагач, тагын көлә башлады сәер дустым:

— Күрше паркта тукталып, берничә хатын-кыз белән сөйләшербез. Бераз гәпләшкәч кенә, шаярган кебек итеп, минем күзлекне алып киярсен. Ләкин минем кулны тотарга онытма. Мангайларындагы экран шул очракта гына ачылачак сина. Экранда күргән саннарны исендә калдырырга тырыш.

Хуш... Әрле-бирле паркта йөрибез... Үзебезгә иш булырдай, хәтта өйләнергә ярардай чәчбикәләр күзлибез. Әнә, житәкләшкән безләргә дә күз салгалап, озын такта эскәмиядә өч чибәркәй көлешеп утыра. Буй-сыннары да кәттә күренә. Затлы «малларга» охшаганнар. Һаман да житәкләшкән

хәлдә шулар янына якынлашабыз. Ә алар, сәер нәрсә күргәндәй, дәррәү чыркылдашып куйдылар:

– Что за чудо! Әй, абый, әллә хатын-кыз тапмадың? Кеше көлдереп, ир башын белән ир житәкләп йөрисең?

Үзебез дә көлешеп-елмаешып, каршыларына килеп бастык.

– Менә, – мәйтәм, – бу япун егетен өйләндерергә исәп. Бик оялчан, безнең телне белми. Ләкин бик тә өйләнергә тели. Саф кыз эзли. Аларда саф кызларга гына өйләнү хуп санала икән.

Тагын да чыркылдашкач, берсе әйтеп куя:

– Әх, ашыкканмын икән... Бер иргә чыгып кайттым шул инде... Икенче ирем булырга ризалашмас микән?

– Качар идем, туйдым бу Россиядән! – дип куя түп-түгәрәк шәрә түшенә алтын тәре таккан иң чибәре, кыска итәгеннән тулышкан ботлары да күренеп һәм ымсындырып торганы. – Минем әле бер кияү дә күргәнем юк.

Өченчесе, карап-карап торды да:

– Бәлки, аның күзе ямьсездер? Күзлеген салсын инде хет. Күзе дә ягымлы булса, үзем чыгам!

Ә миңа шул гына кирәк тә! Шаярган кебек итеп кенә Мирзаның күзлеген салдырып, үзем киям дә, тегеләргә төбәләм. Әстәгъфирулла! Чыннан да, һәркайсының маңгае экранга әйләнде дә куйды бит, әттәгенәсе! Күргәч, телсез кала яздым. Ләкин, Мирза белән килешкәнчә, кабат елмая башладым. Ә Мирзага нәрсә! Без сөйләшкәндә, әледән-әле:

– Худасай!

– Банзай!

– Хатимунди! – кебегрәк япун сүзләрен кычкыргалап вә һәм дә алга чыккан казнасын ыржайткалап, безнең кебек көлгәләп тора бирә...

Чәчбикәләр исә, берсеннән-берсе уздырышып, сорауларга күмә Самат дигән бу бәндәгезне:

– Нәрсә дип әйтә ул?

– Ни дип кычкыра?

– Бигрәк шат бу! Бик байдыр, ахрысы?

Ә мин, шартына китереп, «тәрҗемә итәм»:

– Бигрәк шәп кызлар болар, сокланудан үлеп китәрлек, дип әйтә. Бәлки анлыйсыздыр, «банзай!» дигәне безнеңчә «уррра!» дигәнне аңлата. Кыскасы, тәмам гашыйк булган ул сезгә – безнең Казан кызларына! Ә инде байлыгына килсәк, Токиодагы кәмпүтерләр, телевизорлар заводының хуҗасы ул. Крупный олигарх!

Ә үзем маңгайларындагы саннарны истә калдырырга тырышам. Гелләрем генә паспорт нумирларын хәтерләтә икән бу саннар, берсеннән берсе аерылып-аерылып тезелгәннәр. Мәсәлән, бер генә ир белән торганыныкында – 79 1327, алтын тәре такканында – 717 2018, Мирзаның күзлеген салдыртканында – 11 160...

Хәтерем житмәслеген аңлагач, кесәмнән мобильнигымны чыгарып, теркәп куярга мәҗбүр булдым һәркайсының «арифметикасын», телефон номерлары язгандай кыланып.

Шулчак Мирза кулын кулымнан ычкындырды да, җәт кенә сәгатенә күз төшереп, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кыбырдап куйды.

Үзем дә, бик ашыккан кебек, чәчбикәләр белән сүзне кыскарттым:

– Интернет аша заводында эшләүче меннәрчә кешеләре белән ашыгыч киңәшмә үткәрәсе бар аның! Ярый, очрашкаларбыз әле, – дип, баскан җиремнән кузгалып киттем. Парктан бераз ераклашкач, телефонга теркәлгән баягы саннарны Мирзага күрсәттем. Ягъни, ни-нәрсәләр болар?

Мирза битараф кына әйтеп бирде:

— Беренче цифрлары — типтергән зинахурларының хисабы. Икенче цифрлары — күпме мәртәбә кочакларда вәрәмәч килүләренен саны... Алтын тәре такканының «Досуг» юлында йөргәне болай да сизелгән иде инде мина. Телевизордан үзен дә күргәнсеңдер, андыйларның «хезмәте» турында Медведев үзе сөйләде: «Аларның хезмәтләре колбикәләрнеке кебек авыр. Махсус заведениеләр булдырып, эшләрен законлаштыру кирәк булыр», — диде. Ә син хәзергә шуны гына бел: саф кызларның маңгаенда бары тик нульләр генә тезелеп торырга тиеш! Шундыйларны алып, иманлы балалар үрчетеп, милләтне сафландыра башларга вакыт безгә! Шуны да онытма, быел, Универсиадага ныклап әзерләнү өчен, май аенда ук төгәллиләр икән уку елын. Саф кызлар сайлау ниятенә керү вакыты житә. Әзерлән!

Гажәпләнүемне күргәч, шаян карашын төбәп, сүзен түгәрәкләү җаен карады:

— Аптырама, үзеннән янга килгәләүчеләрнең маңгаен да карарсың әле... Буйдаклыкны ташларга вакыт безгә, Самат!

Шыркылдап алды да, тиз генә саубуллашып, килеп туктаган трамвайга кереп тә утырды.

***

...Фатирыма кайткач, караңгылык тойдым. Бәй, хикмәтле күзлеген салдырып алырга онытткан икән бит, мөртәт! Минем дә башка килмәгән кире бирү, сүз белән мавыгып китеп... Шуна күрә, бераз вакыт үтүгә үк, өенә чылтыраттым:

— Кадерле күзлеген миндә калган икән бит..!

— Калсын, әйдә... Пүчтәк...Миннән башка беркемгә дә кирәге юк аның... Кунакларыңның кулы житмәслек жиргә алып куй. Ял көннәре житкәч, очрашырбыз...

Дөресен әйтим, йокым йокы булмады ул төнне. Башымдагы уйлар, бер-берсенә үрелә барып, әллә нинди куркыныч фаразларга кертте... Хуш, Мирзаның әйтүенә караганда, гали кешеләргә чыкмаган һәм өч ел буе чыкмаячак икән мондый товар. Ләкин табылган ачышның иртәмесонмы дөньяга чыкмый калуы мөмкин түгел. Нәрсә була соң әле бу?! Әгәр дә шушы гыйбрәт дөньяга таралса, әйтик, һәр кеше кулына керсә, миллиардлаган гаиләләр таркалып, җимерелеп бетәчәк, мал-мөлкәт бүлешү, судларга ыргылулар башланачак, миллионлаган ирләр, хатыннар арасында үтереш-суешлар шаукымы кузгалачак. Чөнки гасырлар буе ирләр, хатыннар арасында хыянәтләр булган һәм булачак! Әнә, даны бөтен планетага билгеле булган генералиссимус Суворов та хатын казасы белән жәфаланган. Үзе, жир тигезлегеннән күп чакрымнар өскә күтәрелгән Альп тауларының түбәләре аша үтә-үтә, армиясе белән соклангыч жиңүләр яулаган, империянен данын арттырган. Бер генә сугышта да жиңелмәгән! Ә менә илле килолы хатынын — Варварасын жиңә алмаган. Ул сугышларда йөргән чакта хәләл жефете дистәләрчә ирләр белән зина кылып яткан. Урысларча да әйтсәк, иренә бихисап мөгезләр куеп яшәгән шул Варвара. Нинди ирләр белән бит әле, житмәсә!.. Аларның күбесе Суворовның үз туганнары, кардәшләре, пләмәшләре булганын да тарих теркәп барган. Хатынын аерырга рөхсәт сорап, Әби патшага елый-елый үтенечләр — челобитныйлар язган бөек полководец. Ләкин Патшабикә ризалык бирмәгән, катгый рәвештә тыйган. «Хатыныңны аерсаң, үзеннән — абруен, бөтен армиянен, империянен даны юкка чыгачак, минем дә әфтәритем калмаячак!», дигән. Менә шундый хурлыклар вә мәсхәрәләрне йөрәге аша кичереп яшәве сәламәтлеген дә кыерлап бетергән, үлемен дә тизләткән...

Мирза әйтмешли, кайсыдыр иргә дәрте кызышкан, чыдые хәттин ашкан хатыннар өчен үз иренең кемлеге дә, әфтәрите дә нипачум! Ире полководец кына түгел, король яки император булса да үзе теләгән зинахуры кочагына пушкадан чыккан снаряд шикелле томырылып бара. (Менә шушы «зинахур» сүзе урынына матбугатта «сөяркә» сүзен куллланучы әдипләрнең, журналистларның вә һәм дә мөхәррирләрнең наданлыгына женем котыра: сөяркә дигән тамга ул хатын-кызларга гына хас, ә этлек юлында йөрүче ирләр бары тик «зинахур» дип бәяләнә!) Зинахуры белән әвәрә килгәне фаш ителгәч, нинди җәзага яки бәхетсезлеккә юлыгу ихтималын да уйламый хатын-кыз. Хәер, кайнар экстаз аның акылын соңгы тамчысына хәтле алып бетерә...

Хәтерегездәдер әле, моннан унбиш-уналты еллар элек кенә принцесса Дианаың язмышы турында радиолар, телевизорлар айлар буе шаулап торды. Дөресрәге, аның да башы әйләнгән гарәпләр илендәге эре капиталистның улына гашыйк булгач. Иренә – принц Чарльзга сиздермичә генә яхтада типтергәннәр болар. Хәтта, соңыннан мәгълүм булганча, бер фотограф ятакта ниләр кылануын төшереп алу җаен да тапкан. Хәзер шул фотосурәтне аукционга куйса, йөзләрчә миллион долларларын чыгарып салырга әзер байларның саны-хисабы хәтсез икән. Бер мизгелдә «эләктергән» сурәткә алдагы егермеләп буының елмаеп-көлеп һәм биеп кенә яшәрлек акча керү бәхет түгелмени? Шул гарәп белән башы әйләнгән, шуның өстенә шәрабне дә шактый чөмергән килен, зинахуры, шул зинахурның шоферы белән машинада томырылып җилдерткән хутка, бәрелеп үлгәннәр. Анри Поль дигән шоферлары дә исерек булган шул... Ләкин шунысы ачык: Диананың үлеме дә ләззәтле булган. Теге гарәп кочагында алган рәхәтлеге тәненнән чыгып та өлгермәгән булган. Бәлки, әле ул теге дөньяда да шул ләззәттән изрәп ятадыр... Югыйсә, мәрхүмәкәй, безнең Казандагы меңнәрчә кызлар кебек, Лондонда фатир «снимать» итеп, барлы-юклы акчага балалар бакчасында эшләүче кыз булган ул принцка кияүгә чыкканчы!...

Менә безнең һәркайсыбызның зиһененә бала чактан ук сеңә килгән «Династия русских царей и императоров» кебегрәк кәлимә бар. Ягъни, бу нәселдәге патшалар гелән урыс булганнар. Шушы династиядәге иң беренче патша, ягъни Михаил Федорович тәхеткә утыруга ук яһүдләшә бу нәсел...

Хәер, әз генә сабыр!.. Патшаларның хәл-әхвәлләрен тикшергәнче, үзебезгә күз салыйк. Һәркайсыбыз белгәнчә, һәр ир үзен булдыклы итеп күрсәтергә тырыша бу дөньяда. Әгәр берничә ел хатын белән торып та балалары булмый торса, ирләр хатыннарын хурлый башлый. Имеш, хатыны балага узмый торган зат булып чыккан. Кайберләре, хәләл җефетен аерып, икенчесенә өйләнмәкче... Кайсылары сабырлык күрсәткәндәй: «Ярый инде... бергә тапкан мал-мөлкәтебез дә бар, түшәк үзгәртмичә генә яшәгәнчә яши бирик, чурт с ней», – дип җиффәрә. Әнә, ике-өч ел бергә торып та бала тапмагач, хатынын куып чыгарып, яңасына өйләнде бер дус. Бәй, аерган хатыны, башка иргә чыгып, ел да үтмәстән, миндәр хәтле көмәне белән урамда күренгәли башлады. Әлеге дус белән бергә барганда да ике-өч мәртәбә күзгә чалынды теге, ә инде бераздан тәпи йөри башлаган бер малайны житәкләп йөргәнен дә күрдек. Әлеге дусның исә икенче хатыны да өч-дүрт ел бала таба алмый, мескен... Анларлык кешегә анларлык бит, ә ?!

Аллаһы Тәгалә без фәкыйрьләрне дә, хәтта хәерчеләрне дә мәхәббәт, гыйш-гыйшрәт җәһәтеннән патшалар белән тигез яраткан. Михаил Федоровичны да үзенен гади колы итеп кенә күргән. Ул да, патшалыгындагы иң чибәр чәчбикәгә (хәзергечә әйтсәк, илкүләм конкурс игълан итеп!) өйләнә! Ләкин ул да, минем дус кебек үк, өч-дүрт ел буе «эти» дигән исемнән

мәхрүм яши... Ул да хатынын аерып җибәреп, яна кәләш алып кайта. Һы, монысы да кысыр җефет хәлендә күз көеге булып йөри... Михаилга үз тирәсендәге кардәш-ыругары, затлы саналучы боярлары киңәш бирә:

— Менә, Ваше сиятельство, фәлән-фәлән җирдә Елезар Анзерский дигән изге зат бар икән. Җефетен янында берничә тәүлек кенә шифалы догаларын укып утырса һәм һәйбәтләп өшкерсә, дәва таба һәм сразы көмәнлегә әйләнә икән! Әллә соң шуны эзләп табыйкмы?

Табып китерәләр мона әлеге чибәр дә, Сабантуй батырыдай таза, көр күнелле Елезарны. Яшь айгыр кебек ялт итеп тора бу, кешнәве генә ишетелми. Түләнәчәк бәя, биреләчәк бүләкләр хакында килешенгәч, кертеп җибәрәләр моны патша бикәченен «покои» дигән бүлмәсенә....

Әйе, кереп китә Елезар Анзерский патшабикә бүлмәсенә, иң шәп, иң изге догаларын укый һәм, бөтен сәләтен җигеп, атналар буе армый-талмый өшкерә. Күрәмсен, җиренә җиткереп өшкергәндер — патша сараенын барлык бәндәләре сокланырлык могҗизага ирешә Елезар: беренче атнада ук Михаил бичәсенен йөзләре нурлана, күзләрендә бәхет очкыннары җемелди. Ике ай да үтми, балага узуы бөтен илгә игълан ителә! Тик менә үгет биргән боярлар, борыннарын җиннәренә тыгып, астыртын гына елмаешып йөрү гадәтлегә әйләнәләр...

Юк шул, булмаган шул Михаил Федорвич заманында Мирзада булган үтәли күрү сәләте. Хатынынын мангаендагы чүтчигенә бер генә карап алса да ап-ачык күргән булыр иде Елезарнын ничек өшкергәнлеген. Бәлки хурлыгыннан асылынып үлгән дә булыр иде.

Хурлыктан үлүчеләр дә күп бу дөньяда. Мәсәлән, шундый хәл сөйләделәр мина: яшьли өйләнешкән ир белән хатынның бер-бер артлы җиде уллары туып-үскән. Алтысы сокланып, горурланып туймаслык гөрнадирдай каракучкыл егетләр! Ә берәүсе зәгыйфь, акылы да юк. Кара бөркетләр арасында сары чебеш кебек, бәләкәй гәүдәсен көч-хәл белән генә сөйрәп йөри икән мескен. Ә зур урында түрә булып эшләүче аталары бу чирләшкәнен үзенеке булуына шикләнә. Хәйлә кора да ата кеше, хәтәр авыруга дучар булган сыман, түшәккә егыла һәм хәләл җефетенә:

— Әҗәл килде мина, хатын! Ләкин үлеп киткәнче бер хакыйкатьне беләсем килә... Менә бу зәгыйфь баланың кемнән икәнен әйт. Дөп-дөресен сөйлә, гөнаһ җыеп калма, — ди.

Инде сулышлары да кыскарып беткән иренә елый-елый карап утырган да хатыны:

— Ярый инде, алайса, дөресен әйтәм... Ул зәгыйфе — синнән, башкалары — сантехник Хәтмулладан, — дигән.

Шул хакыйкатьне ишетүгә сары чәчле ата үзе дә сау-сәламәт хәлдә җан биргән...

Кызганыч. Ләкин күпчелек хатыннар өчен кызык өчен сөйләрлек вакыйга гына. Әнә бит, күп балалы бичәләрнең берсе:

— Кеше күнелен күрәм дип яши торгач, үз иремнән бала да таба алмадым, — дип көлгән.

Шулай ул, мәхәббәт, хыянәт, азгынлык дәрәҗәгә карап тормый. Әнә, исеме бөтен дөньяга мәгълүм бөек пролетар шагыйрь Владимир Маяковский да мондый эчтәлектәге шигырь язып калдырган: «Кочагымдагы хатын министр хатыны булса да, уборщица булса да, минем өчен барыбер! Буржуаз Европага үч итеп коммунистлар үрчетүем хак булсын!»

Димәк, мин министр яки генераль директор дип масайсан да, шуны бел: хатынынны урам себерүчедән — дворниктан да балалар үрчетеп, үстереп ятуы гаҗәп түгел син тапкан миллион долларларга.

Дворник дигәннән, бер попның дворник вазыйфасын да башкаручы

батрагы ихатадагы юлны себергәндә, себеркесен унга селтәгәндә дә, сулга селтәгәндә дә: «И так хорошо! И так хорошо!» дип бертуктаусыз сөйләнеп бара икән. Еллар буе тынлап йөргән хуҗасы, ягъни побы:

— Менә син, Иван, ул сүзләренне теленнән төшермисен. Әйт әле, нәрсәләр куандыра сине шул кадәр? — дип сораган.

— Әйтмим, — дигән батрак. — Әйтсәм, эштән куачаксын.

Поп, чукына-чукына, «ей Богу, кумыйм!» дия-дия ант иткәч кенә серен чишкән батрак.

— Менә син, атакай, мин күрмәгәндә хатыным белән шаярасын һәм аңа акча да бирәсен бит, әйеме? Ә син чиркәүдә чакта анакай мине ятагыгызга чакыра. Үзен уйнаткан саен ул да мина акча бирә. Шулай булгач, болай да хорошо, тегеләй дә хорошо була бит инде. Чөнки акчага туя яшибез! Сездә — минем улым, бездә синен кызын үсә. Димәк, без инде туганлашып беттек! Монысы инде сәпсим хорошо!!! — дигән.

Һай, бу Мирзаны! Валлаһи, дип әйтәм, бәреп кенә үтерәсе бар аны. Әнә бит, япуннардан нәрсә алып кайткан, яптырмалахай! Анда гына булса бер хәл иде әле центильон электронлы ул нәмәкәй. Өч ел үткәч, бөтен дөньяга таратулары, ягъни бихисап кешеләргә сатулары бар бит ул зәхмәтне япуннарнын. Ул чакта инде ким дигәндә уйнаштан табылган миллиардларча балалар, урамнарга куып чыгарылып, төркем-төркем хәер сорашып, тилмереп йөриячәк. Ләкин ризык таба алмаячак. Ни өчен дисәгез, андый чакта кешеләрдә ашлык үстерү кайгысы бетәчәк. Алай гына да булмаячак әле. Ирләренә хыянәт иткән хатыннарны да горур ирләр өйдән себереп чыгарачак. Мондый ук зур афәттән Жир шарынын асты өскә генә килеп калса бер хәл. Әле бит анын экватор дигән кабыргасына ятып тәгәри башлавы да ихтимал бөтен Галәм буйлап!.. Әгәр дә инде хатын-кызлар кулына да эләксә чүтчикләр карый торган ул галәмәт, дөнья бетте дигән сүз!... Ник дисән, үзләре типтерергә яратсалар да, ирләренен башка бичәләр кочагында ятуларын йөрәкләренә сыйдыра алмыйлар. Миллионнарча йөрәкләр шартлаячак! Йөрәкләре шартламый калганнары йоклап яткан ирләрен суячаклар. Кан дәрьялары Жир шарын басачак, шул кан эчендә мәетләр агачак. Мондый ук коточкыч хәлне күргәч, хыянәт итмәгән сирәк-мирәк кенә адәмнәр дә куркудан кырылачак. Ка-аш-ма-ар!!!

Ирләр арасында да суешлар хәттин ашачак. Күп ирләр, чит хатыннарга ясаган балаларынын куылып чыгарылганлыгын белгәч, теге хатыннарнын никахлы ирләрен якаларыннан элеп алып:

— Ник минем баламны куып чыгардын, ысбулыч! — дип, сүзен пычак белән дәвам итәчәк... Кы-ххх! и вәссәлам...

Кыскасы, Мирзанын сөйләве хак булса, Обама дөрес бәяләгән япуннарнын бу яна ачышын: планетадагы барлык атом бомбаларын дөньяга сипсән дә бу кадәр үк фаҗигаләр тумаячак.

Чын кыямәт көтә безне, җәмәгать, ан булыгыз!

...Ә бит, төбенә төшеп уйлана белсән, дөньяны җәһәннәмгә әйләндерәчәк бу фаҗигаләрнен бер генә сәбәбе бар: адәм балаларынын үз нәфесләрен тыя алмаулары һәм шул нәфес коткысына бирелеп, шыпырт кына чит кочакларда әвәрә килә-килә ләззәт өстенә ләззәт җыясы килүләре... Бөтенләй пүчтәк сыман. Ләкин, әнә, шул ләззәтләр аркасында туган миллиардларча фальш балалар — гомумән, барлык кешелек — җан ачысы белән газапланып, каберләргә күчәчәк...

***

Атна ахырында килеп кергән Мирзага, беренче эш итеп, күзлеген тоттырдым.

— Ал бу зарарлы нәрсәнне. Йокымны качырды, йончып беттем...

Ә ул, ашыкмый гына күзлеген сөртә-сөртә, сөйләнә башлады:

— Бик файдалы булачак ул сина да, мина да... Ярый, менә мин катлаулы кәмпүтерләрне көйләү, төзәтү белән көн итүче бәндә генә... Ә син бит адвокат! Судларда бик күп кешеләрнен язмышын хәл итәсен. Бәлки әле ялгышып һәм чын хакыйкатьне белми калып, гөнаһлы да буласыңдыр. Кулыбызда мондый мөмкинлек бар чакта син бер чакта да ялгышмаячаксын. Судьяларнын һәм прокурорларнын да, син якларга тиешле кешеләрне судка биргән кемсәләрнен дә уй-гөнаһларын, кылган гамәлләрен күзгедән күреп торгандай дөп-дөрес итеп белеп торачаксын. Хәтта үзен яклаячак кешен дә бер кабахәт жулик яки аферисттыр... Һәрхәлдә, отучы булачаксын. Анын өчен, парктагыча, бер-ике минут минем белән контактта булуын да житәчәк. Шаһит рәвешендә барып утыруымнан беркем дә тыймас... Галеллегең белән жинүче булып, атаклы адвокат булып танылачаксын!

Күзлеген киеп һәм күзләремә карап алгач, кайгыга калгандай булды Мирза:

— Һы, кәнишне, бу кадәр әллә нәрсәләр уйлап яткач, саташуын да ихтимал!... Экваторына ятып тәгәрәүче Жир шары да күренә ләбаса карашыннан... Син бит лирик шигырьче түгел... Юрист!

Аннары, бу дөньяга күнел ачар өчен генә туган адәм сыман кеткелдәп куйды.

— Житди уйлар белән баш катырып утырмыйк әле, өйләнү темасын янартып жибәрик!

Шушы сүзләреннән сон гына игътибар иттем өс-башына, чырай-кыяфәтенә: ну киенә дә белә инде шомлык! Башында алтын жепләр белән чигелгән затлы түбәтәй, өстендә елкылдап торган өр-яна кәчтүм, ап-ак күлмәге, гүя, бөгелүне-жыерылуны белми торган ак калайдан ясалган... «Самурай» кыяфәтенен әсәре дә калмаган. Хет хәзер үк туй түренә кияү итеп утыртырлык! Борынны иркәли торган хушбуй да сөрткән житмәсә...

— Күңеленне ачып жибәр, брат! Үзем дә өйләнәм, сине дә өйләндерәм Мүкләк сыер хәлендә яшәүне туктатыйк! Әйткәнемчә, саф кызлардан туган балалар үрчетеп сафландырырбыз бу пычрак, каһәрле дөньяны.

Көлештек, елмаештык, билгеле... Ләкин күп уйландырган, жәфалаган бер соравым башымнан чыгып бетмәде...

— Менә бу синдәге үтәли күрсәткечне дөньяга сатмый калмаслар... Хатын-кызлар да куллана башлаячак бит аны. Ин куркыныч мәхшәр шуннан башланачак...

Мирза исә, тузга язмаган нәрсә ишеткәндәй кистереп карады да, татарча сүз таба алмагандай, учынын кыры белән һаваны ярды.

— Анысы — исключено! Уйлап та таба алмаячаклар! Чөнки хатын-кыз күзәнәкләре нык аерылып тора безнекеннән.

— Сон... без дә гөнаһсыз түгел бит инде ...

— Ә синен, нииндидер хикмәт белән, чит-ятлардан балага узып, өендә шул баланы тудырып, хатыны кулына үзенеке итеп тоттырган ирне күргәнен бармы?!

Ана жавап бирерлек, бәхәс куертырлык бер сүз дә таба алмадым...

### Суялар гына...

И, бирсә-бирә, кавыштырыйм дисә кавыштыра Ходай холык-фигыльләре тач бертөсле булган бәндәләрен! Гыйбрәт алыйм дисәгез, әнә, Мәхмүт белән Миләүшәгә генә карагыз. Монысы да көнче, тегесе дә. Сүзне нәрсәдән генә башласалар да , ике-өч жөмләдән сон инде шуна — көнчелек галәмәтләренә килеп терәләләр...

Бүген дә, йокыдан торып аякка басуга ук, талаш башланды. Мәхмүте:

— Район үзәгенә барып, коймалык такталар кайгыртып кайтасы бар әле... — дип авыз гына ачып өлгергән иде, Миләүшәсе шундук кабынып китте:

— Бар инде, бар!.. Көтәләрдер! Бер-икесен генә булса да кайгыртып, хәстәрен күреп кайтырсың. Дәфтәрләрен әфтәрләрсен... Бер атна булмадың бит инде. Сагына торгач, саргая башлаганнардыр...

— Син мине үзен белән чагыштырма, яме! — диде йодрыгы шундук йомарланып өлгергән Мәхмүт! — Син үзен ул дәфтәр белән хәстәрләнеп йөрүче! Исәп-хисапларыңны бер дәфтәргә җыештырасың да, сводкаларны биреп кайтырга вакыт, дип, атна саен шунда олагасың! Бар инде, бар, биреп кайт... дәфтәренне. Өстәлендә утыручы кәмпүтердә электронный адреска хәтле бар югыйсә. Шуннан гына җибәрсәң, бер секундта барып җитәсе сводкаларың. Ә синен үзеннең биреп кайтасың килә...

Мондый чакларында тәрәзә пыялалары чатнардай булып зыңлый башлый. Көнчелектән талашканнарын бөтен авыл белә, ишетә, бөтен халык көлә. Әмма кайсысының кемнәр белән «йөрүен, сөйрәлүен» беркем дә белми. Һы, яшереп кара син авылда үзеннең кыңгыр эшләреңне! Алган сулышыңа кадәр ишетәләр, аякларыңның кай якка кыяклыйсына хәтле чамалап торалар... Берәр ярамаган эшеңне сизсәләр, нәтиҗәсен дә тиз чыгаралар, хәбәре дә яшен тизлегедәй таралып өлгерә. Район үзәге дидек... Анда да шушы Дию авылыннан чыккан йөзләрчә кеше яши. Кайсы тишеккә кереп, кайсы ишектән чыгуына кадәр телефоннан шылтыратып торалар...

Талашны дәвам итәргә сүз дә таба алмый башлагач, кайнар канлы Мәхмүт, сикереп торды да, капка төбендәге эскәмиягә чыгып утырды. Тәмәкесен дә кабызып өлгермәде, аягына басардай булып, каршысына затлы машина килеп туктады. Ул арада тәрәзәсенең кара-тонык пыяласы да ачылып китте.

— Бәй, Мәхмүт түгелме соң син?...

Руль артындагы иргә күз ташлап алуга ук, Мәхмүт үзе дә урыныннан калкынды:

— Һә-һә! Сәфәр бит бу!.. Күпме гомерләр үткәч бит, ә?..

— Унбиш ел үткәч... — диде дә Сәфәргали, Мәхмүтне кочаклап алды.

— Нинди йомышлар белән йөрү?

— Бер йомыш та юк, дустым. Әткәй мина исемне дөрес биргән. Бик ерак сәфәрдән кайтып килеш. Атна буе Кавказ якларында, кардәш-ырулар янында йөреп кайтыш... Үтеп барам — син утырасың!.. Шуңа тукталдым. Хәл белешеп үтми килешми бит. Дус яшәдек, бергә йөрдек бит техникумда укыганда.

Әйе, шулай бергә укыган иделәр алар заманында. Мәхмүт — агроном, үзеннән олырак Сәфәргали зоотехник булып кайтып киткәннәр иде техникумнан.

Хатынының ачык тәрәзәдән күреп, тыңлап торуын сырты белән сизгән Мәхмүт, авызын тәрәзә тарафына борып алды:

— Миләй! Кунак бар, чәй куй! Ә син, Сәфәр, болай гына узып китә алмыйсын инде, ахири. Чәй йоткалап булса да сөйләшеп утырыйк.

Бер уйласаң, Миләүшәсе бик өлгер хатын инде. Мәхмүтнең әйтүе булды, өстәлгә әллә нинди ризыклар чыгып кунды. Нинди генә кунак пәйда булса да, йөзгә кызыллык китерердәй түгел ул. Иң әүвәл Сәфәрне сөйләттеләр: ул якларда халык ничек яши, ничек көн күрә?

— Ничек дип инде... Безнең кебек үк, иртән кузгалуга ук, алар да дөнья куа. Ирләре төзелеш, ягъни йорт-кураны ныгыту белән мәшгуль, уллары, оныкларын да дөнья көтәргә өйрәтәләр. Караңгыга кадәр эшлиләр дә эшлиләр. Анда бит җимеш бакчалары күп. Хатыннары да көне буе шул бакчаларны кайгырталар. Урамда йөргәннәре дә күренми андагы хатын-кызларның...

— Алай аеры эшләгәч, көн буена тормыш кайгырткач, ул ирләрнең хатыннары белән талашырга вакытлары да калмыйдыр инде... — дип сүз кыстырды Миләүшә, иренә күз төшереп алганнан соң.

— Нинди талаш ул?! — дип кытыкланып көлә башлаган Сәфәргә Мәхмүт тә, Миләүшә дә гаҗәпсенеп куйдылар. — Анда ир белән хатын арасында талаш була да алмый ул! Аларда бер-берсенә тавыш күтәреп эндәшү дә юк!

— Юктыр, алар да фәрештә түгелдер... Әйтик, менә, хатыны иренең күңеленә ятмый торганрак сүз ычкындырса, ир нәрсә дә булса әйтми калмыйдыр бит инде?

— Бер сүз дә әйтми! — дип кистерде кунак Мәхмүткә. — Ирлегемә тап төшәр дип курка! Ояла!

— Ир башы белән ләм-мим булып каламыни инде ул? Телевизордан да күреп торганыбызча, бик кайнар холыклы халык бит анда. Хатыннарына салып та җибәрәләрдер әле...

Сәфәр исә һаман көлә:

— Ачуы килгән чакта да сукмый анда ирләр хатыннарына. Ул хакта уйлый да алмыйлар алар.

— Ничек инде, ничек?! Хатыны суынган аш куйса да, ятышсыз сүз әйтсә дә шым булып, шуна түзеп яшиләрмени ул батыр ирләр?! — дип, соравын куәтләргә кереште үртәлә башлаган Мәхмүт. — Фәнни тел белән әйтсәк, бернинди реакция дә сиздермиләр булып чыгамыни инде? Ышанмыйм!

— Ник сиздермәсеннәр... Сиздерәләр! Әле ничек ке-е-нә-ә!

— Ту-ты! Шулай диген син! Менә хәзер әйт инде, сабакташ: ничек итеп сиздерәләр?

— Сез бит инде ул яктагы халыкларның озын да, сырлы-мырлы борынлы икәнен дә беләсез. Әйтик, чиркәсләрдә дә, карачәйләрдә дә, чеченнәрдә дә шундый борыннар...

— Причум монда борын? Борыннары белән сукмыйлардыр бит инде, алай-болай, хатыннарына?

— Борыннары белән сукмыйлар, билгеле.

— Шулай булгач, ничек җәза бирәләр?

— Ачулары килсә, шул озын борыннарын тартып куялар. Чыш-ш-т иттереп!

— Ә аннан ни файда?

— Файдасы бик зур! Хатыннары гомер буе ялгыш сүз әйтүдән сакланалар. Бер көн килеп, иренең тамак кырып куюы да бар бит әле! Шуннан сагаялар! Тамак кырса ире, бу инде хатынның гаебе хәттин ашкан дигән сүз. Андый чакта хатын кая керергә дә тишек табалмагандай өтәләнә.

— Нинди гаебен тапса тамак кыра соң ул хатынына? — дип сорый беренче мәртәбә генә күргән кунакка иярләшә башлаган Миләүшә.

— Гаебе зур, бик зур була андый чакта хатынының. Әйтик, кайсыдыр уллары, әтисе ерактан кайтып кергәч, яки бабасын күргәч баш иеп исәнләшмәсә...

— Туктале, тукта! Юньләп исәнләшмәсә, уллары гаепле була бит инде?

— Юк, анда алай фикер йөртмиләр! Атасына, бабасына, гомумән, өлкәннәргә карата хөрмәт тәрбияләүне, әйе... тәрбияне күбрәк гомерен өй тирәсендә үткәрүче ана бирергә тиеш дип саныйлар.

— Әнә, күрдеңме?! — дип куйды хатынының күзенә өтәрдәй карашын текәгән Мәхмүт. — Ә безнең малай нәрсә дип кычкырды беркөн миңа, ә?! Исенә төшер әле!

Ләкин кунак Миләүшәгә уйларлык та вакыт калдырмыйча, көлә-көлә кабат телгә килде.

— Менә син, Мәхмүт, хатыныңа көйдерердәй итеп текәлеп карап куйдың бит әле, әйеме? Мондый караш хатынга карата үтә рәхимсезлек дип санала чиркәсләрдә. Бик сирәк вакытта гына шулай карый алар. Хатын-кызның йөрәге ярылуы мөмкин икән.

— Ә хатын шулай караса, мин нишләргә тиеш булам инде?

— Анда бит хатыннар ирләренә алай карый алмый. Гореф-гадәтләрен изге итеп саклый алар...

— Ә менә ирләре өсләреннән йөрсәләр, нишләргә тиеш ул хатыннар? Каты күз белән карарга да хаклары юкмы? — дип, кылт кына сүз кыстырды Миләүшә.

— Карарга хаклары бардыр. Ләкин карамыйлар. Чөнки ирләре хатыннары өстеннән йөрми. Инде дә зур гаиләне дә тулаем тәэмин итәренә ышана икән ир, икенче, өченче, хәтта дүртенче тапкыр да өйләнергә мужыт. Никахлашып, шәригать законнарына туры китереп, әлбәттә.

— Менә минем Мәхмүт йөри өстемнән, башка ирләрнеке дә сизелә. Кавказлыларның да нәфесләре бардыр инде. Әнә, шул ук Кавказдан шабашкага килгән әрмәннәрнең типтерүен күп сөйлиләр. Хак түгел микәнни? — дип чираттагы соравын бирде бәхәскә керә башлавын сизми дә калган Миләүшә.

— Монда бит мин шәригать белән яшәүчеләр турында гына сөйләп утырам. Ә алар йөрми. Хурлыкка калудан да бик куркалар. Ни өчен дисәгез, һәр авылның, һәр шәһәрнең уртасында җәза мәйданы бар.

— Асып куяларммы шунда?

— Асмыйлар да, атмыйлар да. Бөтен халыкны җыеп, аракы эчкән яки хатынына хыянәт иткән ирне, трусиктан гына калырлык итеп чишендерәләр дә, бик зур өстәлгә сузып салып, сыек чыбык, таяк белән яралар дуслары. Тәннәре чиләнеп, чи иткә әйләнеп, канга батканчы чиратлашып тетәләр икән. Хәер, андый хәлләр егерме елга дүрт мәртәбә генә булган. Икесе эчкән, икесе хатынына хыянәт иткән.

— Менә-менә, ишеттеңме, Мәхмүт. Безнең якта да шундый җәза мәйданы булса, адәм хуры итеп бөтен халык алдында ярырлар иде сине, бөтен халык алдында рисвай итеп! Иллә дә мәгәр койрыгыңны кыскартырлар иде, ә?!.

Мәхмүте исә, аның сүзенә колак та салмагандай, кунакка таба тартылды:

— Ху-уш-ш-ш, сабакташ-ш, инде минем сорауга да җавап бир-р!.. Әгәр дә кайсыдыр ирнең хатыны башка ирләр, ягъни зинахурлар белән чуалса, нишләтәләр анда? Аны да бөтен халык алдында шәрә килеш чыбык белән яраларммы?

— Юк, Алла сакласын, ярмыйлар. Чөнки хатын-кызның тәне гаурәт дип санала. Аңа чит ирләр күзе төшәргә тиеш түгел.

— Шулай булгач, кыйнап кына иманга кертәләрмени?

— Һәй, юк-бар сорау бирмә инде, сабакташ... — диде, тора-бара бу ир белән хатынның ничек яшәүләрен, бер-берсеннән көнләшеп гомер үткәрүләрен тәмам аңлап бетерә язган Сәфәр. — Хатын-кызны кыйнау түгел, аңа сукмыйлар да, туганкай... Ирләр өчен хурлык ул хатын кыйнау. Андый ирне кешегә дә санамыйлар анда...

Кыза башлаган, чыдые тәмам бетә барган Мәхмүт, чәүчәләкләнеп, урында кыбырсынып куйды.

— Ничек була соң инде ул, дустым?! Сүгәләр дә аералар гынамы?

— Юк, сукмиләр дә... Тел чайкап тормый анда ирләр хатын-кыз белән...

— Шул килеш кенә, җилкәсеннән сөеп кенә аералар булып чыга инде, алайсаң, ә!..

Сәфәр исә, сүзне бөтенләй икенче якка борды да куйды:

– И чәйләрегез бигрәк тәмле икән. Балыгыз да шәп. Юлда ук тамагым бик кипкән иде, артыграк эчеп ташлаганмын. Тышта көйрәтеп керим әле бер, – ди-ди, урыныннан кузгалды. Ул чыгып китүгә үк Миләүшә иренен колагына тукырга кереште:

– Ә си-ин?! Бер дә гөнаһсызга күпме суктың миңа? Яле, әйт, аяктан екканчы кыйнаганың ничә мәртәбә булды?

– Син үзең чиркәс яки чечен хатыннары кебекме? Бернәрсә дә белмәгән көе күз ертып нахакка кычкыруларың аз булдымы көнләшүдән?

– Әнә, әйтте бит Сәфәр, хәтта хатыннарының йөрүен белгәч тә кыйнамыйлар да, сукмыйлар да икән чиркәсләр, чичиннәр...

– Ничауа, керсен әле кунак, тамырына төшәм мин аның хәзер...

Өйалды идәннәрен бөгә-сыга атлап кергән тавыш ишетелгәч кенә шым булдылар. Ә Сәфәр, кулларын ишек катындагы кулъюгычта юа-юа, ягымлы елмаеп һәм шаярткандай итеп, Миләүшәдән сорап куйды:

– Менә син, сеңлем, минем сабакташның өстеннән йөрүен әйттең. Ниндирәк хатын янына бара инде ул? Исеме ничек? Синнән дә затлыракмы?

– Һе, сиздерәмени ул кая барганын! Бик елгыр бәндә бит ул.

– Ну бит инде һичьюгы бер мәртәбә булса да тотkансыңдыр чит хатын белән? Бөтенләй булмаганны сөйләмисеңдер бит?

– Хәйләкәр ул. Тоттыра торганнардан түгел...

– Шулай булгач, Миләүшәкәй, минем яшьлек дустымны гаепләмә. Кавказда бит ирләргә дә, хатыннарга да бары тик бөтен гаепләре ачыкланып беткәч кенә, күп шаһитларны тыңлагач кына каттый җәза бирәләр. Ә нахак сүз үзе җинаять санала. Менә Мәхмүт дустым да синнән шикләнә сыман. Сорауларыннан шул сизелә...

Әле соңгы сорауларына җавап та ишетмәгән Мәхмүт исә, ачуы чыга башлаганын да яшереп тормастан, үзе һөҗүмгә күчте:

– Менә син, Сәфәргали дус, мине бөтен халык алдында чыбык белән ярдырдың. Әйе-әйе, фаразан диикме, имеш, дип әйтикме, ми-нем ке-бек йөргәннәрнең бик каты җәзага тартылуларын сөйләп, хатынның күңелен күтәрдең. Ә инде ир өстеннән йөргәннәрне кыйнау да, сугу да юк икән анда... Чынлап сөйлисеңме моны?

– Һич алдамыйм.

– Димәк, аерып кына җибәрәләр, әйеме?

– Аермыйлар да...

Тәкате калмаган Мәхмүт өстәл сукканын үзе дә сизми калды:

– Йә инде, тилмертмичә генә төгәл бер сүз әйт, ниһаять: ниндирәк җәзалар бирә соң ире нәселен хур иткән, нәселен бозган хатыннарга. Андыйлар да бар бит дөньяда!..

– Җәзалап маташмыйлар аларны, дустым... Суялар гына...

Миләүшә, күлмәгенә ут капканлай, сискәнеп куйды:

– Нич-чек?!

– Кәҗә яки сарык суйган кебек! Чалып кына ташлыйлар...

Шулчак ир, җәт кенә борылып, карашы белән хатынына каталды. Дерт итеп куйган хатыны исә, өстәлдә яткан ипи пычагын күрүгә үк, шыр ачык тәрәзәгә күз төшереп алды. Бу хәлне күреп тә күрмәмешкә сабышкан Сәфәргали, берни булмагандай, тыныч кына сөйләвен дәвам итте:

– Әйе, суялар гына... Ләкин ризык кисә, ит турый торган үтәр-үтмәс, вак-төяк пычак белән суймыйлар. Гөнаһ санала чөнки... Аның өчен аерым пычаклары була. Анысын, озынлыгы да ярты метр чамалысын, һәйбәтләп үткенләп, башка пычаклар тезелгән кыстыргычтан өстәрәк торган махсус кыстыргычка куялар. Хатыны көн саен күреп торсын өчен...

Шулчак Миләүшә үз авызыннан моңа кадәр берчакта да чыкмаган сүзне әйткәнен сизми дә калды:

– Әстәгъфирулла! – Аннары гына кунакка тилмереп карады. – Ни сөйлисең син, Сәфәргали абый?! Тузга язмаганны... Ул пычакны көн дә күргән хатыннарының йөрәге ярыладыр бит! Булмасны сөйләп утырма инде...

– Ник булмасын... Үткән гасырларда безнең халыкта да булган андый пычаклар. Яулыклы җефет андый пычакка хөрмәт белән караган, шуңа карап иренә кадерле булуын аңлап куанган, иренең яр бирмәс ир булуы белән горурланган! Чөнки һәр хатын иренә хыянәт итмәячәген, бу пычакның гомер буена хәрәкәткә килмәячәген яхшы белә. Икенче төрлерәк әйтсәм, өйгә, нәселнең сафлыгына тап төшермәү символы, гарантиясе булган ул!

– Ярар... Менә син әйттең, сую очраклары да булган, дидең... Ә менә закон алдында ничек җавап бирәләр инде ул ирләр? Элек милиция булгандыр анда, хәзер полициядер... Алар нишләтә ул рәхимсез ирләрне?

– Аңламадым, – диде Сәфәргали, аптырашлы карашын Миләүшәгә төбәп. – Закон да, полиция дә белми ул хакта. Дөресен әйткәндә, күрмәгәнгә, белмәгәнгә салышалар. Чөнки халыкның иманын, гореф-гадәтләрен кадерли беләләр.

– Әгәр... Анда бит әле Мәскәүдән, Казан кебек күп шәһәрләрдән командировкага йөриләр милицияләр. Барысы да мөселман түгел бит инде! Әгәр алар бәйләнә башласалар, ничек котылалар?

– Елмаялар...

– Ничек елмайсыннар инде?!

– Әйе, елмаялар... Елмаялар да, террористлар казасы бу, диләр. Чөнки ишетеп, телевизордан күреп торасыз, анда көн саен террорчылар дип аталган кешеләр баш калкыта.

Беркадәр шактый тынып торган, сабакташы белән хатыны арасында барган әңгәмәне генә тыңлап утырган Мәхмүт, ниһаять, авызын ачты:

– Шулай да, сабакташ, хатынын суйган иргә дә рәхәт түгелдер. Пытамышта күпмедер гомер иткән хатыны бит инде ул аның. Яратып яшәгәндер, кайгырадыр. Кайгысын ничек баса икән ул ир?

– Анысын да белдем, Мәхмүт дус... Башта үзегезгә бер сорау бирим әле... Гәҗит-журналлардан, китаплардан, телевизордан Кавказ ирләренең ниндирәк киемнәр киюләренә игътибар иткәнегез бармы икән...

– Күргән бар, – дип куйды Мәхмүт, сабакташының сүзен бүлдереп. – Күбрәк алар бөрмә билле җиләнгә охшаган казакин дигән җинел бишмәт кияләр...

Ул арада Миләүшәнең дә йөзе ачылып китте:

– Мин дә күргән бар, Сәфәргали абый... Мәхмүт әйткән шул бишмәтнең түшендә һәр патронны аерым тыгу өчен бүлемтекле-бүлемтекле күн кесәләре була. Башларына Батулланыкы кебек бүрек кияләр. Билләренә кинжал тагалар.

– Менә хатын да дөрес әйтә, – дип, сүзне Мәхмүт дәвам итә. – Алар әле билләренә кылыч та асалар. Кулларына тотып та йөриләр кайчак шул кылычны.

– Аякларына башы дугаланыбрак торган җинел читекләр кияләр, – дип өстәүне кирәк тапты Миләүшә.

Ир белән хатынның мәктәп балалары кебегрәк самими җавап бирүләрен тыңлап бетерүгә үк, баягы сүзен дәвам итәргә тиешле Сәфәргали учын өстәлгә чәпәп алды.

– Урысча әйтсәк, маладчина! Яхшы беләсез татарга бертугандай халыкларны!. Әйе, хатынын үз кулы белән суйган ир дә бик кайгыра...

Шул кайгысын басу, йөрәген тынычландыру өчен беләсезме нәрсә эшли сез әйткәнчә киенгән ир? Кылычын тартып ала да...

Шулчак, сикереп торып:

— Бәй, әллә үз-үзенә кул саламы?! — дип кычкырып куйды коты алынган Миләүшә, сискәнеп китеп.

— Юк, салмый... Башка ирләр җыелып торган җиргә бара да, чылгый мыегын өскә таба бөтереп җибәреп, кулларын биленә куеп, өермә кузгатырлык җинел хәрәкәте белән ярсый-ярсый бии башлый. Үзегез дә беләсез, аяклары пропеллердай житез аларның, күзгә дә күренми кебек. Йөрәге дә чаптар атныкы сыман кагып-кагып куя. Ә башка ирләр, бөтенесе бер авыздан «Һасса! Һасса! Һасса!» дип кычкыра-кычкыра куәт биреп торалар. Кайбер ир сәгатьләр буе бии икән. Инде дә тәмам хәлдән тайгач, дусларының кулына егыла икән...

Шулвакыт Сәфәргалигә сабакташының күзеннән яшь чыккан кебек тоелды. Ә инде бу мәлдә Мәхмүтнең чираттагы соравы да әзер икән:

— Егылгач җылап җибәрәдер инде, әйеме, сабакташ?

— Юк, ирләр еламый анда, парин... Алар бит бездәге кебек эчеп, йөрәкләре җебеп беткән, хәмердән, көнчелектән таушалган, корсаклары күпкән, Алланы да оныткан мәмкәләр түгел...

Өчесе дә, сүзләре беткәндәй, кайгыга чумгандай тынып калдылар. Әледән-әле борын тарткалап һәм авыр сулап куюлары гына ишетелеп торды. Ниһаять, хәлсезләнгән тавышы белән Миләүшә телгә килде:

— Гаҗәп гыйбрәтле нәрсәләр сөйләден син, Сәфәргали абый. Тик... Тик шулай да аерым кыстыргычка куела торган пычак турында әйтмәскә иде... Ышан син Мәхмүтнең дуамал холкына! Кыстырып куюы булыр пычакны, каны кызган чакта, кыстыргычыннан суырып алып, нахакка суеп ташлавы булыр...

— Минме?! Пычак куярмынмы?! Булмый торсын әле! КөнчелегеН саташу чигенә җиткәч, мин йоклап ятканда суяр иден бугай... Тәтеми торсын!

Шулчак берьюлы көлә башлауларын үзләре дә сизми калды. Көлә-көлә йөзләре яктырып беткәч кенә шул ук Миләүшә тагын һушына килде:

— И-и Сәфәргали абый, безнең хакта ниләр уйларсын икән инде? Ире дә, хатыны да азгыннар, көнчеләр икән диярсең сыман...

— Юк, алай уйламам. Дустым Мәхмүт тә, хатыны Миләүшә дә бик бәхетлеләр, бер-берсен өзелеп яраталар, тик шул бәхетне көнчелекләре, үзара шикләнүләре белән сүрелдерәләр, дип уйлармын... Яши-яши шунысын да аңладым мин: ирме яки хатынмы көнләшә икән, ул үзенең тугрылыгына ышанып бетми дигән сүз. Ярар, безнең көнгә калсагыз, сез дә онытырсыз әле көнләшү дигән зәхмәтне...

— Сезнең хәл дә шәптән түгелмени?

— Алай түгел... Үзебезчә, бик бәхетле без.

— Хатыныңнан да көнләшмисеңме?

— Һу-у-у, сең-лем! Кая ул безгә көнләшеп яшәүләр!... Ул бәгъремнең, мескенемнең койрыгына биш бала ябышкан... Алары да тәпи басуга ук эш юлында. Һичьюгы, нәни кулларына чыбык тотып, үрдәкләр, казлар артыннан йөгерә башлыйлар... Эре малларыбыз да бик ишәйде. Ул хатыным шуларны карасынмы, олырак малайлар белән көтү көтсенме, әллә чит-ят ирләргә күз салсынмы? Бик арыйбыз, биеп егылган чиркәс кебек кайтып егылабыз караватларга, бер-беребезнең рухын терелтергә тырышабыз. Шунсыз булмый. Булдырганбыз, тапканбыз икән инде ул балаларны, аларны бит әле үстерергә дә, укытырга да кирәк. Дөньясын әйт тагын... Ниндидер каһәрле чорга юлыктык бит... Нужа белән тормыш парлап кыйныйлар! Бер-беребезне дә борчып, тинтерәтеп яшәсәк, ятып үләсе генә кала... Көнләшергә, тиргәшергә вакыт юк безнең. Шулай да, ерак дип тормагыз,

парлап кунакка килегез. Сездәй якыннарны сыйларлык, кунак итәрлек вакыт та, сый да табарбыз.

Машинасы кузгалып китүгә, озатырга чыккан Мәхмүт белән Миләүшә, бер-берсенә карашып алдылар да, сүз башларлык хәлләре дә калмаган кебек, тавыш-тынсыз гына эскәмиягә барып утырдылар. Үргә менеп барганда, Сәфәргали үзалдына елмаеп куйды:

– Артыграк сөйләп ташладым, ахрысы, боларга... Шыттырып та җибәргәләдем бугай... Ничауа, зыянга булмастыр...

## Сак булыгыз!

*(Буйдак рәссам монологы)*

Әгәр дә мин сезгә:

– Кырык яшемә җиттем инде, әмма хатын–кызның кулын да тотып караганым юк әле, – дисәм, ышанырсыз микән, минем кебек үк шушы журналны укып яшәүчеләр. Валлаһи, дип тә, билләһи, дип тә сөйлим бит инде югыйсә бу хакта танышларыма, дус-ишләремә – ышанмыйлар! Хәтта бер матур кызга да әйткән идем әлеге сүзләремне. Ул да ышанмады. Киң итеп елмайды да, очкынлы күзләрен төрле якларга бора-бора уйнатып алгач, йөземә дә текәлеп карый-карый басып торгач:

– Абый, – ди, – син, –ди, – һәрвакыт хатын-кызларның башка җирләрен генә тотып яшәгәнсеңдер, кулларын тотарга кулларың бушамагандыр , – ди.

Аннары, аптыраулы йөземә кабат карап алгач, көлә-көлә һәм дә серле генә бармак яный-яный, өстәп тә куйды:

– Әйе-әйе, абый! Үзең чибәр, ыспай булсаң да, кешеләрнең анатомиясен белмисең бугай! Хатын-кызлар куллардан гына тормыйлар бит! Аларның, мәсәлән, муеннары, билләре, җилкәләре, сыйпарлык-сөярлек аркалары һәм башка әгъзалары да була, бик беләсең килсә!.. Аяклары да була!

Дөрес әйтә болай... Аяклары да булмаса, теркелдәп йөрмәсләр иде бит.

Шулай менә... Хак сүзләремә ышанмады... Мин наданга тулы фәнне аңлатты да, килешле гәүдәсен уйната-уйната, китеп тә барды...

Их, ярый әле якын дусларым күп! Шулар көн саен берәмләп-берәмләп тә, икешәрләп-өчәрләп тә килеп тормасалар, ялгызлыктан саргаеплар үлгән булыр идем, яисә, берүзем генә ашап утырсам, тамагымнан ризык үтмәс иде... Әйе, бәхетсез үк түгелмен. Кунакка килеп керүгә үк аш өстәлемә күкрәк кесәсенә сыярдай матур кап эченә салынган вафлилар яки аллы-гөлле зефирлар чыгарып куялар. Хәтта, мондый тәмнишкәләрне үзе генә ашап куансын диптер, күчтәнәчләрен авыз итеп тә карамыйча, мин, ягъни мескен буйдак әзерләгән гап-гади ризыкларны мактый-мактый яратып ашыйлар. Берсе – Казакъстан ягыннан кайтып торучы уклаудай ат казылыкларын, икенчесе – базардан алып кайтып пешергән кырык дүртенче размерлы туфлидәй сыер телен яки ананасларны, өченчесе таза кызлар балтыры юанлыгы, тишекләренә әчтерхан чикләвекләре сыярлык «Масдам» дигән сырымны турый... Өстенә бал агызып куйган чәкчәкләремне дә, шоколадларымны да, җәй айларында торпедога охшаган кавыннарымны да яратып ашагандай кыланалар. Күңеле төшмәсен, кимсенеп гомер итмәсен, диләрдер инде җандай күргән газиз дусларым. Кызганалардыр инде бу бәхетсез бәндәгезне... Авызлары ризыктан бушабрак торган чакларда мәзәкләр сөйләп тә, үзебезнең уртак эшләребез, уңышларыбыз турында мактанышып та алабыз. Әйе, бер әртил кешеләре без, ягъни барыбыз да мәдәнияткә хезмәт итәбез. Араларында минем кебек хыдужниклар да, язучылар да, җырчы һәм музыкантлар да, театр артистлары да бар... Аракылар, коньяклар, баллы шәраблар баш түбәсенә менеп җиткәч, кайсысыдыр өстәл яки табуретка төеп көй чыгара, башкалары кушылып җырлый яки сәхнәдәге кебек биеп тә җибәрәләр...

Һаман да шул инде — буйдаклыгымның, ямансулап яшәвемнең ачылыгын аз булса да киметергә тырышып, миңа хезмәт итәләр бәгырькәйләрем! Ә инде аерылышыр минутлар якынлашкач:

— Ярый әле син бар!

— Кунакчыл булуың, сыйлавың мәңге онытылмас!

— Ризыкларың тәмле булды! — диешә-диешә, минем исәнлеккә багышлап бокаллар күтәрәләр...

Соңгы айларда үзем дә сүз кыстыра башладым тегеләрнең гәрләшүе арасына.

— Их, егетләр, сез бит бәхетлеләр! — димен, саркып чыккан яшьләремне сөртә-сөртә. — Әйе, сез бәхетлеләр, сезнең хатыннарыгыз бар! Алар бит сезләрнең алдына өйдә пешкән кайнар кыстыбыйлар, өчпочмаклар, сусыл пирәшкиләр өяләр, табасы белән мичтән чыгарып, кайнар бәлешләр китереп куялар! Менә шуларга кызыгып яшим бит мин, е-гет-л-ә-әр!...

Аннары, ятимлек үксүемне сиздермәскә тырышып:

— Ничауа, сезгә дә барып чыккан чаклар булыр әле, Алла боерса, сез дә сыйларсыз... — дип куям ахыр чиктә.

Ә тегеләрнең, ягъни дистә еллар буе йөзгә якын җыйган, миндә көн саен, атна саен сыйланып утырган газиз дусларымның башларына кайгы ишелеп төшкәндәй, муеннары бөгелә, йөзләре каралып китә. Тын да алмыйлар беравык.. Шуннан соң гына берсе телгә килә башлый.

— И, Котлыхан, белсәң иде син хатынлы кешеләрнең хәлләрен! — дип сыкрана ул, ачынып. — Минем, мәсәлән, хатыным котырган аждаһа кебек бит... Берүзем кайтып кергән чакларда да өстемә ут кебек кызарган кисәү агачы белән өстемә ташлана...

— Минем карчыга да бик явыз. Кеше дә ияртеп кайтсам, күзләребезне чукып чыгармаса да, өстебезгә кайнап утырган кәчтрүлне дә каплавы мөмкин, — дип куәтли икенчесе.

Шуннан соң инде тыңлап утырырга гына кала:

— Беркөн, Газизулла белән кайткач, минем кара елан, чажлап куйды да, кәбестә чаба торган беләк буе пычак белән өстебезгә ыргылды. Ярый әле чыгып качарга өлгердек. Алай да, Газизулла, подъезд баскычыннан йөгереп төшкәндә, абынып егылды. Авыз-борыны кара кан булды мескеннең. Ике атна буе бүлнистә, реанимациядә ятты.

— Менә карагыз минем муенга, җәмәгать... Җөй күрәсезме анда? Өч ел элек, төн уртасында торып, хатыным судай үткен бритва белән суя башлаган мине. Ярый әле уянып өлгердем...

— Синеке пүчтәк... Минем юка баш агу эчертеп үтермәкче булды бер елны. Ул сузган стаканны эчәм генә дигәндә, күзендә үз мәетемне күрдем һәм агуны унитазга илтеп түктем.

...Тупсамны атлап чыкканда тукталып башын борды да берәүсе саубуллашыр алдыннан болай диде:

— Горурланып яшә, Котлыхан! Өйләнгән ир бәйле дурак ул, ә син ирекле буйдак! Кадереңне бел, каберенне табарга теләмәсәң!

Тегеләр киткән саен «әстәгъфирулла!» дип, кайгыга калам. Әнә нинди икән бит мин кызыккан, сокланып үткән чәчбикәләр! Күрәм бит, еш күрәм аларны ирләре белән йә базарда, йә театр буфетында! Урамда да, үземнең картиналарымны тезгән күргәзмә залларында да күрәм! Ялгыз гына да очрыйлар миңа, буй-сыннары ук өйләнү дәртен кузгата ул фәрештә йөзле шайтаннарның. Ләкин, сәлам бирүгә үк, өскә ыргылмагайлары, ул-бу каза китермәгәйләре дип өркеп, шыпан-шыпан гына качып китәм. Шулай да эләктереп алды берсе, ләгыйнь! Сәлам бирүгә үк изүемнән эләктереп алды да, барыр юлыма аркылы басты:

— Туктап тор әле бераз, Котлыхан абый! Нишләп син дусларыңның хатыннарына нәфрәтле!?

Үзе сорый тора, үзе, чаяланып-наянланып, наз тулы рәхимле күзләрен йөземә текәп, елмаеп, язгы кояш сыман балкып тора. Куркуымнан кипкән авызымны, аңкауга ябышкан телемне көч-хәл белән кузгатып, әйткән булам үзенә:

— Хөрмәт итәм... Шуңа күрә исәнләшми үткәнем юк лабаса...

— Ә бер-ике минутка булса да тукталып, хәл белешеп торырга ярамыймыни?! Укам коелыр дисеңмени?!Безнең ирләрне сыйлап ятасың үз өеңдә, ә үзең бер мәртәбә дә безнең фатирларга аяк басмыйсың. Әнә, синең хакта Сәлимәләр, Хәлимәләр, Сәкинәләр, төрле-төрле Ләйсәннәр, Лилияләр, Розалар, Данияләр аптырап та, гаҗәпләнеп тә сөйлиләр, нинди сәер кеше микән ул, диешеп... — Аннары, имән бармагын пистолеттай түшемә терәп, кем әйтмешли, котмагәндә шап итеп, катгый сорау бирде:

— Әйт, ник кунакка килмисең?!

— Ярар, — мәйтәм, — ирләрегез чакырса, барырмын, — димен.

Теге чибәркәй бот чабып көлгәнен үзе дә сизми калды кебек:

— Көт син алардан! Гастрольләргә, төрле очрашуларга йөреп, хатыннарыннан башка гына кеше өстеннән ашап, сәйран кылып яшәргә күнеккән затлар бит алар.

— Соң, шулай булгач, алардан башка бару ярамый бит инде...

— Ярый, бара алмасаң, үзебез барырбыз! — диде дә шушы ябь-яшь назлыбикә, каядыр ашыккандай, китеп тә барды.

Вәйт шаяртты бу дип артыннан карап калдым моның.

Ләкин бик нык ялгышканмын икән. Сүзне озакка сузып тормыйча гына әйтсәм-әйтим инде, җәмәгать: хәзер минем кунакларым бары тик чәчбикәләр. Берәмләп тә киләләр, өчәрләп тә киләләр. Өчәрләп килүләрен аеруча яратам. Шулай килүләренең файдасы да зур миңа. Чөнки хыдужник икәнемне әйткән идем бит инде. Хәзер нинди хыдужник икәнемне генә әйтәсем калды. Шишкин дигән атаклы рәссамне беләсезме? Ул урманнар гына ясап яшәгән, ләкин кеше ясый белмәгән. Айвазовский дигәненең бөтен картиналары фәкать диңгез күренешләре белән тулы. Берәүләре хайваннар, өченче-дүртенчеләре — хан заманы күренешләрен ясап дан алса яки кешеләр миллионлап үлә, кырыла торган баталияләрне сурәтләсә, минем иҗат аларныкына капма-каршы: кешеләр ясау остасы мин! Иң яратып ясаганым — борынгы Рим яки грек рәссамнары ясаган ялангач хатын-кыз. Әлеге дусларымның хатыннары өчәүләп килгән көннәрдә иҗатымның колачы күзгә күренеп киңәя. Илһамланып, җиң сызганып эшлим. Әйтик, килгән чәчбикәләрнең кайсысындыр матур чәчәкле ефәк җәймәгә чишендереп... әй, ялгыша яздым... чишендертеп салам да, ашкына-ашкына шуның бинихая гүзәл тәнен карават җәймәседәй киң полотнога күчереп ясыйм. Теге икесе дә ярдәм итәргә ясап куйган кебек: уң яктагысы палитрамны тотып, сул яктагысы файдаланган пумалаларымны әлиф яки бензин белән юып тора. Күрсен әле килер буыннар татар Касыймханының да атаклы Рафаэльдән ким түгеллеген! Веласкесның «Көзгеле Венера»сы да бер читтә торсын! Белсеннәр алар мин ясаган хатыннарның чибәррәк тә, затлырак та икәнен! Әйе, күреп туймалы түгел бу гүзәлләрне, ягъни якын дусларымның җефетләрен!.. Һы, хатыннары кызган кисәү агачы яки Чапай кылычыдай пычак күтәреп ташлана, имеш... Ачуын китерсәң, койрыгын авыртырлык итеп кыссаң, куян да шырпы сызарга өйрәнә. Чыраеңа ташланырга да күп сорамас озын колак!

Шунысын да боргаланмый-сыргаланмый гына әйтми булмастыр... Нәрсәне, дисезме? Шул картиналарны ясаганда Сәлимәнең башын Хәлимә гәүдәсенә, Хәтимәнекен Хәкимә бәдәненә ялгап ясыйм. Әгәр дә минем дусларым күргәзмәмә килсәләр, өздереп әйтә алмасыннар, Котлыхан тач

минем хатынны ясаган икән, шәрә гәүдәсен дә күргән икән дип. Чөнки, алай ясаганда, үз хатынының тәнен таныса да, башының яки йөзенең башка хатынныкы икәнен күргәч, берсе дә мина дәгъва белдерә алмаячак. Башына карап кына да «минем җефет бит бу!» дия алмаячак сакаллы бәрәнге. Чөнки шуны белегез, чәчбикәләр, һәр ир үз хатынының тәнен кап-караңгыда да таный!

Юк икән, мыекташларым сөйләгәнчә, аждаһа да, кара елан да, ир суярга кыҗрап торучы затлар да түгел икән хатыннары. Сокланып, кызыгып кына карап торырлык болар. Җайларына төшеп, җылы сүзләр сибеп макташтырсаң, салпы якларына салам да кыстыргалап торсаң, яшәп буладыр болар белән, ә!

Ләкин, сак бул, укучым, мина шиген төшеп, гөнаһлы була күрмә! Юк-юк, хәйләкәр елмаеп, бармак та янама. Булмады безнең арада син уйлаган хәлләр. Кайнар кыстыбыйларына, өчпочмакларына ике куллап тотынсам да, бая әйткәнемчә, кулларын да тотып карамадым. Ул гөнаһсыз, изге затларга нәфесемне сузсам, баягы дусларымның, ягъни боларның ирләре күзенә ни күз белән карамак кирәк?! Әйтеп торам бит мин сезгә, алар китергән яки пешергән кайнар кыстыбыйларын, өчпочмакларын ике куллап тотып, комсызланып ашасам-ашадым, ләкин үзләренә бармак белән дә ягылмадым. Инде алай да ышанмыйсыз икән, хәтта Ленинның ...тфү-тфү... хәтта Путинның рәсемен тотып ант итәргә дә әзермен. Вәйт, шул! Әле бит алар мина ике чатлы шырпы уйлап тапкан атаклы татар академигының дөньяда тиңе булмаган кызын да димләргә ниятләп йөриләр... Әгәренки дә үзләре белән шаярган булсам, җаннарына да, тәннәренә дә хуш килсәм, бирерләр иде микән мине башка затларга? Тоттырырлар! Хатын-кыз ул андый ирне суйса-суяр, кайнап торган су белән коендырса-коендырыр, әмма дә ләкин көндәшләренә бирмәячәк! Мәхәббәткә бик тә тугры бит ул асылзатлар! Кадерләрен белеп яшәгез, сакалбайлар, хатыннарыгызны хурламагыз! Хурлаганыгызны ишетсәм, валлаһи дип әйтәм, чәчбикәләрегезне өемә алып кайтам да, чәчкәле җаймәгә салып, сурәтләрен ясыйм. Йөрерсез аннары минем күргәзмәләрдә хатыннарыгызның буй-сыннарына, матур йөзләренә сокланып. Сак булыгыз!

## Кешеләр шәп – була яшәп!

Кешеләрнең соңгы елларда миһербанлырак, мәрхәмәтлерәк була баруын үзегез дә шәйлисездер, әйеме? Элек, мәсәлән, Ельцин заманында дип әйтик, төнге урамга чыгудан гына түгел, тәрәзәдән карарга да курка идек. Ник дисәң, талаучыларның кансызлыгына, оятсызлыгына чыдашлы түгел иде: яканнан элеп алулары була, шундук салып егулары була... Син һушыңа килгәнче кулыңдагы затлы сәгатең дә, колагыңдагы алтын алкаларың һәм бармагыңдагы кашлы йөзекләрең дә – барысы да юкка чыккан...

Менә хәзер адәм балалары алай тупас кыланмыйлар. Шуңа күрә төнлә йөрүчеләр дә күзгә күренгәли Казаныбыз урамнарында. Әйтик, бер дустымда кунакта булган идем беркөн. Төнге уникеләр үткәнче утырылды бит, каһәр. Кайтып барам шулай, биек үкчәле, дагалы туфлиләре белән асфальт тротуарга кәс-кәс кенә басып, телефоннан назлы тавыш белән сөйләшә-сөйләшә, бер чибәркәй узып китте. Алым саен бөтерелеп, җилпенеп барган итәгенең хушбуй исләре борынымны иркәләде хәтта!.. Күпме алгарак киткәндер, әллә каян гына моның каршына бер егет чыгып басты. Кыз да туктады. Әһә, мәйтәм, сөйгән егете каршы алды моны!.. Һәм, чыннан да, егетнең тавышы назлы икән. Очрашуга ук кызга әйтә бу:

– Бир мина, гүзәлем, мин дә сөйләшермен, – дип, телефонын алды тегенең. Шундук: – Каяле, чибәрем, башыңны күтәребрәк тор, муеныңны мишәйт итә, – ди-ди янагыннан үбеп алгач һәм матуркайның алтын

чылбырын салдыргач, минем түбәтәй хәтлерәк кенә сумкасын да кулыннан ипле генә шудырып алды да, өстәп тә куйды: — Мондый нәфис кулларынны авыр нәрсәләр күтәреп бозма, жәме, жаныем!

Әйе, сүзләре жылы булды кызга, әмма үзе, күзләремне йомып ачкан арада, юкка да чыкты. И сөенде теге хуш исле кыз, шатлыгыннан елый-елый, болай диде мин тукталган арада:

— Әле ярый суймады, абыем, кулында ялтырап торган кинжалы да бар иде бит югыйсә!..

Хәер, үземә дә очрады бер тәбәнәк кенә гәүдәле рәхимле егет, юлым карангы тыкрыкка борылгач.

— Абый, — ди, — гафу итә күр, тәмәке кабызгычымны кесәгә салмаганмын. Шырпы-мазарын булса да юкмы?

Карашы шундый ягымлы, ә үзе, мине туктатуына кыенсыныптыр, сигаретын бармаклары белән әвәли-әвәли, баскан урынында тыйнак кына таптанып тора. Кабыздыргач, китү ягына бер-ике адым атлавым булды, йомшак тавышы белән туктата бу мине:

— Ашыкмый тор әле, абыем. Бик файдалы бер нәрсә күрсәтәсем килә, — ди. Шулай диюгә үк, кесәсеннән пистолет тартып чыгара. — Менә күр әле, абый жаным, миндә нәрсә барлыгын. Көпшәсен сыйпау да жанга рәхәтлек бирә. Менә бу мушка дигән нәмәкәе дә күнелгә ышаныч индерә. Шундый төз ата үзе! Сокланып туймаслык.

— Әллә сатарга уйлыйсынмы? — мәйтәм.

— Шту син, абый, ул бит минем тормышымда бердәнбер таянычым. Ул булмаса ачтан үләсе кеше мин. Мактанасым гына килде синең алда...

Аннары болай дип куйды:

— Абый, бик мәрхәмәтле күренәсең... Акчаң булса, ярдәм ит әле. Мин сина гомерем буе ихтирамлы булыр идем...

Шундый кешегә акча жәлмени?! Кесәмә дүрт 500лек тыккан идем чыкканда, чалбар кесәмдә казынгач, шунын берсен нурлы карашлы егеткә чыгарып тоттырдым.

— И рәхмәт, абый! — ди. — Мең яшә!

Аннары тавышы төшенке янгырый башлады монын.

— Шулай да, абый, саранрак икәнсең... Тагын да бардыр бит әле кесәндә?...

— Юк шул, энем, — дидем, бераз аптырап калгач.

— Шулай да, үзем кулны тыгып карыйм әле кесәнә, абый, бәлки калгандыр. Үпкәләмә түлке, жәме?

Кесәмнән тагын өч кәгазьне чыгаргач, үз кесәсенә сала-сала, мондый кинәш тә бирде:

— Син дә минем кебек культурный, намуслы кешегә охшагансың, абый. Сина алдау килешми. Моннан сон әфтәритенне югалтмаска тырыш, жәме, — диде дә, ун кулындагы наганын сулына күчереп, кулымны кысты. — Сау булып тор, абый, очрашкан чаклар булыр әле, — дип, тамак төбе белән генә «Озата барма, жаный, озата барма» көен көйләп, салмак кына китеп барды.

Нәрсә генә димә, кешеләрнен мәрхәмәтләнә баруы нык сизелә хәзер. Элек, мәсәлән, берәр ир хатынын башка ир белән тотса (кайда, ни хәлдә икәнен әйтеп тормыйм, үзегез дә беләсез) хатынын рәхимсез рәвештә ут өертеп кыйный иде. Ә хәзерге ирләр маладислар, орды-бәрде кызып китмиләр, һәр вакыйгага сабыр нәтижә ясый беләләр. Мисалга да ерак барасы юк. Каршы йортта гына торучы ир яз уртасында Төмәнгә йөреп эшли башлаган иде. Ягъни нефтьче һөнәренә гашыйк булган иде күптән түгел генә өйләнгән бу егет. Көннәр жылытып жибәргәч, ишек алдындагы

эскәмиягә чыгып утыруым булды, каршыма килеп басты. Хәл-әхвәл белешкәч, кәефсез генә сөйләп алды.

— Хатыным бик оятсыз булып чыкты бит әле минем, Әхтәм абый. Кайтыр вакыт житкәч, фәлән көнне кайтам дип телеграмма да суккан идем югыйсә. Ә ул, кайтып керүемә, икенче ир белән кайнаша. Аерам!

Соңгы елларда үзем дә бик сабыр кешегә әйләнә баруым хикмәтедер, болай дип кинәш бирдем егеткә:

— Бик ашыгып хәл итмә әле, энем. Төбенә төшеп ачыкла, бәлки, күзен ялгыш күргәндер, хатынын гаепле түгелдер, — дидем.

Вәйт, дөрес акыл биргәнмен күршемә — икенче көнне үк рәхмәт әйтергә чыкты!

— Дөрес әйткәнсен, абый. Хатынымда булмаган икән гаеп. Телеграмма ташучы кабахәт ир аркасында нахак бәйләнгәнмен жаныкаема.

— Әллә шуның белән йөргәнме?! — дип соравымны сизми дә калдым, каһәр.

— Юк! — диде күршем, кистереп. — Шул ысбулыч вакытында тапшырмаган икән телеграмманы. Икенче көнне иртән үз кулыма кертеп бирде, оятсыз!

Менә шулай, мыекташлар, хатыннарыгызга бәйләнгәнче, ул изге затларга кул күтәргәнче, чын хакыйкатьне ачыклагыз. Нахакка рәнжетсәгез, тәмуг кисәве булуыгыз ихтимал.

Бая әйткәнемчә, үзем дә сабыр була башладым соңгы вакытта. Элек, мәсәлән, хөкүмәтне сүгә идем: «Биш-алты процент пенсия өстәгән саен, тауар бәяләре ике мәртәбә арта. Хәтта көн саен имә торган сигаретымның бәясе дә 6 сумнан 36 сумга житте бит инде, ачуым да килмәгәе!» — дип. Хәзер, аларны гаепләүдән тыелып, үз-үземне ипле генә юатып утырам: «Шул ук Путин да миннән күбрәк алмастыр әле пенсияне, чөнки стажы минекеннән дә бик күпкә кимрәк», — ди-ди... Әнә, март уртасында пенсияләрне 3 процентка тагын арттырачагын әйтте бит әле ул! Кайгырта бит! Мәсәлән, минем пенсиягә дә ярты кило итлек акча өстәләчәк. Пенсияләрнең ни өчен, кем гаебе аркасында аз күренгәнен дә яхшы беләм. Һаман да шул Америка шомлыгы бу, жәмәгать! Безне юри кимсетү, мыскыл итү нияте белән үз гражданнарына пенсияне егерме-утыз мәртәбә күбрәк түлиләр дә президентлары, Россиябезгә, аның житәкчеләренә карата нәфрәт тудырырга ниятлиләр. Тәтеми торсын! Сез дә, ватандашлар, ан булыгыз, Россиянең стабилизм һәм модернизация байрагын югары тотыгыз! Патриотлар булуыбызны күреп, Американың йөрәге янсын! Хәерчелектән ыштансыз калсагыз да сер бирмәгез! Вәйт шул сезгә кинәшем...

**Редакциядән:**

*Бу айда күренекле язучы-сатирик, журналыбызның күптәнге авторы Фәнзаман Батталга 75 яшь тулды. Каләмдәшебезне олуг юбилее белән ихластан котлыйбыз! Аңа исәнлек-саулык, күңел көрлеге, иҗади куанычлар телибез!*

## Моң–тәлгәштән – көчтәнәч–җыр...

*Журналыбызның бу санында мин укучыларны үзем өчен әле яңа гына ачылган бер гаҗәеп дөньяга – башкорт шагыйрәсе Тамара Искәндәриянең күңел дөньясына чакырам. Чын шигърияттән һичвакытта да туймаган, матурлыкка битараф булмаган, журналыбызның 90 елдан ашкан тарихында башкорт шагыйрьләренең дә үзенчәлекле, күптөрле шигъри әсәрләре белән танышып барган зәвыклы укучыбыз бу юлы да чын рухи ләззәт кичерер, дип нык ышанып әйтәм.*

*Ә Тамара ханым Искәндәрия – бүгенге башкорт шигъриятендә үзенчәлекле затлы-зыялы иҗатчы буларак, абруй казанган санаулы шагыйрьләрдән. Узган елның октябрь аенда бер төркем башкорт әдипләре белән Татарстан һәм Башкортстанның яшь әдәби көчләренә багышланган ике көнлек семинарда да катнашты ул; безнең яшь шагыйрьләр иҗатына җентекле анализ белән чыгыш ясап, каләмдәш әдипләрдә җылы, матур тәэсир калдырды...*

*Шул көннәрнең бер истәлеге булсын дип, бу үзенчәлекле, безнең укучы өчен яңа исемгә аерым бер игътибар юнәлтәсем килде: шигырьләрен шагыйрәнең «Моң-тәлгәш» исемле саллы китабыннан сайлап, үземчә бер бәйләм-шәлкемгә җыеп, татарча имляга күчердем. Менә шул – Сезнең хөкемгә, укучылар!*

**Рәдиф ГАТАШ**
*Татарстанның халык шагыйре.*



Тамара
Искәндәрия

### Төрки дөнья

**Төрки дөнья...**
**Тузган байракмы син? –**
**Ертыкларың тора ни сорап?!**
**Булдымыни башка кавем – синнән**
**Акыллырак? Бәлки, чосырак?**

**Төрле төстән инде киенәсең,**
**Таныйсың син Күкне төрлечә.**
**Киң дә, тар да яңакларың аша**
**Багасың син һаман – бүречә...**

Төрки дөнья...
Бергә җыйсаң, син бит –
Тоташ галәм сыйган олы куч.
Аяк асларыңда җәйрәп яткан
Бәхетең иле –
Далаң кебек үс!

Хакимлекләр ава имән сыман,
Патшалыклар корый – нәкъ агач.
Дала үләне бит, бөгелә дә,
Кабат баш калкыта – тапталгач...

## Хаким

Хаким булдым, диеп, сөенде ул,
Ә хакимлек – түгел булу өстен.
Хакимме син? Димәк, башың идең
Кылычына кара уйлы көчнең.

Миһербанлык, егәр, тапкырлыгың
Алмаштырды хөсет, хөсет, хөсет...
Хаксыз хаким, инде үз-үзеңне
Битлек салган иблис итеп хис ит!

Фәрештәләр сиңа кунган иде бит,
Алданамы икән фәрештәләр?
...Баткакларда алар аунап ята,
Гүя, хәмер эчкән фахишәләр...

## Сорау

Күр, якында гына кошлар сайрый,
Нур эчендә
Шаулый гөлбакча...
Ләкин дөнья –
Бөек куласа:
Бакчаларны бурап көл баса.
Бакчаларны бурап
Чүп баса...

Мәңгелекнең бөек әйләнеше
Бер китерер сорау-әңгәмә:
Кешелеккә миннән ни фәтва?
Кадер күрсәттемме әнкәмә?

...Кадер
Күрсәттеңме
Әнкәңә?!

## Дәвер ташы

1

Син ни тиклем бу заманга
тап килгәнсең,
Мин шул тиклем бу заманнан
Алыстамын.

Яуда, дауда синең булмыш.
Ә мин һаман
Мәңгелек рух эргәсендә алыштамын.

Ялган белән йөзгә-йөз син
килгән чакта,
Бәрелгәнең саен сыктап,
Мин тетримен.
Бу дөньяның Ак,
Карасы якалашып,
Син янасың...
Аһлар орып,
Мин күкримен.

Яшәешнең һәр бизәген кабул итәм,
Салкын ташта калган
Эзләрне дә.
Калсын иде Сөюемнән
Иң матур эз,
Дәвер ташы, синең
яну-гомереңдә.

2

Мин бит беләм: мин — бердәнбер
Синең өчен.
Бердәнбер Җир,
Бердәнбер Күк булган төсле.
Вак тойгылар күзгә тула,
комдай очып.
Мин бердәнбер булганга, син —
шундый көчле.

Яшисең син җиһан белән
исәнләшеп.
Әнә, кара, йолдыз очты —
ул бер гашыйк!
Галәм иңләп балкып оча
Синең йөрәк —
Заманыңның акыл чыңы,
бәллүр ташы... —
Дәвер ташы!

## Алтын тузан

Сине югалтудан курыкмадым мин,
Курыктым — сөюемне югалтудан.
Кот очарлык берни юк икән лә,
Очты-китте сөюең — алтын тузан.

Вак тузанлы — алтын чаңлы давыл...
Күзләремдә шуның томаныдыр.
Күзләремне сукыр иткән дә ул,
Башларымны иткән томанадыр...

Очты-китте, хуш, дип әйтәлмәдем,
Калдым бире, сөю китте ары...
Абый белән сеңел — без икебез,
Абый белән сеңел — тик шул бары.

Абыем, дип синең өчен утка,
Суга керермен мин, тәкъдир кушса.
Ләкин инде олы туганлыкны
Вак тузанлы сөюең белән кушма!

## Асыл таҗ

Башкаемны ике учка кысып,
Уртны тешлим, әйе, мин көчле.
Алла түгел,
Бәндә уйлап тапкан
Чик-киртәгә генә мин үчле.

Давыл булып аударыйммы аны,
Ташкын булып бәреп үтимме?
Ялкыннарга чорнап яндырыйммы,
Чүп үләне булып үбимме –
Аяк табаныңнан?..

Ходай үзе
Сине сөеп, миңа яр иткән.
Баксаң, сөю –
якты тап икән лә... –
Башкаемда асыл таҗ икән!

## Өзеп өлгер вакыт чылбырларын...

Синең мәңгелеген чикләрендә
Мин яшәрмен, диден, ярты мәл...
Өзеп өлгер вакыт чылбырларын,
Мәңгелектән мине тартып ал!

Мәхәббәттә вакыт үлчәмнәре –
Сөеп баккан караш иң элек.
Минем карамакта – тик ярты мәл,
Синең карамакта – мәңгелек.

## Гашыйк

Ә син – рәссам.
Карашыңа батам –
Аяк очлап басам,
Сине ачам.

Ә син – шагыйрь.
Тыңлап туя алмыйм,
Аңлап туя алмыйм.
Син – бик маһир.

Ә син – гашыйк.
Мәгърип белән Мәшрикъ
Кавышкандай, шашып,
Миңа
Ашык!



АХИР

# ТАШ КАЛАДА БАШ КАЛА...

РОМАН

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

## Бәхетсез җаннар

### 1

— Син миңа кияүгә чыгасынмы, юкмы?
— Чыгам.
— Кайчан?
— Әгәр авылдан китсәң...

Ташландык авыл йортының биек, авыш бусагасына менеп кунаклаган егет һәм кыз авылдан киту-китмәү турында әнә шулай гәп куерталар иде. Таза гәүдәле, нык бәдәнле, житди һәм кырыс кыяфәтле, тик шул ук вакытта нечкә күңелле, авыл җанлы Нариман кызларның, үсеп җиткәч, авылда калырга теләмәүләрен гакылы белән аңласа да, күңеле белән һич кенә дә кабул итеп бетерә алмый иде. Нәрсә калган аларга читтә, шул таш калада? Бәхетне каядыр читкә китмичә генә, туган җирендә генә табып булмый микәнни соң? Инде менә аның яраткан кызы Динә дә (алай дип кенә әйтү аз булыр — башлангычтан бер сыйныфта укып, бер партада утырдылар!), калада училище тәмамлаганнан соң, авылдан китүчеләр төркеменә кушылды. Бу кызый башкалада бер генә ел укып та, егетнең төн йокыларын качырырга өлгерде. Анда аның сөеклесенә гашыйк булырлар да, урлап китәрләр төсле тоелды ана. Урлавын урламадылар тагын, Аллага шөкер, исән-имин әйләнеп кайтты. Аңа да Нариманнан башка беркем дә кирәк түгел: ул да аңа табынган, җаны белән аңа береккән. Юк, ул Нариманын беркайчан да, беркемгә дә алыштырмас, ярата ул аны, һәм егет тә шул ук халәттә. Кинодагы сымак, кинәт кенә кабынып китеп мәхәббәт аңлашмасалар да, яшьләр өчен бу мәсьәлә көн кебек ачык иде: алар тиздән ир белән хатын булачаклар. Өйләнеш кенә! Бернинди дә каршылык юк, ике як та риза...

—Димәк, китәм дисең инде? — Бер мәлгә тын калган егет, көрсенеп,

Ахир (Хәбир ИБРАҺИМ) (1958) – *язучы, шагыйрь, драматург; «Аһәң», «Йокыга талган гүзәл», «Газиз ярым» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши*

авыр сулап куйды, учларын уып, авыл хезмәтеннән тупасланган бармак сөякләрен шыгырдатты. — Китмичә генә ярамыймыни?

—Мина авылда эш юк, — диде Динә. Ул трамвай йөртүчегә укыган иде. Аны хәзер депода өр-яңа трамвай көтә. Ялгышмаса, Димитровградтан кайткан, андыйга хәзер яшь комсомолчыларны гына утырталар икән.— Ярый ла синең тракторың бар!

—Башка эш кенә ярамыймы? Яңа ферма ачтылар... Сыер савучылар житми...

—Менә син гел шулай! — Кыз шундук үпкәләп, борынын салындырды.

— Ачуланма... Шаярдым гына... җә...

— Кит!

—Син мине дә аңла: мин гомер авылдан чыккан кеше түгел. Армиягә дә бармадым. Ак билет белән калдым. Син барсын да яхшы беләсең...

— Аңлатма, кирәкми...

— Анда киткәч, кайда торырбыз?

— Мина тулай торактан бер бүлмә бирәләр.

— Унбиш квадрат метрмы?!

— Башкалар яши бит әле...

— Әни белән нишлим? Ялгызын калдырыйкмы?

—Юк! Синең белән борчак пешереп булмас, ахры! — Кыз кулын селтәп, урыныннан торды. Нариман аны, кулыннан тартып, кире урынына чүктерде, дәү учын кызның нечкә биленә шудырып, аны кочагына алды.

— Чыгасыңмы?

— Чыгам. Әгәр дә...

— ... авылдан китсәм... ие бит...

Әйе, ул Нариманга чыгарга әзер, ләкин авылдан китү шарты белән. «Чукынып китсен инде! — дип эчтән сызланды егет. — Шулай итеп, китәргә туры килер микәнни соң?»

Шулай! Яратмыйлар кызлар авылда калырга! Укыгач, әзрәк дөнья күргәч, офыклар киңәя, яңа мөмкинлекләр ачыла. Иләсләнгән башта яңа уйлар, үзгә фикерләр туа. Шуларны тормышка ашырыр өчен авыл жире генә тар булып тоела аларга. Күңелләре белән алар барсы да туган авылларын яраталар, ана тартылалар, әле киткәч тә туган якларын үлеп-китеп сагыналар, еш кайталар. Ләкин шул китү, урнашу бәрабәренә алар ярату, сагыну хисләрен читкә кагарга, ушсызлар вә җансызлар юлына басарга мәжбүр булалар. Ә ул китүнең иге-чиге юк. Авылдан китеп, шәһәргә барып урнашу хәзер бер модага, тансык гамәлгә әйләнде. Үзләре генә түгел, инде бер-берсен ияртеп алып китәләр. Авылда ачлыктан, хәерчелектән интеккән ата-бабалар кайчандыр Донбасс, Себер якларына юл алганнар, тайгада урман екканнар, шахтада күмер чапканнар. Ләкин бу сәфәр киткән кеше өчен вакытлыча гына булган. Исән калса, ул кире әйләнеп кайткан. Авылда аны гаиләсе, бала-чагасы көтеп торган. Ә хәзер бер киткән кеше кире әйләнеп кайтмый, ничек булса да шул киткән жирендә төпләнеп калырга тырыша. Авылга кунакка кайтуы гына рәхәт. Жир эшен, авыл хезмәтен сөючеләр генә сирәк. Хәер, аларны да аңларга була. Көз-яз быкырдыкта галуш яисә резин итек киеп, пычрак ерып йөргәнче, чиста һәм шома асфальтта модный ботинка, затлы туфли белән текелдәвең күңеллерәктер шул...

— Күңелсез монда!

—Рәхәт эзләп калага киттең, фермада эшләргә тиешле бер елыңны тутырып та бетермәдең, — дип орышкан булды аны Нариман.

—Әйе, киттем! — дип кырт кисте Динә. — Китәргә хакым бар: минем дә кешечә яшисе, ял итәсем килә. Ни жүнле эше юк, ни ялы. Ардым мин, беләсеңме... туйдым... Син авылга гына кара!

— Ни булган аңа?

— Авыл менә шушы ташландык йорт сымак, таралып, картаеп бара...

Нариман, ирексездән, йортка күз төшереп алды. Бу — тирә-якка даны таралган Шәмсегаяннар йорты иде. Колхозда бухгалтер-кассир булып йөргән Шәмсегаяннын дүрт баласы булган. Икесе ир, икесе кыз бала. Җәйләүдә көтү көткән Заһиры белән матур гына яшәп яткан чакта шул хатын авылда су плотинасы төзүче Сәлим атлы берәүгә ияреп, калага китеп бара. Боларның мәхәббәтләре бик көчле булган дип сөйлиләр, бигрәк тә Шәмсегаян ягыннан. Булгандыр да, бәлкем, булмаса, беренче күргән кешесенә ияреп китмәс иде! Тик шунысы аяныч, көтүче Заһир дүрт яшь баласы белән өйдә үзе генә утырып кала. Баштарак түзә мужик, тешен кысып булса да түзә. Ләкин аналары була торып, ятим калган балаларның һәр көнне: «Әти, кайчан әни кайта, без бик сагындык әнине!» — дип елашуларын вә сыкрануларын ишеткәч, мескен ир, калага барып, азгын хатынын кабат гаиләсенә кайтарырга тырышып карый. Ялына да, ялвара да ул аңа. Тик файдасы гына тими. Уйнашчы хатынның бу оятсыз кыланышларына бик нык ачуы чыккан авыл халкы ана бәддога укый. Аны оялтырга, акылына кертергә теләп, партия ялчылары хәтта җыелышлар җыйнап, аны да шунда чакырып карыйлар. Ләкин ул аларның берсенә дә кайтмый. Гарьлегеннән үз-үзен кая куярга белмәгән Заһир эчәргә сабыша. Өйдә хатын-кыз хезмәтен унбиш яшьлек Айсылулары алып барган. Балалар үсеп житеп, кайсы-кая таралышып беткәч, яшәү мәгънәсен югалткан Заһир мунчаларында асылынып үлә. Иртән мунча яккан, ә кичен кереп асылынган. Шәмсегаян ирен күмәргә дә кайтмаган. Хәер, аналарыннан бик нык күңелләре бизгән балалары да аны инде чакырып азапланмаганнар. Анын турында Сәлимнән күптән киткән, хәзер ялгызы гына яши, елга бер мәртәбә җүләрләр йортында да ятып чыга, дигән сүзләр ишетелгәләп торды...

Йорт, нигез бушап калды. Кызлар кияүгә чыкты, берсе Мәскәүгә, ә берсе хәтта Владивостокка ук китеп барды. Ир-егетләрнең берсе юл һәлакәтендә вафат булды, Назыйм исемлесе, берникадәр вакыт кайтып-киткәләп йөргәләсә дә, бераздан бөтенләйгә кайтмас булды. Шулай итеп бу йорт ташландык хәлдә калды.

Заһир абзыйның йорты яр кырында урнашкан. Ике адым атласаң — инеш буена барып чыгасың! Куркыныч урын бу: монда яз саен яр убыла. Яр кыры текә: аскы урында таллар тамыр җәйгән, бик тә куе әрәмәлек. Яшьләр өчен менә дигән очрашу урыны инде бу, гашыйклар, чын гашыйклар шунда сөю анлаша. Аңардан да тын, аңардан да илаһи урынны авылда каян табасың ди!

Хәзер инде көз. Тик жылы әлегә. Лепелдәшеп сары яфраклар тама. Караңгы төшеп килә. Йорт яны — авыл пьесасы уйналган моңсу пейзаж, уйчан сәхнә бизәлешен хәтерләтә. Ишегалдын куе яшел чирәм, ә киртә тирәсен орлыкланган көрән алабута һәм инде ничәнче мәртәбә үсеп чыккан кычыткан үләне баскан. Такталары суырылып алынган киртә диварларыннан сүрән яктылык бөркелә, кара тузанга баткан тоныкк тәрәзәләре (кеше күзләремени!), күнелгә сагыш салып, еламсырап торган төсле тоела. Уртадарак ат арбасы тора, анысы да тугарылган ат сыман, төрле якка чәчелгән. Арбаның агач тәртәләре череп сынган, коргаксып кыйшайган көпчәкләре кайсы-кайда аунап ята. Кемдер шул урында учак тергезгән, кирпеч өемнәре тезеп, шашлык та пешереп караган. Ләкин аңар карап кына, бу йортка барыбер жан кермәгән, әллә ни ямь өстәлмәгән. Мунчаның карарлыгы да калмаган: моржасы ауган, түбәсе ишелгән, бурасы янтаеп, яр ягына авышкан. Әлеге мунча белән ташландык йорт эчендә Заһирның өрәге йөри сыман: очрашып күрешергә килгән яшьләр беркайчан

да шушы куркыныч бусагадан ары узмыйлар. Йорт ишегенә тимер кәлә генә салынган, йозагы юк, теләсән әнә ач та кер! Тик йорт эченә кереп, шунда «кунак» булып чыгарга теләүче генә юк. Кайчандыр мәет чыккан ташландык йортта анын өрәге йөри һәм ул үзенә дәшә, диләр. Юк, өрәк кенә куркытмый кешене, кеше әнә шул иске, ташландык йортны күреп, күнеленә чиркангыч ят хис, сагыш йотудан курка...

— Авылда яшәмәслек түгел әле, — дигән булды Нариман, — яшәргә була. Яшьләргә йорт та салып бирә колхоз... Әгәренки... әти-әниләр белән яшәргә читенрәк булса, дим инде...

—Яшәгән кеше яшәсен авылда, минем бер сүзем дә юк, — диде кыз, сүзенә нокта куярга теләп. — Ә минем бу дөньяда үз уем, үз хыялым бар...

—Хыялын нинди дип сорап тормыйм... билгеле инде... китүдер...

— Юк, ул гына түгел...

— Ә нәрсә тагын?

— Әйе, минем калада яшисем килә, авылда каласым килми! Нишлим!? Мона мин гаепле түгел. Әйтик... менә бер генә мисал... Син беләсен, мин мул итеп, матур итеп киенергә яратам. Әгәр дә мин шулай модный киенеп, авылга кайтсам, авыл халкы мине анламаячак, мина көлеп карыячак. Юк, мин аларга үпкәләмим, чөнки алар аны күрмәгән. Ә калада мин шул киемемдә рәхәтләнеп йөрим, мина беркем дә кырын карый алмый, чөнки кала мине шулай кабул итә. Анладынмы?

— Шулмы бар булган хыялын!?

— Юк, бу бер мисал гына...

— Әгәр хыялын шул гына икән, жаным, буш хыял бу. Кала стилягалары янында син барыбер ала карга булып күренерсен.

—Син мине анламыйсын, анларга да теләмисен! — дип авызын турсайтты Динә һәм, каударланып, торып та басты. — Син егет кеше, ә мин кыз. Сезгә авылда яшәве жинел, сез...

— Кайтырга теләмисен инде?

— Юк.

— Димәк, чыкмыйсын... мина?

— Юк... алай түгел... Мин яратам сине, мина синен белән рәхәт, тыныч. Әйтеп анлаттым бит инде мин сина барсын да... әйттем...

— Нәрсә әйттен!? — дип шаулады Нариман. — Синен әле мина өзеп кенә бер сүз дә әйтмәден!

— Әйттем бит инде... Шәһәргә китеп башта урнаш!

— Ярар, урнаштым ди, шуннан!?

— Менә шуннан сон, мин сина чыгачак!

— Их, Динә, Динә!

— Ачуланма мина, Нариман, шартым ул хәтле үк авыр түгел лә! Әгәр дә син мине чын-чынлап яратсан, әгәр дә мине анларга теләсән, аны гына үтәве әллә ни читен булмас...

Каядыр еракта авыл башында берәү өзләреп гармунда уйнады. Авыл көен уйнады ул, озату көен! Кынгыраулы гармун чыннары йөрәкне телгәләп үтте. Каян чыга диген син гади генә бер гармуннан шул хәтле мон, каян?

—Рөстәмне армиягә озаталар, — диде Нариман, — бүген яшьләр барсы да кызмача булачак...

—Безне дә чакырдылар алкага, ә синен шунда барасын килми!?

—Мин аракы эчмим, кеше эчкәнне дә карап утырырга яратмыйм.

—Алкага эчәр өчен генә бармыйлар, күнел ачар өчен баралар. Ә син минем күнелне ачасы урынга, миннән сорау алып утырасын. Әле урыны урын булса иде! Шәмсегаяннар йорты каршында...

Кинәт кенә карангы капты. Ул гел шулай була инде! Инеш ягыннан иләс жил исеп куйды. Чирәм өстенә коелган яфраклар, шыштырдап, күгәрек йозакка ябылган ватык капка турысына тәгәрәделәр, саташып, багана тирәсендә бөтерелделәр дә, арык тәгәрмәч өстенә килеп өелделәр. Гармун тавышы каядыр еракка китеп югалды, аның көен шыксыз жил һәм жир гүләве алыштырды. Артта кемнендер боегып басып торганы, ишек артында кемнендер сак атлаган аяк тавышы ишетелгәндәй булды. Кара шәүләне хәтерләткән бер нәмәстә, ябырылып, киртә авызын каплады. Динә, куркып, Нариманга сыенды. Егет (шуны гына көткән сыман!) кызны кочагына кысты...

— Нишләп монда соң без? — дип пышылдады Динә.

— Монда тынычрак булыр дигән идем лә...

— Тапкансың тыныч урын!

— Туйганчы бер кочаклыйм сун үзенне!

— Тукта әле! — дип тынычсызланды Динә. — Анда кемдер йөри кебек...

— Шәмсегаян апайны жирләгәннән бирле, кешеләр бу йортны әйләнеп уза башладылар...

— Нигә?

— Жен-пәриләр йөри, имеш...

— Шаярмале...

— Шаярмыйм бит, дөресе шулай...

Ә дөресе шул иде. Авылын һәм гаиләсен ташлап, азгын ир артыннан ияреп киткән Шәмсегаян авылга кайтып үлде. Сәлимнән качып, берничә ел жүләрләр йортында ятып чыккан хатын кинәттән генә авылга кайтып төште. Аның кайтканын күрүче дә булмаган, кешеләр сөйләве буенча, ул төнлә белән кайткан. Ташландык йортта ике төн рәттән шәм уты янып торган. Аның янына беркем дә кермәгән. Өченче көнне урамда уйнап йөргән бала-чага аның өенә килеп кергәч (күрәсен, белештермичә!), хужабикә: «Әй, балаларым кайтты, сөекле балаларым, әйдәгез, табынга узыгыз!» — дип бала-чаганы чуен мичкәдә пешкән кабыклы бәрәнге белән сыйларга тотынган. Бәрәнгеләрне тәлинкәләргә бүлеп салган. Тәлинкәләре шакшы, китек, өстендә кара тараканнар чабыша. Чал чәчләре тузгыган хатынның чырае да кешечә булмаган, ул балалар өчен куркыныч булып тоелган. Ялгыш кына адашып кергән балалар, чыр-чу килеп, барысы бергә урамга чыгып йөгергәннәр. Бу хәбәр шундук авылга таралган. Берәр сәгатьтән аның сәер куышына, балта-сәнәкләр күтәреп, авыл мужиклары бәреп керәләр, һәм шунда башын өстәлгә салып, мәрткә китеп утырган хатынны күреп өнсез калалар. Күтәреп карасалар, ул инде үлеп ята. Хәер, боларның барсы да кеше сөйләве аша гына билгеле. Күбесе моның уйдырма, ялган сүз булырга да мөмкин. Ләкин Шәмсегаянның авыл зиратында күмелүе хак. Нариман аларын хәтерләми, ул чакта шактый яшь иде әле ул. Мәрхүмәнең кайда күмелүен инде беркем дә хәтерләми, аның кабере дә билгесез. Кабер ташы куелмаган (кем куйсын инде анар!), ә кабер тактасы инде күптән черегән, күрәсен. Әлеге сәер хатын турында дөньялыкта бик күп сүзләр, бик зур гайбәтләр йөри һәм аның сере әлегә тиклем ачылмаган. Сүз дә юк, тора-бара ул сер дә бер ачылыр. Нариман өчен шунысы мәгълүм: Шәмсегаян жансызлыкның бер корбаны. Жансызлык... жансызлар... бәхетсез жаннар... Каян килеп керде соң бу уй аның башына? Каян һәм кайчан?

## 2

Алар сонга калып килделәр. Мәжлеснең кызган чагы гына иде. Бу совет илендә бөтен нәрсә эчүгә һәм юуга корылган. Диплом алсан юу, комсомолга керсәң юу, туган көнен житте икән — юу, ә армиягә китсән,

анда инде икеләтә, өчләтә! Ә бит аракы эчүне, хәмер кабуны безнең борынгы бабаларыбыз кайчандыр нәрсә икәнен дә белмәгәннәр, авылда булса бер сәрхуш булган, анысы да аның җүләр-җүнкә генә. Чөнки дин көчле, әхлак көчле. Большевиклар әнә шул рухи хәзинәне чүп базына чыгарып түктеләр. Хәзер авылда аек кеше табалмыйсың, барысы да эчә, хезмәт бәясе дә аракылата түләнә. Эчүне безгә урыслар такты, һәм ни кызганыч, без дә аларга иярдек. Ә татарга бөтенләй эчәргә ярамый, татар аракы эчеп кырыла. Урыс халкы гомере буе эчкән, ул шунар күнеккән. Алар аракыны тозлаган кыяр һәм кәбестә кабып эчә, ә татарлар гөбәдия белән чөмерә. Тозлаган кыяр, кәбестә кандагы спиртны йота, аны ваклый, ә менә камырдан ясалган гөбәдия тәнгә агу булып ята. Үзгә халыкның аракыга иммунитеты көчле, әлеге иммунитет аларда гасырлар буена яшәп килә, ә татарның аракыга каршы торырлык геннары юк, аракы татар өчен агу ул.

Чәчен төбенә тиклем кырдырып аткан Рөстәм, хәлбуки, бүген игътибар үзәгендә иде. Ул Нариманга туган тиешле кеше. Атасы ягыннан. Нариманның атасы Халик моннан биш ел элек һәлак булды, «К-700» тракторы астында калды. Андый дәү, гигант тракторны кем уйлап тапкандыр, аның бер көпчәге генә дә ике «Жигули» зурлыгында. Авыр, җайсыз, кыр өстен изеп, таптап йөри, икеләтә күп яга. Шул хәшәрәт астына «Урал» мотоциклы белән килеп керде аның атасы. Күкрәгеннән сытып, эчен тишеп, баш миләрен як-якка чәчкән иде хәшәрәт. Атасы бригадир иде аның. Артык кырыс һәм бик тә таләпчән. Таләпчән кешене авыл халкы бигүк яратып та бетерми. Үзе килеп кермәгән, үтергәннәр, дигән сүзләр дә йөрде. Андый дәү трактор кабинасыннан «Урал» мотоциклы да чыпчык булып кына күренгәндер шул. Хәер, тракторчыны гаепли алмадылар. Шуннан бирле күралмый Нариман «К-700» тракторларын! Мәктәпне бетергәч, аны да шунар утыртмакчылар иде, тик ул аяк терәп каршы торды. Соныннан —«Беларусь»ка утырды...

Алкага авылның бөтен яшьләре дә җыелган. Табын өйдә әзерләнгән, ишегалдында — бию мәйданы. Каяндыр стерео магнитофон табып алып кайтканнар, тимер капка624ның ике ягында ике зур динамик эленеп тора. Аннан нигәдер татар көе, авыл көе түгел, ә чит ил көе агыла. Җитмәсә, тавышын бар көченә куеп, аны бар көченә акырталар. Яшьләр шул музыкага боргаланып, селкенеп торалар иде. Кем генә юк монда: борын асларына яңа гына мыек чыгып килгән, кызлар исен сизенеп килгән тугызынчы һәм унынчы сыйныф малайлары, армиядән кайтып, инде кызлар кочып йөргән житез егетләр, өлгереп, пешеп житкән, инде күкрәкләре калкып торган япь-яшь кызлар да житәрлек иде. Ләкин алар арасында ике чит егет тә күзгә шәйләнә: берсе (музыка янында кайнашканы!) шактый ябык, чырайсыз, битен җирән сакал баскан, зәңгәр джинсы, чуар батник кигән, ә менә икенчесе озын буйлы, усал чырайлы, нык, таза гәүдәле һәм аның спортчы икәнлеге әллә каян күренеп тора иде.

Рөстәм Нариманны да, Динәне дә кочаклап каршы алды. Соңлап йөргәннәренә шелтә белдерде. Аннан ул аларны табынга чакырды, һәм билгеле ки, эчәргә кыстады...

— Әйдәгез, өйгә!

— Беләсең бит инде!

— Нәрсә?

— Эчмәгәнне!

— Ә Динә?!

— Динә дә шул! — дип каршы төште Нариман. Тик озак сөйләшергә ирек бирмәделәр, яшьләр Рөстәмне, шундук өстерәп алып, түгәрәк эченә алып кереп киттеләр. Динә дә шуларга иярде. Нариманга тимәделәр. Авылда аның күңел ачарга, биергә яратмаганын барсы да яхшы белә иде. Ул ялгызы

гына кырыйда басып торды. Шул чит ил музыкасын жене сөйми иде анын! Тыеп та карыйлар шуны, ләкин барыбер акырталар. Магнитофон янында бөтерелүче кала егете алып кайткан, күрәсең, аны, авылда андый музыка тынлаучы сирәк. Инде хәзер менә бу авыл гыйбадлары да, әлеге музыкаль күчтәнәчкә бик нык сөенешеп, шунар биеп, селкенешеп торган булалар. Янәсе, болар чит ил музыкасына бииләр! Клубта бервакыт яшьләр шундый музыка акырта башлагач, Нариман бик каты тавыш, җәнҗал чыгарып алган иде. Ул магнитофоннын шнурларын өзеп ташлап, тавыш динамигын тәрәзәдән атты. Аппаратура кешенеке түгел, клубныкы булып чыкты. Яңа алганнар. Клуб мөдире аның тәмам җанына төште. Ремонтларга туры килде. Милициягә хәбәр итәргә курыктылар, чөнки Нариман авылны кулда тотып тора иде. Күнел ачарга дип төшкән яшьләр, татарчага биеп булмый бит, дип зарланышкан булалар. Ә ничек булмасын икән!? Нинди генә бию көе юк татарда! Ә юк, татарча бию модный түгел икән хәзер, һәм дә ки, чикерткә сымак, чит ил музыкасына сикерергә кирәк!

Күзләре белән Динәне эзләгән Нариман, үзе дә сизмәстән, биючеләр төркеме янына килеп басты. Алар арасына берничә авыл егете кушылды. Кул биреп күрештеләр. Егетләрнең берсе Һади, икенчесе Зиннур исемле иде. Һади, армиядән кайтканнан бирле, колхозда хезмәт итә. Ә Зиннур, зимагур (кушаматы да шундый!) ике арада калды: ни салада калырга, ни калага китәргә белмичә йөри. Бер кайта, бер китә, һәм әле һаман да җүнләп урнаша алганы юк. Һади кечкенә буйлы, нык, үҗәт, кермәгән тишеге юк. Зиннур уртача озынлыкта, ак чәчле (авылда аны акбаш дип йөртәләр!), еламыйча бер генә эш тә эшләми, бер пешмәгән, булдыксыз егет кәмәше иде шунда. Һади белән алар музыка мәсьәләсендә дә капма-каршы фикердә иделәр: Һадига, әйтик, андый музыка ошамый, ә Зиннурга барыбер. Ләкин алар нигәдер дуслар, аларны авылда Агылый белән Тагылый дип атап йөртәләр иде.

— Бу ике егет кемнәр сон? — дип сорады Нариман алардан.

— Тазасы Хамис, ябыгы Альфред! Икесе дә — Казаннан... — диде Зиннур.

— Кемнәргә кайтканнар?

— Шәкүрләргә. Альфред Шәкүрнен абыйсынын малае.

— Ә тазасы?

— Анысы ана ияреп кайткан. Корешлар...

— Нindiрәк?

— Болай ярыйсы егетләр...

— Масаерга яраталар! — дип сүзгә кушылды Һади. — Бер сүз әйтергә ярамый, шундук кабынып китәләр. Иркәнең энесен шушы җүнсезләр кыйнады бит инде...

— Андый нәрсә бар инде аларда! — дип өстәп куйды Зиннур.

—Туктагыз әле! — дип фикер йөртте Нариман. — Бу манкалар шулай авылга кайтып, безнең егетләрне кыйнап йөрергә тиеш димени! Кая карыйсыз сез? Нишләп чара күрмисез?

Агылый белән Тагылый башларын аска иделәр. Янәсе, алар гына нишләтә ала инде!?

— Алар монда Наполеон булып йөрергә тиеш түгелләр, анлыйсызмы! Казаннарында шулай йөрсеннәр!

Яшьләр сикерешеп, биешеп ардылар. Шуны сизеп алган Альфред тиз генә пластинканы алыштырып куйды. Мәйданда — тын көй, ягъни «медляк» янгырады. Урысча бу биюнен исеме «белый танец» дип атала иде. Мондый биюгә егет түгел, ә кыз егетне чакыра. Динә, уч иткәндәй, Нариман каршына килеп басты. Нариман селкенмәде дә — ачулы күзләре белән Динәне ашады.

Кыз, елмаеп, бер Һадига, бер Зиннурга карап алды. Янәсе, сез ничек? Тегеләр, юк дип, баш селкеделәр. Нариманның йөргән кызы белән «белый танец» биеп йөрергә җуләр түгел бит инде алар! Ә Динә (кирәк бит әй!), үпкәләп диярлек, шундук теге кала егете, таза Хамис янына авышты. Ачу чыгарып, әле шуның алдында тез чүккән була! Егет, карышып-нитеп тормады, Динәне тиз генә эләктереп, түгәрәк эченә алып кереп китте. Нариман, шыгырдатып, йодрыгын кысты. Динәдән мондый ук мәнсезлек көтмәгән иде ул. Бию беткәнче, тыныч кына басып торалмады. Музыка куючының маңгаен ярып, аппаратурасын пыран-заран китерәсе килде аның! Чак кына тыелып калды. «Медляк» бетүгә үк, ул Альфред каршына барып басты.

— Ыслушай, бырат!

— Ыслухаю, бырат!? — Аның чыраенда мыскыллы елмаю чагылды.

— Синең башка музыкаң юк мәллә!?

— Ә нәрсә?

— Татарчаң бармы!?

— Татарча!? — дип тел шартлатты диск-жокей. — Татарча — Арча да гына, быр-р-ат!

Нариман чак кына аның яңагына сукмыйча калды. Ләкин арадан берәү шулчак:

— Егетләр, әллә гармунга биеп алыйкмы!? — дип кычкырды. Барсы да кауглаланып: «Әхмәт кая, Әхмәт?! « — диештеләр.

Әллә каян гына Әхмәтне табып килделәр. Артсыз урындыкка утыртып, кулына хромка тоттырдылар. Әхмәт дигәннәре кытайга охшаган кысык күзле, хатын-кыз күзе төшмәслек чырайсыз гына бер адәм иде. Инде кырыкка житте, әле һаман да өйләнми. Шәп егет, жырга-моңга гашыйк. «Ыслух»ы менә дигән! Нинди генә җыр көйләмә, ул аны шундук уйнап куя. Баягынак авыл башында гармун сыздыручы да ул булгандыр әле, чөнки аныңча оста уйнаучы юк иде авылда. Мәжлес яисә концерт кебек нәрсә булса, барсы да ана йөгерә. Карусыз үзе, гармунын күтәреп килә дә житә. Кайбер «күркүлләр» сымак, акча сорап та интектерми. Аракы эчми, бирсәләр алып кайта. Авылда аракысыз яшәп булмый, трактор чакыртып, бәрәңге жиренне генә сукалатсаң да, яртысыз котылам, димә.

Әхмәт үтүкләнгән кәчтүм-чалбарына кызыл төсле аш жәймәсе җәеп, башын кырын ташлап, гармунда уйнарга тотынды. Бию көен су урынына эчә, ара-тирә, дәртләнеп китеп, хәтта импровизация дә ясап алды...

Яшьләр тупырдашып биешкән арада Динә Нариманга килеп елышты. Гаепле кеше сыман, башын аска иеп, нишләргә белмичә егете янында ышкылып торды. Ул ана күтәрелеп карарга да курыкты. Нариманның холкын яхшы белә: аныңча эшләмәсәң, бәла киләсен көт тә тор! Кызу канлы: тиргәү генә түгел, сугып егарга да күп сорамый. Әнә хәзер дә аның ана бик нык ачуы чыккан, котырыныр хәлгә житеп, тәмам тулышкан. Сөйгәненең жайларга теләгән кыз учы белән генә егетнең терсәк кырына ябышып, башын жилкәсенә салды. Хатын-кыз шул, белә ир-атны кай яктан алырга кирәген! Ачуыннан шартларга житешкән Нариман акрынлап кына эреде. Юк, ул Динәне кочакламады да, үпмәде дә, тамагын кыргалаган булып, жиңелчә сулыш алырга тырышты. Кинәт дөнья жиңеләеп киткәндәй булды! Ләкин анысы да вакытлыча гына булган икән...

Әхмәт гармунда уйнап, яшьләрне биетеп туктарга да өлгермәде, теге сакаллы малай, рөхсәтсез-нисез, кабат магнитофонын кушты. «Бони-М», имеш! Нариман, Динәне ташлап, дәү адымнар белән, диск-жокейга таба атлады. Атлау дип кенә әйтеп булмас иде аны, бу чын-чынлап кешегә ташлану, һөҗүм итү белән бер иде. Ул музыкага да, магнитофонга да кагылмады (кемгәдер ошый икән, биесеннәр!), ә Альфредны, күлмәк

якасыннан эләктереп, жилтерәтеп диярлек, каралты-кура артына алып чыгып китте. Күпләр моны сизми дә калды.

— Син нәрсә тагын шул музыканны куйдың?! — дип акырды ул аңа.

— Яшьләр сорый...

— Сорый торганнардыр, бер сүзем дә юк, — дип аңлатырга тырышты ул сакал малайга, — әле бит бию көе дә бетмәгән иде, ә син тагын шул шайтан музыкасын китереп тыктың!

— Син нәрсә, бырат, ычкындың мәллә! — дип тыпырчынды Альфред. Ул Нариманның музыка өчен генә түгел, ә гомумән бәйләнәсе килгәнен аңлады. Мондый нәрсәнең яхшылык белән бетмәгәнен сизгән диск-жокей, ярдәм көтеп, тирә-ягына каранды. Кинәт кенә һөҗүмгә күчкән дошманын ул башта исерек дип уйлады, ә исеректән, мәгълүм ки, теләсә нәрсә көтәргә була!

— Сакалың өзәм, ыслушай!

Озак та үтмәде, алар арасына Хамис килеп керде. Альфредтан ике баш югары булган бу әзмәвер, күкрәген киереп, дустын дошманнан, биек дивар сымак, каплап куйды...

— О чем базар?!

— А... ф... тум...

Урысча, ягъни калача сөйләшкән кешеләр янында әзрәк каушабрак калырга гадәтләнгән Нариман бу юлы да бер мәлгә югалып калды. Юк, ул курыкмады, өнсез дә калмады, бары тик беразга сүз куәсен югалтты. Шул арада, эшне сизенгәндәй, болар янына авыл егетләре дә йөгереп килделәр. Кала этләреннән бигүк өркемәсә дә, Һади белән Зиннурның якында басып торулары, аңа ниндидер көч өстәде. Аларга Динә дә ияргән иде, тик аны шундук куып жибәрделәр. Ир-атлар арасында була торган бәхәскә хатын-кызны катыштыру кирәк нәрсә түгел иде. Шулчак эшнең зурга киткәнен аңлап алган бер яшь жилкенчәк өйдән Рөстәмне дәшеп чыгарды. Совет армиясенә чакырылган рекрут: «Егетләр, сез барыгыз да минем кунаклар, әйдәгез, тыныч кына ял итик инде!» — дип үтенеп сорагач, бер-берсе белән каты гына бәрелешергә торган ике як та, тынычланып, әкрен генә таралышырга мәжбүр булды. Ул арада музыка да туктады. Яшьләр, дәррәү килеп, өйгә, табын артына кереп тулдылар. Нариманны ничек кенә кыстасалар да, ул өйгә кермәде, Динәсен житәкләп, урамга чыгып китте...

— Нишләп син шундый соң, ә!?

— Нигә!?

— Кешечә генә кыланырга ярыйдыр бит инде...

Нариман: «Кешечә кылану ничегрәк була соң ул?» — дип кайтарып сорарга теләсә дә, бу юлы дәшмичә калды. Йөрәген ашаган шул жүләр көнчелеге, кала этләренә булган чиксез ачуы тиз арада эреп юкка чыкты. Аның хәзер, авыз ачып, аның хакында сөйләшәсе дә, хәтта сүз дә эндәшәсе килмәде. Ул иң элек бер генә нәрсәдән, Динәсен югалтудан курка иде.

— Рөстәм дә китә инде...

— Рөстәм китер дә, кайтыр да! Ул әллә кая китми, армиягә генә китә! — диде Нариман. — Менә син кайтырсың микән... бер киткәч?

—Без синең белән сөйләштек түгелме соң!? — дип монсу гына елмайды кыз.

— Нәрсә дип?

— Икәү бергә китәбез дип...

— Мин сиңа китәм, дип вәгъдә бирмәдем...

— Димәк, син мине яратмыйсың...

— Яратам...

— Мине түгел, авылны...

— Авылны да, сине дә, Динә...

### 3

Ана арттан китереп тарттылар. Динәне өенә хәтле озатып, кире кайтырга чыккач булды бу хәл. Урам чатыннан борылган гына иде, муен асты артына шап берне! Карангыда суктылар! Шактый каты эләкте! Дошман кулында йомарланган корыч корал — кастет ук булды, ахрысы, коры кул белән генә шул хәтле каты итеп сугып булмый. Әле ярый аның җуеп егылмады, егылса, типкәләп, имгәтеп үк киткән булырлар иде. Егылмады Нариман, аягында басып калды. Борылып, артына карарга итенгән иде, муены чыртлап куйды һәм, яман каты итеп, авыртырга тотынды. Аптырагач, ул муенын катырып, мөчәсе белән борылды. Каршысында, биш метр гына арада күкрәген киереп кунак егет Хамис, ә аның артында яшеренеп Альфред басып тора иде. Карангыга күз тиз ияләшә, диләр, ул аларны бик тиз танып алды. Кала белән сала арасында буталган Зиннур-Зимагурның: «Сак бул син ул егетләрдән, перваклар алар!» — дигән сүзләре искә төшкәч, ул, ирексездән, калалагы яман аты чыккан группировкалар турында уйлап куйды. Ләкин бу ике шакалның берсе дә группировка малайлары түгел иде. Авылга кунакка кайтып, без перваклар, дип дан эстәп йөрүчеләр генә иде алар.

— Ну, как, колхозник, эләктеме!? — дип мыскыллы елмайды тазасы.

— По ходу, да! — дигән булды ябыгы.

— Авызың ачканчы, уйла башта!

— А может на мировую...

— Әйдәгез сун...

Нариман беренче булып кул сузды. Дошманнар моны көтмәделәр, билгеле, аны, шүрли икән бу, дип уйладылар. Ләкин ялгыштылар. Хамис шуна алданып, аңа якынаюга ук, Нариман аягы белән аның тез астына китереп типте. Нидер чыртлап сынды. Тез асты аякның иң йомшак һәм иң зәгыйфь җире. Бу ысулга ул бригадир атасыннан өйрәнеп калды. Колхозчылар бер генә бригадирны яратмыйлар, аны гел мыскыл итәргә генә торалар. Бервакыт тракторчы Гайфине, җирне сай сукалаганы өчен, трактордан алып бәргәч, өч-дүрт исерек, җыйнаулашып, бригадирны кыйнарга дип килгәч, әтисе Халик аларны ике-өч минут эчендә, барсын да диярлек, җиргә түшәп салды. Тез аслары имгәнгән колхозчылар ай буе чатанлап йөрсәләр дә, бригадир өстеннән шикаять язарга курыктылар. Шуннан бирле аны мыскыл итүчеләр азайды, ә хөрмәт итүчеләр, киресенчә, күбәйде генә. Менә шушы шакалларга да шундый бер шәп сабак укытырга теләде ул. Хамиска шактый каты эләкте, күрәсең, ул, авыртуга түзә алмыйча, башта бик яман каты итеп кычкырды, аннан соң тез башын тотып, җиргә чүкте. Нариман Хамис каршына барып басты, тегесенең (кыйнарга тели дип уйлады, ахрысы!) куркудан күзләре акайды..

— Без егылганны кыйнамыйбыз, бырат, сез генә ул егылганны изәсез! Бар, бүтән бу авылда күренмә! — дип, ул Хамисны тартып торгызды. Шулчак җигүле ат артыннан өреп барган ләңгелдек әнчек сыман:

— Казанга гына кил! Без сине изәчәкбез! — дип Альфреды чәңгелдәргә тотынды.

Нариман озак уйлап тормады, җирдә аунап яткан бер таш кисәген кулына алып, Альфредка томырды. Тегесе чырулап алга томырылды. Төзәмичә генә аткан таш тегенең нәкъ аркасына килеп төште, качкын, әнчек сымак чинап, күрше тыкрыкка кереп югалды. Хамис исә, бер аякка чатанлап, бар көченә сүгенә-сүгенә, әнчеге артыннан иярде...

Нариманны таң белән уяттылар. Мәктәптә гомере буе балалар укыткан, инде хәзер пенсия яшенә җитеп килгән Хәлимә ханым:

—Тор, әйдә, сонга каласын! — дип тәмле йокысыннан изрәп йоклап яткан улын төртеп уятты.

— Кая? Эшкәме?

— Эшкә! Ә кая тагын?

—Рөстәм китә бүген, озатасы бар, әбәткә тиклем зәбкә чыкмыйм...

— Сун... Әбәт житеп килә бит инде!

— Ай!!!

Нариман, армиядәге солдат сыман, ялт кына сикереп торды һәм ыштан бауларын эләктерә-эләктерә, урамга чыгып йөгерде. Капка төбендә халык жыйналган, шунда «ГАЗ-51» машинасын китереп куйганнар. «Китмәгән әле!». Нариманның йөрәге жылынып китте. Озату кичәсендә утыра алмады, капка төбеннән генә булса да озатып калырга кирәк егетне! Йоласы шундый: туганмы, туган түгелме, бер-беренне озата белү зарур. Халык шактый күп жыелган. Күбрәк яшьләр, Нариманның яшьтиләре. Машинага утырыр алдыннан, митинг сыман бер нәрсә үткәреп алдылар. Башлап сүзне парторг абзыйга бирделәр. Карт чырайлы, күзлекле агай, бик тәмләп һәм озак итеп, матур сүзләр сөйләде. Ир-егетнен армиягә баруы, ил алдындагы изге бурычын үтәве анын намус эше булуын анлатты. Абзыйнын тел төбендә әнә шул нәрсә ята иде. Яшьләр аны бигүк тынларга теләмәсәләр дә, йоласы шул булгач, башларын аска иеп басып тордылар һәм хәтта соннан кул да чаптылар. Парторг сөйләп бетергәч, капка төбендә ыгы-зыгы китте. Рөстәм, кочаклашып, берничә кат әти-әнисе, туганнары белән саубуллашты. Нариман белән ул коры гына хушлашты. Күрәсен, кичәге хәлне ул да оныта алмаган. Аннан сон аны яшьтиләре, дуслары сырып алды. Алар Рөстәмне күтәреп алып, кузов өстенә чөйделәр. Анын артыннан барсы да машинага менеп төялде. Басып торырга урын да юк иде. Алар инде егетне районга, хәрби комиссариатка хәтле озата барачаклар. Бертуктаусыз жырлашалар, акырышалар. Жырлый белмәгәне жырлый, бии белмәгәне дә биегән булып маташа. Машина кузгалып киткәч кенә, капка яны тынып калды. Китүчеләргә караганда, озатучылар азрак иде. Рөстәмнен сөйгән кызы Жәмилә (ул авылда башлангыч класслар укыта) районга хәтле бармады, исерекләр арасында кысылып барырга яхшысынмады. Ни әйтсән дә, укытучы кеше бит! Ул кулын болгап, машина артыннан берникадәр атлап барды да, бер урында туктап, батып калды. Яшьләр төялгән машина авыл башын узып, кыр юлына кереп күмелгәч, дөньясы жиненәеп калгандай булды. Һәрхәлдә Нариманга шулай тоелды. Ә менә кадерләп үстергән баласын кеше белмәгән, күз күрмәгән жирләргә чыгарып жибәрү ата-анага жинел булды микән? Әйе, әнә шул армиягә китүче һәм аны озатучыларнын:

Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде томаннар,
Исән булсак, бер кайтырбыз,
Сау булыгыз туганнар...

— дип жырлавы әле һаман да аларнын жаннарына мон салып, колакларында янгырап торыр. Тик ин аянычлысы шул: «Ике генә ел бит, туганнар, ике ел нәрсә инде ул!?» — дип сөйләнгән Рөстәмнен, сонынан Әфганга эләгеп, мәете цинк табутта әйләнеп кайтуын алдан белсәләр, анын кырыс ата-анасы да, башлангыч класс укытучысы Жәмилә туташ та Рөстәм белән болай жинел генә хушлашмаган булыр иделәр. Анасы баласын кочаклап елар, сөекле яры исә яшьләр төялгән машина артыннан, кыр юлында күмелгәнче, йөгерер иде кебек. Чын ир кеше армиядә хезмәт итәргә тиеш, дип тукыган акыллы атасы да, кызыл сүз сөйләп, черек патриотизм чире белән чиләнгән парторг та азрак кына уйланырлар иде, бәлкем!?

Кадерләп, иркәләп үстергән баланны тот та шул тәмуг эченә китереп

тык әле! Ә сугыш, ялкын өркеп торган аждаһа авызы сымак, гөнаһсыз бала жаннарын суырып кына тора. Жан кирәк аларга, жан! Властьны, сәясәтне тотып тору өчен кирәк! Ә аны каян алырга? Каян!? Авылдан, билгеле! Инде кайчаннан бирле шул авылның жанын суыралар, тик әле һаман да суырып бетерә алмыйлар. Ләкин жан «капчыгы» да төпсез һәм жан чишмәсе дә мәңгелек түгел бит, жәмәгать, кайчан да булса бер тишелергә һәм саегырга мөмкин. Беркемгә дә әнә шуның ахырын күрергә язмасын иде...

4

Авылда сыерга, сарыкка кадер зур. Сарыктан әллә ни файда булмаса да, авыл халкы аны асрарга ярата. Хезмәте күп: ашатырга, көтүгә куарга, елга ике тапкыр йонын кыркырга кирәк. Йон кырку үзе бер бәла. Бетле сарыкны үтмәгән, кайралмаган кайчың белән кыркып карале син! Яшьрәк чакта Нариманга бик каты эләкте ул — сарык кырку. Өстәге алгы һәм арткы ике аягын каты итеп бәйләп, астагыларын иректә калдырып, жиргә яисә такта жәйгән идән өстенә китереп саласың да, башын каерып тотып, мескен сарыкны кыркырга тотынасың. Чыдамый сарык, бар көченә тибенә. «Чыда, чыда!» — дип кычкыра башлагач, хайван, сине аңлаган сыман, бер мәлгә тынып та кала һәм үзен кыркырга ирек бирә. Ләкин андый чыдамлык озакка бармый, теге, акыра-бакыра, кабат тибенергә тотына. Атасы сарык асрагач, анасы кая китсен: малае белән бергә ел саен ике мәртәбә сарык йоны кыркый. Шуңар күрә дә Нариман сарык яратмый. Атасы үлгәч, ул аны бөтенләй асрамый башлады. Йонын кырку гына бер нәрсә, аны бит суя да белергә кирәк. Элек күршеләрендә генә Хәбибрахман атлы мал суючы яши иде, авылда сыер-сарыкны ул чала иде. Күптән түгел ул да якты дөньядан китеп барды. Өйдән-өйгә мал суеп, кешедән кешегә сыйланып йөргәч, ул инде бөтенләй эчкечегә әйләнде, һәм шулай эчеп үлде дә. Нариман терлек суярга өйрәнә алмады, нигәдер кызгана иде ул шул жан ияләрен...

Ә менә авылда сыер асрамыйча булмый. Сөте, каймагы, катыгы, эремчеге кирәк тә кирәк. Авылда яшәп тә, сөт сатып алып булмый бит. Сыерсыз тормады алар. Атасы бригадир булганда печәнен, фуражын ат арбасына салып алып кайтса, Нариман аны, үзе хезмәт итә башлагач, трактор арбасында ташыды. Моны авылда урлау дип түгел, ә алып кайту, дип атыйлар. Колхозда азык күп, һәркемгә дә житә. Мондый ирек, мондый хөррият булганда авылда сыер асрамау гөнаһ эш, билгеле.

Нариман ат ярата иде. Техникага да шул хәтле һәвәс түгел ул, ә менә ат дигәндә, үлеп китә торган иде. Атасы гомер буе ат жикте, улын да ат жигәргә өйрәтте. Укучы бала өчен ат жигү бик жаваплы нәрсә ул, атны аны жигә белмәүчеләр дә шактый. Йокысыннан уянгач: «Олум!» — дип бер генә кычкыра иде атасы, Нариман шундук кәнүшнидән ат жигеп төшә торган иде. Бу бер иртәнге бишләр, алтылар булырга мөмкин. «Олум»ның йокысыннан торасы килми, жылы, йомшак урында әзрәк иркәләнеп ятасы килә. Юк, кая анда иркәләнү — «олум!», и бетте! Кәкре аягын (бу якларда күпләр кәкре аяклы, күрәсең, аларның ерак бабалары, атта чапканнар!) кәкрәйтеп, кәнүшнигә ат жигәргә йөгерә. Ел буе шулай. Янгырда, карда. Нариман атасына ат жигеп төшү белән генә чикләнми, кәнүшнидә атлар карап, атлар белән «сөйләшеп» йөрергә дә бик мәгъкуль иде. Яшь балага тирес һәм тир исе аңкып торган кәнүшни эчендә йөрү, калага барып, милли музей карап йөрү белән бер дәрәжәдә иде. Билгеле, монда халыкара ярышларда, күргәзмәләрдә катнашучы нәселле чабышкы атлар асрамыйлар, аларны инде монда үстереп тә, тәрбияләп тә булмый һәм аларның монда кирәге дә юк. Монда чын эш атлары, колхоз эшенә яраклы жигүле атлар асрыйлар. Айгырны, рысакны аерым бүлмәдә тоталар, көтүгә сирәк кушалар.

Бер биянен тайлаган вакытын күрергә насыйп булды ана, шундый матур колын китерде ул. Үзе кап-кара үзе, ә маңгае ап-ак. Ул аны Көмеш маңгай дип атады. Һәркөнне кәнүшнигә менеп, шул Көмеш маңгайны ашатып төшә торган иде ул. Шундагы ат караучыларны, атларны начар ашатасыз дип, сүгә-сүгә, кырдан аларга күп итеп печән чабып кайта иде. Иң яхшы азык, билгеле ки, Көмеш маңгайга!

Нариманга үз гомерендә авылда атларның бетеп, ат утарларының ябылуын күрергә дә туры килде. Кәнүшни ябылыр алдыннан мескен атларның тирескә әйләнеп барган черек саламнарны, каткан тизәк арасында чемченеп йөргәннәрен күргәч, аның шунар ничек итеп йөрәге әрнегәнен ул үзе генә белә иде. Тик ат җене кагылган Нариман дүрт аяклы дусларына гомере буена тугры калды...

## 5

Динә калага дүшәмбе көн китте.

Атнага өч мәртәбә станциягә йөрүче иске автобус ватылган булып чыкты. Нариман Динәсен «Беларусь» тракторында илтте. Дамба (өелгән юл) шул тиклем тетелгән ки, чокыр-чакырдан сикертеп барасы килмичә, ул тракторын кыр аша гына куды. Турыдан юл якын — унар километрга кыскара. Авылны чыккач ук, Сикәлтә башы дигән таулы җир бар, башта әнә шуны, шул тауны менәргә кирәк. Сикәлтәне узгач ук, гаҗәеп күренеш башлана: күз алдында зур тау асты җәйрәп ята. Киң кырлар, түгәрәк күлләр, тасмадай сузылган инешләр, күлләр, йортлар. Көзнең дә бит әле нинди матур чагы: әбиләр чуагы. Күңелләрне җилкендереп талгын гына җылы җил исә, кыр өсләрендә тезелгән салам чүмәләләре кояш нурларында, алтын сымак, җемелдәп, ялтырап китә. Бу хозурлык һәм бу матурлык калага китеп баручы кызга да: «Кал, Динә, йөрмә әллә кая!» — дигән тылсымлы сүзләр белән эндәшә сыман иде...

Тракторның тәрәзәсе ачык, кыр ягыннан җанны кытыклап җил исә. Менә ул аның сөеклесе, өзелеп сөйгән якын кешесе, күлмәк итәкләрен җилфердәттереп, терәлеп диярлек, аның янәшәсендә генә, янында утырып бара. Кая бара бу кыз, кая ашыга? «Нариман, бор тракторыңны, әйдә кире кайтыйк!» — дип кенә әйтәсе иде дә бит! Юк, кызның башында әллә нинди иләс-миләс уйлар җилкенә. Ул каядыр ашкына, уыга, әйтерсең лә шәһәр җирендә ул бик кирәк, аны анда көтеп торалар, аңа анда барсын да әзерләп куйганнар. Юк, аңа тизрәк китәргә кирәк, ул авылда калу турында уйламый да! Ул бар көченә үкереп барган тракторны да, аны дуамал йөрткән Нариманны да эченнән генә сүгеп бара. Ә инде җинел машиналарга утырган, аларны узып киткән кешеләрдән исә көнләшеп кала иде.

Нариман станциягә хәтле барып җитә алмады. Олы юлга, трассага чыккач, Динә трактордан төшеп, бер «Жигули» машинасына күчеп утырды. Поездга соңга калырга курыккан кызның теләгенә каршы килеп булмый иде. Ә каршы килергә аның хакы бармы соң? Хушлашканда кыз аны кочмады, һәм хәтта кул да бирмәде, хат язарга, шалтыратырга вәгъдә итеп, тиз генә китеп барды. Тау астында, кызу җәй айларында шактый саеккан һәм актык тамчы суларын җыйнап, Идел ягына аккан инеш кырында ул бер ялгызы гына басып калды...

Ул Динәне бик нык юксынды. Эштә вакытта ул аны әзрәк оныткалап торса да, кичен өенә кайтып яткач, Динәсен уйлап бертуктаусыз газаплана торган иде. Әле дә ярый өендә телефон бар, авылда күп кешедә ул юк, атасы бригадир булып эшләгәч, телефонны районнан килеп куйганнар иде. Динә башта һәр көнне шалтыратты, аны уйлап сагышлануын,

сагынуын житкерде. Ләкин телефон аша ул егетнен сагынуын баса алмады, киресенчә, ул анын сагышын көчәйтте генә. Ярты ай вакыт узгач, Динә инде һәр көнне түгел, атнага ике, йә бер мәртәбә генә шалтырата башлады. Сәбәпләре дә табылды. Беренчедән, ул эшли башлаган, беренче сменада, икенчедән, һәркөнне сөйләшү пунктына төшеп, анда чират көтеп утырудан да туйгандыр, күрәсен. «Үзен кил, килгәч күрерсен!» — дия торган иде ул. Динәнен шулай өздереп әйтеп куя торган гадәтен тракторчы егет яхшы белә иде.

Улынын газапланганын күреп сагышланган анасы бер көннәре Нариман белән бик ныклап сөйләшергә булды. Уку елы әле башланган гына, мәктәптә физика укыткан Хәлимә ханымнын эше алай бигүк тыгыз түгел иде. Пенсия яшенә якынлашып килгән, күзгә күренеп олыгая башлаган укытучы хатын һәрвакытта да улынын бердәнбер якын кешесе, кинәшчесе булды. Юк, ул әле дә үзенен сылулыгын югалтмаган, чөнки ул беркайчан да калынаймады, юанаймады, гел шулай чандыр булып, ябык торды. Анын мөчәсе дә, фигурасы әле дә яшь кызларныкы кебек, ләкин йөзе, бите бик нык жыерчыкланган, йөзендә исә ниндидер арыганлык, тирән монсулык сизелә иде. Олыгаюын да ул сонгы икеөч елда гына олыгайды. Нариманнын атасы үлгәннән сон, анасы бик нык бетерешсте дисәк, бигүк дөреслеккә туры килмәс. Әйе, Халик бик нык аянычлы, фажигале үлемгә дучар булды. Хәлимә иренен үлемен шактый авыр кичерде, ул бик нык кызганды мәрхүмне, төннәрен йоклый алмыйча, утырып, елап чыккан вакытлары да еш булгалады. Шулай да ул ирен бигүк яратып яшәмәде кебек. Сөйләүләре буенча, анын атасы әнисе артыннан жиде ел йөргән. Атасы бик артык матур кеше түгел иде анын, кыска буйлы, кызыл чырайлы, тукмак борынлы, холкы да ташка үлчим генә. Әнисе анын алдында патша кызы булып күренә иде. Атасы аны бик каты яратты, ә анасы анар бик исе китмәде кебек. Һәрхәлдә Нариманга шулай булып тоелды. Өйдә тавышлар да чыккалады. Бик тә ярсыган, дуамалланган чакларында атасынын: «Яратмыйсын инде син мине, хатын, яратмыйсын!» — дип өзгәләнгән чакларын яхшы хәтерли әле улы. Хатынынын жанына төшеп, канына тоз коя торган гадәте дә юк түгел иде анын. Халик, әле үлгәчтен дә, Хәлимәнен төшенә кереп интектерде. Каберенә таш куйганнан сон, Нариман колхоз пилорамында агач рәшәткәләр кайтарган иде. Шулар белән ул атасынын каберен тотып алырга уйлады. Әллә Нариманнын эше күп булды, әллә башка сәбәпләр табылды, бу рәшәткәләр, урынына куелмыйча, озак кына өй кырында яттылар.Тик менә шуннан сон фажигаи төстә якты дөньядан киткән Халик: «Нишләп куймыйсыз шул рәшәткәләрне, шунар жаным сызлана!» — дип, төннәрен Хәлимәнен төшенә кереп йөдәтә башлады. Күп тапкырлар керде. Ире гел өй янында йөри икән, шыгыр-шыгыр килеп, һаман да рәшәткәләр актара. Атасынын каберен шул рәшәткәләр белән тотып, аны яшел төскә буяп чыккач кына анын рухы беразга тынычланган кебек булды. Ләкин монысы да озакка бармады: бераздан ул кабат Хәлимәнен төшенә керде. Боз каткан елгада яланаяк йөгереп йөри, имеш. Хәлимә, аптырагач, парткомга сиздермичә генә, әбиләр жыеп Корьән укытты, укучы әбиләргә дәү-дәү калын башмаклар, жылы оекбашлар таратты. Аннан мәрхүмнен каберенә барып: «Халик, бу синен мәнгелек йортын, бүтән минем төшемә кереп борчыма!» — дип ялварып үтенгәч, ул инде анын бүтән төшенә кереп йөдәтмәде...

— Улым, — дип сак кына башлады ул сүзен. — Синен газапланганынны күреп торам бит, Динәне яратканынны да беләм, яшен инде житкән, сина башлы-күзле булырга вакыт житкәндер, дип уйлыйм?!

— Вакыт житкәнен үзем дә яхшы беләм, әни, тик чагышмаган әйберләр бар шул! — диде ана Нариман җавабында.

— Нәрсә, Динә каршымы?

— Юк, ул каршы түгел.

— Ә нәрсә тагын?

— Дөньясы каршы...

— Нәрсә булган дөньяга?

— Берни дә булмаган, әни, ләкин өйләнергә, туйлар уздырырга безнең көчебез житәр микән соң дим?

— Туйлык кына акча бар бездә, жыйган акчабыз бар...

— Кайда соң ул?

— Саклык кассасында.

— Күпме?

— Бер мең.

— Каян килеп?

— Соң... атаннан күпме калды, аннан атаң үлгәч, төрле пособиеләр алдык, мин дә ярты хезмәт хакымны шунда салып бардым. Синеке ашауга, киемгә китте... Соң син үзең дә моны яхшы беләсең!

— Беләм...

— Шулай булгач!?

— Тик шул хәтле акчабыз бар дип уйламаган идем...

Нариман аш ягында әнисе белән чәй эчеп утыра иде. Әнисе сыек итеп ясаган чәйне, ул куертып, каралтып куйды. Ул чәйне шулай каралтып, куе итеп эчәргә ярата иде. Эчте, ләкин чәйнең тәмен тоймады. Ул, тынычсызланып, чыраен сытты.

— Нәрсә, шикәре әзме әллә? — дип борчылды анасы.

— Шикәре житәрлек, үземә нидер житми! — дип кыбырсынды егет.

— Нәрсәдер житмәгәнен мин дә күреп торам, тик менә һаман да аңлап кына бетерә алмыйм, улым!?

— Аңлыйсы юк монда, әни, эш бит әле акчада гына да, туйда гына да түгел, эш Динәдә!

— Ни булган ана?

— Берни дә булмаган...

— Шулай да?

— Аның авылда каласы килми.

Хәлимә, шулайдыр дип уйлаган идем, дигәндәй, аны аңлап, баш какты. Ул берни дә дәшмәде, суынып өлгергән чәйнекне, шапылдатып, газ плитәсенә китереп утыртты да, башын аска иеп, уйга калды. Хәлнең кискенлеген анасы яхшы аңлый иде. Улы да дәшми, анасыннан җавап көтә кебек...

— Динәнең авылга кайтмаячагын беләм, — диде Хәлимә, — ләкин син ир кеше, хатының артыннан ияреп йөрмәссең дип уйлыйм!

— Ә нишлим?

— Ә өйләнергә кирәк, — дип сүзне башкага борды анасы. — Кызлар услувие куя башлагач, уртак тормыш була алмый инде ул, улым. Ир кая, хатын шунда яшәргә тиеш!

—Син дә әтине жиде ел буе чаптыргансың бит әле! — дип төрттерде Нариман. Усаллык житәрлек иде егеттә, сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел, ни әйтсәң дә, укытучы белән бригадир малае бит! Анасы аның сүзләренә үпкәләмәде, улына үпкәләүдән узган иде инде ул.

— Безнең башкачарак булды, улым, — диде анасы...

— Әни, әйт әле, ә син әтигә яратып чыктыңмы?

— Атанны хөрмәт итмәсәм, мин авылга кайтмас идем. Мин бит

институтны бетергәч үк, калада калдым. Артымнан нинди генә егетләр йөрмәде, кулымны сораучылар күп булды, тик мин аларның барсын да кире кактым...

— Ни өчен?

— Атаң хакына.

— Хөрмәт иткәнсең, ә яратмагансың!?

— Хөрмәт итү — яратудан өстенрәк. Син әле яшь, дөньяны бигүк аңлап бетермисең, олыгайгач, бер искә төшерерсең әле сүзләремне...

— Минем аның артыннан иярәсем килми, әни, ләкин нишлим соң, яратам бит...

— Нишләргә уйлыйсың?

— Өйләнсәм әгәр...

— Нәрсә?

— ... китәргә туры киләчәк...

— Киткәч китәсең инде, улым...

— Ә син?

— Ә миңа ни булган?

— Ялгыз калудан курыкмыйсыңмы?

— Юк, курыкмыйм...

Бу сүзләрен ул улына әзрәк үпкәләбрәк әйтте кебек. Үзең, янәсе, авылны яратам, дисең, ә үзең кемгәдер ияреп китәргә генә торасың!

— Әни, әгәр дә син каршы булсаң, мин Динәгә өйләнмәячәкмен! — дип сөйләнде Нариман.

— Юк, юк, син нәрсә, мин синең бәхетеңә каршы килә алмыйм, улым, өйлән...

***

Туйлар бик матур узды. Бер генә як та балаларның бәхетенә каршы килә алмады. Динә тулы гаиләдә үскән: атасы Салих атлы, анасы Сафия исемле иде. Атасы колхозда бухгалтер (авылда андыйларны «считавут» диләр!), анасы колхоз ашханәсендә пешекче булып эшли. Динәнең әле бер абыйсы да бар, Сәлихҗан атлы, анысы маржага өйләнеп, Владивосток якларында яшәп ята. Ул туйга кайтып тормады, яшьләрне туйлары белән котлап, телеграмма гына сукты. Туйны, өйдә кысан булыр дип, район рестораныңда ясадылар. Туй кыйбатка төшәр дип, анасыннан яхшысынмыйча йөргән Нариман ялгышты: ресторанда узган мәҗлес арзанга төште, һәм иң мөһиме, ул мәшәкатьсез узды. Хәтта балдакка да акча түләнмәде: партиянең яңа чыгарган указы нигезендә балдаклар яшь өйләнешүчеләргә бушлай тапшырылды. Нариман балдакны бушлай алудан баш тартып, сатып алырга талпынып караса да, Динәнең исәп-хисапны яхшы тоткан «считавут» атасы булачак киявен бу җүләрлектән бик тиз туктатты. Туй күлмәге белән генә әзрәк читенлек килеп чыкты, аны ике мәртәбә тектерергә туры килде. Башта размеры ярамады, аннан фасоны килешмәде. Төрле гайбәт, хорафатларга ышанучылар, туй күлмәге белән булган хәлне яхшыга түгел бу, дип юрарга тырышсалар да, кияү кеше боларның берсенә дә ышанмады, чөнки ул, ниһаять, яраткан кешесенә өйләнде һәм үзен чын мәгънәсендә бәхетле итеп сизде. Ул Динә артыннан озак йөрде, ләкин аңа кагылмады, минутлы хисләргә исереп, башын югалтмады — Динәне кияүгә кыз килеш, саф килеш алды. Өйләнәчәк кешесенә туйга тиклем тимәү ул кыз кешене хөрмәтләү дип санады. Ләкин туйдан соң әзрәк конфуз да чыгып алды. Зөфаф кичennән соң, урын өстенә җәелгән ак җәймәне иртән бирәү, әллә уйнап, әллә кирәк дип табып, кер бавына чыгарып элгән. Аның урта бер җирендә алсу кан таплары беленеп тора иде...

### 6

Нариман авыл белән авыр хушлашты.

Калага төпләнеп урнашканчы, ул аннан тугыз-ун мәртәбә әйләнеп кайтты. Колхоздан китәргә дип гариза язганнан соң, ул озак кына тракторын тапшыра алмыйча интекте. Яраткан техникасын начар кулга калдырасы килмәде анын. Яхшы тракторга ике-өч кеше дәгъва кылды, нәтиҗәдә, ул күрше егете Василга эләкте. Васил аңа хәтле иске ДТ тракторында йөреп маташкан, ләкин анын моторы шакылдаган иде. Нариманнын «Беларус»ын эләктергәч, ул үзен кош тоткандай сизде, бик нык сөенде, күршесенә рәхмәтләр укыды. «Кара аны, эчкән килеш тракторга утырасы булма!» — дип бик каты кисәтеп китте ул аны...

Станциягә хәтле попуткага утырып барды. Авылны чыккач ук, кыр буйлап, өелешеп, чабышып йөргән иясез этләрне күргәч, анын йөрәге кысылып куйды. Авылда иясез этләр күбәйгәч, махсус ялланган аучылар килеп, таң алдыннан урамнарда шул мескеннәрне атып йөргәннәр. Исән калганнары исә, гомерлек курку алып, бүтән авылга борылып кайтмаслык булып, кырга чыгып качканнар. Чырт иткән тавышка да сискәнгән мескенкәйләр, инде хәзер кая барырга, кая китеп олагырга да белмичә, койрыкларын кысып, зират тирәсендә бер чарасызга тулганып йөриләр иде. «Бәхетсез җаннар!» — дип эчтән генә сызланды егет, һәм нигәдер үзе турында да ул нәкъ шулай уйлап куйды...

Хезмәт кенәгәсен кыстырып, калага килеп төшкәч тә, ул җанына тынгылык табалмады. Дөресен әйткәндә, яратмады ул каланы, күңеле белән аны кабул итмәде. Ят җир, ят кешеләр, ят шәһәр, ят урам. Белмәгән урысчанны, ватып-җимереп, гел урысча гына такылдарга кирәк. Тимер юл вокзалына килеп төшкәч, утырып елардай булды. Казанны белми, каланы аңламый. Кемгәдер ияреп калага бару әле бер нәрсә, анысы җинел, ә менә шаулап торган кала урамында таныш кешесез бер үзең генә басып калу бигүк күңелле хәл түгел икән. Дулкынланудан анын хәтта, каты итеп, эче бора башлады. Кая барырга, кая барып утырырга да аңлашмый торгач, ул вокзал чатында таксига охшаган «шашка»лы бер иске «Волга» машинасын туктатты. Машина йөртүчегә нинди адрес белән кая барырга кирәклеген аңлатып биргәч, тегесе әллә ни каршы килеп маташмады, юлчысын «Волга»сына утыртты. Такси йөртүче татар егете булып чыкты. Шактый озак кайттылар. Динә үзе яшәгән тулай торакны тимер юл вокзалыннан әллә ни ерак түгел, якында гына дигән иде ләбаса. Соныннан ачыкланды: вокзалдан хатыны яшәгән йортка трамвай белән ике генә тукталыш барасы икән, такси йөртүче, Нариманнын мокытлыгыннан файдаланып, акча күбрәк каерып өчен, аны ике-өч мәртәбә шул вокзал тирәсеннән әйләндереп, уратып узган икән. Шулай итеп, өч тиенлек юл өч зур берлеккә әйләнде.

Динәгә тулай тораклан бүлмә биргәннәр иде. Ике бүлмәле. Берсе зур — урам ягына киң тәрәзә чыгып тора, икенчесе кечкенә — «глухой» як, анысынын тәрәзәсе дә, мәйданы да юк. Анысын инде склад итеп тотсаң гына, ул башка нәрсәгә ярамый. Кухня, ягъни аш ягы коридор башында, ул берничә гаиләгә исәпләнгән, ә менә бәдрәф бүлмәсе үзендә үк, аерым ясалган иде. Динә башта шушы кечкенә бүлмәгә дә сөенеп туя алмады, тик Нариман гына әллә ни зур сөенеч кичермәде. Бүлмәнен тарлыгыннан түгел, дөньянын тарлыгыннан читенсенде ул. Авылда өе генә түгел, дөньясы да киң, иркен кебек тоела иде ана. Шунын өстенә капкаң да биек, киртәң дә тирә-якны томалап тора, син кеше күзеннән дә читтә. Ә монда, кая гына барма, адым саен кеше, һәр адымын санап, һәр сүзенне үлчәп сөйләргә кирәк. Аннан ул әзрәк кыргый да иде, кеше белән бик авыр таныша, аралаша торган адәм иде. Табигате белән ул бик күп сөйләшергә яратмый, кирәк чагында анын

авызыннан сүз дә тартып алалмыйсың. Казанга килеп урнашкач та, ул әле озак кына эш табалмыйча интекте. Вакансияләр юк түгел, бар, теләсәң әнә заводта, теләсәң төзелештә хезмәт ит. Игълан буенча да барып карады. Бер үзе генә түгел, билгеле, ә Динә белән бергә барды. Хатыны бер тәүлеген эшләсә, өч тәүлеген ял итә иде. Хатынының ни өчен трамвай йөртергә кергәнен ул һич кенә дә аңламады. Транспорт йөртү, ни генә әйтсәң дә, хатын-кыз һөнәре түгел бит инде. Бу турыда ул анардан күп белеште, күп сорашты. Җавабында хатыны: «Мин укырга теләмәдем, миңа югары белем кирәк түгел, калага беренче мәртәбә килеп төшкәч үк, урамда игълан күрдем. Ярты гына ел укыйсы, торырга урын бирәләр, стипендия түлиләр. Ә нигә бармаска, бардым!» — диде. Бер-ике мәртәбә ул хатыны йөрткән трамвайда утырып йөрде, көне буе йөрде. Таныш булмаган урамнар аша йөрү үзе бер күңелле, үзе бер зур яңалык булды. Ләкин соңнан аңысыннннан да туйды, хатынына бүтән ияреп йөрмәскә тырышты. Динә өйдә булганда бар да әйбәт, бар да рәхәт. Ул назлы, ул ягымлы, иртән торып, тәмле итеп ашарга пешереп куя, аннан аны бергә утырып ашыйлар, телевизор карыйлар, серләшәләр, урамга, кибеткә чыгып керәләр. Ә менә Динәсе сменага чыгып киткәч үк, аның җанын чиксез бер сагыш биләп ала. Ул үз-үзен кая куярга белмичә, көннәр буе тинтерәп йөри, бер чыга, бер керә, вахтер хатынның нервысында уйнап, гел «вертушка» тирәсендә кайнаша. Менә, ниһаять, төн уртасында Динә кайтып керә, ул инде арган, талчыккан була, ашыгып бер чәшкә чәй каба да, ишелеп урынга ава. Көне буе хатынын көткән ир ана елыша, аның башыннан, чәчләреннән сыйпап, кочагына кыса, аны иркәләгәндәй итә, ләкин көннәр буе трамвай штурвалын тоткан, хатын-кызга хас булмаган каты, нык куллар, аны бу изге теләгеннән кырыс кына туктатырга мәҗбүр булалар. «Иртәгә, җаным, иртәгә, яме!» — дип эндәшә Динәнең кура җиләге сыман пешкән алсу иреннәре...

Нариманның эшсез утыруы аның үзен генә түгел, инде Динәне дә туйдыра башлады. Ниһаять, бер белгән кеше аркылы аны сөт комбинатына эшкә урнаштырдылар. Нариман үзе дә каршы килмәде, һаман да хатын-кыз җилкәсендә утырып булмый бит инде. Эше җиңел түгел, билгеле, иртәдән кичкә хәтле конвейер каршында басып торырга кирәк. Хәер, мәктәптә укыганда, җәйге каникулларда ат җигеп, фермада тирес түккән, комбикорма ташыган егет бервакытта да авыр хезмәттән курыкмады. Сөт заводын ул колхоз фермасы кебегрәк кабул итте. Сыер савучы апаларның сөт бидоннарын шактый күп ташыды инде ул. Монда да шул: бер литрлы сөт шешәләре унлап-унлап тимер ящикларга тутырылган һәм шулар конвейердагы транспортир буйлап бер цехтан икенче цехка күчәләр. Шуларны үз вакытында берсеннән икенчесенә күчерә барырга кирәк. Билгеле, ул зур кул көче сорый, ялкауларны, сыек куллы хөрәсәннәрне яратмый. Өендә һәркөн диярлек, берәр потлы гер күтәреп уйнаган Нариман монда да үзен сынатмады, конвейер буйлап йөзгән сөт шешәләрен, бер-бер артлы икенче якка чөя торды. Егетне күзәтеп торган цех бригадиры да аның эшеннән бик нык канәгать калды. «Маладис, сынауны әйбәт уздың, егет, кал бездә, китмә!» — дип ул тырыш авыл баласын аркасыннан сөеп мактады. Әлеге урынга җүнле кеше табуы да бик авыр икән. Кем генә килеп, кем генә китмәгән моннан! Түзә алмыйлар! Акча эшлибез дигән булып, монда хәтта студент яшьләр дә килгәләгән. Әле яна гына берсе килеп, шушы конвейерга басып караган булган, ләкин имгәнеп, чак кына ящик астында калмаган. Ящиклар бер-берсе өстенә килеп өелешкәч, конвейр туктап калган. Шуннан соң бу җебекне (үпкәләмәсен дип!) җиңелрәк урынга, каймак цехына күчергәннәр.

Хезмәт авыр булса да, Нариман заводка эшкә урнашканына сөенеп туя алмады. Бер ай узгач, аңа беренче хезмәт хакын бирделәр. Динә мул итеп табын әзерләде, ире, үзе эчмәсә дә, хатынын сыйлау йөзеннән шампан шәрабы алып кайтты. Икәү генә утырдылар, башка беркемне дә чакырмадылар. Үзләренчә беренче хезмәт хакын юулары булды бу. Төнлә йокыга китә алмыйча, озак кына сөйләшеп яттылар...

— Нариман, синең нинди дә булса хыялың бармы?

— Хыял? — дип шаккатты ир. — Нәстә соң ул?

— Хыял! Теләк!

— Бар!

— Нинди?

— Минем машина аласым килә.

— Шулмы хыялың?

— Минем өчен бу зур хыял. Нәрсә, ошамыймы?

— Ошый, бик тә ошый. Машина алу зур бәхет ул, җаным...

— Яңаны алып булмас, искене алсаң да ярар. Яңасына акчаң җитсә дә, талон кирәк шул, блат кирәк.

— Мин менә шуңар аптырыйм...

— Нәрсәгә?

— Нишләп машиналарны бөтен кешегә дә җитәрлек итеп чыгармыйлар икән? Күпме кеше акчасын учлап тотып, яңа машина ала алмыйча йөри.

— Бөтен кешегә дә җитәрлек итеп чыгарсаң, бөтен дөнья машина белән тулыр иде, — дип фикер йөртте Нариман. — Йөрергә урын, суларга һава калмас иде. Менә шуңар күрә дә артыгын чыгармыйлар, чамалап кына чыгаралар. Сөтне дә заводта кирәк хәтле генә тутырабыз, артыгы әчи генә...

— Син дә инде! — дип көлде Динә. — Чагыштырдың сөт белән машинаны!

— Сөт тә кирәк нәрсә, сөтсез торып булмый...

— Ну, яхшы, — дип төпченгән булды хатын, — алдың ди ул машинаңны... Ни өчен? Нигә кирәк ул сиңа?

— Авылга кайтып йөрер өчен!

— Синең уеңда гел шул авыл да, авыл инде. Ә мин башкача җавап ишетермен дип уйлаган идем...

— Нинди?

— Мине йөртерсең дип...

— Син дә йөрисең инде...

— Ничек?

— Минем белән авылга утырып кайтасың.

— Мине сәяхәт иттерерсең, кибетләргә йөртерсең, шулай бит!?

— Әйе... шулай...

Яшь парлар беразга тын калдылар. Алар озак кына түр башында элингән стена сәгатенең текелдәвенә колак салып яттылар. Мәскәү кремле төшерелгән бу дәү, кыйммәтле сәгатьне аларга туйга бүләк иткәннәр иде.

— Ә син нишләп сорамыйсың? — диде бераздан аңа Динә. — Минем хыялым турында?

— Ә... әйе... сөйлә...

— Беләсеңме...

— Белмим!

— Минем шә-ә-әп итеп киенәсем килә!!!

— Шулай дип уйлаган идем инде...

— Минем шәп итеп киенеп, барсын да аяктан егасым килә! Ха-ха!

— Нигә? Син миңа болай да ошыйсың!

— Бу дөньяда бер син генә түгел, жаным, мин башкаларга да ошарга тиеш!

— Ирләргәме!? — дип көнләшкәндәй әйтте ир.

— Ирләргә дә, хатын-кызларга да!

— Киенеп кая барырга уйлыйсың?

— Кая да булса ресторанга, мәжлескә...

— Кем белән?

— Синең белән!

— Минем ресторанга йөрмәгәнемне беләсең ич.

— Яхшы, син бармассың!

—Нәрсә, миннән башка гына бармакчы буласыңмы? — Бусын ул ачуланып әйтте.

—Яхшы, ресторанга бармабыз! Бауманга чыгарбыз, киного барырбыз!

— Менә әле бусы ярый...

— Тик мин шәп итеп киенергә тиеш!

— Киен инде, акчаң бар бит! — диде Нариман, бик теләмичә.

— Монда матур кием табып булмый, аның өчен Мәскәүгә барырга кирәк!

— Мәскәүгә!?

— Мин бармыйм, иптәш кызым бара!

— Ыспекулян мәллә?

— Юк, ул ай саен Мәскәүгә барып, кием жыйнап кайта. Мин ана заказ бирдем, ул иртәгә китә... «Татарстан» поездына билет алган...

— Нинди заказ?

— Джинсыга.

— Джин... ысы?

— Джинсы, чалбар, made jn USA...

— Күпме тора?

— Йөз илле сум.

— Инәнне!!! — Нариман анар күзләрен акайтып акырды. Динә, кулын алга сузып, учы белән иренен авызын каплады. Иренең тупас, ахмак тавышы аның ачуын гына чыгарды. Хәер, Нариманны да аңларга була, ул шул йөз илле сумга ай буе конвейер каршында басып торды бит!

— Нигә акырасың!? Синнән акча сораучы юк!

— Жаным, бигрәк кыйбат бит! Ун тәнкәгә дә менә дигән чалбар алырга була!

— Каян?

— «Детский мир»дан...

— Ун тәнкәлесен, жаным, син алып ки инде, яме!

— Киермен ярар! —дип мыгырданды ир. —Ләкин джинсы алуны мин зур хыялга санамыйм.

— Сүзең дөрес: бу әлегә минем кечкенә хыялым...

— Ә зурысы нинди соң?

— Зурысы алда әле, жаным...

Нариман йокыга киткәннән соң да, Динә әле озак кына йоклый алмыйча, боргаланып ятты. Тиздән аның шул кечкенә генә хыялы тормышка ашачак, джинсыга дигән, бөрәмтекләп жыйган акчасын ул инде күптән Катюшага (чын исеме Кадрия) биреп куйган иде.

Нариман аның турында онытты. Тик бер атнадан соң, Динә өйгә зәңгәр тостәге фирменный джинсы белән фирменный футболка киеп кайткач, хатынының юкка гына сөйләнеп йөрмәгәнен ул бик тиз аңлап алды. Нариман авыл мужигы һәм ул болай акча сарыф итүне күңеле белән кабул итмәде һәм шуңар күрә артык сөенә дә алмады. Чыраен сытып,

борынын салындырып торган мокыт иренә сәерсенеп караган Динә дә үзенен кем белән торганына тагын бер кат инанды булса кирәк. Әйе, алар тормышта икесе ике төрле кеше иде. Авылга булган мәхәббәтен, сагынуын йөрәк түрендә йөрткән, төшләрендә сары башаклы иген кырларын, көмеш маңгайлы колыннарын күреп уянган Нариман бу сәер кала сәясәтен берничек тә кабул итә алмады. Чит кеше иде ул бу калада һәм шулай чит булып калды да. Шунысы кызык, калада яшәгән саен, ана тизрәк ияләшәсе урынга, ул ни өчендер анардан читләшә генә барды. Ә Динә бөтенләй икенче кеше иде. Әйе, ул да ире кебек үк, авыл кешесе, авыл баласы иде. Ләкин анардан аермалы буларак, ул бөтен җаны-тәне белән кала кешесе булырга омтылды, җанында бурсык булып оялаган авылчанлыгы һәм оялчанлыгыннан тизрәк котылырга теләде. Ләкин бер көндә генә үзгәреп бетеп булмаганын ул акылы белән анламаса да, җаны белән сизә иде. Шунар күрә дә ул аны көнләкләп, тамчылап бетерергә булды. Ләкин ул әле яшь иде, ул шуны анламады: авылга булган мәхәббәт җанда гына түгел, ул бит канга да күчкән. Ә бик күпләр шуны анламыйча үзләрен упкынга китереп тыктылар, төрле фаҗигаләргә юлыктылар. Авыллыгыннан котылырга теләү ул үз-үзенне үтерү белән бер, күрәсен.

Нариман хатынына каршы бер сүз дә әйтә алмады. Динә өчен әле бу бер кечкенә генә җину иде. Ирен шулай әкренләп җинәргә һәм үз ягына аударырга уйлаган хатынны әле алда тагын да зур җинүләр көтә иде. Ләкин алар берсе дә җинел генә бирелмәс, анын өчен анар гел көрәшергә туры киләчәк. Гаилә, дөресен генә әйткәндә, ике ярны, ике капма-каршы җенесне берләштерер вә сөештерер өчен генә түгел, ә аларны көрәштерер һәм хәтта талаштырыр өчен дә төзелә торгандыр, мөгаен!?

Чынлап та, бу әле бәланең башы гына булган икән. Язлар җитеп, ташулар аккан чак иде. Депога белешмә алырга дип киткән Динә (ул сменада түгел иде) төнлә белән генә кайтып керде. Бүлмәгә атылып керде дә, урынга капланып ятты. Нариман ана тегеләй дә, болай да эндәшеп карады. Хатын озак кына эндәшмичә ятты. Анар авыр иде, күрәсен, анын күз төпләре каты елаудан шешенеп, кызарып чыккан...

— Мин эштән киттем!

— Нигә? Ни булды?

— Берни дә булмады... киттем... бетте...

— Эшенне бик ярата иден бит...

— Романтика... очты... Мин сина әйтмәдем...

— Нәстә?

— Кичә чак кына кеше таптатмадым.

— Ничек?

— Карт әби... Трамвай юлыннан чыгып килә. Мин ана сигнал бирдем. Юлдан чыгып бетәр дип уйладым, ә ул, киресенчә, чайкалып китте дә, артына утырды. Сумкасы, кулыннан ычкынып, рельс кырына килеп төште, әбинең кибеттән сатып алган ризыклары трамвай юлына чәчелде. Кисәк кенә тормозга бастым, трамвай чинап әби каршына килеп туктады. Бераз гына! И...

— Нәрсә?

—... әби трамвай астында кала иде. Салондагы пассажирлар кабинам артына килеп өелделәр: кайсы кулын имгәткән, кайсы кашын ярган...

— Үлүчеләр?

—Юк, травмалар җинелчә генә... Ләкин ике-өч кеше директорга жалыбы язып кергән. Мине бүген директор чакыртты, ярты көн шунын каршында утырдым.

— Синен гаебен юк монда, әби үзе гаепле...
— Беләм...
— Белгәч!?
— Эштән киттем...
— Ишеттем...

Ләкин Динәнең эштән китүе дөрес хәл булып чыкмады. Ул кызып кына, артык хискә бирелеп язган гаризасын кире алды һәм кабат шул «өченче» трамваенда калды.

7

Шул арада Нариман бер кызык хәлгә юлыкты: ул авылга кайтып үлгән Шәмсыяган апайның улы Назыймны очратты. Авылдашлар булсалар да, алар бер-берсен бик начар беләләр. Назыйм авылдан иртә чыгып киткән. Атасы асылынган, анасы калага китеп адашкан. Ә ин гаҗәбе шунда, шул мужик Нариманнар яшәгән тулай торакта ялгызы гына көн күреп ята икән. Депода монтер булып эшли. Аерылган. Кайчандыр ике балалы хатынга йортка кергән булган, хәзер шул хатыннан китеп, тулай торакка кире әйләнеп кайткан. Әйе, хатыннарыннан аерылган ирләрне совет заманында бары тик бер генә юл көтә, ул яшәгән фатирын бушатып, тулай торакка кайтырга мәҗбүр. Буш квадрат метрлар булган очракта, билгеле. Закон бу очракта һәрвакыт хатын-кызны яклый һәм ул дөрестәдер — балалар күп очракта гүзәл затлар тәрбиясендә кала.

Назыйм нигәдер Нариманны үз итте. Авылдаш булганы өчен генә түгел, ә ничектер үзара уртак тел таптылар алар. Алар икесе дә авылда туып, авылдан чыккан кешеләр, икесе дә тормышны үзләренчә аңлыйлар һәм шулай ук үзләренчә бәхетсез дә иде. Назыйм, калага китеп, монда әллә ни зур бәхет таба алмады. Ул ялгышып, балалы кала хатынына өйләнде, ана йортка керде. Кала хатыны аны баштарак үзенә ияләштерергә тырышса да, соңрак, балалары үсә башлагач, аны бик нык мыскыл итәргә тотынды. Кала хатыны анардан бала да табарга теләмәде. Соңгы вакытларда ул аңа хәтта исеме белән дә эндәшми башлады: «Колхозник!» — бар әйткән сүзе шул булды. Бераздан барсы да ачыкланды: беркая да эшләмәгән хатын базарда өрек сатучы кара халык белән дуслашып, туганлашып киткән. Назыймның азлап кына алган чыпчык хәтле хезмәт хакыннан канәгатьсез калган хатын Ленин башлы егерме бишлекләрне куен кесәсенә тутырып йөргән үзбәк егетен иреннән өстенрәк күрде. Яшереп кенә йөрсәләр дә бер хәл, инде ачыктан-ачык йөри башлагач, Назыйм бу хурлыкка түзеп тора алмады, вак-төяк әйберләрен җыйнап, бер көнне тулай торакка күчте...

— Хатыннан уңмасаң юк икән инде ул! — дип көрсенде Назыйм. — Бәхетең генә түгел, тормышың да уңмый...

Нариман буш вакытында аның янына кереп, авылдашы белән сөйләшеп утырырга ярата иде. Ләкин аның белән сөйләшүе җиңел түгел, чынында исә, ул авыр кеше иде. Кара чырайлы, калын кашлы, яше әле кырыктан узмаса да, маңгаен тоташ сыр баскан Назыйм шактый сәер холыклы, үзенчә бер кыргый кеше иде. Шул ягы белән ул әзрәк Нариманга да охшаган. Кызып-кызып сөйләшкән арада ул кайчак кинәт кенә үз эченә китеп, үз эченә бикләнеп, кем белән сөйләшкәнен дә онытып торган иде. Ул вакытта аның болай да караңгы чырае тагын да караңгылана, болытлана, маңгай өстен каплаган калын җыерчыклар, бер-берсенә өелешеп, тирән буразна хасил итәләр иде. Назыйм гади эшче, институтлар бетермәгән, ләкин үзгә акылы, фикерләве белән әле ул бик күп диплом ияләрен бәреп егарлык гали зат иде. Ул бик күп укый һәм күп нәрсә белән кызыксына иде...

—Юк, дустым, мин үземнең бәхетсезлегемдә хатынымны гына гаепләмим, мин бит аны үзем таптым! — дип сөйләгәнен хәтерли әле ул аның Ә сөйләгәндә ул, аудиториядә дәрес алып барган профессорлар кебек, саллы итеп, үтемле итеп, басынкы, калын тавыш белән сөйләргә ярата иде. — Минем бәхетсезлегем безнең нәселдән килә, безнең геннардан, ягъни... Син кара, анам, дүрт баласын ташлап, шул оятсыз, шакшы адәмгә ияреп, калага китте, ә инде шул хурлыкка түзә алмаган атам асылынды. Нәселебезнең борынгы шәҗәрәсенә күз салсак, анда бик кызыклы мисалларга тап буласың. Анамның бабасы калада милиция начальнигы булып хезмәт иткән, бик яман, авыр холыклы адәм булган. Ул начальник булганда ике-өч кешенең башына житкәннәр, аларны ерак түгел, шул ук милиция бүлегендә кыйнап үтергәннәр. Өч хатын аерган, соңгысын (яшен) үзе үк асып үтергән. Хатыны үз-үзенә кул салган, дигән ялган уйдырма чыгарып, абзый төрмәдән качып калган. Ләкин кылган явызлыклары, бумеранг булып, барыбер кире үзенә әйләнеп кайткан: абзый җүләрләнеп үлгән. Күп алар безнең нәселдә, сина барсын да сөйләп тормыйм. Ерак китәсе юк: әни белән ни булып бетте. Әнинең ниндидер мужикка ияреп, тиктомалдан калага китеп баруы иң элек безне, балаларны акылдан екты. Без башта берни дә аңламадык, без шулай кирәктер дип уйладык. Әти, әниегез тиздән кайта, балалар, чынлап әйтәм, кайтачак, дип әйтеп, сөйләп торгач, дөньяда иң кадерле кешебезнең, әниебезнең кайтуына без бер дә шикләнмәдек. Олы апабыз Айсылу барсын да белә иде, ул безне тынычландырган була, ләкин аның бездән нидер яшергәнен, нәрсәнедер әйтеп бетермәгәнен без соңлап кына булса да сизендек. Әйе, кечкенә балалардан күп нәрсәне яшерергә була, тик вакыт дигән нәрсә бар һәм ул барсын да үз урынына куя. Әни юк та юк, кайтмый да кайтмый. Әти һаман да безне өметләндерә, тик өметләр генә акланмый. Еллар узгач, уйлыйм-уйлыйм да, әтине аңларга тырышам. Күрәсең, ул аның кайтуына актыккача ышанган, көткән, мондый хурлыкны коточкыч яман төш итеп кенә кабул иткән. Билгеле, бу нәкъ шулайдыр дип тәгаен гына кистереп әйтә алмыйм, ләкин безнең хәлебез авыр, бик тә авыр иде. Юк, без начар яшәмәдек, ач тормадык, колхозда эш житәрлек, ярдәм булмады түгел, шактый күп булды. Ләкин... мораль яктан... ничек диләр әле... рухи яктан читен иде. Исән әниебезне югалту авыр булды, алай гына да түгел, обидно иде, до слез обидно... Без бик горур нәсел, без монар нык хурландык. Урамда да, мәктәптә дә... Ух... шул вакытларны искә аласым да килми! Төпчегебез Мөһипнең: «Әнине сагындым, әни кайтсын!» — дип әтине кочаклап елаулары әле дә күз алдымнан китми. Ни булды соң безгә? Кемнең шулай каргышы төште? Бервакытны хәтта... — Назыйм бер мәлгә сүзсез калып, күз яшенә буылды...

— Әйе!? — дип йомшак кына дәште Нариман, дустының күңелен яраламаска тырышып.

—... әти үзе дә түзмәде, йомшап китеп, безнең алда күз яшьләрен күрсәтте... Елый... бахыр... үкереп елый... анар кушылып без дә елыйбыз... өелешеп... чатта...

Ә ул кайтты, берничә мәртәбә кайтты. Без әнине күрмәдек, без аның барлыгын сиздек. Дөресрәге, безгә аны күрсәтмәделәр. Ә без аны олы апаманың шатлыклы йөзендә, әтинең сагышлы күзләрендә күрдек...

Назыйм теләсә кемгә ачылмый. Ә менә Нариманны нигәдер үз итте, дус итте. Кем беләндер үзеңнең бар булган кайгыңны, шатлыгыңны уртаклашырга да кирәк бит инде, бу дөньяда гел йомылып кына да яшәп булмый.

—Авылга нишләп бер дә кайтмыйсың? — дип сорады ул бервакыт Назыйммнан.

— Ә нишлим анда кайтып?! Йорт жимерелде, нигез таралды...

— Иске булса да, йортың тора бит, нигезең тора. Аның янында хәзер яшь парлар очраша. Тыныч анда. Без дә Динә белән берничә мәртәбә шунда очраштык...

— Ишегалды ничек? — дип кызыксынды Назыйм.

— Элеккечә...

— Элеккечә булалмый инде...

— Әзрәк коймаларыгыз ишелгән, билгеле.

— Ат арбасы торамы?

— Тора.

— Әти күрше авылдагы Вилдан абыйга заказ биреп ясаткан иде ул арбаны. Алтын куллы кеше иде әти, үлгәнче хуҗалыкта ат асрады. Аннан менә шул камыт бавына асылынып үлде дә инде мескен...

— Ат яратам, ат асраучы кешеләрне дә хөрмәт итәм...

— Әллә шул хөрмәткә чыгып керәсенме, ә?! Әче су аласынмы?! — диде Назыйм. Аның күзләрендә яшь җемелдәде, бүлмәне чиксез сагыш биләп алды...

— Эчмәгәнне беләсен бит инде! — дип җилкәсен җыерды Нариман.

— Ә... оныттым, гафу ит...

— Теләсәң, алып керәм!

— Кирәкми! Шул хәтле тинтәк түгел әле мин, бер үзем аракы эчеп утырырга...

Салган килеш ул аны берничә мәртәбә урамда күрде. Аягында чак кына басып тора. Нариманны күргәч, тиз генә ларекка кереп качмакчы иде, булдыра алмады, абынып егылды. Нариман аны тулай торакка хәтле өстерәп кайтты. Ана шелтә белдерүче дә, хәтта сүз әйтүче дә булмады. Комендант та дәшмәде. Чөнки Назыйм шушы тулай торакның бөтен эшен башкарып тора иде. Ут янмаса да, краннан су акмаса да комендант, беренче булып, Назыймны эзләп килә. Ә ул шундый карусыз, бервакытта да каршы килми һәм, җанынны интектереп, акча да сорамый. Авыл егете чөнки, ул шулай тәрбияләнгән.

**8**

«Мәскәүләрне торак мәсьәләсе бозды!» — дигән әйтем, гыйбарә Казан халкын да читләтеп үтмәде. Әле ничек кенә! Калада фатир алу — авыл кешесенең иң зур хыялы. Ә совет илендә фатир алу җиңел нәрсә түгел, чөнки аны теләсә кемгә бирмиләр. Дөресрәге, аны теләсә кем алырга да мөмкин (ничек бәхет елмая бит!), тик теләгән кеше генә вакытында ала алмый. Әйе, фатирны бушлай бирәләр, ләкин ул барыбер бушка төшеми. Аның өчен кайсы да булса оешмага эшкә урнашырга һәм шунда чиратка басарга кирәк. Чиратың килеп җиткәнче, сират күперен узасың. Менә шулвакыт дуслар, танышлар, югарыда утыручы зур абзыйлар белән танышлык кирәк була, ә шунсыз бәхеткә ия булам, димә. «Блат» дигән төшенчә нәкъ менә шул чакта туды һәм шул чорның яман билгесе булып калды.

Динәнең: «Минем хыялым — шәп итеп кияүгә!» — дип сөйләнүләре дөреслеккә туры килсә дә, чынында исә ул калада яхшы фатир алырга хыяллана иде. Тулай торакта, башкалар сымак, таракан куып йөрисе килми иде аның. Трамвайдан ул бүген үк китәр иде, ләкин монда тиз арада фатир алу мөмкинлеге бар. Ул кооперативка чиратка басты. Әйе, ул бөтенләйгә бушлай бирелми, ана күпмедер акча түләргә кирәк, ләкин бу тиз фатир алуның бердәнбер уңышлы юлы иде. Динәнең калада зур дуслары да, танышлары да һәм, билгеле ки, блаты да юк. Фатирлы булу өчен тиз һәм якын арада зур суммада акча кертергә кирәк. Эшләп алган

акча бар, ләкин ул гына аз, анысына яшисе, киенәсе дә бар. Динә әлеге акчаны колхозда баш бухгалтер булып эшләгән саран атасыннан сорап карарга булды, ул шунар өметләнде, шунар хәтта бернигә дә ышанмаган ирен дә ышандырды. Ләкин Салих абзый анын өметен акламады, җавабын да бик кыска тотты. « Кызым, синен ирең бар, ул хәзер баш, ул хуҗа, әгәр дә ул акчаны мин бирсәм, ирең йортка кергән кебек була!» — диде. Кызы исә атасының холкын яхшы белә: бер әйттеме — бетте! Чынлап та, саран кеше иде шул анын атасы. Анын кысмырлыгы турында авылда легендалар йөри иде. Анын шундый сыйфатына түзә алмаган малае Сәлихҗан да, атасыннан туеп, авылдан чыгып качты, Себер якларына китеп, Камчаткага тиклем барып житте. Салих абзыйнын бер яраткан сүзе бар, ул — бир, дигәнне ишетмим, мә, дигәнне генә ишетәм, дигән сүз иде. Абзый гомере буе акча җыю чире белән чирләде. Банкта берничә кенәгә ачкан «считавут» үзен күктән төшкәндәй хис итеп яшәде. Анын банкта ачкан һәрбер кенәгәсендә җидешәр мең сум совет акчасы яткан. Динә шуны соңыннан гына белде. Шунын бер кенәгәсен бирсә дә, яшьләрнең торак мәсьәләсе хәл ителер иде. Ләкин бирмәде абзый, күрәсен, саранлык көчле булган.

Ярдәм һич көтмәгән җирдән килде. Акчаны Динәнен каенанасы Хәлимә ханым тапты. Ул очраклы рәвештә атасының банк кенәгәсен табып алды. Атасы ара-тирә акчасын шунда салгалаган булган һәм тора-бара ул шактый зур күләмдә җыелган. Хәлимә банкка барып, ул акчаларны үз исеменә күчертте. Нариман белән Динә бервакыт авылга кунакка кайткач, ул шул акчаларны аларнын алларына чыгарып салды һәм: «Мәгез, балалар, алыгыз, кирәкле җирегезгә салыгыз!» — диде...

Ләкин акча кертеп кенә дә фатир алып булмый икән. Анын өчен ин элек өстәгеләрне җайларга кирәк. Динә бу йөкләмәне үз өстенә алырга булды. Фатир профком аркылы бирелсә дә, күрсәтмәне ин элек житәкчелек бирә. Директор катлаулы кеше, теләсә кемне кабул итми. Анын Гаврилин исемле урынбасары бар, күп кеше фатир мәсьәләсен шунын аркылы хәл итә торган иде. Михаил Иванович (милләте белән керәшен) яше кырыкта булган, матур, ыспай киенергә яраткан, чит хатын-кызларга шактый битараф булмаган бер ир заты иде. Директор аны хөрмәт итә, анын сүзен сүз итә. Гаврилин: «Була!» — дисә, булдырмыйча калмый, чөнки ул сүзендә тора белә. Анын шундый чуар гадәтен яхшы белгәнгә күрә, йомыш белән ана күбрәк хатын-кызлар йөри иде. Билгеле, бу үзенә бер төрле уен гына иде, күп очракта андый уеннар житди женси мөнәсәбәтләргә барып житә дә алмый иде. Шуны аңлаган Динә дә мут җанлы урынбасар белән әзрәк уйнап карарга булды. Һәм бер көнне...

Ә бер көнне гүзәллек салонына (ин кыйбатлысына!) барган Динә танымаслык булып үзгәреп кайтты. Башын-күзен буяткан, чәчен кистереп, химия ясаткан һәм соңгы мода белән киенгән хатынын күргәчтен, Нариман чак кына егылмады.

— Нишләдең син!?

— Ошыймы сина!? — Динә ире каршында шома гына боргаланып, бөтерелеп алды. Сүз дә юк, хатыны чибәр иде анын. Ләкин шул тиклем чибәрлек, матурлык кирәк иде микән соң ана!?

— Ошый... тик...

— Ни булды?!

— Бу курчак уены ниемә?

— Мин әле уйнамыйм, уен башлана гына!

— Нинди уен?

— Иртәгә мин бер кеше янына барам...

— Кем ул?
— Гаврилин.
— Шаяртасыңмы?
— Юк, чын.
— Нигә?
— Фатир сорарга.
— Ә нишләп анардан?
— Фатир мәсьәләсен фәкать ул гына хәл итә!
—Ә нигә шулай киенден соң, ясандың?!
— Ничек?
— Обизиян кебек!
— Аны шулай гына алып була!
— Кемне?
— Гаврилинны...

Нариман бу сүздән шартлардай булды. Авылдан киткәненә инде ничә мәртәбә үкенергә мәжбүр булган мужикка кабат шул авыр хисләрне татырга туры килде. Динәдә барган тискәре үзгәрешләр аны инде куркыта һәм ул анардан читләшә дә башлаган иде. Инде шунар хәзер көнчелек хисе дә килеп кушылды. Динәсен көн саен, сәгать саен югалта барганын сизгән ир өчен тиздән читен вакытлар житәчәге ап-ачык иде. Ул әле хатынын һаман да ярата, бик тә ярата һәм аны чит ятлар белән бүлешү уе акылдан шаштыра иде...

— Ба-а-армыйсың!!!

Нариман хатынына шундый каты итеп акырды, тегесе сискәнеп, баскан жиреннән урынга инде. Иренең аңа кычкырганы булгалады, ләкин бу хәтле үк каты итеп кычкырганы булмады. Дөньялар болай барса, тиздән ире аңа кул күтәрергә дә мөмкин!

— Барам!
— Бармыйсың!
— Яхшы! — Динә, кәжәләнеп, өстенә матурлап кигән киемнәрен салып бәрде дә, урын өстенә барып ауды. — Үзең бар алайса!
— Ә нишләп мин?
— Сиңа фатир кирәкмимени?
— Юк, кирәкми!
— Кирәкми!? — Динәнең болай да нечкә тавышы бу юлы чәрелдәп чыкты. Аңарда истерика башланды. — Нишләп сиңа берни дә кирәкми? Нишләп соң миңа гына кирәк!? Нәрсә, гомерең буе шушында, шкаф хәтле бүлмәдә яшәргә уйлыйсыңмы?
— Юк, уйламыйм.
— Ә нәрсә уйлыйсың?
— Кайтып китәргә!
— Кая?
— Авылга, кая!
—Во, во! — дип үртәнде хатын. — Синең башка әйтер сүзең дә юк, һаман шул, авыл да авыл! К чурту!
— Ие... авыл...
— Алайса, бар, кайт та кит!
— Яхшы, кайтам! Хәзер үкме?
— Хәзер үк...
— Ә бәлкем...
—Юк! — Динә, демонстратив рәвештә, арты белән борылып ятты. Нариман тәнлә аңа кагылмады, идәнгә матрас җәеп, шунда йоклады. Иртән ул, хушлашмыйча-нитмичә, авылына кайтып китте. Шимбә-ял ул

болай да эшләми. Хәер, аның бу беренче генә кайтуы түгел иде. Динә аны туктатмады һәм үзе дә аңа иярмәде.

Ә менә Динә Гаврилин янына барыбер барган. Ире аны соныннан гына белде.

**9**

Кала белән бөтенләйгә саубуллашу түгел иде бу, Нариман ике көннән соң кабат Казанга килде. Динә өйдә юк, ул сменада булып чыкты. Эчендәге сагышын кая куярга белмәгән ир Назыйм янына керде. Авылдашы бик нык дулкынланган иде. Ул әнисен авылдан алып киткән жирбитне — Сәлимне эзләп тапкан икән. Ул әле һаман да исән. Зур урында (органнарда) хезмәт иткән, инвалидлыкка ялган белешмәләр ясатып, яшеннән элек алдан пенсиягә чыккан, хәзерге көндә персональ пенсионер дәрәҗәсен алып, тыныч кына яшәп ята...

— Мин аны эчеп, юкка чыккан бер бәндә дип уйлаган идем, — дип башлады ул сүзен. — Ялгышканмын. Ана үз яшен биреп булмый, шактый яшь күренә...

— Нindирәк кеше соң ул? — дип кызыксынды Нариман.

— Нинди дип әйтим икән... Ул инженер да, партия хезмәткәре дә түгел, ул кантур күсесенә охшаган. Озын буйлы, калын гәүдәле, кара чырайлы... Мангаенда, гаҗәп бит, ник бер сыр, җыерчык булсын! Үзен гел карап, көйләп кенә тора, күрәсең...

— Хатыны юкмыни?

—Юк, үзе генә яши. Бер хатын һәркөн килеп ашарына пешерә, өен җыештыра. Фатиры өч бүлмәле. Берсендә зал, икенчесендә йокы бүлмәсе, өченчесендә китапханә. Ну, җыеп та караган инде китапны! Том-том... әйтсәм-әйтим! Укымый инде ул аларны, җыйган прусты... коллекционер...

— Ничек таныштың?

— Мин бит общагада гына түгел, буржуйларга да (фатирлы, машиналы кешеләрне ул шулай дип атый иде) хезмәт күрсәтәм. Кемнең уты янмый, кемнең краны ватылган. Мин аның шул тирәдә торганлыгын азрак чамалый торган идем. Әтинең сүләве буенча инде. Ул берничә мәртәбә баргалаган да әни янына. Әтине өйгә кертмәгән, алар тышта гына сөйләшкәннәр. Ул бәндә ана: «Алып кайт хатыныңны, мин аны тотмыйм!» — дигән. Ләкин әни кайтмаган. Башта ул берни дә аңламады. Мине сантехник дип кенә уйлады. Краны акмый моның. Башлаган эшемне икенче көнгә калдырып, өйгә кайтып киттем. Беренче көнне үк ана серне ачасым, үземнең кемлегемне танытасым килмәде. Икенче көн тагын килдем. Күрәм, тегенең эче поша, кранны төзәтү озакка сузылганга борчыла. Ул мине чакырганга үкенә дә башлады бугай. Ләкин ул көнне мин ремонтны бик тиз тәмамладым. Күп итеп акча сузды бу миңа, акчалы кеше, күрәсең. Яртысын гына алдым. Яхшысынмадым. Үкенәм хәзер, алырга кирәк булган! Биргән хәтлесен генә түгел, артыгы белән каерырга! Оятсызларча! Әнине харап иткән өчен, безнең тормышны җимергән өчен, безне ятим калдырган өчен бугазына басып аласы калган ла хайванның!

Назыйм... Минназыйм... гади бер авыл мужигы. Үзенең тормыш бәласен, ачы язмышын әнә шул явыз кала бәндәсендә күргән мужик аның турында исә йодрыгын төйнәп, ачыргаланып сөйләде. Соныннан ул фәйләсуфка әверелде...

— Беләсеңме, мин нәрсә уйлыйм, — диде ул, — мин ул бәндәне шушы шакшы, ушсыз калага охшатам! Ие, нәкъ шулай! Кала безне — саф күңелле авыл балаларын тартып, йолкып ала да, үзенең шакшы казанында болгатып, бар булган тормышыбызны чуалта. Сыга! Безнең җанны сыга бу иблис

кала! Ана да бит тере жан, тере кан кирәк, аңлыйсыңмы, аңсыз ул яши алмый, аңсыз ул үлә, таш калага әверелә. Иң аяныччы шул, шул таш кала безнең жаннарыбызны тартып ала да, файдалангач, таш урамга чыгарып ата. Һавасы чыгып торган резин тупны, яисә машина көпчәген күргәнең бармы? Күрсәң, без дә нәкъ шул бушаган туп, бушаган машина көпчәгенә охшаганбыз. Без бөтенләй буш калып, бетеп, сынып авылга, туган нигезгә кайтып егылабыз. Менә шуннан барлыкка килә дә инде алкоголизм, депрессия, менә шуннан килеп чыга төрле фажигале хәлләр! Гасырлар буена шушы таш кала, үзен яшәтер, үзен көйләтер өчен якты өметләр баглап килгән авыл кешесенең жанын суыра. Ә хәзер инде ул бөтенләй рәхәтләнеп, сөенеп кинәнә! Ни өчен дисеңме? Чөнки бөтен халык, ахмак сарык сыман, шушы таш калага агыла. Ә анда аларны шундый Сәлим кебек кара аждаһалар, монстрлар көтеп кенә тора! Иманым камил, алар иблис тарафыннан куелган махсус ялчылар — корбаннарын саклап кына торалар... корбаннарын...

— Син һаман авыл халкы турында гына сөйлисең, ә кала халкын кая куясың? Аларның саны безгә караганда күбрәк түгелме соң?

— Кала халкының жаны юк бит аның! Алар бер тиен өчен жанын сатырга да әзер! Ниемә аларга жан, вөждан? Андый мөһим сыйфатлар, киресенчә, аларга яшәргә генә комачаулый...

— Әйттеңме Сәлим абзыйга үзеннең кем икәнлегеңне? — дип сорады Нариман, түземсезләнеп. Назыймның бу фәлсәфи нотыгыннан бигрәк, ана бу минутта шул нәрсәне белү лазем иде.

— Әйттем, аңлаттым, — диде ул, — башта берни дә аңламыйча торды. Мине иң женләндергән нәрсә шул булды: ул озак кына әниемне искә төшерә алмыйча интекте.

— Шул хәтле күп булганмыни хатыннары?!

— Күп. Бик күп. Закунлы рәвештә генә дә бер биш тапкыр өйләнгән. Әле болай... килеп-китеп йөрүчеләре күпме булгандыр. Ул беркем белән дә бер елдан артык яшәмәгән. Бик тә хәйләкәр, астыртын кешегә охшаган. Ләкин хатын-кызны алдый белеп алдаган. Мас-тер! Аңлавымча, ул минем әни белән ярты гына ел яшәгән. Бик тиз киткән анардан әни...

— Кая?

— Башта ул апаларга күчкән. Аннан соң эш тапкан. Тулай торакта торган. Соңгы елларда фатир снимать иткән. Бишбалта ягында булса кирәк. Бер кечкенә бүлмә инде шунда, чолан кебегрәк нәмәстә... Аннан... әнинең акылына бик нык зәгыйфьлек килгән, ул өч ел психбольницада ятып чыккан. Шизофрения...

— Нәстә соң ул?

— Мания сымак бер нәрсә...

— Маниясе нәстә?

— Мания нәрсә... синдром... психоз...

Ул кисәк кенә Нариманга карап куйды. Әнисенең авыруын китап укырга яратмаган авылдашына үтемле итеп аңлату өчен гади сүзләр табалмаган Назыймга акылын тагын да тырышыбрак жигәргә туры килде:

— Болай ул, дустым... ниндидер сәбәпләр аркасында кешедә акылсызлык чире башлана, кеше акрынлап акылын жуя. Әни мисалында мин сина шуны гына әйтә алам, аның иң элек авылга кайтып, безнең белән, гаиләсе белән кушыласы килгән. Бу теләк анарда көннән-көн, елдан-ел көчәя барган. Ләкин хыялы тормышка ашмагач, аның жанына чир йоккан. Аның башында да, жанында да авыл, бары тик авыл гына булган. Безне күрәсе, безне, ягъни мәсәлән балаларын бер кочып-сөясе килгән аның! Дөресен әйтим, күчтәнәчләр кайткалый иде авылга! Хәлвәдер, прәннектер, конфеттыр килә

торган иде. Аларның тәме, ышанасыңмы-юкмы, әле дә менә авызда тора. Безгә аны, каладан тәти апагыз җибәрде, дип бирә торганнар иде. Хәзер аңлыйм, ул күчтәнәчләрне безгә каладан әни җибәреп яткан... әни...

— Ә нигә кайтмаган?

— Әти кайтармаган.

— Нигә?

— Ул аны кичерә алмаган. Баштарак ул әнигә бик нык ялынган, аның кайтуын теләгән, тик соңыннан үзе үк аны кайтармаган...

— Ни өчен?

— Хурлыгы ни тора, дустым, хурлыгы...

— Ә кем гаепле?

— Нәсел, дустым, нәсел. Нәсел дигәннән, мин күптән түгел генә үзем өчен бер ачыш ясадым. Моны миңа кайчандыр Казандагы тәти апа сөйләгән иде. Ул безгә әни ягыннан туган. Минем әнинең әтисеннән ишеткән ул аны. Әнинең Сиражи атлы бер ерак бабасы булган. Бабай яшь чагында Хәерниса исемле бер хатынга өйләнә. Шул хатын анардан ике бала таба: берсе ир бала (анамның әтисе), икенчесе кыз. Кызга Гайникамал дип кушалар. Менә шул Сиражи бабай, Хәернисага өйләнгәчтен, Самар губернасы алпавытында хезмәт итеп йөргән. Баштарак бабай, ел саен кайткалап, гаиләсенә ярдәм итеп киткән. Шуннан соң ул бөтенләй кайтмый башлаган. Шул чорда миссионерлар дин мәсьәләсендә бик зур пропаганда алып барганнар. Бабайга бер марҗа димләгәннәр. Бабай, кахәр суккыры, ислам динен ташлап, христиан диненә күчкән. Әлеге кара хәбәрне хәтта вулыстан килеп, рәсми төстә игълан да иткәннәр. Әби, бу хурлыклы хәбәрне ишетеп, бик каты елаган, кара күз яшьләре белән елаган. Гомер кеше каргамаган әби динен алыштырган хыянәтче ирен генә түгел, ә шул Сиражиның бөтен нәселен, ыруын каргаган. Тормышлар бик авыр, кулда ике бала. Шуннан соң Хәерниса әби Кече Пәтрәк авылының бер картына кияүгә чыга һәм үзе белән Гайникамалны да алып китә. Бабай (горур булган, күрәсең!) әнисенә иярми, аны бер туганы үзенә асрамага алып кала...

— Син моның белән ни әйтмәкче буласың?

—Әнә шул Хәерниса әбинең каргышы төшмәгән микән, дим безнең нәселгә. Кешене каргау начар гамәл, тик әбине дә аңларга була. Хәер, мин үзем бу юрауларга бигүк ышанып та бетмим...

## 10

Буласы булган икән: Нариман Динәне Гаврилин белән тотты. Хыянәт өстендә түгел, билгеле, ә урамда, Бауман урамында. Алар кычкырын, култыклашып, «Татарстан» кинотеатрыннан чыгып баралар иде. Аларның ял көне кинога барачакларын аңа тулай торакта яшәүче бер таныш егет житкерде. Ул да депода эшли икән. Ул аны, начар уй белән түгел, ә ялгышып, белештермичә генә ычкындырды. Нариман моңа башта ышанмады. Ышанырлык та түгел шул. Газиз хатынның тик торганнан, рөхсәтсез-нисез, чит кеше белән кинога барсын әле! Егет аларның кинога барачакларын эштә үк ишетеп кайткан. «Татарстан»да бик тә тансык бер фильм бара, аншлаг, чөнки билетлар инде ике ай элек алдан сатылып беткән. Гаврилинга кемдер билетлар китереп биргән, тегесе коллективка: «Үзем генә бармыйм, бер кеше белән барам!» — дип мактанып алган. Шундагы хатын-кызлар Гаврилинның хәтта кем белән кинога барасын белеп, исәпләп тә чыгарганнар. Ул Динә булып чыккан.

Динә ял көне иртән уянды. Көзгә каршына барып, ясанырга, бизәнергә кереште. «Ял көне — сменан юк бит!» — диде аңа ире. «Апайларга барам!» — дип җавап кайтарды ул аңа. Каушамады, ярсымады. Нариман: «Мин дә

барыйммы?» — дип сорагач, ул: «Юк, апай бу юлы үземне генә чакырды!» — дип кырт кисте. Нариманның йөрәге жу итеп китте, жанны кабат шул ачы, кахәр көнчелек хисе телеп алды...

Кинотеатр каршында басып торган ирен күреп алгач та, Динә ин элек үз-үзен кулга алырга тырышты. Гаврилин (тиз генә аңлады булса кирәк!), Нариман тарафына жинелчә генә баш какты да, Динәгә кул болгап, каядыр китеп тә югалды. Алар, бер-берсенә карашып, кинотеатр каршында басып калдылар. Нариман хатыныннан, дөресрәге чибәр хатыныннан күзен ала алмады: чынлап та, читләрнең күзе төшәрлек булып чибәрләнгән аның жан кисәге! Ни өчендер хатынын гаеплисе урынга, бу юлы ул үзен гаепле итеп сизде.

— Динә, аңлат, нәстә бу?

— Нәстә түгел, ә нәрсә!

— Нәрсә бу?

— Син бөтен эшне боздың! — дип гаеп атты ул иренә. — Нигә килден монда? Өйдә генә утырсаң, яхшырак булган булыр иде... чүп жыеп...

— Нинди чүп!? — Нариман берни дә аңламады. Соңыннан башына барып житте: Динә аны кешегә дә санамый башлаган икән ич! Кеше түгел икән ул, ә мәми! — Ыслушай, бер китереп сугам хәзер, тучны асфальтка сеңәсен!!!

Нариманның күңелендә ярсу инстинкт уянды, йомшак холыклы хатын-кыздан өстенлек иткән кыргый көч, табигый рәвештә, тышка бәреп чыкты. Динә бу очракта иренә каршы дәшмәүне артыграк күрде. Нариманны үз кулына алып, аны курчак урынына йөртергә хыялланса да, ул барыбер иреннән шикләнә, аңардан курка иде. Бауман урамы буйлап озак кына сөйләшмичә бардылар. Кара-каршы бастырылган агач эскәмияләр каршында туктап калгач, икесе дә, ирексездән, шунда чүмәлделәр. Ачуын яшерә алмаган Нариман Динәдән жавап көтте.

— Кичер мине! — дип башлады сүзен хатыны. — Сиңа әйтмичә, чит кеше белән киногa барганым өчен, кичер...

— Син ялганладың миңа, туганнарыңа барам, диден...

— Мин башка юл тапмадым...

— Курыктыңмы миннән?

— Юк, син мине аңламассың дип курыктым. Син әле хәзер дә мине аңламыйсың кебек. Аңла, мин аның белән күңел ачар өчен, йә ятып йоклар өчен бармадым...

— Нәрсә өчен бардың соң?

— Аңламаган булып кыланма, зинһар!

— Фатир өченме?

— Әйе, фатир өчен. Чиратсыз фатир алыр өчен. Аңла, бу кешедән бик күп нәрсә тора. Ул бездә бик зур кеше. Аның бер сүзе бөтен вапрусны хәл итә дә куя, аңлыйсыңмы?

— Юк, аңламыйм, аңларга да теләмим!

— Хәзер белмим инде, — дип көрсенде Динә, — ничек булып бетәр...

— Нәстә! — Нариман, явыз чыраен жыерып, чөлт итеп, асфальтка төкерде. — Эшегезне боздыммыни?!

Динә дәшмәде. Башын аска иеп утырган жиреннән, кинәт, «шың-шың» килеп, еларга тотынды. Хатыннарның күз яшенә каршы торалмаганын аңлаган Нариман аны кисәк кенә, иңбашыннан кочып алды. Динә, сырпаланып, аңа елышты һәм пышылдап:

— Миңа синнән башка беркем дә кирәк түгел, жүләрем! — дип эндәште һәм почык борынын иренең муен астына төртеп, аны назлап үпте. Урамнан узган кешеләр аларга гажәпләнеп карап киттеләр, аларны әле яңа гына өйләнешкән бәхетле парлар итеп кабул иттеләр...

— Сина бала табарга кирәк!

— Бала!? — Динә өчен бу яңа борылыш иде. Ләкин яңа сүз түгел, бу турыда инде Нариман шактый ук аның колак итен ашарга өлгергән иде.

— Табасың!

— Юк!

— Мин бала телим! Ир бала!

— Булыр...

— Кайчан?

— Фатир алгач... яме...

Сүз һаман да шул фатирга барып терәлә. Тулай торакта өчәр бала белән яшәүче гаиләләр дә бар. Аннан, бала тапкач, хатыны авылга кайтып торыр, шул арада ул да колхозда йөреп алыр, әзрәк авыл һавасын сулап калыр дип хыяллана иде Нариман. Бер мәртәбә балага узган иде инде аның хатыны, тик нигәдер, киреләнеп, баласын төшерде. Җүнсез хатын! Әгәр дә ул кабат балага узалмаса, гомер кичерәчәк түгел ул хатынның, гомер!

**11**

Назыймны ул урамнан эзләп тапты. Ничәмә айлар аек йөргән мужик, әле яңа гына салу ягына ычкынган иде. Аның ул салуы, шул салмыштан кыланмышлары, әгәр дә вакытында туктатмасаң, айлар буена да сузылырга мөмкин.

Назыйм аны, өстерәп диярлек, сасы пивнушкага алып керде. Ресторан булса бер хәл, анда хет ашау ягы да шәп, интерьеры да башка, кешечә, ә монда — дөньяның иң ямьсез урыны кайда дип сорасалар, шушы сыраханәдер дип әйтер буласың! Анда кемнәр генә юк: дөньяның бөтен шакшысы шушында җыелган диярсең. Монда беркая да эшләргә теләмәгән сәер язмышлы сукбайлардан алып, төрмәдән башы чыкмаган криминаль шәхесләргә хәтле очратырга була. Шакшы тәмуг казанын хәтерләткән һәм тулы антисанитария хөкем сөргән бу сыраханәдә Нариман үзен шактый уңайсыз хис итте. Сыраны баскан килеш кенә чөмерәләр. Кырылган, куптарылган түгәрәк өстәлләр өстендә балык башлары, ипи валчыклары аунап ята. Аларны, җыеп алып, чистартучылар да күренми. Җәйнең эссе вакытларында сыра эчүчеләрнең саны тагын да күбрәк, сыраханәдә зур-зур чиратлар барлыкка килә. Тынчу, авыр һава, бөтен җирдә тәмәке төтене, өстәл өсләрендә, түшәмнәрдә кап-кара чебеннәр очып йөри. Сыраны дәү пыяла кружкаларга салып бирәләр. Озак агызалар, чөнки сыра ясаучылар моны үзләре үк шулай таләп итә. Сыраны тиз генә салдырып, шундук эчәргә тотынсаң, кружкадагы эчемлек яртылаш кына кала, ә шуның яртысы исә күбеккә чыгып бетә. Сыра яхшы күбекләнсә, эчүчеләр дә сөенә, димәк, эчемлек яхшы, яңа. Кеше сөйләве буенча, яхшылап күбекләнсен өчен, сырага, дөрес булса, чебен, таракан үтерә торган дихлофос та кушалар икән. Чебенне дихлофос белән бер сиптерүдә үк үтерергә була, ә менә бер кружка сыра өчен җанын бирергә дә әзер торучы сәрхушләрне берни белән дә алып булмый...

— Ү-ү-үтерәм мин аны!

— Кемне?

— Сәлимне...

Сыраханәгә кергәнче үк шактый капкан, монда кергәч инде бөтенләй эреп киткән Назыйм кружкадан берничә йотым сыра кабып куйды да, йодрыгы белән каты итеп өстәлгә сукты. Төкерекләрен чәчеп, селәгәен агызып акырган авылдашы гайрәтен чигерсә дә, Нариман үз-үзен кулга алырга, аны ахыргача тыңлап бетерергә булды.

— Нигә?

— Ул кабахәт бу дөньяда яшәргә тиеш түгел!
— Нишләргә тиеш?
— Аңлыйсыңмы, кебени!
— Сүгенмә!
— Җаным сыкрый, аңлыйсыңмы, юкмы! Кабатлап әйтәм: ул кабахәт жир йөзендә яшәргә тиеш түгел! Беркайчан да! Аңлыйсын...
—Аңлыйм... Тик гаепне бары тик ул кешедән генә эзләргә ярамый. Монда бит синең анаң да гаепле! Ул сезне ташлап киткән! Ул шунар, шул кабахәткә ияреп киткән! Балаларын ташлап...
—Әй, син, маңка! — дип үкерде Назыйм. — Ни сүлисең син! Орынма син әнигә, яме! Әни ялгышкан... ие... Ләкин ул кире безнең янга кайтырга теләгән, тик әти аны кичерә алмаган, кире кайтармаган! Авыл... авыл аны кичерә алмаган! Ул бит безне сагынып, зар-интизар булып яшәгән, безне күрер өчен, Чичи башына кайтып, төннәр кунып чыккан. Орынма, әнигә яме! Орынасың икән...
— Ни була?
— Маңка!!!
Исерекнең эчкәч эчендәге тышында була, диләр. Аек баштан әйтә алмаганны ул салмыш хәлендә чыгарып бетерә. Әйе, Назыйм ана абый тиешле кеше, ул ана энекәше кебек, ләкин үзен кечерәйтеп, түбәнсетеп сөйләшкәннәрен кем генә ошатсын икән! Баядан бирле күкрәк кагып, чүп иләп торган Назыйм тирләп чыккан шакшы куллары белән энекәшенең якасына ябышты. Юкка, билгеле, абзый ни эшләгәнен үзе дә аңлап бетерми иде. Нариманның гер күтәреп ныгыган таза куллары аны бик тиз бөгеп салды. Нидер чыртлап, сынган кебек тә булды. Авыртудан бик каты итеп чыраен сыткан абзый кулын кире тартып алды һәм бер мәлгә каршысында кем басып торганын да, кем белән сөйләшкәнен дә онытып, комсызланып, калын кружкасыннан, кызу-кызу сыра чөмерде. Бер генә атна элек аек акыл белән эш иткән, яшәгән бүлмәсен, кызлар кебек, пөхтә һәм чиста итеп тоткан, вәгазь көйләп, фәйләсуф булып йөргән кеше бүген бер мизгелдә әнә шундый шакшы убырга әйләнгән иде. Нариман аның янынннан тиз генә таю ягын карады...
— Кая!? — дип сөйләнде исерек аның артыннан.
— Синең белән утыра алмыйм монда!
— Кайда?
— Бу тәмуг оясында!
— Ә мин аны барыбер ү-ү-үтерәм! Ха-ха-ха! Әле аның... краны ябылып бетмәгән. Өч көннән бәреп чыгачак ул... су... менә күрерсең... кып-кызыл... су... ха... ха... ха...

*Дәвамы киләсе саннарда*



*Татар язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышыннан соң. Сулдан уңга – Фатих Хөсни, Сергей Викулов (Мәскәү), Гариф Ахунов, Зәки Нури, Кайсын Кулиев (Нальчик), Сибгат Хәким, Җәмил Мостафин (Мәскәү), Гази Кашшаф. 1971 ел.*



*Мулланур Вахитовның көрәштәше Исхак Казаков (1876-1939). М.Вахитов үтерелгәч, 1918 елның август-сентябрь айларында Үзәк мөселман Комиссариатының комиссары булып эшләп ала. Шул вакыттагы фоторәсем. Мәскәү. 1918 ел.*



*Түбән өлкәсенең Акъяр урта мәктәбендә язучы Хәсән Сарьян белән татар теле һәм әдәбияты укытучылары очрашуы. Утырганнардан – уңнан икенче Х.Сарьян, дүртенче – мәктәп директоры Хатип Хәбибуллин. 1982 ел.*



*Язучыларның Казан «Тасма» фабрикасында хезмәткәрләр белән очрашуы. Уртадагы рәттә – Татарстан язучыларының VI съездына килгән Мәскәү язучылары Сергей Михалков, Анатолий Алексин, Леонид Соболев (РСФСР Язучылар Союзы председателе); уң якта – татар язучысы Мирсәй Әмир. 1965 ел.*



*«Казан утлары» журналы редакциясендә редколлегия утырышы бара. Сулдан уңга: Тәлгат Галиуллин, Мансур Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Розалина Шаһиева, Марс Шабаев. 2003 ел.*

# БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫНДА АЛМАНИЯДӘ МӨСЕЛМАН ӘСИРЛӘРЕ

## 1.Серле план

2014 елда Беренче бөтендөнья сугышы башлануына 100 ел тула. Гыйбрәтле һәм уйландыра торган «юбилей». Бу сугыш күп кеше өчен бөтенләй таныш булмаган, тарих катламнарында югалган серле бер вакыйга. Чыннан да Икенче бөтендөнья сугышы безнең өчен аңлаешлырак дип әйтергә мөмкин — әле арабызда сугыш һәм тыл ветераннары яши, һәрбер гаилә тормышында диярлек ул тирән эз калдырган, безнең тарихи хәтеребез өчен ул әле төзәлеп бетмәгән яра булып тора. Шуңа күрә дә 1941-1945 ел вакыйгалары бездә кызыксыну уята, тарихчылар бу кызыксынуга җавап биреп эзләнүләрен дәвам итә – нәтиҗәдә китап кибетләре киштәләрендә Икенче бөтендөнья сугышы тарихына караган дистәләгән, йөзләгән монография табып була. Алар арасында, кызганычка каршы, уйдырмалар да, фальсификацияләр дә җитәрлек. Шуңа күрә күптән түгел Россия хөкүмәте сугыш тарихын фальсификацияләүгә каршы хәтта махсус комиссия дә оештырырга мәҗбүр булды. Димәк, безнең җәмгыятьтә сугыш турында хәбәрдар булмаган кеше аздыр. һәрхәлдә, Бөек Ватан сугышы тарихыннан без зур хәрби операцияләрне, аерым каһарманнар исемнәрен искә төшерә алабыз. Ә хәзер, хөрмәтле укучылар, үзегезгә бер сорау куеп карагыз: Беренче бөтендөнья сугышы турында без нәрсә беләбез? Минемчә, хәтта үзен белемле, укымышлы дип санаган кеше дә кыен хәлдә калырга мөмкин – чыннан да нинди вакыйгалар искә төшә соң? Нинди исемнәр? Беренче сугышның каһарманнары кемнәр булган? Кызганыч, бүгенге буын 1914-1918 еллар фаҗигасен бөтенләй белми диярлек. Дөресен генә әйткәндә, Беренче бөтендөнья сугышы Бөек Ватан сугышы күләгәсендә кала килә...

Берничә әһәмиятле сан китереп узыйк.

Беренче бөтендөнья сугышында рәсми рәвештә 38 ил катнашкан, Антанта илләрендә (Англия, Франция, Россия) барлыгы 45 миллион кеше мобилизацияләнә. 1914-1918 елларда Россия империясе гаскәрендә хезмәт иткән 2 миллионга якын солдат һәм офицер сугыш кырында һәлак була, 2,5 миллион солдат хәбәрсез югала яки әсирлеккә алына. Димәк, илнең төрле төбәкләрендә тормыш иткән миллионлаган гаилә өчен бу сугыш коточкыч фаҗига булып тора. Житмәсә, сугыш Россия өчен ахыр чиктә бары тик югалтулар белән генә бәйле була — миллионлаган солдат сугыш кырында каһарманлык үрнәкләрен күрсәтсәләр дә, аның мактанырлык, горурланырлык нәтиҗәләре юк диярлек.

Беренче бөтендөнья сугышы тагын шунысы белән дә тарихта зур урын алып тора — аның турыдан-туры йогынтысында һәм нәтиҗәсендә Россиядә хәлиткеч сәяси үзгәрешләр башлана һәм ахыр чиктә бөтен дөнья ике сәяси лагерьга бүленә. Ике система арасында XX йөз дәвамында күзәтелгән каршылыклар һәм бәрелешләр шул бөек сугыш нәтиҗәсе булып карала алалар.

Әйе, бу сугыш дистәләгән ил, миллионлаган кеше өчен зур фаҗига булганлыгы аңлашыла. Ә татар халкы өчен ул нәрсә булган соң? Татар тормышында нинди эз калдырган? Алдагы мәкаләләремдә мин сугышның нәкъ шул ягына игътибар

итәргә телим. Ләкин, бу теманың бик күпкырлы икәнен истә тотып, анлы рәвештә чикләнергә булдым. Чөнки «Татарлар һәм Беренче бөтендөнья сугышы» гомум темасы аерым зур эзләнү таләп итә.

Төгәлрәк әйткәндә, сүз бары тик бер тәгаен мәсьәлә турында барачак — алман хәрби әсирлегендә булган мөселман солдатлары язмышы. Бу тема укучыларыбызга азмы-күпме таныштыр — заманында Мөхәммәт Мәһдиев, Ленар Жамалетдинов, Дамир Гарифуллиннарның аерым басмаларын искә төшерергә мөмкин, соңгы вакытта «Түгәрәк уен» журналында кайбер кызыклы мәгълүматлар басылды. Радио һәм телевидение аша әсирләрнең жырлары белән дә танышырга мөмкинлегебез булды. Ниһаять, алман галиме Готтһольд Вайль әсирләр арасында язып алган «Татар текстлары» күптән түгел Казанда дөнья күрде. Шулай да әсирләрнең язмышын тулысынча күзаллау мөмкинлеге укучыларыбызга бирелмәде шикелле. Менә шул мәсьәләгә бераз ачыклык кертәсем килеп бу мәкаләләремне язарга керештем дә инде. Алман (немец) архивларында эзлекле рәвештә эшләп шактый күп мәгълүмат туплаганнан соң, жәмәгатьчелегебезне эзләнү нәтижәләре белән дә таныштырасы килде.



*Алмания кайзеры Вильгельм II (1859-1941)*

Беренче бөтендөнья сугышы елларында алман хәрби әсирлегенә Россия гаскәрендә хезмәт иткән дистәләгән мең татар солдаты юлыга. Архив документлары шуны раслый – татарларны һәм башка милләт вәкилләрен бер-берсеннән махсус аерып тормаганнар. Алмания (Германия) территориясендә урнашкан кимендә 100 хәрби әсирләр лагеренда татар солдатлары булуы мәгълүм. Ләкин алардан тыш тагын ике «махсус пропагандистик лагерь» булганлыгы билгеле. Болары исә үтә оригиналь һәм үзенчәлекле булганлыктан шушы лагерьлар тарихы һәм анда тупланган мөселманнар тормышы зур кызыксыну уята. Кыска гына итеп әйткәндә, сугыш елларында Алмания житәкчелеге, Россия, Англия, Франция гаскәрләрендә хезмәт иткән берничә мең мөселман әсирен ике лагерьга туплап, алар арасында махсус пропагандистик чаралар уздыра һәм бөтен мөселман дөньясын «революционлаштырып», изге сугыш — «жиһад» ачып, мөселман халыкларын Антанта илләренә каршы сугыштыруны максат итеп куя. Әлбәттә, бу күренешнең тирән тамырлары һәм алшартлары бар, аларның барысын да журнал мәкаләсе кысаларында анализлап та булмас, шулай да кайбер мөһим моментларга тукталып узарга кирәк дип саныйм.

Бары тик 1871 елда гына бердәм дәүләт булып формалашып беткән Алмания империясе дөньяның колониаль бүленешенә «өлгерми» кала. XX йөз башында дәүләт житәкчелеге үзенең халыкара абруен үстерү юлларын актив эзли башлый, нәкъ шул нигездә Алманиянең ислам тәгълиматы һәм мөселман илләре белән күптәнге дуслыгы һәм дустанә мөнәсәбәтләре турында миф туа. Моның хикмәте бик гамәли: Алмания мөселман дөньясында үз позицияләрен төрле юллар белән ныгытырга омтыла. Бу омтылышның иң ачык мисалы – 1898 елда кайзер Вилһельм Госманлы дәүләтендә рәсми визит белән булганда Димәшкъ шәһәрендә уздырылган мәжлестә ислам дине хөрмәтенә түбәндәге сүзләрне әйткән: «Солтан галижәнапләре һәм бөтен дөньяга сибелгән, хәлифәне хөрмәт иткән 300 миллион мөселман ышанып торсыннар – алман кайзеры аларның мәңгелек дусты булачак». Алман пропагандасы тырышлыгы белән бу сүзләрне күпчелек гарәп һәм төрек газеталары бастыра, ә соңра аларны алман һәм төрек телләрендә төсле открытка формасында да миллионлаган тираж белән Һиндстанда, Урта Азиядә, Якын Көнчыгышта тараталар. Алман агентлары мөселман илләрендә тагын бер уйдырма тарата башлый – имеш, алман кайзеры ислам динен кабул иткән, яшерен рәвештә хаж кылган һәм исемен үзгәрткән – аны хәзер инде Хажи Вилһельм Мөхәммәт дип атарга кирәк. Алмания халкы илбашына ияреп шулай ук ислам диненә күчәргә ниятли... Никадәр фантастик

янгырамасын, аерым кешеләр бу уйдырмаларга ышанган дип фараз итәргә мөмкин.

Күрәсен, соң булса да татар җирлегенә дә бу хәбәр килеп ирешкән – архив чыганаклары раславынча, 1915 елның апрелендә Казан генерал-губернаторы полиция хезмәткәрләренә кайзер Вилһельмның ислам диненә күчүе хакындагы хәбәр губерна мөселманнары арасында ни дәрәҗәдә таралган дигән сорауга җавап эзләргә күрсәтмә бирә. Кызганыч, бу хәбәр татарлар арасында никадәр таралганлыгы һәм күрсәтмәнең ничек үтәлүе турында әлегә кадәр чыганаклар табылмады.


*Алман дипломаты Макс фон Оппенһайм(1860-1946) гарәп киемендә. Фото 1896 елда Көнчыгыш сәяхәтләре вакытында эшләнгән.*

Әлбәттә, кайзер вәгъдәләре һәм пропагандистик чаралар сәяси уенның бер өлеше генә була – XX йөз башында Алманиянең бигрәк тә Госманлы дәүләтен үз ягына тартырга омтылганы көн кебек ачык. Бу омтылышның тагын бер нигезе бар – Госманлы солтан (1908 елдан – Мәхмәт Рәшат яки Бишенче Мәхмәт) рәсми булмаса да дөнья мөселманнарының рухи башлыгы – хәлифәсе булып саналган. Алман стратеглары исәпләвенчә, кирәк чакта барлык мөселманнар хәлифәгә ияреп барырга тиеш – димәк, әгәр дә солтан Антанта илләренә каршы торырга өнди икән, мөселманнар үз вазифаларын үтәргә мәҗбүр булачак. Шулай итеп, берьюлы ике максатка ирешеп булачак – беренчедән, Төркия киләчәк сугышта Алманиянең тугры теләктәше була; икенчедән, мөселман халыклары хәлифәләренә ияреп Алмания дошманнары берлеген эчтән таркатачак.

Пропагандадан тыш Алманиянең ислам дөньясы белән булган «дуслыгының» фәнни-гамәли нигезе дә оешып килгән – илнең югары уку йортларында (Берлин, Һамбург шәһәрләрендә) инде XIX йөз ахырыннан көнчыгыш телләре, ислам дине белгечләре әзерләнә, 1908-1910 елларда алман телендә «Ислам» һәм «Ислам дөньясы» дигән житди журналлар чыга башлый.

Беренче бөтендөнья сугышы башланып китү белән, 1914 елның 1 августында Алмания Россиягә сугыш игълан иткәннән соң, шундук диярлек алман җитәкчелегенең хәтеренә мөселман «дуслары» искә төшә – 2 август көнне Алмания Госманлы дәүләте белән хәрби хезмәттәшлек турында яшерен килешү төзи. Алманнарның конкрет максатын бу очракта чыганаклар бик ачык күрсәтә – аларны бары тик бер нәрсә кызыксындырган: Төркия мөмкин кадәр тиз арада Россиягә каршы сугыш башлап җибәрергә, димәк, Россия игътибарын читкә юнәлдерергә тиеш булган. Ләкин Төркия үз мәнфәгатьләрен дә онытмый – ул әзерлексез рәвештә Россия белән хәрби низаг башлап җибәрергә ашыкмый. Бары тик 1914 елның 29 октябрь көнне генә төрек хәрби флоты Одесса һәм Севастополь портларын утка тотып, Төркия рәсми рәвештә сугыш хәленә керә.

Шунысы кызык – нәкъ 1914 елның октябрендә инде Алманиянең «ислам стратегиясе» нигездә әзер була. Ул стратегиянең авторы – күренекле дипломат һәм галим Макс фон Оппенһайм (1860-1946). Сугыш башына кадәр ул инде дипломат буларак Көнчыгыш илләрендә шактый зур тәҗрибә туплаган кеше булган, Алманиядә иң абруйлы Көнчыгыш һәм ислам белгече булып саналган. Үзенең тәҗрибәсенә таянып 1914 октябрендә М. фон Оппенһайм Алманиянең Тышкы эшләр министрлыгына үзе әзерләгән күләмле бер документ тапшыра. Ул «Безнең дошманнарның колониаль өлкәләрен революционлаштыру» дип аталган. Ахыр чиктә нәкъ шушы документ Алманиянең Беренче бөтендөнья сугышы вакытында мөселман дөньясы һәм мөселман халыкларына карата алып барган сәясәтенең нигезе булып торган. Аның эчтәлегенә күз салыйк.

Алман дипломатының төп ышанычлары түбәндәгедән гыйбарәт: беренчедән, дөнья мөселманнары барысы да бер зур дәүләттә яшәмәсәләр дә, алар бердәм,

оешкан көч тәшкил итәләр — аларны «исламчылык» («панисламизм») тәгълиматы берләштерә; икенчедән, бар мөселманнар Госманлы солтанын хәлифә итеп танышлар һәм анын өндәүләренә иярергә әзер; өченчедән, Алманиянен мөселманнар арасында абруе чиксез зур. Дөресен генә әйткәндә, аталган тезисларнын берсе дә дөреслеккә туры килмәгән, ләкин М.фон Оппенһайм шул ышанычына нигезләнеп алман дәүләт стратегиясен (планын) булдыра.

Дипломат фикеренчә, Госманлы дәүләте, сугышка кушылганнан соң, барлык Антанта илләренә «җиһад» игълан итәргә тиеш (М.фон Оппенһайм җиһадның «тылсымлы» көченә инде күптәннән ышанган булган, бу фикерне инде XIX йөз ахырында ук анын язмаларында да табарга мөмкин). Меморандум төзелгәннән соң күп тә үтми, алман дипломатынын «хыялы» тормышка аша — 1914 елнын 11 ноябрендә төрек солтаны Антанта илләренә — Англия, Россия һәм Франциягә җиһад игълан итә.

Шуннан соң, фон Оппенһайм фикеренчә, табигый рәвештә, мөселман халыклары Төркия һәм Алманиягә ияреп китәчәк. Ләкин игълан итү генә, әлбәттә, җитми — алман ягы мөселманнар арасында актив пропаганда эшен җәеп җибәрергә, Төркия исә пропагандистик чараларны һәр яктан хуплап, Россиягә каршы актив хәрби операцияләр уздырырга тиеш: «Төркиянен сугышта катнашуы — пропаганданың ин саллы инструменты булачак», — шулай дип уйлаган дипломат. Госманлы дәүләте барлык пропаганда чараларынын үзәге дә булып торачак, бирегә әзерлекле кадрлар, матди ярдәм җибәреләчәк. Бу эшне алып бару өчен Тышкы эшләр министрлыгы каршында махсус хезмәт оештырылачак (соңра андый учреждение чыннан да барлыкка килә — ул Шәрекъ буенча мәгълүмат үзәге дип атала).

Пропагандистик һәм хәрби һөҗүмнен төп объекты булып, әлбәттә, Англия саналган, чөнки ул дөньяның ин зур колониаль империясе булып торган. Макс фон Оппенһайм исәпләвенчә, Россиягә каршы көрәш бары тик Англия чын мәгънәдә хәлсезләнгәч кенә башланып китәргә тиеш булган. Бирегә бер кызыклы үзенчәлекне исәпкә алырга кирәк дип саныйм — алман дипломатынын күп кенә Шәрекъ илләре турында белеме шактый тирән һәм киң булган, ул үзе барып, алар турында мәгълүмат туплаган, ләкин Россия һәм Россия мөселманнары хәле турында ул артык күп белмәгән. Ул язганча, Россиядә барлыгы 19 миллион мөселман яшәгән (алар барлык империя халкынын 11 процентын тәшкил иткән). Бу саннар 1897 елда уздырылган халык санын исәпкә алу нәтиҗәләренә нигезләнгән, ахрысы — Россиядә XIX йөз ахырында чыннан да 11 процент мөселман исәпләнгән, ләкин аларнын гомум саны кимрәк булган, якынча 14 миллион. Меморандум текстында, мәсәлән, М. фон Оппенһайм бары тик Кавказ халыклары турында гына чагыштырмача төгәл сүз алып бара — имеш, Кавказ халыклары арасында Төркия һәм Алмания зур абруйга ия, алар арасында пропаганда эшен Төркиядә тупланган мөхәҗирләргә таянып алып барырга мөмкин дип исәпләгән ул. «Мөселманнар Кавказ халыкларынын ин кыю, сугышка сәләтле һәм көчле өлешен тәшкил итә, алар хәтта тыныч елларда да Мәскәү өчен зур проблемалар тудырып торган», — дип яза дипломат. Русиядә яшәгән башка мөселман халыклары турында ул өстен-өстен генә фикер йөртә. Бохара һәм Сәмәрканд халкы «тыныч холыклы» булганлыктан, анын «җиһад»ка кушылулары икеле дип исәпләгән ул, аларнын бер өлешенен генә өндәүләргә иярүләре ихтимал. Ә Идел-Урал мөселманнары «рухи яктан нык үскән һәм солтан-хәлифәне бик ихтирам итсәләр дә» бөтенләй «изге сугыш»ка кушып җибәреп булмас дип санаган М. фон Оппенһайм. Шулай да ул биредәге мәктәпләр һәм вакытлы матбугат аша пропаганда эшен алып баруны барыбер зарур дип тапкан.

Тора-бара Алмания бу стратегик планга нигезләнеп Шәрекъ илләрендә чыннан да шактый күпкырлы һәм актив пропаганда эшен җәелдереп җибәрә. Аңлашыладыр ки, Русия мөселманнары Алманиядән дә, Төркиядән дә географик яктан ерак территорияләрдә урнашкан, алар арасында пропаганда алып бару мөмкинлеге матди һәм оештыру проблемалары белән бәйле булган, җитмәсә, Русия хөкүмәте андый хәлне булдырмас өчен мөселманнарны каты һәм өзлексез күзәтү астында тоткан.

Шуна күрә Алманиянең пропагандистик тырышлыгы Идел-Урал татарлары яшәгән төбәккә кадәр сугыш вакытында барып җитә алмаган. Пропагандистик активлык нигездә хәрби әсирләр арасында күзәтелгән һәм бик үзенчәлекле нәтиҗәләргә китергән.

Мөселман әсирләре арасында пропаганда эшен алып бару хакында рәсми документларда шул ук М. фон Оппенһайм меморандумында укып була. Минем аңлавымча, бу кеше беренчеләрдән булып андый мөмкинлек турында җитди уйланган һәм бу юнәлештә тәгаен адымнар да тәкъдим иткән. Нәрсәләргә игътибар иткән соң алман дипломаты?

Аның мәгълүматларынча, Алманиядә инде дистәләгән лагерьда мөселман хәрби әсирләре тупланган, шулар арасында ул өчесен искә ала – Цоссен, Альтенграбов һәм Зенне. Төрле лагерьдан мөселманнарны җыеп махсус бер лагерьда туплау зарур дип саный ул. Алар өчен мәчет төзелеше планлаштырылган булырга тиеш – күп акча чыгармыйча мәчетне хәтта тактадан да төзеп була дип санаган М. фон Оппенһайм. Мәчеткә исә, җитәкчелек итү өчен, имам-хатыйп чакырылырга, ә мөселман әсирләре хәләл ризык белән тәэмин ителергә тиеш. Дипломат әсирләр белән мөгамәләдә тәрҗемәчеләрнең зур ролен аңлаган – тылмачлар аша пропаганда алып бару мөмкинлеген ассызыклап узган ул. Фон Оппенһайм тәкъдименчә, мөселман әсирләре бер лагерьга тупланганнан соң аларны «туу урыннары, кавемнәре, мәзһәбләре буенча» аерым төркемнәргә бүлү сорала, әсирләр арасында укый-яза белә торганнарына аерым игътибар итәргә кирәк – андыйлар пропаганда эше өчен аерата «файдалы» булырга мөмкин дип санаган ул. Әсирләргә туган якларына хат язу мөмкинлек бирелергә тиеш, чөнки хатлар аша да пропаганда алып барып була.

Әлбәттә, Макс фон Оппенһаймның 1914 елның көзендә ясалган бу тәкъдимнәре төгәл һәм тулысынча уйланылган җентекле план түгел. Җитмәсә, бу план күбрәк инглиз һәм француз гаскәрләрендә хезмәт иткән хәрби әсирләрне күз алдында тоткан – Русия мөселманнары турында белеме бик сай булганга күрә, М. фон Оппенһайм алар турында бик сак фикер йөртә: «Русия мөселман солдатлары белән артык күп нәрсә эшләп булмас, ахры. Аерым очракларны санамаганда, аларны күпләп хәрби хезмәткә тартып булмас. Алар аерым хәрби берәмлекләрдә берләштерелергә дә тиеш түгел. Шулай да, безнең кулда алар бик күп булып китсәләр, бу очракны да зур игътибар белән өйрәнергә кирәк».

Сонра тормыш бу фаразларга үз төзәтмәләрен кертәчәк – Алмания әсирлегендә дистәләгән мең Русия мөселман солдаты туплангач, алман хәрби һәм сәяси җитәкчелеге татарлар белән бик актив пропаганда эшен җәеп җибәрергә мәҗбүр була. Ни гаҗәп, сугыш ахырына аз санлы гарәп яки һинд хәрби әсирләре алман җитәкчелеге өчен «әһәмиятләрен» югалталар, ә меңләгән татар реаль пропагандистик эшнең бердәнбер объекты булып кала.

Бу эш ничек алып барылган, Алманиядә мөселман әсирләре нинди хәлдә булганнар, алар тормышына алманнарның пропагандистик эшчәнлеге ничек тәэсир иткән — монысы турында мин алдагы мәкаләләремдә сөйләрмен.

*Дәвамы бар*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор*

# «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»ДӘ — ТУЛЫ БЕР ГАСЫР

*Социализм чорында СССРда социаль-икътисади үсешне Россия империясенең 1913 елда ирешкәннәре белән чагыштырып күрсәтү киң таралган иде. 1913 елдан соң нәкъ йөз ел үтте.*

*2013 елгы статистик мәгълүматлар йөз ел элгәреләреннән үзләренең күптөрлелеге белән дә, төгәллеге белән дә аерылып тора... Шулай да күп милләтле, күп конфессияле уртак ватанда һәр халык, һәр милләтнең үз урыны, үз кыйбласы да бар бит әле... Йөз ел эчендә алар ни дәрәҗәдә үзгәргән, кайсы юнәлештә: үсү ягынамы, әллә киресенчәме? Редакциябез кунаклары: тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков, фәлсәфә фәннәре докторы Айдар Юзеев, тарих фәннәре кандидаты Рафаэль Мөхәммәтдинов, педагогия фәннәре кандидаты Марат Габдуллин әнә шул хакта сөйләшәчәкләр.*



Күмәк әңгәмәне кереш сүз белән журналның баш мөхәррире **Илфак ИБРАҺИМОВ** ачып җибәрде.

*— Йөз ел, бер гасыр вакыт узган. Шушы йөз ел дәвамында Россия дәүләте эчендә татар милләтенең тормышында нинди үзгәрешләр булган — шул хакта фикер алышсак иде. Инде ул вакыттагы Россия белән хәзерге Россияне чагыштырып булмый, СССРны гына чагыштырып була. Халык саны ягыннан да, территориясе ягыннан да.*

*Шул вакыт эчендә ике бөтендөнья сугышы булды. Татарлар икесендә дә актив катнашканнар. Совет дәүләтен төзү өчен, татарлар Урта Азиягә дә бик күп җибәрелде. Татар халкының демографик хәле йөз елдан соң ничегрәк? Өстәп шуны да сорыйсы килә: элек демографик мәгълүматларны алганда, яшәү сыйфаты дигән төшенчә булдымы икән? Болар хакында сүзне олуг галимебез, тарихчы-этнограф Дамир әфәнде башлап җибәрер, әлбәттә.*



**Д.ИСХАКОВ:**

— Куелган сорау буенча, бигрәк тә халык саны буенча гади генә сөйләшеп булмый. Иң әүвәл, без нинди географик чикләрдә карыйбыз Россия дигән дәүләтне? 1913 елгы яки 1917 елгы революциягә кадәрге Россия ул — бер дәүләт, ә аның нигезендә барлыкка килгән Советлар Союзы — ул инде бүтән дәүләт. Чөнки Рәсәйнең Көнбатыш өлеше төшеп кала: Польша, Финляндия. Ә инде хәзерге Россия Федерациясе ул — өченче төр дәүләт чынлыкта. Советлар Союзының шактый өлеше аерылып чыкты. Боларны турыдан-туры чагыштыру мөмкин дә түгел. Әмма Россия империясен СССР белән берникадәр дәрәҗәдә чагыштырырга була әле. Бердәнбер яхшы ягы шул инде безнең өчен: татарның төп массасы барыбер шул Россия эчендә. Татарларның саны буенча зур үзгәрешләр кичермибез. 1913 елны Рәсәйдә 159,2 миллион халык яшәгән. Бу — зур сан ул вакыт өчен. Шуңа күрә Россия империясе зур дәүләтләр янына кергән халык саны ягыннан. Ә инде 1980 елны, ягъни совет чоры бетәр

алдыннан, Советлар Союзында 286,7 миллион халык яшәгән. Гомумән алганда, Рәсәйдә 1913 елны, бу барлык демографлар тарафыннан да таныла инде, тормыш дәрәҗәсе ин югары вакыты Рәсәйнен. Аннан сон, сугышларга кереп киткәч, тормыш дәрәҗәсе төшә һәм халык арасында үлем-китем дә күбәя. Беренче зур катаклизм, демографик яктан катастрофа дип тә әйтергә ярый — Беренче бөтендөнья сугышы һәм ана ялганып киткән Гражданнар сугышы, ана ялганган ачлык еллары. Мин ачлыкны ни өчен аерып әйтәм, бусы буенча исәпләүләрем дә бар: шушы ачлык вакытында татарлар 13 процентка кимегән! Ә Рәсәй буенча Беренче бөтендөнья сугышы һәм Гражданнар сугышын да кертеп санаганда югалтулар саны 15 миллион кеше чамасы булган. Бу әле — турыдан-туры югалтулар гына, бар әле шул вакытта үлгән кешеләр гаилә кормыйча бала тумаганлыктан кимү дә. Болары якынча 7 миллион була. Ягъни Рәсәйдә 20-22 миллион югалту булган шул чорда.

Икенче Бөтендөнья сугышында югалтулар, барыгыз да беләсез, Советлар Союзында 25 миллионнан 30 миллионга кадәр һәм аннан да күбрәк дип исәпләнә. Әле бит шушы ике вакыйга арасында булган коллективлаштыру һәм индустрияләштерү вакытында халык кимү дә бар. Турыдан-туры мәгълүматлар юк, ләкин ким дигәндә 10 миллион кеше юкка чыккан. 37нче елларны да кертеп. Бу — бик зур саннар. Менә хәзер яна тарих дәреслегендә шушы вакытларны яктырту турында бәхәсләр бара. Гомумән XX йөздә Россиядәге югалтуларны исәпкә алган вакытта демографлар арасында шундый бәяләмәләр бар: әгәр дә Рәсәй шундый катаклизмнар кичермәсә, Советлар Союзында халык саны Американыкыннан ким булмас иде.

Бөтен XX гасырда Россиядә халык саны, 1913 елдан XX йөзнен ахырына кадәр, ничек кенә авыр булмасын, 1,8 тапкыр арткан. Татарларнын саны күбрәк тә үскән. 1913 ел буенча татарлар саны юк. Ә менә 1912 ел буенча санаган идем, мөселман статистикасын файдаланып, Россиядә 3 миллион 254 мен татар булган. 1926 елгы мәгълүмат та бар: 3 миллион 364,4 мен. Ягъни татарлар саны бик аз үскән шушы еллар арасында, әгәр нормаль үсеш булса алай гына булырга тиеш түгел иде. Шул сугыш-ачлык казалары инде. Ләкин шуна да карамастан, 20нче елларда татарларда семьялар зур булган әле, урта гаиләдә 4-5 бала үскән. Бала табуны чикләп булмаган. Үлем күп булгач, 10-12 бала туган, шунын яртысы исән калган. Әмма демографлар арасында шундый күзәтүләр бар: татарлар арасында бала үлеме азрак булган. Урыслар һәм безнен күрше халыклар белән чагыштырганда бу. Монын төп сәбәбе татарларда санитар хәл яхшы булу диләр, аннан сон татар әниләре бәбиләрен озак имезгәннәр. Бу — 20нче елларда да шулай булган: татар хатыннарынын бары биштән бере генә производствода эшләгән. Өйдә торгач, баланы карау да, имезү дә әйбәтрәк булган. Шуна күрә бала үлеме дә азрак булган. Бу хәл татар демографиясенә унай йогынты ясаган.

1989 елгы халыкны исәпкә алу буенча Советлар Союзындагы татарларнын саны 7 миллионга житә язды — 6 миллион 920,5. Бу — яхшы күрсәткеч инде. Әмма менә сонгы елларда тискәре күренешләр дә күзгә чалына башлады. 2002 елгы исәпкә алу вакытында Россия Федерациясендәге татарларнын саны 5 миллион 550 мен иде. 2010 елны исә 5 миллион 310 мен калды. Үлем дә зур һәм балалар саны да кимеде. Һәм, беләсез инде, Башкортстанда татарларнын бер өлешен башкорт дип яздылар. 200 менләп татар һаман да «башкорт» исәбе эчендә йөри әле. Алга таба халыкнын үсү мәсьәләсендә төрле прогнозлар бар. Әйтик, Рәсәйдә халыкара оешмалар, Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан эшләнгән прогнозлар буенча 2030 елга Россия халкы 135 миллионга, ә 2050гә — 116 миллионга калачак. Ягъни, хәзерге белән чагыштырганда (2010 елгы халык санын алу буенча Россия халкы 143 миллион чамасы иде), нык кына кими. Әмма пессимистик прогноз да бар: Россия халкы 2050 елны 80 миллион гына калырга да мөмкин. Татарлар буенча бердәнбер прогнозны без ясаган идек: 2025 елга татарлар саны 5 миллионнан аз гына артык булачак. Без исәпләгән вакытта 2002 елгы мәгълүматларга һәм аннан алдагыларына таянган идек. Хәзер менә, 2010 елгы халык исәбе мәгълүматларына баксаң, бәлкем, безнен исәпләү оптимистиграк та булгандыр әле дип тә уйлыйм мин хәзер. Беренче чиратта шушы ике фактор буенча: балалар туу аз булу һәм үлүчеләр саны күп булу.

Халыкнын уртача яше турында Рәсәй буенча хәзерге күрсәткечләр: ирләр — 59 яшь чамасы, хатын-кызлар — 72дән артыграк. Уртача күрсәткеч — 65,5 яшь. Америкада

ирләрнең уртача яше — 72,2, хатын-кызларныкы — 79,2. Ягъни без нык калышабыз. Татарларның хәле Россия күрсәткеченә якын дип уйлыйм мин. Бәлки, ирләрнең яше бераз гына зуррактыр. Халыкара оешмалар, демография белән шөгыльләнүчеләрнең шундый бәяләре бар: кайсы илдә халык саны алдагы дистә елларда күбрәк булса, шул илләрнең икътисади (экономик) потенциалы да югарырак була. Чөнки хәзер технологияләр бик тиз үзгәрә, шуңа күрә халык саны зур булган илләрнең икътисади мөмкинлекләре дә зуррак булачак. Ягъни Кытайның һәм Һиндстанның икътисади мөмкинлекләре зур булачак. Бу күзлектән караганда, ни кызганыч, Россиянең перспективалары зур түгел. Шуңа күрә ул киләчәктә Кытай, Һиндстан һәм Урта Азия арасында кысылып калган бер ил генә дә булырга мөмкин. Европаны да әйтсәк була тагы. Анда бала туу бик аз. Төге төп Европа саналган илләр халкы кимиячәк. Әмма анда, беләсез инде, эмигрантлар күп, шуңа күрә халык саны тулаем сакланып калыр. Әмма алдагы дистә елларда Европа әллә ни әһәмиятле төбәк булмаска да мөмкин. Шушы күзлектән караганда, билгеле, татарның саны аз булу безнең мөмкинлекләрне нык чикли. Ул яктан без хәзер төрки кардәшләребездән дә нык калышабыз. Мәсәлән, 20нче йөз башында үзбәкләрнең һәм казакъларның саны безнекеннән әллә ни аерылмаган. Хәзер исә алар безне инде нык кына узып киттеләр. Фаразлар буенча 2050 елда без, бәлки, 5 миллион чамасы гына калырбыз, ә инде казакъларның саны 25, ә бәлки, 30 миллион булыр, үзбәкләр исә 45-50 миллионга житәчәк. Безнең өчен бердәнбер үсү мөмкинлегебез хәзер — сыйфат ягын кайгырту. Менә яһүдләрнең (еврейларның) да балалары аз туа. Яһүд һәрбер баласын, кулыннан тотып, 5 яшеннән үк 3-4 төрле мәктәпкә йөртә башлый — музыка, тел өйрәнү һ.б. Менә безгә дә шундый юл гына кала. Сыйфатлы милләт булырга уйласак, үзебезнең аз санлы балаларны шәп кенә тәрбияләп, гаиләне яхшыртып, шул юл белән бара алабыз. Билгеле, кайбер экзотик мәсьәләләр турында да сөйләшә алабыз. Мәсәлән, күп хатынлылык турында. Әмма татарда андый традиция бик юк. XVIII гасырда, мәсәлән, Казанда бернечә хатынлы татарлар нибары бер процент тәшкил иткән. Авыл җирлегендәген дә караганым бар — XVIII-XIX гасырларда күп хатын гадәттә муллаларда һәм бераз байларда булган. Байларның да күбесе бер хатын белән яшәгән. Шуңа күрә, алга таба исламны кире кайтарсак та — ислам дүрт хатын алырга рөхсәт итә — бу яктан әлләни перспектива күренми. Хәлбуки, Жириновский әйтә инде ул, күп хатынлылык кирәк, дип, урысларны кайгыртып әйтә, әлбәттә, ләкин православиедә мондый нәрсә каралмаган. Ә менә Төньяк Кавказдагы мәгълүматлар буенча анда күп хатынлылык таралган, бигрәк тә Чечняда һәм Ингушетиядә. Һәм моның чыннан да нәтиҗәсе бардыр. Чеченнар һәм ингушларның саннары тиз үсә.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**



— Халык саны буенча белгеч түгелмен, бары шуны гына әйтә алам. Татарларның милли ризыгында ит һәм сөт ашамлыклары зур урын алып тору һәм хәмер эчмәү сәбәпле, алар урыска караганда сәламәтрәк халык булган. Моны 2нче Дөнья сугышында немесләрнең әсирләр лагерьларында төрле милләт кешеләренә язылган медик тасвирламалары да күрсәтә. Мәсәлән, медиклар татар һәм башкорт әсирләренең башкалар белән чагыштырганда сәламәтрәк һәм ныграк булуына игътибар иткәннәр. Мондый өстенлекне табиблар аларның яхшы туклануы һәм сәламәт тормыш рәвеше белән аңлатканнар.

Сугыштан соң татарның туклануында бер унай һәм бер тискәре күренеш пәйда булды. Унае — ул, урыска ияреп, үз бакчасында яшелчә һәм җимеш үстерә башлады һәм шуның белән ризыгын төрләләндерде инде. Яманы — татар ирләренең фронтта йөз грамм «наркомовский аракыны» эчәргә күнегеп, аннары сугыш беткәч тә, бөтен халыкны эчәргә өйрәтүе.

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Сез ясаган йомгак Равил Фәйзуллинның: Тәкъдир шундый — дөньяда башка халыкларга караганда безгә ун тапкыр тырышыбрак эшләргә, ун тапкыр күбрәк иҗтиһад итәргә, ун тапкыр бердәмрәк булырга, ун тапкыр яшәү сыйфатын яхшыртырга кирәк дигән сүзләренә туры килә икән.*

*Татар халкы укый-яза белүче иң алдынгы милләтләрдән саналган. Милли мәгариф стандартлары төшенчәсе йөз ел элек бар идеме? Хәзер бармы? Җәдитчелек узган гасыр күренеше генә идеме, әллә, яңа рәвешләр алып, ул әле дә дәвам итәме? Чит илләрдә уку элек тә булган. Сорбонналар, Гарвардларда укыганнар. Милләттәшләр бүген дә чит илләрдә укыйлар. Алар безнең милли мәгарифне үстерүгә ни дәрәҗәдә бәйле булачаклар?*



**М.ГАБДУЛЛИН:**

Милли мәгариф турында әйткәндә, хәзерге терминологияне сак кына кулланырга кирәк. Әлбәттә, XX гасыр башында нинди дә рәсми гомуми стандарт булмаган. Әлбәттә, омтылыш булган: берничә тапкыр алар «Правила образования восточных инородцев» кебек документлар кабул итеп караганнар. Аларның берсе — нәкъ менә 1913 елда кабул ителгән кагыйдәләр. Әмма алар, рәсми булсалар да, нинди дә бердәнбер ысул, бердәнбер кагыйдә булып калмаган. Алар дәүләтнең таләбен, ягъни дәүләт татар милли мәгарифенең нинди булуын теләр иде — шуны гына күрсәтә. Ә инде татарларның үз карашы турында әйткәндә, анда да нинди дә бердәмлек булмаган, чөнки ул вакытта татарларның берниди Мәгариф министрлыгы да була алмаган. Роно, инспекторлар, нинди дә рәсми оешмалар... Әмма, мәгариф системасы булган, чын мәгънәдә милли система...

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Ул бердәм системаны милли стандарт дип атарга ярыймы?*

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Алай бик стандарт дип әйтмәс идем, чөнки ул табигый үскән, үз кагыйдәләренә, үз кануннарына нигезләнеп — үзлектән үскән табигый система һәм ул шактый чуар булган. Мәсәлән, бер яктан традицион ислам кануннарына, ислам җәмгыятенә нигезләнгән безнең мөселман белем бирү системасы, мәдрәсәләр һәм мәктәпләр. Әлбәттә инде, мәдрәсәләр соңыннан кадим һәм җәдит мәдрәсәләренә бүленгән. Бу — бер юнәлеш. Икенче юнәлеш инде дәүләт һәм берникадәр земство карамагында булган урыс һәм татар мәктәпләре. Өченче юнәлеш — миссионерлык мәктәпләре һ.б., һ.б. Алар инде христиан дине әгъзалары карамагында булган һәм аларның турыдан-туры максатлары — христиан динен тарату. Бу мәктәпләрнең йогынтысы керәшеннәр арасында бик көчле булган. Шуна күрә менә бу бик чуар система нинди дә бердәм кануннарга нигезләнмәгән. Әлбәттә, дәүләт аны нинди дә бердәм системага салырга тырышкан, кагыйдәләр дә кабул иткән, әмма, гомумән әйткәндә, татар мәгариф системасы үз үзенчәлеген, үз мөстәкыйльлеген саклап кала алган, чөнки аның матди нигезе булган. Бездә мәктәп-мәдрәсәләр эшенә дәүләт әлләни кысыла алмаган, чөнки акча күбесенчә байлардан, меценатлардан, тулаем татар җәмгыятеннән килгән. Фәнни яктан, методик яктан да бу система мөстәкыйль булган. Татар галимнәре үзләре программалар язып, үзләре дәреслекләр язып, үзләре үк аларны тараткан да. Мәсәлән, XVII гасыр башында без шундый дәрәҗәгә җитәбез ки, татар мөгаллимнәре үз араларыннан берәр абруйлы мөгаллимне сайлап, аны инспектор рәвешендә төрле мәктәпләргә җибәреп, ул мәктәпләрне өйрәнеп, аларга бәя биргәннәр. Нинди дә рәсми инспекция түгел бу, әлбәттә, бары тик үзеннән коллегана, хезмәттәшенә чын мәгънәсендә бәя бирү. Әйтәләр бит инде, «по гамбургскому счету» дип. Нинди дә исемнәр, мактаулы бүләкләр тарату түгел, бары тик бу мәктәптә эш ничек куелган, аны ничек яхшыртып була һ.б., һ.б. Һәм шулай ук инде үзлектән татар мәгърифәтчеләре тырышып карадылар мөгаллимнәренең белемен күтәрә торган системаны торгызырга, беләсездер инде, атаклы Буби мәдрәсәсендә шундый курслар оештырып карадылар. Әмма дәүләт бу мәдрәсәне бик тиз генә япты һәм ул үсә алмады. Асылда татар мәгариф системасы ул мөстәкыйль, үз-үзен оештыра һәм үстерә торган система булган. Берниди күзәтеп тора торган башлыгы булмаган, бары тик татар җәмгыятенең ихтыяҗларына, таләпләренә җавап бирә торган система булган. Инде тарих үзгәреп, җәмгыять үзгәреп, ана таләпләр туа икән, бу мәгариф системасы да шул яңа таләпләргә туры килә торган реформалар, мөмкинлекләр хасил иткән.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Марат әфәнде, минемчә, әгәр дә шушы халыкның дәүләте булмаса андый стандарт булмый чынлыкта.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Әлбәттә, әлбәттә. Ә инде җәдитчелеккә килгәндә... Мәсәлән, Европада мәгърифәтчеләр мәгариф чоры дип әйтәләр — Вольтерлар, Руссолар чорын, ә безнең өчен шундый бренд, марка ул — җәдитчелек.

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Бүгендәме?*

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Әлбәттә, әлбәттә, ул бүген дә саклана, абруе, дәрәҗәсе бик югары. Әгәр дә без чынбарлыкка баксак, чын вәзгыятьне анласак, ниндидер бердәнбер партия кебек юнәлеш булмаган. Әлбәттә, күпләр үзләрен «без җәдитче» дип әйткәннәр һәм без аларны җәдитче булган дип туплыйбыз ниндидер бер төркемгә. Ләкин алар бит ниндидер уртак фикерләр нигезендә хезмәттәшлек иткән, фикердәшләр булган кешеләр. Шул җәдитчелек хәрәкәте эчендә төрле кешеләр бар. Алар эшчәнлекнең ниндидер өлешендә фикердәшләр булганнар, әмма башка принциплар буенча капма-каршы фикердә торганнар. Берәүләр татар телен укытырга кирәк, дигән, икенче берәүләр, юк, кирәкми, аны бала гаиләдә өйрәнә, дигән. Кемнәрдер, дөньяви фәннәр күбрәк булырга тиеш, дигән, әмма безгә бары тик арифметика, алгебра, бухгалтерия генә кирәк, диючеләр дә булган. Приказчиклар әзерләсәк житә, янәсе. Кемдер әйтә: юк, безгә, киресенчә, яна фәннәр — методика, психология ишеләрне үстерергә кирәк. Һәм шулай ук җәдитчелек хәрәкәтендә ниндидер үзәк орган булмаган. Әлбәттә, башкаларны туплаган бөек шәхесләр булган. Шул ук Исмәгыйль Гаспринский. Аның «Тәрҗеман» газетасы бик абруйлы булган, үзенә күрә бер үзәк кебек инде. Әмма ул барыбер дискуссия мәйданы гына булган. Шуңа күрә җәдитчелекнең тарихи әһәмиятен бәяләгәндә ул заман кешеләренә без хәзерге карашларны такмаска тиеш. Без аларга шул заман вәзгыяте күзлегеннән карарга тиеш. Шуңа күрә инде, бөтен җәдитчеләрне булмаса да, берләштерә торган бер сыйфат — татар халкын, татар милләтен артта калган, урта гасыр кагыйдәләренә таянып яши торган түгел, ә бәлки заман таләпләренә җавап бирә торган, Россия һәм дөнья халыклары арасында мөстәкыйль һәм дәрәҗәле халык дип күрергә теләү. Һәм моның юлын алар заман таләпләренә җавап бирә торган мәгариф системасы аша табып була дигән фикердә торганнар. Бу ниндидер гомуми төшенчә, әлбәттә, бу — бәхәсле мәсьәлә. Әгәр дә без инде бөтен җәдитчеләрне бер гомуми төшенчә белән генә берләштерергә теләсәк, менә бу аларның бөтен фикерләрендә яткан бер уртаклык дип уйлыйм.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Җәдитчелекнең эш нәтиҗәләренә килгәндә, беренче чиратта без татар мәгарифенең эш нәтиҗәсен дә карарга тиешбез. Менә мин статистика белән шөгыльләнүче кеше буларак әйтә алам: XX йөз башында татар ирләренең өчтән ике өлеше грамоталы (сәвадлы) булган — ул вакыт өчен зур күрсәткеч. Хатын-кызлар арасында мондыйлар өлеше күпкә кимрәк булган. Урта Идел буенда татар хатын-кызларының укый-яза белгән өлеше урыс һәм башка милләт хатын-кызларына караганда күбрәк булган. Бу — бик әһәмиятле нәрсә. Без уйлыйбыз менә, ни өчен егерменче елларда төрле коммунист чиновникларның хатыннары татар хатыннары булган дип. Белем булган чөнки аларда. Менә бу — эшләгән эшнең нәтиҗәсе. Инде менә Советлар Союзы вакытында модернизациягә кергән вакытта татарларда беренче дәрәҗәдәге укый-яза белү — белем дәрәҗәсе житәрлек булган.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Мин моның белән килешәм. Һәм нәкъ шуннан башларга теләгән идем. Менә бу җәдитчелек хәрәкәтенең йогынтысы һәм аның мирасы шулкадәр зур ки, без аны хәзер дә кулланабыз.

Әгәр дә бу мәгърифәтчеләрнең һәм җәдитчеләрнең мирасы булмаса, фин-угыр халыклары кебек әле һаман да 10-11 еллык милли мәктәпне торгыза алмас идек.

Бу безгә бик яхшы фундамент булды, һәм шул фундаментка таянып, без бу егерме ел эчендә бик тиз үсә алдык.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Бер мисал гына китерәм. Безнең бөтен тарих дәреслекләренен концепциясе Мәрҗанидә бар инде. Шуннан ерак китмәдек без, шул ук кысада эшлибез.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Һәм, кызганычка каршы, без әле дә — безнең хәзер министрлыклар бар, Фәннәр академиясе бар — һаман да әле җәдитчеләребез менгән үрләрдән артык күтәрелә алмадык. Әмма бүген безнең вәзгыять бөтенләй башка. Әйткәнемчә, XX гасыр башында татар системасы күбесенчә мөстәкыйль үскән — үз кануннары буенча, үз теләкләре буенча. Татар җәмгыятенә ничек кирәк булган — шулай үскән. Бүген без бары тик Россия кысаларында, бүген бердәм мәгариф тирәлеге — «единое образовательное пространство» дигән нәрсә бар, һәм бүгенге кануннар буенча мөстәкыйль мәгариф системасы Россия эчендә рөхсәт ителмәгән һәм каралмаган. Ул мөмкин дә түгел. Бер яктан рәсми кануннар буенча бу бердәм киңлекне без җимерә алмыйбыз, икенче яктан, моның матди нигезе юк. Бүген безнең Рәмиевләр кебек, Хөсәеновлар кебек меценатларыбыз күренми.

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Сүзегезне бүлеп түгел, аңларга теләп сорыйм: җәдитчелек бит миллилекне инкарь итмәгән. 2013 елда гына да матбугатта 400ләп татар шагыйренең әсәрләре басыла. Бүгенге мәктәпләребездә милли укыту стандарты булмаса, без киләчәктә дүртәр йөз шагыйрьне күрә алырбызмы?*

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Кызганычка каршы, бүгенге вәзгыятьтә Россиядә без үзебезнең милли стандартны тудыра алмыйбыз. Без язып карадык. Берничә галим — Рашат Әмирхан, башкалар милли университет концепциясен язып карадык. Милли мәгариф доктринасын, концепцияләрен язып карадык. Әмма алар бары тик безнең милли хыял, теләк кенә булып калды, чөнки, телибезме-юкмы, без бүген бары тик Россия кануннарына нигезләнеп кенә эш итә алабыз.

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Ул кануннарга каршы килмичә генә, йөз ел элгәре кебек үзебезнең милли мәгарифне булдырып булмыймыни?*

**Д.ИСХАКОВ:**

— Гафу итегез, безгә мәсьәләгә киңрәк карарга кирәк. Шушы мәсьәләне тикшереп карасаң, революциягә кадәрге Россиядә демократия бүгенгегә караганда күбрәк булган. Әмма эш бит шуңа барып тоташа. Кызганычка каршы, без булган мөмкинлекләрне дә файдаланмыйбыз. Бүген Марат әфәнде белән сөйләштек, кичә дә сөйләшкән идек. Милли тарихны укыту буенча безнең бөтен дәреслекләр дә бар. Татарстан эчендә моны эшләп була әле. Хәлбуки, кысылды анда вәзгыять — сәгатьләр җитми, диләр инде. Татарстаннан читтә исә укытып булмый, чөнки бүтән төрле программа. Әмма Россия стандартларында төбәк тарихын укыту каралган. Төбәк тарихын укытканда беренче чиратта әйтәчәкләр: сезнең менә бармы, мәсәлән, Төмән өлкәсендәге татарларның тарихы? Юк безнең андый тарих. Бу яктан без үзебез әзер түгел. Менә шушы яңа вәзгыятькә җайлашып кереп китәргә кирәк безгә. Ә бит Төмән өлкәсе татарларының тарихын укытканда да шуның эчендә бөтен милли тарихны биреп була.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Әлбәттә, әлеге Россия мәгариф стандартлары кысалары эчендә дә эш итеп була. Әмма без менә бу хәзерге вәзгыятьтә җәдитчеләр тәҗрибәсен дә өйрәнергә тиешбез. Ул вакытта бит Казан гына үзәк булып тормаган. Троицк, Оренбург, Төмән... — татарлар яшәгән һәрбер төбәкнең мәгърифәтчеләре булган, китапханәләре булган, үз наширләре-нәшриятлары булган һәм алар китаплар, газитләр, журналлар чыгарып ятканнар. Ул вакытта ук безнең нинди дер үзәкләштерелгән система булмаса да,

мәгарифебез бөтен төбәкләргә таралган, шул төбәкнең вәзгыятен аңлап-белеп хәл иткәннәр һәм шул ук вакытта аларны берләштерә торган уртак фикерләр дә булган. Шуңа күрә без бүген Россия кануннарын әйбәт кенә өйрәнергә тиешбез. Кызганычка каршы, без бүген дәүләт биргән мөмкинлекләрне белеп бетермибез. Мәсәлән, ата-аналарга яңа мәгариф кануны буенча һәм Конституция буенча бик зур мөмкинлекләр бирелә. Әмма без аларны файдаланмыйбыз.

**Д.ИСХАКОВ:**
— Чөнки мәктәп сайлый.

**М.ГАБДУЛЛИН:**
— Әйе. Бүген региональ компонент, төбәк компоненты бетте. Бу — тискәре күренеш. Әмма мәктәп компоненты артты. Һәм ата-аналарның хокуклары артты. Әгәр дә ата-аналар әйтсә, безнең балаларга татар теле кирәк, әдәбияты кирәк, татар тарихы, мәдәнияте кирәк, дисә, мәктәп, һичшиксез, бу ата-аналарның теләкләрен кире кага алмый, чөнки закон буенча бары тик ата-аналар гына үз балаларына нинди телдә белем бирү, кайсы фәннәрне укытуны сайлау хокукына ия. Алар хәл итә моны. Мәктәп бүгенге көндә бары тик хезмәт күрсәтә. Шуңа күрә без бүген үзебезнең җәмгыятьне, үзебезнең ата-аналарны тәрбияләргә тиешбез, аларга хокукларын, бурычларын аңлатырга тиешбез. Баланы бирдем дә шуның белән минем вазифалар бетте дип уйларга тиеш түгел һичкем.

**Д.ИСХАКОВ:**
— Тагын бер нәрсә өстик. Төрек дуслар белән очрашканда алар болай дип әйтәләр: Төркиядә 15-20 шәхси университет бар. Россия эчендә өч яһүд университеты эшли. Һәм белегез: һәр зур шәһәрдә яһүд мәктәпләре бар. Димәк, менә бу милләт үзенең мәгариф системасын корган булып чыга. Димәк, бу мәсьәлә буенча татар милләте әле җитлекмәгән. Юкса революциягә кадәр безнекеләр алдынгы урында торган.

**М.ГАБДУЛЛИН:**
— Без һаман да әле дәүләттән көтеп, кемдер килеп безгә мәктәп ачар, нәрсәдер тамар дип совет идеологиясе кысаларында яши бирәбез.

**А.ЮЗЕЕВ:**
— Җәдитчеләр мәгърифәттә бик олы эшләр башкарганнар, әйе. Ләкин алар шул ук вакытта сәясәтчеләр дә булганнар бит әле. Һәм тагы кем генә булмаганнар. Менә шундый кин хәрәкәткә ия татарлар.



**М.ГАБДУЛЛИН:**
— Йомгаклап шуны әйтик: XIX йөз ахырында рус дәүләте дә, татар мәгърифәтчеләре дә татар халкына белемне, мәгарифне таратырга тырышканнар. Әмма максатлар ике төрле булган. Татарлар, мәгариф системасын үстереп, татар халкын үстерергә омтылса, рус дәүләте мәгариф системасын бары тик инструмент буларак кына күргән. Татарларны мәгариф системасы аша рус мәдәниятенә, рус дәүләтенә якынайту һәм аларны яхшы гражданнар иттереп, бердәмлекне ныгыту булган максат. Һәм татар теле монда укыту теле буларак бары тик башлангыч, беренче адымда гына каралган. Чөнки рус теле ул чакта чын мәгънәсендә чит тел булган, татарлар бит рус телен белмәгәннәр. Шуңа күрә Ильминский системасын алып, татар телен файдаланып, әкрен-әкрен шул хәрефләр таный башлап, рус телен өйрәнеп, аннары инде тулысынча рус теленә күчеп, рус мәгариф системасына кереп китүне максат иткән Россия дәүләте. Бүген дә шул ук системага әйләнеп кайттык.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**
— Мәскәүнең бөтен сәясәте, аның бөтен кануннары милли мәгарифне юкка чыгаруга юнәлтелгән. Мисал итеп шул ук Бердәм дәүләт имтиханын гына алыйк. Аны русча гына бирү рөхсәт ителүе генә дә татар мәгарифен җимерергә җитәрлек бер чарадыр.

Татар халкы һәм аның Татарстанның иҗтимагый оешмаларындагы һәм

парламенттагы милләтпәрвәр вәкилләре исә мондый сәясәткә каршы иделәр. Алар татарның балалар бакчасыннан башлап милли университетка кадәр үз милли мөстәкыйль мәгариф системасын булдыру ягында иделәр. Йөз ел элек мәгарифебез мөстәкыйль иде һәм аның финанс нигезен татар байлары тәэмин итте.

Җәдитчелек ул конкрет тарихи күренеш иде. Бу күренешнең яшәүчәнлеге ике нәрсәгә таяна иде. Беренчесе — ул заманда милләтебез мәхәлләләрдә һәм бистәләрдә укмашып, саф татар мөһитендә яшәгән. Икенчесе — мондый яшәү системасын тәэмин итүче урта сыйныф, ягъни байлар, мөгаллимнәр һәм муллалар иде. Хәзерге җәмгыятебездә боларның берсе дә юк, шуна күрә заманча җәдитчелек тә юк.

Чит илдә, мәсәлән, Төркиядә укып кайткан яшьләребез берничек тә милли мәгарифне үстерүгә тәэсир итә алмый. Бу тәэсирне булдыру өчен Татарстан җитәкчелегенең бу өлкәдә максатчан стратегик сәясәте булырга тиеш, ә ул юк. Яшьләребез читтән кайткач, аларны лаеклы эш белән тәэмин итү планнарыбыз булырга тиеш. Ләкин акчаны менә шундый изге максатларга бирү урынына, миллионлаган долларны чит ил футболчыларына бирәбез.

Әлбәттә, татар җәмгыятенә бәяләмәләрне ул чор матбугатында да, төрле әсәрләрдә дә табып була. Мәсәлән, «милләт» һәм «милләтчелек» төшенчәләренең мәгънәсе нәрсәдә, милләтнең асылы нидән гыйбарәт, милләт булу өчен җәмгыять, зыялылар нишләргә тиешләр? кебек сораулар татарны йөз ел элек тә борчыган.

**А.ЮЗЕЕВ:**

Мин дә хәзерге Россия сәясәтендә мәгърифәт буенча берни дә үзгәрмәде дип беләм. Татарлар табигать фәннәрен өйрәнмәскә тиеш дип ачыктан-ачык язалар әнә. Академиклар «российская нация» — «россиялеләр милләте» турында сөйлиләр. «Ни нәрсә соң бу?» дип сорагач, берсе болай дип ярып салды: «Тут все знают, что российское — это русское». Башка милләтләр нишләргә тиеш икән соң? Этнология институты директоры Тишков «Они должны ассимилироваться потихоньку», дип яза әнә. Ягъни йотылырга, урыслашырга тиешбез. Һәм шундый сәясәт бара да.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Берничә ел элек Екатеринбург шәһәренә барган идек, татар гимназиясе ачарга дип. Шунда Свердлов өлкәсенең мәгариф министры килде безнең янга, сөйләшергә дип. Сорый бездән: «А что, математику можно преподовать и по татарски?!» — ди. Бәхеткә каршы, заманында мәдрәсәдә эшләнгән математика дәреслеге алып барган идек, күрсәттек. Чиновниклар да надан шул инде, аларның элементар белемнәре дә юк.

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Җәмәгать, әйдәгез, 1913 елгы статистика белән йөз елдан соң булганны чагыштыруны дәвам иттерик. Йөз ел элек татар матбугатының да киң таралган чагы булган. Дөрес, аларның күбесе озын гомерле түгел. Шул ук вакытта Төркиядә һәм бездә дә таралган уртак газеталарыбыз да булган. Ул чорда матбугатта милли идея темасы нинди чагылыш тапкан? Бу, әлбәттә, татарның үз дәүләтчелеге идеясеДер, үз мәдәниятен саклау, үстерү идеяседер, халыкның узаңын тәрбияләү милли идеягә керә торгандыр. Бүгенге көн милләтчеләре, безнең зыялыларыбыз милли идеяне ничек дип аңлыйлар? Йөз ел аралыгында милли идея төшенчәсе нинди үзгәрешләр кичерде?*

**А.ЮЗЕЕВ:**

— 1905 елгы беренче рус революциясеннән соң мөмкинлек чыгу белән татарлар моннан беренчеләрдән булып файдаланган. Газета-журналлардагы чыгышларының темасы милли мәсьәлә белән бәйле. Татарлар Россия империясендә үз урыннарын таба алсын өчен ни эшләргә кирәк? Әйе, төрлерәк сәяси агымнар булган. Берәүләр урынны күбрәк — исламга, икенчеләре татарлыкка биргән, әмма барыбер дә төп идея бәйсезлеккә ирешү булган. Хәтта Галимҗан Ибраһимов белән Мулланур Вахитов кебек социалистлар да шуна омтылган, алар бары 1917 елда большевикларның шул хактагы вәгъдәләренә ышанып алданганнар гына. Садри Максуди белән Йосыф Акчура кебекләр турында инде әйтеп тә торасы юк.

Аннары Акчурадан бер кызык фикер таптым мин. Милләтчелек идеясе тарала

башлауның сәбәпләрен аңлатканда болай дип фикер йөртә ул. Тарихта, — ди, — ислам нинди генә зур эволюция кичерсә дә, ул барыбер бәйсез шәхескә үз-үзен яклар өчен берниндИ дә хокук системасын булдыра алмаган. Шуңа күрә Көнбатыш Көнчыгышны мәдәни йота башлаган. Бик кызык фикер. Чөнки чыннан да Көнбатыш, анда милләтчелек формалашкач, демократия килә, гражданлык җәмгыяте. Индивидиумны, шәхесне яклар өчен кеше хокуклары барлыкка килә. Менә шул демократияне яклап яшиләр европалылар. Ислам дөньясында исә тәки килеп чыкмады бу механизм. Исламда нәрсә ул коллективизм? Менә өммәт — ул коммунизмда шикелле. Бер толпа, бергә яшибез, вәссәлам?!

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Әмма аның эчендә дә демократик орлыклар бар бит. Үсә генә алмады ул.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Хикмәт анда түгел. Әгәр дә дин дәүләттән аерылмаса, демократия белән нисбәт мәсьәләсе туа. Аңа игътибар итәргә кирәк шулай ук. Татарлар алар, башка милләтләрдән аермалы буларак (исламлылар турында сүз бара), барыбер реформация чорын үткән. Менә бу җәдитчелекнең мөһим бер кисәге — ислам реформасын башкарып чыгу. Менә шул күзлектән караганда бүгенге мисырлылар әнә, иракълылар, иранлылар — алар бездән шушы яктан артта. Алар бу этапны үтмәделәр дә, шуның өчен сугышып яталар. Бу яктан без хәтта рустан да өстен торабыз, чөнки руста шулай ук православие дине реформация үтмәде. Ни өчен Рәсәйдә капитализм үсешенең рәте юк? Шуңа күрә. Әгәр реформация юк икән, динне дәүләттән аермыйлар икән, ул дәүләтнең үсеше нормаль булмый. Дин үзе мөстәкыйль дәрәҗәдә калырга тиеш. Дәүләт ул — бер әйбер, җәмәгатьчелек — башка әйбер. Шул вакытта гына чынлап торып алгарыш була. Ләкин моның авыр ягы да бар. Ислам дине бит ул бөтен җәмгыятьне каплап алырга ярата. Структурасы шундый. Менә ул яктан авыррак ислам дине белән демократия кору. Әмма, Төркия тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бу юлдан да барып була әле.

**А.ЮЗЕЕВ:**

— Мин бу фикер белән килешеп бетә алмыйм. Мисыр белән Иран заманында беркадәр реформа үттеләр әле. Бөтенләй үтмәгән илләр — Согуд Гарәбстаны белән Гарәп Әмирлекләре.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

Төрле шәхесләрнең милләтчелеккә мөнәсәбәте турындагы сүзне дәвам итик әле. Йосыф Акчура милләтчелекнең тууын урта сыйныф формалашуы белән бәйләгән, аныңча урта сыйныфның икътисади мәнфәгатьләре милләтнең һәм милли идеянең куәтле булуы белән тыгыз бәйле була. Татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин үзенең 1913 елда чыккан «Милләтчелекнең кайбер әсаслары» әсәрендә, этносны милләт дәрәҗәсенә фәкать милли культура гына күтәрә ала, дип яза. Татар галиме вә журналисты Җамал Вәлиди исә үзенең «Милләт вә миллият» дигән әсәрендә татарда милләтчелекнең барлыкка килүен болай аңлата: «Аңлашыла ки, бездә милли идея барлыкка килер өчен, иң элек гомуми бер уяныш кирәк иде. Милли аңның тууы өчен элек гомуми бер аң хасил булырга тиеш иде. Менә 1885 һәм 1905 еллар арасында булган җәдитчелек агымы бездә шушы гомуми аңга хезмәт итте». Ә милләтне ул, кан, дин, тел, гадәт һәм традиция кебек принципларның берлеге нигезендә җыелган бер җәмгыять, дип билгели. Г.Гобәйдуллин әлеге әсәрендә, башта без, татарлар, үзебезне «төрк будун» (халык) дип атадык, аннары — «мөселман милләт» дип, тагын да соңрак — «милләт (nation, нация)» дип атый башладык, дип яза. Тарихчының фикеренчә, 1913 елда татар җәмгыятендә «милләт» сүзенең 3 төрле аңлатмасы таралган булган. Берәүләр ул сүз белән дөнья мөселман өммәтен атаганнар, икенчеләре милләт итеп болгар яки татар халкын атаганнар, өченчеләре исә бөтендөнья төрки халыкларын күздә тотканнар.

Нәтиҗәдә шуны әйтергә була. Югарыда искә алынган зыялыларның күпчелеге татарны милләт итеп санаган. Ләкин аермалары да булган. Мәсәлән, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов һәм Ж.Вәлидиләр татарны «татар милләте» дип санаганнар. Й.Акчура исә татарны бөтен Русия төрки милләтенең бер өлеше итеп күргән. С.Максуди үз халкын зур төрек-татар милләтенең бер өлеше итеп санаган.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Милли идеология турында сөйләшкәндә, аны күп яктан карарга кирәк. Безнең революциягә кадәрге мәдәни кырда кинәт кенә пәйда була Сөембикә образы. Һади Атласи белән Ризаэддин Фәхретдин махсус хезмәтләр яза. Фатих Әмирханның «Сөембикә» дигән хикәясе басыла. Шушы мәсьәләне Германиядә эшләгән бер галим — Ноок, исеме Андерс, күтәреп чыга. Аның фикере бик кызыклы: татарлар эшләргә тырышканнар Милли Ананы. Бу бит — трагик фигура. Бу инде Казан ханлыгы шәхесе генә түгел, гомуммилли шәхес килеп чыга. Үзе әле хатын-кыз, берләштерүче. Минем әйтергә теләгән фикер шул: милли идеология ул төрле яклардан оешкан. Аның фәлсәфи ягы да булган, менә бу ягы да килеп чыккан.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

— Йөз ел элек эшләгән шәхесләрнең һәм хәзерге зыялыларыбызның эшчәнлегендә нинди уртаклыклар һәм аермалар бар, дигән сорауга җавап эзләгәндә Җ. Вәлиди фикерләренә мөрәҗәгать итү файдалы булыр иде. Аның фикеренчә, безне алар (руслар) изми, без бу хәлдә торсак (үсмичә, алга бармыйча), үзебез аның аяк астында калып изелербез. Алар (руслар) — тулы көчкә килә торган поезд. Әлбәттә, без начар арбабыз белән аның юлына кермәскә тиеш, керсәк, тапталуда үзебез гаепле булырбыз (моны мин татар рус культурасын тулысынча кабатлап яши башласа, татар булудан туктаячак дип аңлыйм). Аннары ул, без аңа тапталмыйк, киресенчә, утырып китәрлек куәт туплыйк, — ди. — Безгә ике нәрсә кирәк: милли мәктәпкә, әдәбиятка, сәнгатькә таянган милли рух вә Русия гражданлыгы.

Аннары ул, рәсми хакимият беркайчан да татарның милли теләкләрен исәпкә алмас, моңа өметләнмик, дип нәтиҗә ясый. Аннары сүзен, Русиянең демократик даирәләре татарга илнең бөтен халкының бер өлешенә караган кебек кенә, социаль яссылыкта гына карыйлар, милли мәсьәләләр аларга мөһим түгел, дип дәвам итә.

Аның дин институтларына да өмете юк. Мөфтиятне реформалаштыру мөмкин түгел, дип яза ул. Духовный Собраниене исә караңгы татар руханилыгының бюрократлык катыш бер почмагы дип кенә саный. Хәзрәтләрнең чиновникларга әйләнеп баруын раслый. Ничек бу сазлыктан чыгып була икән дип уйлана Җ. Вәлиди. Ул, безгә бу хәлдә бары бер генә юл кала: рәсми дини идарәләрне, формальлекләрне бер якка куеп торып, дәүләт кануннары мөмкинлек биргән кадәр милли, иҗтимагый, мәдәни хәрәкәтләр башлап, үзебезгә алгарыш юлына басарга кирәк дип саный. Аның тәгаен тәкъдимнәре дә бар. Мәсәлән, авылларда рус классларын һәм җәдитче мәктәпләрен күбәйтү, хәйрия җәмгыятьләрен, алгарышлы ислам вә мәгариф нәшриятларын, җәмгыятьләрен арттыру, мәдрәсәләргә яңа фәннәр кертү, әдәбиятны, матбугатны да күбрәк «халыкка хезмәт» ноктасына төбәбрәк алып бару.

Йөз ел элек булган һәм бүгенге вәзгыятьләрдә һәм зыялылар эшчәнлекләрендә нинди охшашлыклар һәм аермалар бар дигән сорауга җавап эзләгәндә, шуны әйтергә була. Минемчә, элек тә, хәзер дә рус дәүләтенең һәм җәмгыятенең татарга карата мөнәсәбәте һич үзгәрмәгән. Аларның нияте — безне ассимиляцияләү. Руханиларыбызның күпчелеге элек тә надан һәм чиновник ролен үтәүче кешеләр иделәр, хәзер дә шул дәрәҗәдә. Элек «халыкка бару» (хождение в народ), дәрт һәм күтәренкелек принципларына таянып, зыялылар милләт өчен шактый эшләр башкардылар. Соңгы елларда да милли идеягә бирелгән зыялылар Татар иҗтимагый үзәге кебек оешмалар аша милләтне уяттылар, изге эшләр эшләделәр. Аерманы шунда күрәм: элек татар мәгарифе татар байлары җилкәсендә иде, хәзер ул Татарстанның, ягъни дәүләтнең бюджетында эшли.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Байлар гына түгел. Ялгышмасам, Оренбургта приказчиклар җыелып, бер белемлерәк егеткә, без сине үзебез акча туплап, мәдрәсәгә җибәрәбез, аннары, белемгә тиенгәч, син безнең хокукларны якларсың, дип укырга җибәргәннәр.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Күп урыннарда мәдрәсәләрне байлар тотмаган бит, халыктан да акча җыйганнар.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

— Әйе, алай да булган. Тагын бер аерма шуннан гыйбарәт. Элек җәдитләр милләтне

алгарышка илтер өчен рус теленә, рус мәдәниятенә бик нык игътибар иткәннәр, хәтта авылларда рус классларын да ачарга тырышканнар. Бу сәясәт йөз елдан соң безне, ниһаять, алгарышка илтеп куйды. Ләкин без, татарлар, бу алгарыш артыннан чаба-чаба арттырып җибәрдек бугай. Аның артыннан куа-куа үз асылыбызны — татарлыгыбызны, үз телебезне югалта башладык. Безгә хәзер җәдитләр кебек авылларда рус классларын оештыру турында түгел, ә татар классларын арттыру турында уйларга кирәк.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Хикмәт шунда бит, ул XX йөз башларында, аннан соң да рус мәдәнияте югары дәрәҗәдә булган. Бүгенге көндә рус мәдәнияте бик нык артта калды. Шуна күрә, рус мәдәнияте артыннан барсаң, син дөнья күләмендә төшеп каласың. Аннан соң бит татарның белем дәрәҗәсе хәзер русныкыннан ким түгел, мәсәлән, Татарстан эчендә. Руслар үзләре дә үзләренең бүгенге дәрәҗәсеннән риза түгелләр. Вәзгыять хәзер тамырдан үзгә.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

— Татар халкының тоткан урыны хакындагы сорауга җавап итеп шуны әйтә алам. Йөз ел элек төрки дөньяда татарлар иң зыялы, иң алдынгы милләт булып саналган. Моны хәтта төрекләр дә таный. Ләкин хәзерге заманда күп кенә төрки милләтләр үз бәйсез дәүләтләрендә яши, шуңа күрә аларның безгә караганда үсү мөмкинлекләре күпкә зуррак, һәм алар өчен без күп өлкәләрдә үрнәк була алмыйбыз инде. Ләкин шәхси һәм иҗтимагый тормыш кимәлендә (аеруча XX гасырның 90нчы еллары дәвамында) татарлар һаман да югары урыннарда торалар иде. Мәсәлән, алар беренче булып Төрки Халыклар Ассамблеясен һәм Төрки Яшьләр Ассоциациясен оештырып җибәрделәр. Статистик мәгълүматларга караганда, Төркиядә укыган бөтен төрки студентлар арасында иң яхшы укучылар татар студентлары булып чыкты.

Милләтнең үсеш перспективалары җәһәтеннән шуны әйтәсем килә. Татарның шәһәрләрдә укмашып яшәвен оештырмыйча торып, милләтебезне үстерүе бик авыр булыр, бәлкем, мөмкин дә түгелдер. Территориаль сегрегациягә ихтыяҗ бар. Укучыларны татар һәм рус мәктәпләренә җибәреп аерган кук район һәм микрорайоннарны да бүлергә кирәк. Шунда гына татар теле һәм мохите туар, үзгә бер тормыш формалаша башлар.

Татар телен дәүләт теле иттереп гамәлгә кертү кебек революцион чаралар гына безне коткарачак. Әгәр без тагын дистәләрчә еллар урыс белән кочаклашып утырып, аны башыннан сыйпап, аның үз иреге белән татар телен өйрәнүен көтеп утырсак, без татар теленә үз кулыбыз белән балта чабачакбыз. Бөтен башка толерантлык чаралары имитация генә булып калыр.

Дини өлкәдә дә үзгәрешләр кертергә кирәк. Мәсәлән, динне фән һәм фәлсәфә белән бутамаска. Фәндә — интеллект, логика, диндә исә йөрәк, тойгы, психика хөкем сөрә. Диндә әхлакый тәрбиягә, социаль ярдәмләшүгә, рухи һәм физик сәламәтлеккә басым ясарга кирәк, чөнки бу юнәлешләрдән халкыбыз алкоголь, наркотиклар, катнаш никахлар, гаиләләрнең таркалуы кебек тискәре күренешләр белән көрәшүдә тәгаен файда ала.

Исламны милләтләштерүне мин нәрсәдә күрәм? Беренчедән, Коръәннең иң кирәкле һәм реаль тормыш белән бәйле булган аятьләрен татарчага шигъри формада тәрҗемә итеп, аларны мөнәҗәтләр сыман татар көйләренә укырга иде. Димәк, бездә Коръәннең адаптацияләнгән бер татар варианты булырга тиеш. Моны эшләмәсәк, тиз арада муллалар — гарәпчәгә һәм русчага, гади халык русчага күчәчәк инде. Хәзер үк Казандагы Россия Ислам университетында бөтен укыту русча бара әнә.

Милләтчелек идеологиясенең һәм хәрәкәтенең икътисади һәм финанс нигезе исә тарихта гел урта сыйныф булган. Шул сыйныф пәйда булгач кына, хәзерге зур бюрократлар һәм олигархлар кулындагы хакимият шул сыйныф кулына күчәчәк. Әлегә кадәр безнең вак һәм урта хәлле татар эшмәкәрләре аз санлы һәм сыйныф буларак һаман формалашмаган. Мин милләтебезнең котылу чарасын урта сыйныфның милли зыялылар белән берләшүендә күрәм.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Конкрет сөйләшик. Менә Америка аерым программа кабул итте. Һәрбер илдән ун мең студент җибәрделәр анда. Казакъстан да ун мең кешесен укыта — дәүләт хисабына укып яталар. Мин Америкада булганда исә Медисон университетына биш

хатын-кыз килгән иде. Болар профессорлар барысы да. Бер елга дәүләт жибәргән — инглиз телен өйрәнү өчен. Һәрберсе кечкенә баласын да алып килгән. Бер ел шунда мәктәпкә биреп укыталар инде. Бездә андый программалар юк бит.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Укыту гына түгел. Казакъстанда һәрбер район хакименен ярдәмчесе яки урынбасары да шул программа аша узган. Димәк, укытып кына калмаганнар, һәркайсына урын да биргәннәр.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Монын нәтижәсе күренә. Казакъстанда телевидениедә эшләүчеләрнен барысы да бит Америкада укып кайттылар. Назарбаевнын кызы да шунда укыды. Шуна күрә, карасагыз казакъ телевидениесен, безнекенә караганда бер башка югары ул. Безнеке исә — провинциаль телевидение.

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Тема шулхәтле зур. Мондый кимәлдәге сөйләшү була алырмы икән дип, йөз ел элек татар милләтенә кагылышлы мәгълүматлар бар микән дип курыккан да идек хәтта. Минем бүгенге сөйләшүне ике сорау белән йомгаклауга юнәлтәсем килә. Беренчесе. Сез моны үзегез дә күзәттегез: йөз ел эчендә Россиянең сәяси дәүләт төзелеше, структурасы үзгәрде. Шушы дәүләт эчендәге субъектларның, төбәк җитәкчеләренең исемнәрен үзгәртү ни дәрәҗәдә принципиаль икән? Татарстан республикасының Президенты ул республика җитәкчесе генә түгел, бөтен дөньяга таралган татар иленең җитәкчесе дә. «Татар Иле» дигән олы бер Ил бар бит әле. Анда дөньяның биш кыйтгасына таралган татарлар керә. Безнең республикабызның җитәкчесе, президент буламы ул, башкача аталамы, барыбер Татар Иленең җитәкчесе, башлыгы булды. Менә шушы статусны югалтмаска иде! Ул исем үзгәрмичә калмас, әлбәттә. Ә менә ничек бөтен татар иле башлыгы статусы алыр икән ул? Сез моңа ничек карыйсыз?*

**Д.ИСХАКОВ:**

— Туксанынчы елларда безнен статусны үзгәртергә тырышып караулар ул барыбер элекке Татарстан автономиясенә бәйле. Безнен артка чигенеп ясаган адымнар — болар бит чынлыкта без кире якка киттек дигән сүз. Безнен күз алдында бит Испаниядәге Каталония аерылып чыгып мөстәкыйль дәүләт төзү турында сүз алып бара. Ә без бөтенләй артка китеп, хәзер губернага әйләнеп барабыз. Һәм шунын бер элементы — республикаларнын дәүләт билгеләрен жуйдырырга тырышу. Татар телен дәүләт теле кимәлендә укыттырмау өчен нинди көрәш бара әнә. Монын өчен көрәшүчеләр — Мәскәүдәге аерым кешеләр тарафыннан кулда тотылып эшләүчеләр. Мин аларнын барысын да беләм. Һәм кем артында кем торганын да беләм. Югары Россия Конституция судынын карары да булды — республика эчендә татар телен тигез рәвештә укытырга мөмкин дигән. Ләкин, шуна да карамастан, көрәш бара. Менә шуна күрә «президент» исемен югалттырырга тырышуны системанын бер өлеше итеп күрергә кирәк. Әгәр дә татар теле Татарстан эчендә дәүләт теле булмаса, әгәр дә аны русларга укыту мәжбүри булмаса, ул бөтенләй бетә чынлыкта. Без бик күп әйберләрне югалттык инде. Авыл исемен алыштырганда да Мәскәүгә мөрәжәгать итәргә тиешбез әнә — топонимнар да кулдан югала дигән сүз. «Президент» исеме дә шуна килеп тоташа хәзер. Шулай әкренләп сүтелеп беткәч, «республика» дигән исеме калса да, эчке яктан ул губернага әйләнергә мөмкин хәзер. Мин, мәсәлән, «президент» исемен саклап калырга мөмкинлек бар дип саныйм. Чөнки ахыр чиктә моны барыбер безнен парламент хәл итә. Әгәр дә халык бердәй фикердә булса, парламентарийлар да каршы тора алырлар иде дип уйлыйм. Аларны бит халык сайлый. Әмма халык монын кирәклеген анлый микән? Хикмәт бит исемдә генә түгел, жисемдә дә. Хәтта исемне алмаштыру да мөмкин. Президент дигән исем — конституция нормасы. Һәм бу конституция нормасы Россия Конституциясе белән тәнгәлләштергәннән сон да калды. Без аны ни өчен югалтырга тиеш ди әле? Мин Минтимер Шәймиевнен фикерен ишеттем. Ул каршы. Һичшиксез, бездә исем сакланып калырга тиеш, диде, Конституция нормасы буларак. Дөрес, аннан сон хәзерге Татарстан президенты үзе,

мина ничек тә ярый, дип әйтте. Әмма монда халыкның фикерен төрле якка бору тиеш түгел. Индус Таһиров та телевидение аша бер чыгышында, Татарстан президенты, Мәскәү тарафыннан китерелгән кеше булса да, Татарстан Конституциясенә кулын куеп ант итте, диде бит...

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

— Без дөрес юнәлештә сөйләшмибез. Руста шундый бер мәкаль бар: «Снявши голову, по шапке не плачут». Мин матбугатны күзәтеп барам. Россиядә хәзер шундый атмосфера, рус халкының һәм дәүләт органнарының кәефе-хәле шундый ки, Россия хәзер зур тизлектә унитар дәүләткә әйләнеп бара. Уйлавымча, берничә елдан Федерацияне, бәлки, юкка чыгарып бетермәсәләр дә, республикаларны барыбер бетерәчәкләр. Безгә нишләргә соң? Ике вариант бар дип уйлыйм. Иҗтимагый оешмалар җитәкчелегендә халык актив күтәрелеп, каршы чаралар күрүне таләп итәчәк безнең җитәкчелектән. Ләкин менә безнең түрәләрнең позициясе нинди булыр ул вакытта? Ике төрле икәне күренеп тора бит әнә.

Исемгә килсәк, хикмәт сүздә түгел бит, аның эчтәлегендә. Алмаштырырга мәҗбүр булсалар, мин тәкъдим итәр идем «Башкың» дигән сүзне. Төркиядә бу «президент» дигән сүз. Чөнки «башлык» башка кия торган әйбер дә ул. «Ил башы»да ике сүздән тора. Аны килештә төрләндерү читен.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Без бер әйберне уйлап бетермибез. Татарча исем куярга тырышканда да, Мәскәү моны шома гына үткәреп җибәрмәячәк. Чөнки анда, Президент аппараты тирәсендә һәм шуңа хезмәт итүчеләр арасында, татар телен бик яхшы белүче шәхесләр дә бар. Алар, һичшиксез, аңлатып бирәчәкләр. «Әфәнделәр, сез болай итеп куйсагыз, болай булачак, бик дөрес булмас», — диячәкләр. «Башкың» ул Төркиядә президентны белдерә, диячәкләр. Башкортстанда «хаким» дигән сүз тикмәгә генә килеп чыкмады бит ул...

**А.ЮЗЕЕВ:**

— Әгәр «президент» дигән исемнән баш тартсак... Безнең суверенитеттан хәзер шул исем генә калгандыр да инде, анысын да йолкып алмакчылар менә. Россияне федератив дәүләт дибез икән, Татарстан дәүләт инде. Дәүләтнең исә президенты булырга тиеш. «Президент» исеме белән дәүләт вәкаләтләрен дә бирәсең инде. Болар бар да хәзер кәгазьдә генә үзе. Ләкин кәгазьдә булса да кала бирсеннәр әле. Бәлкем, күпмедер вакыттан тиешле шартлар да туып куяр?

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Озак сөйләштек, сүзне йомгаклыйсак та буладыр инде. 1913 елдан соң йөз ел үтеп китте. Һәркайсыгыз шушы йөз ел эчендә булган, Россия өчен яки безнең милләт өчен әйбәт, позитив бер яки ике үзгәрешне әйтсен иде.*

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Позитив әйбер шул: хәзер безнең яшь буын татар теленнән хурланмый совет чорындагы кебек. Ул вакытта бит безнең тел күп кенә яшьләргә авыл теле, артта калган мәдәният теле булып тоела иде. Соңгы чирек гасырның казанышы шул: яшьләр горурланып татарча сөйләшә. Без менә бу йөз елның баштагы һәм урта өлешендә җуйган күп нәрсәләрне кире кайтара алдык. Әйтик, шул ук фәндә, мәгариф системасында.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Гаяз Исхакый әйткән ике йөз еллык инкыйраз юлының яртысын үткәнбез инде. Әмма без исән әле. Татар телен белүчеләр дә шактый әле. Шуңа күрә мин бөтен нәрсә дә начар димәс идем. Казанышлар да бар. Егерменче йөздә бездә профессиональ фән формалашты. Яхшымы, начармы, бездә Фәннәр академиясе бар, институтлар эшли. Безнең буын китсә дә, ул институтлар сакланачак, алга таба үсү мөмкинлеге бар. Тагын бер казаныш шул: минем белән килешмәскә мөмкиннәр, әмма шушы йөз ел дәверендә татарның шәһәр катлавы оешты. 1917 елда шәһәрдә 5-6 процент кына яшәсә, хәзер татарның 70 проценты чамасы шәһәрдә яши. Моның кимчелекле яклары да бар, әмма алдагы перспективага карaганда төп тормыш шәһәрдә булачак. Татарның шәһәр халкы бар. Сыйфаты — башка мәсьәлә.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

— Мин тагын өстәп шуны да әйтим әле. 1913 елга караганда безнең хәзер татар тормышының «тармагы кинәйде». Профессиональ җыр-бию, рәсем ясау, опера-балет кебек сәнгать төрләре барлыкка килде. Хәзер безнең бюрократия бик көчле. Түрәләр, идарә системасы барлыкка килде. Безнең 80 процент бюрократ — татарлар хәзер. 1913 елда мондый урыннарда урыслар утыра иде.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Россиянең берничә министрлыгында татар кешесе утыру да унай күрсәткеч бит. Россия империясендә мондый күренеш булмаган.

**Р.МӨХӘММӘТДИНОВ:**

— Бу тулаем унай күренешнең тискәре ягы да бар. Менә бу киңәйгән, үскән система, аның төрлелеге. Әмма ул элекке мөстәкыйльлеген җуйган һәм бераз тирәнлеген дә югалткан. Чөнки большевиклар властька килү белән асылда шул рус большевик калыбыннан ясалган культура инде күпчелек очракта. Калька, безнең мәгариф системасы да татарчага тәрҗемә ителгән генә. Философия дигәне дә шул коммунистик философия генә. Үз тарихыбызны үстерергә дә бирмәделәр безгә.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Әбрар Кәримуллин 1913 елда татарларның чыккан китаплар саны буенча Россиядә икенче урында торганлыгын язды. Тиражы буенча, урыслар һәм латышлардан кала, өченче урында булганнар. Бу бит бик зур җиңү чынлыкта.

**Р.ЮНЫС («Казан утлары»):**

— Галим булмасам да, сүзгә кушылып шуны да өстим әле. 1968 елны Камал театрында Татарстан Язучыларының VII съезды үтте. Шунда Рафаэль Мостафин чыгыш ясады һәм, 1913 елда татар китаплары хәзергегә караганда күбрәк чыккан, дип әйтте. Татарстанның Табиев кебек олы җитәкчеләре алдында бу. Шушы дөрес фактны әйткәне өчен Рафаэль абыйны эшеннән алдылар. Ягъни «Казан утлары» редакторлыгыннан.

**Д.ИСХАКОВ:**

— Шулай, ул чакта китаплар күбрәк чыккан. Дөрес, күләм һәм сыйфат ягыннан хәзергеләрдән калышалар инде.

Тагын бер әһәмиятле мәсьәлә шул. Безгә бер әйбер турында нык кына уйларга кирәк. 1913 елда татарларның абсолют күпчелеге авылда яшәгән. Һәм һәрбер татарның милке булган. Җир. Менә безнең шәһәр халкы формалашты. Ләкин шәһәрдә милек мәсьәләсе бик катлаулы хәзер. Ул күзлектән караганда, бәлки, безнең старт позициясе капитализмда яшәү өчен унайрак булгандыр — бүгенге белән чагыштырган вакытта. Безнең монда халыкның күпчелеге хәзер — милексез. Һәм аны туплау өчен, алга таба үсү өчен бик күп вакыт кирәк булачак.

**М.ГАБДУЛЛИН:**

— Тагын бер нәрсә өстәп була. Татарлар яхшымы, начармы, интеграция процессын узган. Бүген бу мөселманнар алдында торган бик зур проблема. Хәтта Төркиядә дә Европа белән интеграцияләшү четерекле проблема. Һәм тагын — дөнья мәдәнияте белән интеграцияләшү. Әмма монда башка проблема барлыкка килә. Бу интеграция барышында үзенчәлегебезне, йөзебезне җуймабызмы? Хәзер без инде урыс теленнән курыкмыйбыз, инглиз теленнән дә курыкмыйбыз, әмма татар теле сакланып калырмы менә бу интеграция формасында?

**И.ИБРАҺИМОВ:**

*— Безне борчыган һәм уйландырган нәрсәләр күп. Аларын киләсе әңгәмәләрдә тикшерербез инде. Бусында шулай актив төстә катнашуыгыз өчен рәхмәт!*

*Әңгәмәне* **Илфак ИБРАҺИМОВ** *һәм*
**Рәфикъ ЮНЫС** *әзерләде.*

*Татарстан Композиторлар берлеге оешуга 75 ел*

# «МУЗЫКА ТЕЛЕ — ИҢ ҮТЕМЛЕ ТЕЛ...»

*1939 ел Татарстан сәнгате өчен иң уңышлы елларның берсе буларак тарихта калган. Мәскәүнең опера студиясен тәмамлап кайткан яшь җырчы, композитор, шагыйрьләр яңа ачылган Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлый, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты барлыкка килә, Композиторлар берлеге оеша. Соңгысының беренче көннәрдән диярлек сәнгатьнең һәрбер өлкәсенә — опера театры, филармония, җыр һәм бию ансамбле, радиокомитет эшчәнлегенә тәэсире зур була. Берлекне бала чактан ук лидерлык сыйфатларына ия булган көчле шәхес, композитор Нәҗип Җиһанов җитәкләве дә үз ролен уйнамый калмагандыр. Җиһановның оештыру, дилбегәне кулда нык тоту сәләте турында бүген дә легендалар йөри. Милли республикаларда беренчеләрдән төзелгән Композиторлар берлеге буларак Татарстан оешмасына Мәскәү тарафыннан да игътибар зур була. Бүген татар музыкасы, берлек эшчәнлеге турында сүз чыкса, еш кына өлкәннәребез әнә шул елларны сагынып искә ала. Татарстан сәнгатенең шаулап алган чорыннан нәрсәләр сакланган соң, беренчеләребезнең традицияләре дәвам итәме, 75 еллыгын каршы алган Композиторлар берлегенең бүгенге вазыйфасы нинди? Әлеге һәм башка мәсьәләләр турында Татарстан Композиторлар берлеге рәисе, Россия һәм Татарстанның халык артисты, Г.Тукай премиясе лауреаты, композитор **Рәшит Фәһим улы КӘЛИМУЛЛИН** белән әңгәмәләшеп алырга булдык.*

**— Совет чорында иҗатчыларны — яңа совет кешесен тәрбияләү коралы — идеолог буларак кулланалар. Шуңа да аларның дәрәҗәсе зур, урыннары түрдән булган. СССР иҗат берләшмәләренең шаны исә чит илләргә дә тарала. Бүген башка заман, бөтенләй башка вәзгыять. Мәдәният күләгәдә калган бу чорда берлекләр, аерым алганда Композиторлар берлеге ни дәрәҗәдә үз асылын саклап кала алды?**

— Совет чорында Композиторлар берлеге зур көч-кодрәткә ия булган. Берлекнең зур терәге — музыкаль фонд аша иҗатчыларга фатир, машиналар, елга ике тапкыр иҗат йортларына барырга мөмкинлек бирелгән. Иҗат йортларында композитор әсәр язып кайтып, сәнгать советы тикшергәннән соң аның өчен гонорар да алган. Әлеге ысуллар югары иҗат нәтиҗәсе булсын өчен, махсус уйлап табылган. Бу чорда зур күләмле әсәрләрнең күпләп иҗат ителүе нәкъ шуна бәйле дә. Әсәрләрнең киләчәк язмышын да күп очракта берлек хәл иткән: радио-телевидениегә язу-язмауны, оркестр яисә башка оешмага бирү-бирмәүне берлек каршында эшләүче сәнгать советлары билгеләгән. Шул ук вакытта иҗатчыларны бер түбәгә туплау, җыю, нинди дә булса дәрәҗәдә, аларны контрольдә тоту өчен дә кирәк булган. Сүз уңаеннан, Венада узган музыка көннәрендә мин бер кызыклы фактка юлыктым: совет музыкасына каршы алар да махсус идеология булдырган, ягъни,

коммунистик системага каршы капиталистик система СРУлар ярдәмендә авангард музыка тудыруга юнәлтелгән сәясәт алып барган. Хәзер формаль идеология юк, шул ук вакытта иҗатчылар өчен шартлар да юк. Бүгенге көндә композитор союзга музыкасын алып килә икән, без аны оркестрларга башкаруга гына тәкъдим итә алабыз. Безгә бүтән хокуклар бирелмәгән.

**— Әлеге хәл РФ иҗат оешмалары турында федераль канун кабул ителгәч үзгәрдеме, әллә алданракмы?**

— Мин Татарстан Композиторлар берлеген 25 ел җитәклим, шушы еллар эчендә иҗат берлекләре нинди генә чорлар кичермәде, аларга кагылышлы нинди генә кануннар кабул ителмәде. Бөтенләй игътибардан читтә калган вакытлар да, хаос-та яшәгән чорлар да булды. Хәтта үз-үзебезне тәэмин итү турында уйларга чакырулар, коммерция белән шөгыльләнергә өндәүләрне дә ишеттек. Ләкин иҗат оешмалары, иҗат кешесе коммерция белән шөгыльләнергә тиеш түгел, бу юл деградациягә китерер иде. Иҗат кешесе вакытын юк-барга сарыф итмичә язарга, иҗат итәргә бурычлы, чөнки ана Ходай тарафыннан шундый сәләт бирелгән. Һәрбер кеше композитор, яисә шагыйрь була алмый, иҗат кешеләре, галимнәр — «сайлап алынган» кешеләр. Шуна аларга игътибар да зур булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, безнен республикада иҗат берлекләренә җитәкчеләр беркайчан да битараф булмады, Татарстан җитәкчелегенә кем генә килмәсен, аларның мәдәниятка мөнәсәбәтләре һәрвакыт унай булды. Шуна да без азмы-күпме дәрәҗәдә үз абруебызны саклап кала алдык дип уйлыйм.



*Композиторлар берлеге бинасы*

**— Мондый вәзгыятьтә берлек иҗатчыга ни дәрәҗәдә кирәк соң?**

— Союз, композиторлар үзәге, яисә башкача аталамы ул, ничек кенә йөртелмәсен, композиторларны бер түбә астына җыю фарыз. Әлеге оешмалар булмаган илләрдә музыка да юк. Төркияне генә алыйк... Анда зур, масштаблы әсәрләр иҗат итүчеләр бик сирәк, бары җыр жанры гына үсештә. Дәүләттән ярдәм булган илләрдә исә барысы да бар. Мәсәлән, Словения, Хорватиядә композиторлар тулысынча тәэмин ителгән. Татарстан спортта гына түгел, мәдәниятта дә алда булырга тиеш. Моны җитәкчеләр анлый: Казанны өченче сәнгать башкаласы дәрәҗәсенә күтәрергә тырышу шунын ачык мисалы. Сладковскийнын симфоник оркестрны җитәкли башлавы очраклы түгел, опера һәм балет театрын да нык күтәрәләр. Чөнки бу сәнгать оешмалары хәзер Казаннын брендына әверелде.

**— Әлбәттә, Казанның өченче мәдәни башкала исеменә дәгъвалавы сөенечле күренеш. Ләкин бирелә яшәүчеләр классик академик музыканы ни дәрәҗәдә кабул итәләр соң? Социологик сораштырулар күрсәтүенчә халыкның 1,5% гына әлеге төр музыкага өстенлек бирә икән.**

— Ул ике процентны ничек саныйлар сон алар? Кеше башы буенчамы, өйләргә кереп аудиоархивларын барлапмы? Концертка йөрү-йөрмәү генә процент мәсьәләсен китереп чыгара дип уйламыйм. Камал театрына ничә процент кеше йөри? Ул да бит академик театр...

**— Ләкин театр — башка сәнгать, халыкка күпкә якынрак, үзе дә бит ул халык уеннарыннан барлыкка килгән.**

— Мин житди музыка белән быел районнарга чыктым, очрашуга килгән балаларның әти-әниләре музыкантлар түгел, гади халык. Шуңа да карамастан алар балаларын әлеге житди сәнгатькә якынайтырга телиләр. Бу концертларда, иң мөһиме, кызыксыну уяту. Очрашу вакытында бирелгән сораулардан, алынган автографлардан әнә шул кызыксыну барлыкка килгәнен аңларга мөмкин. Мәктәпләрдә, башлангыч сыйныфлардан ук, музыка дәресләре кирәк мөһим (жыр дәресләре түгел!). Әлеге дәресләрнең ничек үтүе дә зур әһәмияткә ия.

Классик музыка концертларына һәм опера театрына йөрү-йөрмәү турында сөйләшкәндә билетларга бәя мәсьәләсе дә мөһим роль уйный дип уйлыйм. Мәсәлән, Софья Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» фестивалендә төрле көнне төрле музыка яңгырады, һәм әлеге концертларга бәяләр дә төрле иде. Менә бәйле аудитория дә төрле булды, керү билетлары очсызрак концертларга студентлар, пенсионерлар күбрәк килсә, башкаларында хәлле кешеләр ешрак очрады. Әгәр дә Жәлил театрына билетлар арзанрак булса, гади халык та опера һәм балетка бик теләп йөрер иде дип уйлыйм.

**— Гади халык кына түгел, музыкант, композиторлар, сәнгать белгечләре үзләре дә анда сирәк эләгә бугай. Берәр премьера турында тапшыру янсә мәкалә өчен фикер сорарга киләсең — алар карамаган булып чыга...**

— Әлбәттә. Чөнки санап узылган профессия вәкилләренә чакыру билетлары калдырылмый икән, аларның һәр премьерага билет сатып алып керергә мөмкинлекләре юк. Мәсәлән, көз көне Резеда Ахиярованың «Алтын Урда» балеты булды, без күбебез әле аны күрмәдек, чөнки чакыру билетлары премьера вакытында таратылмый диярлек — бу театр сәясәте. Югарыдан да сәнгатькә кагылышлы ниндидер сәясәт булырга тиеш: репертуар мәсьәләсендә дә, билет хаклары буенча да... Чөнки бүген академик музыка концертына бер кеше килеп, тәэсирләнеп кайтып китсә, ул бу сәнгать төренә гашыйк булып, киләчәктә дусларын да жәлеп итәргә мөмкин.

**— Сез районнарга чыгуыгыз турында әйтеп уздыгыз. Бәлки, чыннан да, иҗат кешеләренә халык белән ешрак очрашырга кирәктер. Ни өчен соң кече шәһәр-районнарга чыгуны ешрак оештырмаска?**

— Ул бит зур мәшәкать. Тоттың да чыгып киттең түгел, район житәкчеләренең дә бу идеяне күтәреп алуы мөһим. Анда барып житәр өчен транспорт, афишалар хәстәрен күрергә кирәк, артистларга түләргә акча юнәтү дә зарур. Композитор очрашуда нәрсәдер сөйләп кенә тамашачыны кызыксындыра алмый, тыңлаучыга иҗатны да ишеттерү мөһим. Шагыйрьләр шигырь укый алалар, ә безгә үз әсәрләребезне яңгыратырга музыкант, жырчылар кирәк. Шуңа да әлеге «сәяхәтләр» турыдан-туры мэрларга, район житәкчеләренең ярдәменә барып тоташа. Мәсәлән, Илдар Шәукәтович мэр булганда, Чаллыда житди музыка яңгыравын теләде. Һәм без оркестр белән Яр-Чаллы шәһәрендә зур концерт биреп кайттык, залда алма төшәрлек тә урын юк иде. Менә хәзер Сладковский Зөлфия Рәүпованың «Ак бүре» операсы белән районнар буенча йөрергә планлаштыра. Бу кирәкле эш. Ләкин, кабатлап әйтәм, моның өчен мәдәният министрлыгы, район үзәкләре бюджетыннан акча бүленергә тиеш.

**— 75 еллык тарихы булган Композиторлар берлегенең 25 елы Сезнең житәкчелектә узган. Сезгә кадәр дә бу вазыйфада бары тик ике кеше: Нәжип Жиһанов һәм Мирсәет Яруллин булган. Гадәттә, башка оешмаларда рәисләргә устав буенча 3-4 елдан күбрәк идарә итү хокукы бирелмәгән. Язучылар арасында, мәсәлән, бу вазыйфа өчен һәрвакыт көрәш бара. Композиторлар берлегендә житәкчеләрнең сирәк алышынуы нәрсәгә бәйле?**

—Композиторлар элек-электән тынычрак халык булган. Сталин чорында, мәсәлән, бер композитор да кулга алынмый. Сез беләсез, ул вакытта кемнедер

халык дошманы итәр өчен өч имза житкән! Татарстан берлегендә рәисләрнең сирәк алышуының тагын бер гади сере бар. Композиторлар аз һәм әлеге җаваплы эшне үз җилкәсендә күтәрергә теләүчеләр юк диярлек. Аннан һәрбер кеше җитәкче була да алмый. Рәислек — зур җаваплылык һәм вакыт таләп итә торган вазыйфа. Мин, мәсәлән, бервакыт үземне колхоз рәисе итеп тоя башладым, иҗатым да артта калган кебек булды. 48 яшьләрдә «мин бит композитор, мин язарга тиеш, миннән соң нәрсә кала, кем бу көндәлек эшләремне бәяләр?» дигән сорауларга җавап эзли, тормышымның мәгънәсе турында уйлана башладым. Хәзер инде иҗат белән рәислек арасында ниндидер баланс булдыра алдым дип әйтергә була.

**— Композиторлар аз дидегез, музыка тарихына күз салсак, элек-электән шулай булган. Бүген дә Татарстанда иҗат итүче профессиональ композиторларны бармак белән генә санарлык. Шагыйрьләр белән чагыштырганда бу аеруча ачык күренә. Моның сәбәпләре нәрсәдә соң?**

—Нәҗип Җиһановның бу уңайдан кызыклы фикере бар иде: «Производствода көненә 500 тундыргыч ясалырга тиеш дигән план куела да, шуңа ирешелә. Ләкин иҗат эше ул башка, бигрәк тә композиторлар, рәссамнар иҗаты». Профессиональ композитор булып ирешү өчен кеше балачактан укырга тиеш: башта музыка мәктәбендә, аннан училищеда, соныннан консерваториядә. Бөтенесе бергә 16 елдан да ким түгел! Әлбәттә, биредә сүз симфония, ораторияләр язучы композиторлар турында бара. Бездә хәзер, үзен композитор дип, көненә 3-4 җыр (аны җыр дип әйтеп булса!) язучылар да бар. Минем беркемне дә үпкәләтәсем килми, үзешчән композиторларның да халык күңеленә үтеп керә алган бик матур җырлары бар. Җитди музыка белән шөгыльләнүчеләр исә, үз-үзен аямыйча, икмәксез торып, еллар буе укырга, иҗат итәргә мәҗбүр.

**— Һәм, әлбәттә, композитор дигән зур исемгә ирешер өчен, сез алдарак әйтеп киткән, Ходай тарафыннан бирелгән сәләт кирәк. Ләкин бүген, материаль кыйммәтләр хакимлек иткән заманда, талантлы яшьләр дә башка юлдан китәргә мәҗбүр. Хәтта музыка училищесы, консерватория тәмамлап, үз тормышларын музыка белән бәйләргә теләмәүчеләр дә очрый...**

— Әйе, бүгенге көндә бу профессияне бары тик фанатиклар сайлый. Шуңа да безнең һөнәргә аерым игътибар булырга тиеш. Без аз булсак та, күп музыка яза алабыз. Иҗатчы ач булганда гына яхшы әсәрләр тудыра ала дигән фикер белән тамырдан килешмим. Менә, мәсәлән, бүген иң күп башкарылучы композиторларның берсе — Верди. Үз вакытында ул бик бай кеше булган. Чарльз Айвз — миллионер, банкир. Вагнер, Моцартларның төрле чорлары булса да, тулаем алганда, алар яхшы яшәгән. Бүген Рәсәйдә сериалларга музыка язучылар гына зарланмыйдыр. Ләкин аларның эш режимы шулкадәр тыгыз: бер сериалны бетерәләр генә, икенчесен башлыйлар... Җитди иҗатка вакытлары калмый диярлек.

**— Вакыт — иҗатчы өчен мөһим нәрсә. Татарстанда мин аралашкан яшь композиторлар ач калмас өчен параллель рәвештә берничә дәүләт эшендә хезмәт куярга мәҗбүр. Аларның фәнни эш белән шөгыльләнүен дә, шәхси тормышлары барлыгын да искә алсак, иҗатка вакытлары бик аз калуын чамалап була. Бу вәзгыятьтә талантлы әсәрләр туа аламы соң?**

— Безнең өчен бүгенге көннең иң авыр мәсьәләләренең берсе бу. Мин үзем дә ничә еллар иртәнге дүрттә торып, ихтыяр көчемне туплап, сигезгә кадәр эшлим, аннан иртәнге аш ашыйм да, эшкә йөгерәм. Иҗат белән генә шөгыльләнер өчен язган әсәрләргә гонорарлар зур булырга тиеш. Әсәрләр өчен гонорарлар күп булса, композиторлар да төрле эшләрдә вакланып йөрмәс иде, төрле якка сибелү беркайчан да яхшы нәтиҗәләр бирми. Мәсәлән, бүген симфоник оркестрда эшләүчеләрнең эш хакын арттырдылар, алар хәзер берничә эштә чабып йөрми

— бөтен вакытларын оркестр эшенә багышлыйлар. Тәртип буенча, алар хәзер зур репетициягә әзерләнгән партияләр белән киләләр. Башта үзләре өйдә әзерләнә, аннан бер төр музыка кораллары җыелып, ансамбльләр белән эшлиләр, гомум репетициягә туксан биш процент әзерлек белән киләләр. Һәм моның нәтиҗәсе дә ачык күренә: симфоник оркестрның яңгыравы хәзер элекке белән чагыштырганда бер башка югарырак.

**— Симфоник оркестр белән Композиторлар берлегенең бүген бәйләнеше нинди? Тарихтан без, мәсәлән, Рахлин җитәкчелек иткән чорда оркестрның яңа сезоны һәр ел татар композиторларының яңа симфониясе белән ачылуын беләбез.**

— Үз вакытында Рахлин традицияләрен Фоат Мансуров дәвам итте. «Фоат Мансуров белән премьералар» дигән циклда нәкъ менә Татарстан композиторлары әсәрләре башкарыла иде, хәзер исә ел саен «Татарстан композиторларының яңа музыкасы» дип аталаган концертлар уза. Әлеге концертка әсәрләр безнең идарә тарафыннан сайлап алына. Бүгенге көндә идарәдә Ренат Еникеев, Леонид Любовский, Резеда Ахияровалар. Әгәр дә әсәр безнең тарафтан сыйфатлы дип бәяләнсә, без аны оркестрга тәкъдим итәбез. Йомшак якларын күрсәтеп, эшләп бетерергә кушкан чаклар да була.

**— Ләкин әлеге концерт бик сирәк, елга бер тапкыр гына уза, аның хакында күпләр ишетми дә кала. Бәлки, реклама җитмидер?..**

— Реклама җитми. Моның өчен һәр радио, һәр телекомпания бер максатта булырга тиеш. Максат исә Татарстан сәнгатен үстерү. Пропаганда булмаса, телевидениедә язмалар сакланмаса, газета-журналларда мәкаләләр язылмаса — безнең эш күләгәдә калачак. Менә узган ел ахырында «Татарстан композиторларының яңа музыкасы» концертында яшь композитор Эльмир Низамовның бик көчле яңача иҗат ителгән әсәре башкарылды. Без, композиторлардан кала, бу фактны кем дә булса белдеме?! Җәмәгатьчелеккә ул яңгырамады, чөнки әлеге яңалыкны дөньяга таратучылар юк.

Композиторлар берлеге Мәдәният министрлыгы ярдәмендә инде 4 ел «Татарстан энҗеләре» проекты белән чит илләргә йөри. Татарстан композиторларының әсәрләре кайда гына яңгырамады: Германиянең Берлин, Лейпциг, Италиянең Флоренция, Рим шәһәрләрендә, Швеция, Израиль, Испания! Һәм һәр концерт тарихи биналарда, ике мең ярым тамашачы сыйдырышлы залларда уздырылды! Сез уйлап карагыз, чит ил оркестры белән чит илдә татар музыкасын яңгыратыр өчен күпме көч, теләк, бәйләнешләр булдыру кирәк. Ләкин, ни кызганыч, әлеге зур вакыйга Татарстанда яктыртылмый диярлек. Телевидение фондында язмалар калса, тарих өчен нинди кыйммәтле ядкарь булыр иде ул!

**— Җитди музыканың бүгенге торышы нинди? Бик күпләр татар музыкасы Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшевлар күтәргән югарылыкка ирешә алмый, диләр. Бу фикер белән килешәсезме?**

— Бәхәсле фикер. Әлбәттә, ул вакытта алар бик актив язганнар, ләкин бүгенге көндә дөнья күләмендә яңгырый алырлык әсәрләр сирәк.

**— Ләкин күптән түгел Петербургның Мария театрында «Шүрәле» балетын карадым. Тамашачылар арасында балетка 10 нчы тапкыр килүчеләр дә бар иде. Мин гаҗәпләнеп, моның сәбәпләрен сорагач: «Музыкасы үзенчәлекле, бу балетны бик яратабыз», — дип, җавап кайтардылар. «Шүрәле» кебек әсәрләр иҗат ителәме бүген?**

— «Шүрәле» — безнең алтын мирас. Фәрит Яруллин музыкасын чит илләрдә дә яраталар. Мәсәлән, Барселонада Яруллинның әсәре репетициясендә оркестр вәкилләре смычоклары белән инструментларына кага башлады. Бу инде музыкантларның әсәрне яратып уйнавының югары билгесе, кайберләре килеп, рәхмәтләрен дә җиткерде. Нәҗип Җиһановның «Нәфисә»сен дә җылы кабул итәләр.

Үз заманында чордашлары бу әсәргә зур ставкалар ясамагандыр. Бүген иҗат ителүче әсәрләрнең киләчәктә кайсысы актуаль яңгыравы турында әйтү кыен, иҗатка вакыт кына үз бәясен бирә ала, вакыт — хөкемдар. Ләкин шуны әйтергә кирәк: 70-90 нчы еллар композиторлык өлкәсендә торгынлык еллары булды. Ул вакыттагы мәдәният министры Тарханов мине чакырып, «ни өчен композиторлар язмый, без гонорар түләргә әзер», дигән сорау катыш тәкъдим белән чыкты. Ләкин ул вакытта заманасы шундый иде: яшьләр килми, консерваториягә укырга керүчеләр дә сирәк, өлгергән иҗат кешеләренең дә кайберләре сату-алу эшенә китте. Ул чор белән чагыштырганда бүген ярыш башланды. Фестивальләр уза, яңа оркестрлар барлыкка килде. Бүгенге көндә яшьләрдән Светлана Зарюкова, Юлия Бикбулатова, Гөлнара Тимербулатова, Зөлфия Рәүпова, Радик Сәлимов, Эльмира Галимова, Эльмир Низамов актив язалар, төрле жанрда иҗат итәләр. Шагыйрьләр белән чагыштырганда алар азрак, ләкин «штучный товар» булып саналган композиторлар өчен бу — зур бер буын.



*М.Мозаффаров (сулдан беренче), А.Леман, Г.Литинский, Н.Жиганов. 50нче еллар.*

**— Бүгенге композиторлар өчен мәйдан бармы?**

— Миләүшә Тәминдарова республиканың камера хоры житәкчесе итеп билгеләнгәч, Татарстан композиторларын пропагандалауда бик матур эш башланган иде. Ләкин, ни кызганыч, бүген хор күбрәк коммерция ягын карый — безнең иҗаттан читләште. Рөстәм Абязов житәкчелегендәге «La Primavera» оркестры, Кыллы квартет, Яңа музыка камера оркестры белән хезмәттәшлек итәбез, яхшы элемтәдәбез. Жыр һәм бию ансамбле Радик Сәлимов белән контакт булдырды, «Жиде энже» концерт программасы зур уңыш белән бара. Симфоник оркестр «Ак бүре» операсын сәхнәгә күтәрде. Менә әле Юлия Бикбулатова опера язып китергән, Мәдәният министрлыгында аңа ничек ярдәм итәргә дип уйлыйлар. Чөнки экспериментал концерт вариантында булса да, ул әсәр дөнья күрергә хаклы. Опера һәм балет кебек зур әсәрләр иҗат итәр өчен композиторга театр рухын тоярга, андагы закончалыклар белән күзгә-күз очрашырга кирәк. Ягъни, яшь композитор гениаль масштаблы әсәрләр язуга үз табыш-хаталары аша гына ирешә ала.

**— Хор, оркестрларның бүгенге көн композиторларына сирәк мөрәҗәгать итүе, бәлки, турыдан-туры сыйфатка барып тоташадыр...**

— Эш сыйфатта гына түгел, билгеле. Безнең музыка замандашлар өчен бераз ятрак булырга мөмкин, аны пропагандалау өчен аерым программалар булдыру кирәк. Күптән түгел мин Каталониянең Композиторлар берлеге рәисе белән очраштым, ул Испания Композиторлар берлеге рәисе дә. Испаниядә оркестрларга испан композиторларының әсәрләрен башкарсыннар өчен зур суммага грантлар бирелә икән.

**—Консерваториядә эшләп килүче опера студиясе яшь композиторлар өчен тәҗрибә мәйданы буларак яши. Ләкин һәрбер композитор бишенче курска кадәр масштаблы әсәр язарга өлгермәскә дә мөмкин. Шуңа да Казанда музыкаль театр булдыру турында хыялларны тормышка ашырырга вакыт житмәдеме икән? Композиторларга да иҗат офыклары, консерватория тәмамлап чыккан вокалистларга да эш урыны булыр иде.**

— Бу фикер күптәннән йөри. Чыннан да, Казанда оперетта театры да, музыкаль театр да юк. Һәрбер зур шәһәрдә андый театрларга мохтаҗлык бар. Ләкин яна театр буш урында гына туа алмый. Анын өчен бина, цехлар, оркестр, труппа кирәк.

**— Әлеге театр консерватория нигезендә туса, оркестр һәм труппа туплауның бер кыенлыгы да булмас иде. Опера театрына эләгә алмыйча, күпме талантлы егет-кызларыбыз читкә чыгып китәргә, яисә, теләге булмаса да, эстрада юнәлешен сайларга мәҗбүр. Сиксән процент Казан хореография училищесын тәмамлаучылардан торган балет труппасыннан аермалы буларак, опера труппасының үзебезнең җырчылардан читләшүе сәерсендерә... Күрше Башкортстанда исә бөтенләй башка күренеш. Алар үз җырчыларын тәрбияләргә тырышалар, бүгенге көндә репертуарларында милли композиторларның 7 операсы, 3 балеты, 1 музыкаль комедиясе бар.**

— Әлеге сорау белән зур проблеманы күтәрәсез. Ләкин бу сорау мина түгел, күбрәк опера театры житәкчеләренәдер. Яшермим, минем дә опера театрында үз җырчыларыбызны күбрәк күрәсем, Татарстан композиторларынын әсәрләрен күбрәк ишетәсем килә. Ләкин, кызганычка каршы, опера труппасы бүген йолдызлар белән генә эшли, һәм анда эләгү өчен Татарстан кыз-егетләренә еш кына иң элек башка театрда танылу зарур. Әле 20-25 ел элек кенә вәзгыять икенче иде, мәсәлән, «Ерактагы кәккүк авазы» рок-операсын мина Рәүфәл Сабирович үзе махсус заказ белән яздыртты, алай гына да түгел, язу процессында бик зур ярдәм күрсәтте. 1989 елны сәхнәгә күтәрелгән әлеге операда күпчелек татар җырчылары иде.

**— Берничә ел элек рус композиторы Владимир Мартынов «Конец времени композиторов» дигән китабы белән музыкаль даирәдә зур шау-шу куптарган иде. Әлеге китапның төп фикере — XXI гасырда композициянең җай гына сүнүгә таба баруы. Авторның бу концепциясе белән Сез килешәсезме? Музыка теле, чыннан да, сарыф итеп бетерелгәнме?**

— Минемчә, әлеге фикер Мартынов тарафыннан эшләнгән пиар адым. Мина калса, ул әлеге игъланы белән үз шәхесенә игътибар юнәлтергә теләде һәм максатына иреште дә. Мин, Рәсәй Композиторлар берлеге рәисенең беренче урынбасары буларак, гомум Рәсәй музыка торышы турында да сүз йөртә алам: музыка яши, яшәячәк тә. Татарстанда да бүген музыка теле күптөрле. Композиторларнын иҗаты бер-берсенә охшамаган.

**— Татарстан композиторы һәм татар композиторы төшенчәсе арасында нинди аерма бар? Бүгенге әсәрләрдә миллилек ни дәрәҗәдә чагыла?**

— Элек күп иҗатчылар авылдан чыккан. Хәтта мөгаллимнәр консерватория каршында эшләүче музыка мәктәбе өчен авыллардан балалар җыеп йөргәннәр. Филармония артистлары да бригадалар белән авыл-районнарга чыккач, сәләтле балаларны күреп, аларны Казанга килергә димләгәннәр. Хәзер андый нәрсә юк диярлек, шуна авылдан килүчеләр дә күп түгел. Телне, милли гореф-гадәтләрне белү турыдан-туры музыкада чагыла. Мәсәлән, Чаллы кызы Эльмира Галимова татарчаны яхшы белә, һәм барлык яшь композиторлар иҗаты арасында анын музыкасында миллилек аныграк ишетелә. Эльмир Низамов — универсаль композитор. Юлия Бикбулатова музыкасы исә башкача янгырый, чөнки ул татар мәдәниятеннән ерак.

**— Ләкин шул ук Эльмир Низамовның иң абстракт әсәрендә дә мәскәүлеләр миллилек ишетә икән... Димәк, Татарстанда иҗат иткән композитор телиме-юкмы үз почеркына милли төсмерләр ала?**

— Кызык күренеш бу. Кайберәүләр Софья Гобәйдуллина музыксында да татар «каны» табалар. Әлбәттә симфоник музыкада татар җырларында ярылып торган миллилек була алмый, чөнки бу төр музыкада пентатоника тулысынча сакланмый. Тагын бер кызыклы мисал: Мәсгудә Шәмсетдинованың бер әсәрен анализлаганда

Мәскәү тәнкыйтьчесенең «у Вас музыка рыхлая по форме, очень много длиннот, надо убрать, сокращать» дигән тәнкыйтенә, грузия һәм әрмән композиторлары: «Сез милли музыка фәлсәфәсен аңламыйсыз, бар көйләрне дә бер шаблонга куярга ярамый, озын ноталар киң далалар кайтавазы ул», — дип каршы чыкты. Яшь композиторлар белән сөйләшкәндә минем дә әйткәнем бар: «Сез беркайчан да үзегезнең кем икәнегезне онытмагыз, миллилектән качмагыз, бу безнең үзенчәлегебез!» Заманча технологияләр белән язылган милли колоритлы әсәр — аерым байлык ул. Ләкин нинди телдә, нинди генә жанрда иҗат итмәсеннәр, безнең композиторлар Татарстан өчен иҗат итә, аларның мирасы безнең республикада калачак.

**— Бүгенге музыка тәнкыйте ни хәлдә?**

Музыка тәнкыйтенең хәлен белер өчен белгечләрнең мәкаләләрен укырга кирәк, ләкин, ни кызганыч, хәзер матбугатта аларның мәкаләләрен бастырмыйлар диярлек. Бу материаллар урынына журналистлар үзләренең язмаларын өстенрәк күрә. Житди мәкаләләргә бүген ихтыяҗ юк дип уйлый алар, чөнки без халыкны очсызлы, сары язмалар, өч-дүрт ноталы җырлар белән җиңел-җилпе тормышка өйрәтеп бетердек. Радио-телевидениедәге җырларны гына тыңлап карагыз сез, нәкъ шулар нәтиҗәсендә җитди музыка аудиториясе ике процентка әйләнде дә инде. Тамашачыга даими рәвештә радио-телевидение аша классик музыканы тәкъдим итеп торсак, бәлки, ул да популярлашыр иде. Шостакович сүзләре белән әйтсәк, «музыка сөючеләр һәм белгечләр булып тумыйлар. Музыканы яратыр өчен аны тыңларга кирәк, соңрак аңлау да килә».

**— Телевидение-радио житәкчеләрен дә аңларга була. Алар өчен рейтинг мөһим. Мәсәлән, бер канал академик музыкага өстенлек бирә башласа, тамашачы башка каналдан шул ук җиңел-җилпе җырларны эзләп табачак. «Культура» каналының рейтингы түбән булуы шуңа бәйле түгелмени?!**

— Ләкин барыбер ниндидер баланс булырга тиеш. Бүгенге көндә тамашачыларның күпчелеге академик җырчылар, композиторларның барлыгын да белми. Ә телевидение-радио зур көчкә ия.

**— Килешәм. Ләкин бу вазгыятьтә профессиональ композиторлар үзләрен җыр жанрында да таныта алыр иде. Эстрададан зарлану урынына, аның дәрәҗәсен үстерүгә үз өлешегезне кертү дә булыр иде бу. Хәтта кайчандыр җыр жанрында актив эшләгән Резеда Ахиярова, Луиза Батыр-Болгари да бүген җырлар язмый диярлек.**

— Безнең һәрберебезнең гаиләсе бар. Композитор җыр яза, студиягә тавыш яздыру өчен түли. Җырчы шул яздырган җыр белән гастрольләргә чыгып китә дә, акча эшли, еш кына композиторның исеме дә телгә алынмый. Без бу иҗаттан берни дә алмыйбыз.

**— Авторлар хокукларын яклау җәмгыяте аша җыр авторларына гонорарлар килә түгелме соң?**

— Нәкъ әнә шул хокукларны яклау барлыкка килгәч, эстрада үзешчәннәр кулына калды да инде. Җырчылар күбесе үзләре җыр яза башлады. Кешегә түләгәнче, үзебез авторлык гонорарлары алабыз дип хәзер алар профессиональ композиторларга мөрәҗәгать тә итми. Җыр бүген музыкада иң йомшак өлкә, бу Татарстанда гына түгел, Рәсәй күләмендә дә шулай. Хәзер мин радио чорларын сагынып искә алам, һәрбер өйдән Мансур Мозаффаров, Нәҗип Җиһанов, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин романслары яңгырап тора иде, бүген FM радиоларда бу төр җырлар яңгырамый диярлек.

**— Сирәк кенә ретро җырлар рубрика кысаларында яңгырый алар. Күптән түгел Эльмир Низамовның Рүзил Гатин башкаруындагы романсларын радиога тәкъдим иткәч: «безнең формат түгел, ретро-җырлар рубрикасында бирсәк кенә», — диделәр. Кызык күренеш: заман җырлары — ретро сәхифәдә... Казанда «Орфей» радиосы**

**филиалы эшли башлавы — матур фал, татарча да шундый радио булса, бу уңайдан проблемалар кимер иде. Тыңлаучының да сайлау мөмкинлеге булыр иде.**

— Төрле илләрдә, төрле өлкәләрдә телне югалткан милләттәшләребез дә жырмоннар аша тамырларына кайта. Милли анны музыка аша да саклап калып була дип саныйм. Музыка теле — иң үтемле тел, ана тәржемәләр дә, аңлатмалар да кирәкми. Татар халкы электән жыр-моңга мөкиббән булган. Ләкин бүгенге жырларның бик сирәге безнең халыкка лаеклы. Безнең мәдәниятебезнең байлыгын күрсәтә торган радио эшләсә, алга китеш булыр иде. Монысы шулай ук хөкүмәт кулында. Гомумән, сәнгать өлкәсендә, һичшиксез, ниндидер система, контроль булырга тиеш.



*Япон һәм татар музыкасы фестивале. 1992 ел*

**— Система, контроль ниндидер дәрәжәдә кирәктер дә, ләкин әлеге сүзләрнең Рәсәй мәдәният министры Владимир Мединский тарафыннан соңгы арада еш яңгыравы шик-шөбһәләр уята. Ижат кешеләренең ирегенн чикләгән, аерым кысаларда тоткан чорны үттек түгелме соң без? Совет системасының иң уңышсыз тәжрибәсенә кире кайту нәрсәгә кирәк?**

— Ирекле илләрнең күбесендә ниндидер дәрәжәдә цензура бар. Иң демократик илләрнең телевидениесенә генә күз салсаң да, моның шулай икәнен аңлап була — анда төшерелгән фильмнар, тапшырулар кайчак бик консерватив тоела. Франциянең американизмга каршы рухи көрәш ачканын беләбез. Бездә дә дәүләт тарафыннан, һичшиксез, контроль булырга тиеш. Юкка гына бүгенге көндә күпләр элекке сәнгать советларын сагынып искә алмый бит! Ижат ирекен чикләү кебек күренсә дә, ул беренче чиратта ижаттагы чүп-чардан арыну ысулы. Ләкин һәрнәрсә акыл белән эшләнергә тиеш, ниндидер чикләрдән узу — ялгышлыкка китерергә мөмкин.

**— XX гасыр башында да, соңрак та сәнгать әһелләре бер-берсе белән тыгыз аралашкан, ижади элемтәдә яшәгән. Бигрәк тә бу дуслык шагыйрь, композитор, жырчылар арасында көчле булган. Әнә шул бәйләнеш нәтижәсендә күпме югары сәнгать әсәрләре туган, күпме бәһасез мирас калдырылган. Бүген исә һәркем үз дөньясында, үз кабыгында яши кебек...**

— Аралашу, чыннан да, сирәк. Заманасы шундый: һәркем каядыр чаба, ашыга. Берлекләр арасында ниндидер уртак проектлар да кирәктер. Бәлки, без язучылар белән бер бинада утырырга тиешбездер. Мин яшь чакта безнең бина реконструкциядә иде. Ижат итәргә урыным булмаганга, Мирсәет Яруллин Туфан Миннуллин белән сөйләшеп, Язучылар берлегендә миңа бер бүлмә бирделәр. Шунда яшәдем диярлек, бик күп музыка яздым, язучы-шагыйрьләр белән аралаштым, бүген яңгыраган жырларның күбесе әнә шул аралашу нәтижәсендә туды да инде.

**— Өлкән буын азмы-күпме бер-берсен белә әле. «Идел» лагеренда ял итүләр дә моңа этәргеч булган. Яшьләр исә сирәк аралаша. «Калеб» яңа буын жыены нәкъ менә яшь ижатчыларны бер-берсе белән таныштыру, аралаштыру, әлеге аралашу нәтижәсендә уртак ижатка этәрү максаттыннан барлыкка килде дә.**

— Бу бик яхшы адым. Могучая кучкада бер лидер булырга тиеш. Әгәр дә андый кеше була икән, нәтиҗәләр дә озак көттермәс. Яшьләрдән инициатива булу кирәк. Кемнәндер нәрсәдер көтеп яту белән генә эшләр бармый. Рәсәйдә Композиторлар берлегенең «Молот» яшь композиторлар агымы бар, Татарстан композиторларының күбесе анда булуы шулай ук яхшы күренеш. Алар аралашалар, тәҗрибә уртаклашалар. Кеше яналыкка ачык булырга тиеш. Сәнгать кешесе өчен ялгызлык ничек кенә мөһим булмасын, әгәр ул куышта ябылып ята икән, аның иҗаты да ярлы була.



Композиторлар берлегендә — Казакъстан композиторлары. 2012 нче ел.

**— 2014 ел Рәсәйдә дә, Татарстанда да мәдәният елы дип игълан ителде. ТЮРКСОЙ карары нигезендә Казан быел шулай ук төрки дөньяның мәдәни башкаласы да. Композиторлар берлегенең юбилей елы икәнен дә искә алсак, Сезнең өчен җаваплы да, өмет-ышанычларга да бай ел булып чыга...**

— Рәсәй дә, Татарстанда да яна елны мәдәният елы дип игълан итү очраклы түгел: безнең өлкәгә игътибар кирәклеге көн кадагында. Һәм менә бәйле һәрбер иҗат оешмасы, һәрбер иҗат кешесенең өметләре зурдандыр. Төрки дөньяның башкаласы буларак көз көне Казанда быел тәүге тапкыр төрки халыклар музыка фестивале уздырыла. Төркия, Казахстан, Кыргызстан, Әзербайҗан, Башкортстан һәм башка төбәк музыкантлары белән берничә көн төрле жанрдагы концертлар үтәчәк. Берлекнең 75 еллыгы уңаеннан күп концерт-очрашулар, юбилей кичәсе планлаштырылган. Бинабызга күптән көтелгән реконструкция эшләнер дип өметләнәбез, бу уңайдан сөйләшүләр алып барыла. Әлеге тарихи бинаны саклап каласыбыз килсә дә, яна бинага да өмет юк түгел. Чөнки Композиторлар берлегенең үзенең зур концерт залы булырга тиеш. Беренче тапкыр әсәрләребезне нәкъ шул залда яңгырату мөмкинлеге дә ачылачак.

**— ...Күз алдына Композиторлар берлеге урнашкан, татар сәнгатькәрләренең архивы тупланган, зур заллы, мәһабәт биналы Музыка үзәге килеп басты. Казанда андый үзәк, һичшиксез, булырга тиеш. Бәлки, ул иганәчеләр ярдәмендә төзелер?! Ни өчен безгә аларны җәлеп итмәскә? Һәрдаим чит илләргә охшарга тырышабыз бит, бу очракта да алар үрнәген кабатлыйк. Европада шактый еллар сәнгатьтәге күп проектлар иганәчеләр булдырган фондлар аша тәэмин ителә. Ничек кенә булмасын, әлеге болгавыр заманда күңел нәтиҗәле үзгәрешләр көтә. Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт! Бәйрәмегез белән ихлас котлыйбыз.**

*Әңгәмәдәш* — **Гүзәл СӘГЫЙТОВА.**

# САБА ТУФРАГЫ БИРГӘН ТАЛАНТЛАР

Безнен Саба ягы талантларга бик бай. Шанлы профессорлар, фән докторлары, язучылар, рәссамнар, артистлар һәм башка бик күп сәнгать осталары биргән безнен уңдырышлы туфрагыбыз. Аларның һәммәсен санап чыгу да мөмкин түгел. Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган җиде лауреатыбыз бар. Болар – китап галиме, академик Әбрар Кәримуллин, мәшһүр актер Шәүкәт Биктимеров, үзенчәлекле рәссам Тавил Хажиәхмәтов, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов, күренекле композиторлар Рөстәм Яхин, Хөснулла Вәлиуллин, Фасил Әхмәтов (ул, Кукмара районында туса да, балалык һәм яшьлек чорының күп өлеше урман хуҗалыгы бистәсендә узган, әтиләре Әхмәтгали исә 22 ел Саба урман хуҗалыгында баш бухгалтер булып эшләгән) – районыбыз горурлыгы буларак, тарих сәхифәсенә алтын хәрефләр белән язылдылар.



*Хөснул Вәлиуллин.*

Бүген сүзне Байлар Сабасы авылында туып-үскән, үзләренең иҗатлары белән татар музыкасы тарихында тирән эз калдырган Хөснулла (мулла кушкан исеме шулай, аны «Хөснул» дип кыскартып та йөртәләр) һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар турында алып барырбыз. Быел, төгәлрәге, 28 февральдә, Хөснуллага –100, аның энесе – бертуган абыйсы Гарифулланың улы Аллаһиярга июль аенда 90 яшь тула. Минем алар турында каләм тибрәтергә хакым бар кебек. Ни өчен дисәгез, зыялы, динле, һөнәрле һәм музыкаль Вәлиуллиннар гаиләсе белән байтак еллар аралашырга насыйп булды. 1967 елда, Шәмәрдән промкомбинаты клубында мөдир булып эшли башлагач, шимбә-якшәмбе саен диярлек концерт белән күрше-тирә авылларга йөри башладык. Талантлы үзешчәннәребез арасында баянчы, җырчы, оста итеп скетчлар уйнаучы, шаян биюләр башкаручы һәм рәссам Миндель исемле егет тә бар иде. Күренекле композитор Хөснул Вәлиуллинның иң олы абыйсы, 1901 елгы Гарифулланың малае икәнен белгәч, аңа хөрмәтем тагын да артты. Аларның гаиләсе Габдулла Тукай исемен йөрткән урамда, милли орнаментлар кулланып үзләре җиткергән тыйнак кына йортта гомер итә. Гарифулла абзый белән озаклап әңгәмәләр дә коргалап утырдык. Ул, тумышы белән мәдрәсәле Сатыш авылыннан булган әтисе Вәлиулла, әнисе Асия, бертуган энеләре Зиннәтулла (1905 елгы), Хәбибрахман (1907), Хөснулла (1914) һәм берләнбер сеңелләре Сәгъдия турында еш сөйли иде. Әтиләре кечкенәдән тегүче һөнәрен үзләштереп, үзебезнең төбәктә генә түгел, Пермь якларында да өязгә чыгып, акча эшләп кайткан. Бик оста музыкант та була ул. Әниләре Асия ханым да тегү эшен яхшы белгән, моңлы итеп гармунда уйнаган. (Безнең Хөснуллабыз ике гармунчыдан туган булып чыга бит!). Вәлиуллиннар Байлар Сабасының ул вакытта урманга терәлеп торган урам очыннан урын алып, йорт-җир җиткерәләр һәм шунда бәрәкәтле гомер кичерәләр. Менә шушы иманлы һәм һөнәрле нигездә дөньяга килә дә инде татар халкының булачак композиторлары. Дөрес, Вәлиулла һәм Асия салган өй бүгенгә кадәр сакланмаган, яңарагы төзелгән. Анысы да композиторлар гаиләләре белән кайтып йөри торган йорт

буларак кадерле безгә. Төп нигездә Вәлиуллиннарның бертуган сеңелләре Гөлзар ханым гаиләсе белән яши.

...Узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында, гомумән, совет чорында ил-республика күләмендә үзешчән сәнгать смотрлары еш уздырылганын күпләр хәтерлидер. Хөснулла һәм Аллаһияр абыйлар шушы бәйгеләрнең йомгаклау концертларына, халык талантларын Казан сәхнәсенә сайлап алу өчен, махсус кайталар иде. Без дә, Шәмәрдәннән аларның Миндель энеләре белән төшеп, күренекле композиторлар белән очраша-аралаша идек. Гомумән, шул еллардан башлап хәзергечә диярлек, Вәлиуллиннар гаиләләре белән тыгыз элемтәдә торылды. Шәмәрдән бистәсендәге Миндель дустыбыз йөгереп йөргән җиреннән 73нче яшендә күптән түгел вафат булды. Бөереннән яман шеш таптылар. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр җинел атлетика – йөгерү белән шөгыльләнде ул. Илебез башкаласы Мәскәүдә, аннары Адлер шәһәрендәге бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар һәм медальләр яулады. 70 яшькә кадәр укучыларга белем биргән педагогның абруе зур булды. Соңгы юлга озатырга да халык күп җыелган иде.

Вәлиуллиннарның Сабадагы төп нигез сакчылары Гөлзар Галиева белән дә мин 1981–2008 елларда, район газетасына мөхәррирлек иткән чорда, даими элемтәдә булдым. Композитор абыйлары турында байтак истәлекләр туплап, «Саба таңнары»нда бастырды ул. Күз генә тимәсен, ярты гасыр педагоглык стажы бар аның. Башта Саба урта мәктәбендә укытты, 1982 елдан – утыз елдан артык Саба аграр көллияте студентларына белем бирә Гөлзар ханым. Аның бер яхшылыгын мәңге онытасым юк. Ул узган гасыр ахырында, 1915 елда нәшер ителгән белешмә – китап биргән иде. Андагы «Мечети и магометанское духовенство Казанской губернии» дигән бүлектәге мәгълүматларның безнең төбәккә кагылышлыларын якташыбыз, танылган язучы Мәгъсум абый Хуҗин белән иҗат иткән «Яшә, Саба –Йорт!» дигән китабыбызга урнаштырдык.

Хөснулла Вәлиуллинның Хәбибрахман исемле абыйсының Гөлчәчәк исемле кызы да бөтен гомерен мәктәпкәчә яшьтәге балаларга музыка белеме бирүгә багышлады, сабыйлар һәм нәниләр өчен көйләр иҗат итү белән дә шөгыльләнде ул, башка педагоглар файдаланырлык ярдәмлек тә төзеде. Гөлчәчәк ханымның иҗаты белән дә газета укучыларыбызны даими таныштырып тордык.

Ә хәзер Россия Федерациясенең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, мөхтәрәм Хөснулла Вәлиуллинның тормыш һәм иҗат юлына кинрәк тукталыйк, бераз хатирәләрне дә янартыйк.

1983 елның сихри алтын көзге көннәренең берсендә Хөснулла ага белән шул чорның әйдәп баручы композиторы Фасил Әхмәтов бергәләп урман хуҗалыгы бистәсендә озачак очрашуларга кайттылар. Юл уңаеннан алар башта Хөснулла агаларның Сабадагы төп нигезләренә сугылганнар. Бу хакта Гөлзар ханым болайрак итеп искә ала:

«...1983 елның октябрь ае. Безнең бәйрәм – Укытучылар көне иде. Минем өй каршына микроавтобус килеп туктады. Хөснулла абый! Лесхозга иҗат концерты белән килгәннәр икән. Ашыга. Хәл белеп чыгарга гына кердем, ди. Табынга чак дәшеп ала алдык. Алар белән композитор Фасил Әхмәтов, баянчы Ганс Сәйфуллин, җырчылар Люция Хәсәнова һәм Мингол Галиев та бар иде. Табында Мингол Хөснулла абыйның әлерәк кенә язылган, «Тик туган җирдә генә» дигән җырын башкарды. Бу очрашу үзе бер күңелле хатирә булып йөрәк түрендә калды».

–Якташ композиторларыбыз Хөснулла Вәлиуллин белән Фасил Әхмәтов кайткан ди.

–Үзләре белән җырчылары да бар икән.

–Бүген клубта очрашу була дип әйттеләр...

Ул көнне бистәдә әнә шундыйрак сөйләшүләргә колак салмый мөмкин түгел иде.

Очрашу башта мәктәптә булды. Бу хакта укучы балалар әти-әниләренә кайтып сөйләгәч, күпләр кич җиткәнен зарыгып көткәндер, билгеле. Ни әйтсән дә авылдашлары, кечкенә уеннарда биеткән, җырлаткан гармунчылары Фасилнең 12 ел

инде кайтканы булмаган бит... Көндезге очрашудан соң ике классик композитор урман һавасы суларга, табигать кочагына чыгарга да өлгерделәр. Сөйләшкән темалары – музыка дөньясы. Икесе дә килешле итеп киенгән, башларында – береткалар. Фасил абый җәйге пәлтәдән, Хөснулла ага яратып кия торган яшел курткасыннан, ак күлмәкләренә килешле галстуклар такканнар.

Һәм менә, ниһаять, күптән көткән сәгать житте. Мәдәният йорты сәхнәсендә Хөснулла Вәлиуллин, Фасил Әхмәтов, Мингол Галиев, Люция Хәсәнова һәм Ганс Сәйфуллин күренүгә зал алкышларга күмелде. Лесхозлылар өчен Фасилләре аеруча якын иде шул. Чөнки аның фаҗигале балачагын күпләр яхшы белә. Шомлы 37 нче елларда Фасилнең әтисе Әхмәтгалине дә «халык дошманы» дип кулга алалар. Әнисен колхоз эшенә куалар. Кечкенә Фасил салкын өйдә кала торган була. Ишек тупсасына утырып елый-елый әнисен көткәндә, юеш ыштаны белән бозга ябышып та калгалаган. Менә шул вакытта «полиомиелит» дигән коточкыч чир эләктерә ул. Аяклары йөрми башлый. Дөрес, Әхмәтгали аганы аклыйлар. Бераздан аларның гаиләсе урман эчендәге Лесхоз авылына 1946 елда килеп урнаша. Фасил биредәге үзләре яшәгән нигездән Казан музыка училищесына укырга китә. Тагын алга узып шуны әйтергә кирәк, 2013 елның җәендә әлеге йортка мемориаль такта куелды: «1952 елда бу нигездән күренекле композитор, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең М.Глинка, Татарстанның Г.Тукай исемендәге премияләре лауреаты Фасил Әхмәтгали улы Әхмәтов (1935–98) олы иҗатка юл ала. Бу йортта аларның гаиләләре 1946–1968 елларда яши».



*Фасил Әхмәтов (сулда) һәм Хөснулла Вәлиуллин Саба урман хуҗалыгында. 1983 ел.*

Ә теге көнне Мәдәният йортында җыр озак дәвам итте. Аларны алмаш-тилмәш Мингол Галиев белән Люция Хәсәнова башкарды. Минголның саф тавыш белән моңлы итеп җырлавы күңелдә ирексездән хис-кичерешләр дулкынын кузгатты. Аның үзенчәлекле, үзенә хас тавышы җыр һәм музыка сөючеләргә тирән канәгатьләнү бирде. Люция Хәсәнова башкарган һәр җырдан тормышка, кешеләргә мәхәббәт бөркелеп торды. Алар башкаруында «Аккошлар» (Р.Фәйзуллин сүзләре, Ф.Әхмәтов музыкасы), «Мин гармун булыр идем» (Ф.Шәфигуллин, Ф.Әхмәтов), «Кошлар тынды» (Ф.Хөсни, Х.Вәлиуллин), «Яраннар чәчәк аткан» (С.Шакир, Ф.Әхмәтов), «Акчарлаклар» (Р.Әхмәтҗанов, Х.Вәлиуллин), «Ядкәр» (Р.Вәлиев, Ф.Әхмәтов ), «Тик туган җирдә генә» (Х. Халиков, Х.Вәлиуллин), «Арышларым» (Г.Латыйп, Ф.Әхмәтов) һәм композиторларыбызның башка бик күп җырлары очрашуда катнашучыларны әсир итте.

Көн артыннан көн уза торды. Теге очрашудан соң нәкъ ун ел үткәч, 1993 елның көзендә сөекле композиторыбыз Хөснулла ага Вәлиуллин вафат булды. 25 сентябрь көнне аны Татарстан Композиторлар берлеге урнашкан бинадан соңгы юлга озаттык. Яңа Бистәдәге мөселман зиратына (капканы кергәч тә), танылган сәнгать һәм әдәбият әһелләре янәшәсенә җирләнде Хөснулла ага. Аның белән бәхилләшкәннән соң без мәрхүмнең җәмәгате Әминә апа, уллары һәм башка якыннары белән тагын бер тапкыр кайгы уртаклашу өчен фатирларына сугылдык. Ул Тукай һәйкәле артындагы биш катлы йортта яшәгән икән. Менә фатирына үтәбез. Ишектән керүгә Хөснулла абыйның безгә киеп килгән яшел курткасы күзгә ташланды һәм гомеренең азагына кадәр яратып кигән икән дигән уй башка килде... Әнә пианиносы. Сугышчан орденнары һәм медальләре, Тукай премиясе

билгесе... Шулай итеп, 80 яше тулырга нибары биш ай калгач, яшәү һәм музыка дөньясы белән үкенечле итеп хушлашып китеп барды олуг композитор. Үзе китсә дә сүнмәс иҗаты, җырлары калды. Аларның үлемсез икәне Хөснулла Вәлиуллинның 80 яшьлек юбилеен үткәргәндә ачык чагылды. Тәүге кичә Татарстан Композиторлар берлегенең концертлар залында башланып киткән иде. Аның югары дәрәҗәдәге ноктасы Вәлиуллиннарның туган җирендә – Байлар Сабасында булды. Тантанага Фасил Әхмәтов (ул юбилей үткәрү комиссиясе рәисе дә иде), Мирсәет Яруллин, Әнвәр Шәрәфиев, Ренат Еникеев кебек композиторлар, Татарстан мәдәният министры Марсель Таишев, аның урынбасары Илдус Тарханов (Ул Саба урта мәктәбен тәмамлаган), җәмәгате Әминә апа, улы Таһир, Вәлиуллиннарның Сабада, Киллебәктә, Шәмәрдәндә, Сатышта яшәүче барлык туганнары җыйналган иде.

Юбилей тантанасы Вәлиуллиннар яшәгән нигездәге йорт капкасына мемориаль такта кую белән башланып китте. Бу хакта ТР Министрлар Кабинеты 1993 елда ук махсус карар кабул иткән иде. Менә истәлек тактасы өстенә беркетелгән җәймә төшерелә. «Бу нигездә 1914–1934 елларда күренекле татар композиторы Хөснулла Вәлиуллин туган һәм яшәгән» дигән текстны һәркем кат-кат укый.

Аннан соң кунаклар, юбилярның туганнары һәм күренекле композиторларның иҗатын хөрмәт итүчеләр Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар исемен йөртүче Саба районы балалар сәнгать мәктәбенә юл тоттылар. Бу урында кыска гына чигенеш тә ясап алырга кирәк булыр. 1993 елның 9 сентябрендә район Мәдәният йорты (хәзер СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров исемен йөртә) каршындагы мәйданда Советлар йортының өч катлы яңа бинасы файдалануга тапшырылды. Ә инде хакимият бинасының элеккесендә Балалар иҗат үзәге ачылып, бер канаты сәнгать мәктәбенә бирелгән иде. Шул ук тантанада хакимият башлыгы Фәрит Гыйльмиев сәнгать мәктәбенә мөхтәрәм Вәлиуллиннар исеме бирелү турындагы Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән дә таныштырганы хәтердә уелып калган. (Гомумән, Фәрит Гыйльметдин улы элекке хуҗаларыннан бушаган биналарны чын мәгънәсендә халык куллана торган итү ягында торды. Аның шундый унай адымын раслау өчен тагын бер мисал китерү кирәктер. Коммунистлар партиясе яшәүдән туктагач, ике катлы КПСС райкомы аппараты бинасы бушап калды. Хакимият башлыгы карары белән бирегә элекке мәчеттәге китапханә күчерелде, район музеена да дүрт бүлмә бүленде. Ә 1841 елда ук төзелгән борынгы мәчет бинасы дин тотучылар карамагына кире кайтарылып, манара утыртылды, реставрация ясалды).

Шулай итеп, Хөснулла Вәлиуллинның 80 еллык юбилеена багышланган тантаналар мемориаль такта ачу белән башланып, район мәдәният йортында йомгаклау концерты белән тәгәлләнде, якташыбызның иҗат мирасын барлауга, исемен мәңгеләштерүгә житди адым ясалды.

...Менә тагын ун ел үтеп китте. Якташыбызның 90 яшьлек юбилее да якынлашты. Анысы инде Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында республика күләмендә зурлап билгеләп үтелде. Безнең, сабалыларның, урыннары ул көнне дә зәвыклы залның түрендә иде...

...Әле менә шушы язманы әзерләгәндә, Саба радиосына да колак салып алам. Әледән-әле Вәлиуллиннар урамында яшәүчеләргә кагылышлы белдерүләр бирелә. Шушы кыска гына игъланнар да мәшһүр композиторларыбызны искә алырга этәрә. Максатым — аларның искиткеч әсәрләрен тирәнтен анализлау түгел, анысын махсус белемле белгечләргә калдырыйк, ә менә Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннарның тормыш һәм иҗат юлларын кыскача гына тасвирлап узсак, зыян итмәс.

Әйткәнебезчә, балалар алтын куллы, эш рәтен белә торган, хәлле гаиләдә тәрбияләнгәннәр, кечкенәдән әтиләре һәм әниләре үрнәгендә тегү, тимер, агач эшенә һәм гармунда уйнарга өйрәнгәннәр.

«Хөснулла абый алтын куллы, эшкә маһир кеше иде,– дип искә ала сеңлесе Гөлзар. –Агач эшенә дә кулы барды. Безнең өйдә бер кадак та кагылмыйча ясалган урындык бар иде. Әнинең әйтүенә караганда, абый аны 15 яшендә ясаган. Рәсем сәнгате белән дә шөгыльләнгән булырга тиеш. Аллаһияр абыйның үзебезнең Бөрә елгасы буенда балык тотып утыруы сурәтләнгән майлы буяу белән ясалган картина

безнең өйдә эленеп тора иде. Ул фотога төшерү белән дә мавыкты. Фотосурәтләрне ярата иде. Аларның зал ягындагы стенада абыйның Нияз Даутов, Усман Әлмиев (болар Самат ариясен башкаручылар) белән төшкән рәсеме эленеп тора иде. Казанга баргач, бер керүемдә шул фотога карап: «Абый, шундый әйбәт исталек бу», – дидем. «Әйе,–диде абый,–кызганыч, хәзер Нияз юк инде...».

Утызынчы еллардагы тирә-як мохит тә яшь буынның талантын ачарга һәм үстерергә ярдәм иткән. Шул чорда Сабада музыкаль түгәрәкләр оеша, рабфак ачыла, театр труппасы эшли башлый. Хөснулланың күңеле шуларга тартыла, рабфакка укырга керә. Ә оркестр түгәрәгенә бертуган Хәбибрахман абыйсы һәм туганнан туган Аллаһияр энесе белән бергәләп йөри. Кларнетта һәм скрипкада уйнарга өйрәнә, спектакльләрдә катнаша. Сеңелләре Гөлзарның сөйләвенә караганда, Вәлиулла карт улларының клуб тирәсендә йөрүен бик өнәп тә бетермәгән. Хуҗалыкта эшләүләрен теләгән. Әмма яшьләр үзенекен иткәннәр.

Сәхнәдә ул елларда ук М.Фәйзинең «Галиябану», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Ил» драмалары уйналуы Саба театр труппасының көчле булуы турында сөйли. Сабалылар уйнаган спектакльне карарга бервакыт Вәлиулла бабай да барган. Соңыннан Хөснулла: «Ярый әле әти мине танымады»,– дип шатланып йөргән.



*Хөснулла Вәлиуллин үзенең яңа әсәре белән иҗатташ дусларын таныштыра. Уңнан беренче – энесе Аллаһияр Вәлиуллин.*

Озакламый Хөснулла абыйның тормыш юлләре Казан белән бәйләнеп китә. Аркасына биштәрен асып, Арчага җәяүләп юлга кузгала торган булган ул. Аллаһияр ул хакта болай дип сөйләгән. «Иртән, әле таң беленер-беленмәстән, әби белән икебез Хөснулла абыйны Тимершык планына кадәр озата бардык. «Сагынасынмы, дип сорыйлар, сагынмаган кая ул», – дип кычкырып җырлап китте. Без карап калдык. Әби елады да елады...»

«Онытырга мөмкин түгел», «Яз», «Яз айлары» дигән һәм комсомол яшьләргә багышланган җырларын Хөснулла абый сугышка кадәр үк яза. Шушы әсәрләр үк инде булачак зур композиторлык сәләтен ачык күрсәтеп торалар аның.

Сугышка кадәр Хөснулла Сабада яшәүче Әхтәм Мостафин исемле укытучының медицина институтында белем алучы кызы Мөнҗиягә өйләнә. 1942 елда аларның уллары Рашат туа һәм шул ук елда Хөснулла фронтка китә. Аларның гаиләсе таркала, әсирлектәге иреннән берничә дә хәбәр булмагач, Мөнҗия ханым тормышка чыга. Озакламый Аллаһиярны да сугышка алалар. Гөлзарның әтисе дә коточкыч сугышның эченә беренче көннәреннән үк эләгә һәм хәбәрсез югала, өч кенә хаты килеп кала.

Аллаһияр сугыштан көчле контузия алып кайта. Башы, бөтен гәүдәсе калтырап тора торган була. Кулы белән тотып чәй дә эчә алмый. Казан госпиталендә дәваланып кайтканнан соң гына бераз рәтләнә Аллаһияр. Бу вакытта сугыш бетмәгән була әле, әмма ана инде кабат солдат киеме кияргә туры килми. Ә менә Хөснулладан хәбәр-хәтер күренми. Әнисе үпкәсе шешеп, 1945 елның гыйнварында, 68 яшендә, улының исәнме-юкмы икәнлеген дә белмичә, гүр иясе була. Үләр алдыннан: «Хөснуллам, Хөснуллам», – дип саташа. Хатыны дөнья куйганнан соң, Вәлиулла бабайның да сәламәтлеге какшый башлый, житмеш биш яшендә ул мәңгелеккә күчә.

1945 елның ноябрь ае була бу. Шуннан соң озак та үтми, Хөснулла берничә хәбәрсез Сабага кайтып төшә. Туган иленә кайткач та әсирлек тамгасы ана тыныч

кына яшәргә ирек бирми. Шулай булса да ул Казан дәүләт консерваториясенең композиторлар бүлегендә махсус музыкаль белем ала башлый. Бер елдан соң энесе Аллаһияр да консерватория студенты була. Җәйге каникул вакытларында алар Сабага кайтып, туганнарына печән әзерләшергә булышалар. Укулар тәмамлангач, улы Рашат та бабайларына кайта торган була. Хөснулла абый Мостафиннар гаиләсе белән (Мөнҗия ханымның әти-әниләре — Т.Н. ) аралашып яши. Аларның икенче кызлары Рәфигага Биектау районының Мәмдәл егете, драматург Хәй Вахит (тулы исеме Габделхәй) өйләнә. Менә шуннан соң бажайларның иҗади дуслыгы башлана, «Самат» һәм « Дим буе» операларын бергә язалар. Башта Хөснулла аганың Казанда үз фатиры булмый. Үзе бер җирдә яши, пианиносы икенче кешедә була. Шуңа күрә ул 1954 елның җәендә Сабадагы йортларының бакчасында, чәчәкләр арасында «Самат»ны оркестрлаштыра.

Ниһаять, 1955 елда Хөснуллага Казанның Спартак урамындагы дүрт бүлмәле фатирның бер бүлмәсен бирәләр. Шуннан соң ул Ленин исемендәге китапханәдә эшләүче бик чибәр, сабыр холыклы Әминә исемле кызга өйләнә. Ул — Акмулла шәһәре кызы, Ленинградтагы китапханәчеләр хәзерге торган мәдәният институтын тәмамлап, Казанга эшкә килгән була. Аларның ике уллары — Нияз һәм Таһир туа.

Кыскасы, хәләл көчләре белән, тормышның төмен белеп, тыйнак кына гомер итә Вәлиуллиннар. Бик тә тырыш, уңган Әминә ханым үзе өчен кадерле булган өч ир-атны — сөекле ирен һәм ике улын яратып тәрбияли. Хәзер мәрхүмә инде.

Хөснулла Вәлиуллин киң колач белән иҗат итеп кенә калмый, музыка сәнгатен пропагандалауга да байтак көч куя. Ул Татарстан китап нәшрияты мөхәррире, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музыка бүлеге мөдире булып эшли һәм утыздан артык спектакльгә көйләр яза. Хөснулла ага Татарстан Композиторлар берлеге эшчәнлегендә дә актив катнаша, идарә әгъзасы итеп сайлана, музыка фондының Татарстан бүлеген житәкли. Ул үзе төрле музыка жанрында уңышлы хезмәт итүче, киң иҗат диапазонына ия композитор буларак аеруча хөрмәт казана. Композитор йөздән артык җыр иҗат итә. «Самат» операсының премьерасы республикабызда зур музыкаль вакыйга буларак кабул ителә. Бу әсәр 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтелү дәрәҗәсенә ирешә. Шулай ук Ленинградта да зур уңыш белән бара. Аның «Дим буенда» операсы, камера-инструменталь әсәрләре, тынлы оркестр, драматик спектакльләр өчен көйләре заказ буенча эшләнми, йөрәгә кушканча языла.

Хөснулла ага Вәлиуллин безгә Саба җирендә бөреләнгән талант иясе буларак кадерле һәм якын иде. Ул гомере буе районлашлары белән тыгыз элемтәдә торды. Үзешчән сәнгать коллективларына якыннан ярдәм итте. Аның соңгы кайтуы 1990 елның сентябрендә — районыбызның 60 еллык тантанасына булды. Хәзер аның эстафетасын улы Нияз һәм оныгы Диләрә дәвам итә. Нияз — скрипкада, Диләрә саксофонда һәм кларнетта уйный.

Ә инде сугышчы-композитор, Сталинград фронтында инвалидка әйләнгән Аллаһияр Вәлиуллинга килгәндә, кыска гомерле була ул. 1972 елда, нибары 48 яшендә якты дөнья белән бәхилләшә. Озак яши алмаса да, аның катлаулы тормышы якты уйлар, матур хыяллар белән үрелә. Аллаһияр Вәлиуллинның иҗади гомере нибары 17 ел гына дәвам итә. Шул кыска вакыт эчендә ул музыка сәнгатенең төрле жанрларында кыйммәтле әсәрләр тудыра. Халык аның «Әтнә» , «Туган ил» җырларын яратып җырлый. Концертларда аның ялгыз скрипкада, торбада уйнала торган һәм ике скрипка, альт, виолончель өчен квартет әсәрләре еш башкарыла.

Аллаһияр Вәлиуллинның профессиональ яктан житлеккән булуын аның симфоник әсәрләре раслый. Бу жанрда ул байтак әсәрләр калдыра. Болар — «Бәйрәм увертюрасы», «Яшьлек», «Тынычлык сугышны җиңәр» дигән симфоник поэмалары, «Симфоник биюләр» һәм башка әсәрләр. Аллаһияр абыйның да бу әсәрләре 1957 елда Мәскәүдә узган татар сәнгате көннәрендәге концертларда зур уңыш казана. Эзләнүчән, иҗади композитор «Язгы җилләр» операсын иҗат итә.

«Ноталарны үтә дә оста яза белүче буларак, ул Салих Сәйдәшевнең кульязмаларын озак еллар дәвамында күчереп язды. Яшь талантларга да аның ярдәме бик зур булды»,— дип яза якташыбыз турында музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина.

—Бервакыт, мин институтта укыган елларда аларда торганда, композитор Рөстәм Яхин килеп керде,— дип искә ала Гөлзар ханым. — Мин анын әтисенен Олы Шынар авылыныкы икәнен белә идем. Шуна күрә якташыбызны аягүрә басып каршы алдым. «Сенлем, шушы ноталарны калдырыйм әле. Аллаһияр күчереп бирергә вәгъдә иткән иде», — дип бер кочак эш калдырып китте...

Аллаһияр консерваторияне тәмамлагач, Әгерже районынын данлыклы Иж-Буби авылыннан булган Рәкыя исемле кызга өйләнә һәм озакламый бер бүлмәле фатир алуга ирешә. Ул шунда яна әсәрләр иҗат итә. Аллаһияр Вәлиулла улы Сабага гаиләсе белән сонгы тапкыр 1969 елда кайта. Һәм үзе укыган мәктәптә чыгарылыш кичәсендә катнаша, тыйнак кына чыгыш ясый... Анын бердәнбер улы Рамил хәрби белгеч була. Космодромда хезмәт итеп, подполковник дәрәҗәсендә пенсиягә чыга.

Озын сүзнен кыскасы, исеме «Идегәй» дастанында «Урмандагы Саба» дип телгә алынган борынгы җирдә туып-үсеп, сугышнын ачысын-төчесен күргән фронтовик Вәлиуллиннар — төрле музыка жанрларында унышлы хезмәт иткән милли җанлы, кин иҗат диапазонына ия классик композиторлар, сәнгать осталары. Аларнын милли музыка сәнгатен үстерүгә керткән фидакарь эшләрен татар халкы, бигрәк тә сабалылар, мәнге онытмас, югалтмас. Чөнки чын иҗат беркайчан да югалмый ул.

**Талгат НӘҖМИЕВ.**

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнен юл», 1930-1932 елларда «Атака» һәм «Яналиф», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**Февраль**

**85 ел элек (1929)** «Безнең юл»да Һади Такташнын «Мокамай» һәм «Алсу» исемле шигырьләре;

**75 ел элек (1939)** «Совет әдәбияты»нда Һенрих Һейненын «Германия» («Кышкы әкият») исемле әсәреннән аерым бүлекләр (алманчадан Мәхмүд Максуд тәрҗемәсе);

**70 ел элек (1944)** «Совет әдәбияты»нда Кави Нәҗминен «Фәридә» исемле драматик поэмасы;

**65 ел элек (1949)** «Совет әдәбияты»нда Ибраһим Газинын «Онытылмас еллар» романы;

**60 ел элек (1954)** «Совет әдәбияты»нда Фатих Хөснинен «Авыл өстендә йолдызлар» исемле повесте;

**55 ел элек (1969)** «Совет әдәбияты»нда Хәсән Туфан һәм Гамил Афзал шигырьләре;

**50 ел элек (1964)** «Совет әдәбияты»нда Фатих Хөснинен «Минем тәрәзәләрем» исемле повесте, Шәрәф Мөдәрриснен «Үлемсезлек» поэмасы;

**45 ел элек (1969)** «Казан утлары»нда Атилла Расихнын «Каһарманнар юлы» романы, Сибгат Хәкимнен «Дуга» поэмасы;

**40 ел элек (1974)** «Казан утлары»нда Гариф Ахуновнын «Ардуан батыр» исемле повесте;

**35 ел элек (1979)** «Казан утлары»нда Әхсән Баяновнын «Аязучан болытлы һава», Сажидә Сөләймановanын «Гөлбадран» исемле повестьлары;

**25 ел элек (1989)** «Казан утлары»нда Аяз Гыйләҗевнын «Яра» повесте дөнья күрде.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Норлат

Норлат авылы Зеленодол районында, район үзәге Зеленодол шәһәреннән 33 чакрым ераклыкта, Албаба тимер юл станциясеннән – 3, Козловка пристаненнан 32 чакрым ераклыкта урнашкан. Норлат – җирле үзидарә советы үзәге.

Норлат авылы 1565-67 елларны эченә алган Зөя өзенең теркәү кенәгәсендә Нурдулат дип телгә алынган. Д.Корсаков бастырып чыгарган белешмәдә авыл Курлат дип билгеләнгән. Рус телендәге белешмә-чыганакларда татар авылларының атамалары бозып язылу һәрдаим күзәтелә. Булат суы ярына утырган авылда 307 йомышлы һәм 35 керәшен татары яшәве билгеле.

Нәҗия апа Борһанова Норлат авылы халкы күршедәге Мулла Иле, Бузай, Городище авыллары белән бергәләшеп Тикен уены җыены үткәргән дип яза. Ул июнь ахырында бәйрәм ителгән (20 гасыр урталары).

Норлат атамасының килеп чыгышы турында төрле фикерләр бар.

Авылның бер өлеше олылары Норлат авылына нигезне борынгы заманнарда ук Нурбулат гаиләсе салган дип исәпли. Икенчеләре исә авыл атамасы Нурулла һәм Булат исемнәре белән бәйле дип саный.

Гомәр Саттаров, авыл элегрәк чорда Норлат һәм Булат атамалары алган ике авыл булып яшәгән, ди. Ул болай фикер йөртә: «Булатово авылы атамасының нигезендә Булат дигән төрки чыгышлы кеше исеме ята. Бу авылда борынгы чорларда чуашлар яшәгән. Булат авылының Казан ханлыгы дәверендә булуы тарихи чыганаклардан билгеле».

Норлат авылы халкы Степан Разин һәм Емельян Пугачев күтәрелешләрендә шактый актив катнашкан.

Гражданнар сугышы авыл хуҗалыгын шактый бөлдерә. Бәла өстенә бәла булып 1920 елның җәендә зур янгын чыга һәм 3 сәгать эчендә 163 хуҗалык көл була. 1921 елгы ачлыкта Норлат авылы халкы да интегә, төрле урыннарга күчеп китә, күбесе ачтан үлә.

1922 елда Норлат авылының хуҗалыгы аякка баса башлый. 1927 елда Норлат районы оеша. 1931 елда Норлатта «Кызыл партизан» колхозы төзелә. 1938 елларда колхоз шактый уңышларга ирешә. Ватан сугышыннан соң авылда «Норлат» совхозы оеша. Анда җиләк-җимеш үстерү белән ныклап шөгыльләнә башлыйлар.

1963 елда Норлат районы Зеленодол районына кушыла.

Бәчкит тавына менеп авылга таба карасаң, Норлат авылының бу тау итәгеннән башланып Гыйззәт тавы белән ике арада утыруын күрәсең. Бәчкит һәм Гыйззәт таулары атамаларын кеше исемнәре белән бәйләп сөйлиләр. Болар авыл тирәсендәге ин биек һәм зур таулардан исәпләнә.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның бичы санында.*

Аю алан чаты дип аталган урынның тарихы да үзенә күрә кызыклы гына. Бу урында элек кара урман булган. Урманда аюлар күп очраган. Урманны кисkәннәр һәм бу тирә сазлы урынга әйләнгән, аннары, сазлык кипкәч, әлеге жиргә яшел чирәм үсеп чыккан һәм ул үзәнлек булып киткән.

Авыл зиратын узу белән Бәйрәмәле чокыры бар. Бәйрәмәле исемле картның землянкасы нәкъ шушы урында булган. Карт үлгән, землянканы су баскан, урын чокырланып тора.

Норлат авылының тирә-юнен бер ягыннан Олы елга чикләсә, икенче ягында, Төрләмә юлыннан керә торган юнәлешендә, Питкә күле һәм Эрә елгасы бар. Ике урыннан буып алынган Олы елга бүгенге көндә бик олы булып күренми, әмма исеме Олы булып кала бирә. Питкә күлендә Петька исемле малай батып үлгән, дип сөйлиләр.

XIX гасырның икенче яртысында Норлат авылында 4 мәчет булган. Бу мәчетләр яманаты чыккан 30 нчы елларда тар-мар ителгәннәр.

Бүгенге көндә авылда бер генә мәчет — Хәмзә мәчете бар. Аны авылның иң бай кешесе Афзалов Хәмзә төзеткән.

## Норма һәм Нормабаш авыллары

Атамаларына Норма берәмлеге кергән авыллар Балтач районында урнашкан. Норма авылы район үзәге Балтач авылыннан 4 чакрымда, тимер юл станциясе Шәмәрдәннән — 26, Малмыж пристаненнан — 36, Нормабаш авылы район үзәгеннән — 15, жирле үзидарә советы үзәгеннән — 11, Шәмәрдәннән — 27, Малмыждан 47 чакрым ераклыкта утырган. Норма — жирле үзидарә советы үзәге. Аның карамагына Кариле, Кили, Норма, Нормабаш, Пүскән һәм Чапшар авыллары керә.

Норма һәм Нормабаш авыллары борынгы, алар икесе дә Казан ханлыгы авылларын барлаган исемлеккә кергән.

XVIII йөздә (Д.А.Корсаков) Норма суы ярына утырган Олы Норма авылында 139 ясаклы татар яшәгән. Нормабаш авылында 76 ясаклы татар көн иткән.

И.А.Износков хезмәтендә (XIX йөз) күрсәтелгәнчә, Норма суы ярындагы Олы Норма яисә Норма Себер элемтә юлының уң ягына урнашкан. Авылдагы 119 хуҗалыкта ислам дине тота торган 391 ир-ат һәм 379 хатын-кыз гомер итә, алар Олы Норма авыл җәмгыятенә кергәннәр. Халыкның тормыш-көнкүреше ярлы, иген игү, чабата ясау, урман кисү белән шөгыльләнгәннәр. Авылда бер мәчет һәм мәдрәсә булган.

Норма суы ярындагы Нормабаш авылы шулай ук Себер элемтә юлының уң ягына урнашкан. Авылдагы 26 хуҗалыкта ислам дине тота торган 103 ир-ат һәм 90 хатын-кыз гомер кичергән, алар Нормабаш авыл җәмгыятен төзегәннәр. Тормыш-көнкүрешләре ярлы, халык иген игү, умартачылык, чабата ясау белән шөгыльләнгән.

Норма һәм Нормабаш авыллары халкы июнь аеның өченче җомгасында күршедәге Пүскән, Кили, Чапшар, Кариле, Иске Салавыч, Яңа Салавыч, Сәрдегән һәм Бөрбаш авыллары белән бергәләшеп Пүскән җыены үткәргән (Н.Борһанова).

Олылар авыллары турында мондый мәгълүматлар хәбәр итә.

Авыл оешканга 700 еллар бар. Болгар дәүләте җимерелгәннән соң халыкның бер өлеше Шушма суы буена да килеп нигезләнә. Норма һәм Нормабашны болгар бабалар башлаган. Норманы Нормабаштан аерылып чыккан дип әйтәләр.

Норманың халык телендә кулланыла торган икенче исеме — Байлар Нормасы. Авылның иң зур бае Ишморатов Габдрахман булган. Ул авылда бәз эшли торган мануфактура ачкан. Авылның ярлы крестьяннары аңа ялланып эшләгән. Аның тегермәне һәм Үрнәктә ат заводы, урманнары булган. Казанда ике йорт салдырган. Мануфактура фабрикасы янгач ул Казанга күчеп киткән.

Революциядән соң Ишморатовның авылдагы йортын клуб һәм кызыл почмак иткәннәр. Яшьләр атнага бер тапкыр анда кичә оештырган, театр куйганнар.

Авылдагы гади крестьяннарның йортлары тәрәүле, өйдә исә сәкедән башка җиһаз булмый. Сәкегә ашъяулык җәеп ашыйлар, аны җыеп алгач урын җәеп йоклыйлар.

Сәке астында – иске-москы. Черемәсен дип идәнне юмыйлар, кырып себерәләр генә, аяк салып йөрү булмый. Өйләрнең барысы да жир идәнле, өй тулы таракан яшәгән.

1936 елларда мәчетнен манарасын кисәләр. 1937 еллар тирәсендә авылда кино күрсәтә башлыйлар.

Авылда чирмешләр дә торган. Олылар сөйләве буенча, авылның иске зираты Наратлык зират дип йөртелгән, аның бер ягына татарлар, икенче ягына чирмешләр күмелгән.

Норма олылары сөйләвенә караганда, элек Норма белән күршедәге Кариле авылы халкы бик үк тыныч яшәмәгән. Хәзер инде авыллар кушылып үк торалар һәм үзара бик дус яшиләр.

Авыл яныннан Шушма суы ага. Аңа Госман елгасы, Төшнәр суы, Карлыгач елгасы, Норма суы һ.б. елга-инешләр кушыла.

***

Норма олылары әйтүенчә, Нормабаш Норма авылыннан аерылып чыккан. Исеменнән үк күренгәнчә, ул Норма суының башланган җиренә урнашкан.

Авыл нигезләү өчен матур урын сайлаганнар. Янында елга, чишмә, инешләр, кое, буа, бәке, куак, агачлык, урманнар, күл һәм саз-баткаклыклар шактый.

***

Нормабаш авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 14 чакрым ераклыкта, жирле үзидарә советы үзәге Байлангардан – 2, якындагы Вятка аланы пристаненнан 24 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авылдан 2 чакрым югарырак Норма суы башлана. Авылга исем шушы елга атамасына бәйле рәвештә бирелгән.

Авыл атамасы шактый тарихи белешмәләрдә искә алына.

XVIII гасыр мәгълүматларын эченә алган тарихи белешмәдә (Д.А.Корсаков) күрсәтелгәнчә, авыл Норма суы башланган урынга утырган авыл дип бирелгән һәм анда 61 татар кешесе яшәгәнлеге күрсәтелгән. 1859 ел мәгълүматлары тупланган тарихи белешмәдән (А.Артемьев) күренгәнчә, Норма суы башланган урынга утырган авылның 83 хуҗалыгында 227 ир-ат һәм 261 хатын-кыз көн иткән, анда бер мәчет эшләгән.

Нормабаш авылының табигате матур. Авыл уртасыннан, аны икегә бүлеп, Норма суы ага. Ул хәзер кечерәйгән, суы да саеккан. Башланган чишмәсе авылдан ерак түгел, шуның өчен Нормабаш атамасы барлыкка килгән. Авылдан бер чакрым ераклыкта Аю күле дип аталган кечкенә генә күл бар. Элек бу тирәдә калын урман үскән, күл бик тирән һәм зур булган. Күл янында аюлар очраштырганга, аңа Аю күле дип исем биргәннәр. Өлкәннәр әле бу күлдә су коенган вакытларын хәтерлиләр. 1960 елларда нефть эзләгәндә бу тирәдәге жирләр күп итеп борауланган, шактый балчык күлгә дә төшкән һәм күл әкренләп юкка чыккан.

Авылдан көнбатышка таба барганда Кабык күпер дип аталган күпер, юлның уң ягында Бабай тавы дип йөртелгән тау бар. Тау итәгеннән бераз барсаң, Урыс базы дип исемләнгән тирән ерганак янына килеп чыгасың. Бик күп еллар элек монда төрмәдән качкан урыслар яшеренеп яткан дип сөйлиләр. Элек бу урыннарда да катнаш урман булган, хәзер инде бу урманнар юк. Янил авылы ягында Бөяр үре исеме алган калкурак жир бар. Моннан башка тагын Рәхилә каенлыгы, Балыклы үзәге атамалары исәпкә алынган.

Авыл уртасыннан күптәнге таш юл үтә. Элек ул Олы юл исәпләнгән, шуннан кешеләр Кукмарага һәм күрше авылларга йөргәннәр. Хәзер авылдан читтә күтәртелгән асфальт юл үтә, ә авылның көньяк юнәлешеннән тимер юл уза.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**САБИР** (чын исеме Мирза Алекпер оглы Таирзадә) (30.5.1862, хәзерге Әзәрбайҗан Шәмахе ш. – 1911, Баку ш.), әзәрбайҗан сатирик шагыйре. 1874 елдан мәгърифәтче, сатирик-шагыйрь С.А.Ширвани (Әзәрбайҗанның Көньяк-Көнчыгышы) тарафыннан ачылган яңа типтагы (җәдиди) мәдрәсәдә укый. Ике елдан соң атасы таләбе буенча укуны ташларга мәҗбүр була. Үзләренең кибетләрендә эшли. 1880 елларда хаҗ кылу сәбәбен уйлап табып, Кавказ буйларына, Гыйрак, Иран, Урта Азиягә сәяхәт кыла. Атасы вафатыннан соң Шәмахегә кайта. 1903-05 елларда әзәрб. газета-журналларында хезмәттәшлек итә. Гомеренең соңгы елларында Бакуда яши, укытучылык итә. Фәкыйрьлектә вафат була. Әзәрб. реалистик әдәбиятында сатира мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Иҗатының башлангыч этабында лирик шигырьләр, элегияләр яза. Укучылар, шул исәптән татар укучылары арасында популярлык казанган «Молла Насретдин» (Баку) сатирик журналында даими автор сыйфатында танылa. Сәнгати чараларның киң спекторын кулланып, С. социаль типлар галереясын (гади кешеләр, милләт мәнфәгатьләрен санламаган, наданлык, рухи торгынлык, саранлык, хыянәт ияләрен) тудыра. С.ның «Шикаять» сатирасына Г.Тукай «Мулланың зары» (1908) исемле шигъри назыйрә яза. Г.Тукай шагыйрьне дәвалау өчен акча җыюда катнаша. С.ның дини характердагы аерым шигырьләре 20 гасыр башы татар матбугатында басылып чыга. 1985 елда С. шигырьләре Ә.Исхак тарафыннан татарчага тәрҗемә ителә.

Әдәб.: Шариф А. Жизнь и поэтическое творчество Сабира (1862-1911). М., 1951; Заманов А. Сабир вә муасирләри. Бакы, 1973.

**САБИРҖАН АКЫН** (чын исеме Сабирҗан Мөхәммәд-Садыйк угылы) (19.7.1878, Казан губернасы Олы Мәңгәр а. – 1922 елдан соң), шагыйрь. Казакъ телендә яза, татар лексикасын файдалана. Яшүсмер елларында казакъ далаларына китеп, тире иләү, тегү һөнәре б-н шөгыльләнә, казакъ халкының телен, традицияләрен, фольклорын өйрәнә. Берничә мәртәбә туган ягына сәяхәт кыла (соңгысы 1922 елда). Акыннар ярышында катнаша, шагыйрь-импровизатор булып дан казана. 19 гасыр ахыры – 20 гасыр башы казакъ халкы тормышы, аның көнкүреше, йолалары, традицияләре чагылыш тапкан «Жумбак казакъ телендә» (1903), «Кызның үлеме» (1903), «Тирмә казакъныкы» (1903), «Казакъның туй бәетләре» (1912) китаплар авторы.

Әдәб.: Әхмәтҗанов М.И. Сабирҗан акын // Казан утлары. 1992. №2.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**САБИРОВ** Ирек Нәгыйм улы (14.4.1950, хәзерге Биектау р-ны Мәмдәл ав. туа), хакимият-хуҗалык җитәкчесе, шагыйрь, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2008). Татар һәм рус телләрендә иҗат итә. Казан химия-технология ин-тын тәмамлагач (1973), Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск шәһәрендә урнашкан «Сигнал-полимер» з-дына эшкә җибәрелә. Бирелә ул гади мастердан, цех начальнигы, баш инженер дәрәҗәсенә кадәр хезмәт юлы уза. 1999 дан шәһәр башлыгы урынбасары. Авторның «Аваз» (Чиләбе, 1999), «Манзара» (2004), «Ләззәт ташкыны» (2010), рус телендә «Люблю и верю» (Челябинск, 1997), «Сезон клубники и зарниц» (Еманжелинск, 1998), «Апрель» (Еманжелинск, 2002), «Предчувствую весну» (Еманжелинск, 2008) исемле китаплары дөнья күрде. 1989 дан Еманжелинск шәһәрендәге Татар һәм башкорт мәдәнияты үзәге идарәсе рәисе. РФның 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләнгән.

**САБИРОВ** Рөстәм Рәис улы (13.12.1951, Казан), язучы. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1973). Казан язу машиналар з-дында (1975-82), «Радиоприбор» з-дында (1982-84), Татарстан китап

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

нәшриятында (1984-92). ТР ЮСнын редакция-нәшрият бүлегендә баш белгеч (1992 дән сон) булып эшли. Рус телендә яза. «Фәрештә белән хушлашу» («Прощание с ангелом», 1991), «Серле вакыйгалар. Очучы Голландияле» («Странные истории. Летучий Голландец», 1998), «Лабиринтнын ахыры» («Конец лабиринта», 2001), «Качкын» («Беглец», 2007) хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары авторы. С. әсәрләрендә фантазия б-н гротеск көндәлек реалияләр белән үрелеп китә. Автор борынгы грек мифларына карата тарихи фантазияләргә, ирекле трактовкаларга мөрәҗәгать итә.

Әдәб.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**САБИРОВ** (Нәзыйров) Сафа Сабир улы (19.8.1915, Казан губ. Лаеш өязе Иске Йорт ав. — 29.3.2004, Казан), язучы, ТАССРнын атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Балалар йортында тәрбияләнә. ФЗӨ мәктәбендә укый. Казан елга техникумын (1938) тәмамлый. 1947-54 елларда Идел пароходчылыгынын Казан бүлекчәсендә диспетчер. 1954 тән «Социалистик Татарстан» г-тасында күчмә хәбәрче. 1957-75 тә Татарстан кит. нәшриятында: матур әдәбият редакциясе мөдире, 1971 дән өлкән мөхәррир. С.нын беренче хикәяләре 1945 тә «Совет әдәбияты» ж-лында басылып чыгалар. 1949 да нахимовчыларга багышланган «Яшь диңгезчеләр» исемле беренче повесте дөнья күрә. Ул «Дүрт елга буйлап» (1951; рус теленә тәрҗемәдә «»По четырем рекам», 1952), «Зур Идел тугандa» (1952), «Су өстендә акчарлак» (1966), «Идел җилләре» (1975), «Жил тулсын жилкәннәргә» (1981), «Идел йолдызлыгы» (1996) исемле елга транспорты кешеләре хезмәтен һәм тормышын яктырткан повестьлар һәм хикәяләр жыентыклары авторы. «Хатлар язам сагынып» (1982) һәм «Хәвефле сәфәр» (1995) тарихи повестьларынын төп геройлары — үзләренең романтик һөнәрләренә гашыйк яшь капитаннар. С.нын кайбер әсәрләре рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителгән. Бөек Ватан сугышында катнашкан, медальләр белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Алтын балдаклы абыстай. К., 2004.

Әд.: Әгъләм М. Үз заманы баласы // Казан утлары. 2000. № 8; Кәримов К. Иске Йорт аксакалы // Казан утлары. 2005. № 7.

*Г.М.Габделхакова*

**САБИТОВ** Габделхәй Вәли улы (28.6.1931, Минзәлә р-ны Югары Тәкермән ав. — 29.10.1995, Казан, Минзәлә шәһ. жирләнгән), язучы. 1949-56 елларда Минзәлә р-ны урта мәктәпләрендә укытучы. 1956-60 елларда А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тында (Мәскәү) укый. 1960-65 тә ТАССР МС нын радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире, «Ялкын» ж-лынын әдәбият бүлеге мөдире. 1965 тән «Чаян» ж-лында, 1968 дән анын жаваплы сәркәтибе. 1950 еллардан көндәлек матбугатта әсәрләре басылып килә. «Туган жир туфрагы» (1963), «Үлемсез Акылгали» (1964), «Тармаклы яшен» (1981), «Урман кызы» (1991), «Кайнар туфрак» (2001), «Ярсулы яз» (2002) исемле хикәя жыентыклары, «Кичерелмәс гөнаһ» (1959 да Минзәлә татар драма т-рында куела), «Гарасат» (икенче исеме «Чулпан таңны уята», 1973 тә шул ук театрда куела) пьесалары авторы. С.нын әсәрләренә катлаулы сюжет, үзенчәлекле характерлар хас, автор геройларнын күнел дөньясын нечкә психологик алымнар белән ачып бирергә сәләтле. С.нын әсәрләре, бигрәк тә хикәяләре, сәнгатьчә эшләнеше, идея-эстетик кыйммәте ягыннан югары сыйфатлы булулары белән аерылып тора. С. әдәби тәржемәре белән дә укучыларга таныш. Ул П.Л.Трэверснын «Мэрри Поппинс» (1972), Р.Э.Распенын «Приключения барона Мюнхгаузена» («Барон фон Мюнхгаузен мажаралары», 1974), Ф.Зальтеннын «Бемби» («Урман әкияте», 1980) повестьларын татарчага тәржемә итә.

Әд.: Хужин М. Өч күнел // Казан утлары. 1999. № 8; Шабаев М. Ихлас күнелле авылдашым // Казан утлары. 2002. № 6.

*Г.М.Габделхакова.*

**САБИТОВ** Рәшит Мәхмүт улы (27.3.1937, Башкортстан АССРнын Гафури р-ны Ялгыз Каен ав. туа), язучы, Башкортостан Респ-касынын атказ. мәдәният эшлеклесе (1997). Башкорт ун-тын тәмамлагач (1967), Кырмыскалы р-ны мәктәпләрендә укыта. 1968 дән Уфа шәһ. яши. «Кызыл тан» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли, 1975 тән «Пионер» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире, бер үк вакытта, 1975-88 елларда — Башкортостан кит. нәшриятынын балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты өлкән мөхәррире. 1991-93 тә «Кызыл тан» г-тасында күзәтүче, 1993-97 дә «Zaman-Bashkortostan» («Время-Башкортостан») г-тасы хәбәрчесе. 2004 тән Башкортостан Респ-касы Язучылар берлеге идарәсе рәисе. «Йәшлегем йөзе» (Уфа, 1980), «Һаумы, мәктәп!» (Уфа, 1983) жыентыкларына кергән беренче шигырьләре, нигездә, комсомолга, эшче

яшьләр темасына багышланган. «Ыласындар бейек оса» (Уфа, 1981), «Кыйгак-кыйгак каз кыскыра» (Уфа, 1985), «Һүнгән йолдыз яктыһы» (Уфа, 1988), «Батырлар кая туа?» (Уфа, 1996), «Ташламачы, мәхәббәтем» (Уфа, 2005), «Мәхәббәт өянәге» (Уфа, 2006) җыентыкларындагы хикәя һәм повестьларында яшь геройларнын яшәү рәвешләре, шөгыльләре мавыктыргыч вакыйгалар аша сурәтләнә.

**САВЕЛЬЕВА** Любовь Ивановна (20.10.1921, Тверь өлкәсе Завидово р-ны Фофаново а. — 15.8.2010, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1971), проф. (1973). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1944). 1947-2005 Казан ун-тында, классик филология (1957-68), рус һәм чит ил әдәбиятлары (1973-88) кафедралары мөдире. Фәнни эзләнүләре антик әдәбият, рус әдәбиятында антик традицияләре өлкәләренә карый. Хезмәтләре Марциал, Плавт, Теренций, Гораций, В.А.Жуковский, Н.И.Гнедич, А.Н.Майков иҗатларына багышланган.

Хезм.: Художественный метод П.Теренция Афра. К., 1960; Романтические тенденции в античной литературе. К., 1973; Античность в русской поэзии конца XVIII — начала XIX века. К., 1980.

Әдәб.: Казанский университет (1804-2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т.3.

**САДРЕТДИНОВ** Шәйхелислам Әләветдин улы (5.12.1936, Чүпрәле р-ны Татар Бизнәсе а. — 21.3.1996, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. канд-ты (1972). Казан ун-тын тәмамлый (1960), 1967-96 елларда ш.у. эшли. Фәнни эзләнүләре 19-20 йөз башы татар әдәбиятына карый. Хезмәтләре С.Рәмиев, Ә.Каргалый, М.Иванов иҗатларына карый. Урта мәктәп һәм югары уку йортлары өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм хрестоматияләр автордашы; С.Рәмиев әсәрләрен бастыруга әзерли (кереш сүз, текстологик әзерләү, комментарийлар).

Хезм.: Рәмиев иҗаты. К., 1973; Ә.Каргалый: студентлар өчен ярдәмлек. К., 1978 (автордаш).

Әдәб.: Казанский университет (1804-2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т.3.

**САДӘ ГОСМАН** (псевд., чын исем-фам. Зәйнетдинов Госман Мохтасар улы) (23.2.1949, Башкортстан АССРнын Аскын р-ны Әмир ав. — 12.01.2014, Казан), шагыйрь, ТРнын атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Башкорт ун-тын тәмамлагач (1972), Казанга күчеп килә. «Татарстан» ж-лында тәрҗемәче (1972-79), «Сабантуй» ж-лында башта җаваплы сәркәтип, сонрак баш мөхәррир урынбасары (1979-95) булып эшли. 1996 дан «Шәһри Казан» г-тасында әдәби хезмәткәр. Шигырьләре 1960 елларда «Башкортстан пионеры», «Кызыл тан» г-таларында, «Сәнәк» ж-лында, «Яшь көчләр» альманахында басыла башлый. «Мәхәббәт елы» (1985), «Җиләкле тәрәзәләр» (1987), «Тайфун күзе» (1990), «Ярату ява» (2009) җыентыклары авторы. Шигырьләре поэтик формаларнын төрлелеге, тел-сурәтләү чараларынын байлыгы, фикер-хисненен ихласлыгы, фәлсәфилеге белән аерылып тора.

**САДРИ** (Садретдинов) Г.-Халик (Габделхалик) Гариф улы (4.8.1890, Самара губернасы Богырыслан өязе Иске Ярмәк а. — 8.3.1955, Казан), язучы. Октябрь революциясе, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Уфа мәдрәсәсендә укый (1912-15). Татар коммунистлары ун-тын тәмамлый (1928). 1919 елда РКП(б)нын 2 нче Бөтенроссия съездына сайлана, делегация составында В.И.Ленин б-н очраша, 1919-22 елларда РКП(б) Самара губкомы татар секциясен җитәкли. 1928-30 елларда Казаннын «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында, 1930-38 елларда Бөтенсоюз уйлап табу һәм хезмәтне рационализацияләштерү буенча өлкә советы рәисе булып эшли. 1946-55 — СССР әдәби фондынын Татар бүлеге рәисе. Беренче публикацияләре матбугатта 1912 елда күренә башлый. Төрле жанрларда яза: шигырь, пьеса, очерк, хикәя. «Кечкенә һөнәрләр» (1915), «Ил батырлары» (1935), «Тимерче малае» (1936, русчага тәрҗемәдә 1953) повесть һәм хикәяләр җыентыклары, «Безнен тан» (1937) романы авторы. Икенче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почет Билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әдәб.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# КҮҢЕЛЕ ҺӘРКЕМГӘ АЧЫК ИДЕ

Хәзер инде абруйлы гәзитләребезнен берсе саналган «Мәдәни җомга»ның әле оешып кына килгән, беренче саннары гына чыга башлаган чагы иде. Редакция Казаныбызның нәкъ уртасындагы һәркемгә мәгълүм булган дүрт катлы соры бинада. Бу — Матбугат йорты. Менәм икенче катына. Озын коридорның сул ягындагы бүлмәләрдә эш кайный. Иң түрдә — баш мөхәррир Зиннур Мансуров бүлмәсе. Янәшәсендә аның урынбасары Газинур Морат утыра. Бер чакны аның белән гәп корган вакытыбызда ишек ачылды да бүлмәгә тәбәнәгрәк буй-сынлы, соры төстәге кәчтүм-чалбар кигән какча йөзле бер егет килеп керде. Бер кочак кәгазь тоткан. Уртак эш хакында сөйләшеп алгач, ул барча кесәләрен суккалап, капшап чыкты да, Газинурга:

— Бер-бер сигаретың юкмы соң? — диде. Аныкы да беткән икән. Күптәнге дустын очраткан сыман елмаеп кына бу егет миңа:

— Тартырга юкмы, иптәш? — дип эндәште.

— Бар. Менә, фильтрсыз гына... «Прима», — дип, аңарга суздым. Әлеге арзан, очсыз тәмәкегә хәйран сөенеп:

— Монысы аның иң тәмлесе инде! — диде дә, рәхмәт әйтеп, шундук чыгып та китте. Менә кадәр аның хакында ишетеп белә идем инде. Тирән, мәгънәле лирик шигырьләрен исләрем китеп укый торган идем. Ә үзен менә беренче тапкыр күрүем. Бу — Нияз Акмал иде.

Нияз «Мәдәни җомга»ның әдәбият бүлеген җитәкли иде. Шагыйрь, прозаик, публицист, уен-көлкегә, юморга юмарт кеше буларак, «13нче бит»не дә әзерләп алып бара иде. Аның бүлмәсендә кеше өстенә кеше булды: ул театр артистлары дисеңме, җырчылар, язучылар, композиторлар, яшь каләм ияләре дисеңме. Һәммәсе белән йомшак, шул ук вакытта акыллы мөнәсәбәттә. Мөгамәләсе һәрчак хәерхаһлы. Берсен-бер рәнҗетмәде, ишеге, күңеле кебек үк, һәркемгә ачык иде.

Мин үзем күбрәк юморга мөкиббән, шуңа күрә язганнарымны аңа бирә, укыта, яклау, хуплау таба идем. Берәр уңышлырак пародия-фәлән алып килсәм, ул, матур уенчыкка сөенгән сабый бала кебек, ихлас куанып, көлеп куя торган иде. Язганнарымның кайберсен күрше бүлмәләргә алып чыгып китә дә хезмәттәшләренә рәхәтләнеп укый иде. Тегеләрнең күңелләрен күтәрә — көлү тавышы әллә кайларга тарала. Бактың исә, ул шулай итеп әсәрләрнең яхшымы-юкмы икәнлеген — егәрен сынап карый икән.

Бер тапкыр шулай янына бер көлтә шигырь күтәреп кердем. Менә Нияз укый башлый, тик укыган саен моның чырае сытылганнан-сытыла бара.

— Әллә ошамыймы, Нияз әфәнде? — дип сорыйм инде.

— Әх, малай! Шигырьләр бит хатыннар кебек матур булырга тиеш! — дип җаваплады ул.

Кире какмады тагын үзе, рәнҗетмим диптер инде. Күп тә үтмәде, үзенчә төзәткәләп-ялтыратып дигәндәй, гәзитнең чираттагы бер санында чыгарып та куйды.

Аның ис-хәтеренә шаккатырсың. Яттан бихисап шигырь сөйләп бирә: Тукай, Дәрдемәнд, Зөлфәт, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләм кебекләрне. Аларны еш кына үрнәк итеп китерә. Гомумән, ул бары көчле, чын шигырьләрне генә үз итте, кабул кылды. Сажидә Сөләйманова шигырьләренә исә гомере буена мөкиббән

булды, талантына чын-чынлап соклана иде. Анын үзен күрер өчен ул хәтта бер көнгә Әлмәткә дә китеп барган. Ләкин күрергә насыйп булмый шул – Сажидә апа каядыр киткән булган.

Мин күп кенә шигырьләргә пародияләр яздым. Нияз шигырьләренә дә. Кайберләр үпкәләүчән, ә ул көлә генә, ихлас елмаеп, аркадан кага... Мин аның эшеннән тәм табып, җиренә җиткереп эшләгәнен беләм. Иртә таннан кичкә кадәр бүлмәсендә була иде.

Бер заманны мин акрошигырьләр белән мавыгып киттем. Байтак кына шагыйрьләргә, күренекле шәхесләргә карата язган идем. Язганнарымны барлап, җыйнап утырганда бер акрошигырьгә юлыктым. Ул Нияз Акмалга атап язылган:

*Нур сибеп тора карашы,*
*Ихлас аның күңеле.*
*Язганнары тирән, төпле,*
*Зәвыклы һәм күңелле.*
*Аларны укый яшьләр дә,*
*Картлар да бик яратып.*
*Масаеп та йөрми бер дә:*
*Арган йөрәкләргә учлап*
*Ләззәт йөри таратып.*

Шунда бер фотосурәт тә килеп чыкты. Матбугат йортыннан күченергә бер-ике ай калган вакыт. Фотоаппаратым белән кереп чыккан идем редакциягә. Ниязны да бүлмәсендә төшереп алдым. Бу аның соңгы сурәте булгандыр дип уйлыйм...

Бөтен татар халкына «Дустым!» диеп эндәшерлек ихлас бер иҗатчы зат иде ул Нияз Акмал...

**Ринат МӘННАН.**

Нияз
Акмал

## Сизгер булсаң...

**Сизгер булсаң,**
**ут чыкканчы сызгыр:**
**«Кабына!» — дип сызгыр,**
**«Яна!» — дип.**
**Әйтер сүзләр безнең**
**һаман саен**
**кабынулардан артта кала бит.**

**Йөрәк — учак.**
**Дөрләп торган учак,**
**хисле учак, утлы...**
**Җыр — ялкын!**
**Телгәләнми торган чагың, йөрәк,**
**ялкыныңны, димәк, җуяр көн.**

Рияланма берүк!
Ихлас җанны
кала алмабыз күк без йолып,
булмаганны һаман эзләп йөреп,
булганына һаман күз йомып.

Эзләп тап син,
көлдән аралап ал
һәр учакның соңгы күмерен.
Җилләр сыный...
көннәр сыный әле,
еллар сыный ялкын гомерен.

Куырылып туңган чаклар була,
бер җылы ут җанга кирәктә.

Чыра телеп түгел,
үзен телеп,
телгәләнеп янган йөрәк лә.
Бу — безнең җыр!
Һәм ул безнең белән,
безнең күзләр белән яңа бит.
Сизгер булсаң,
ут чыкканчы сызгыр,
«Кабына!» — дип сызгыр,
«Яна!»— дип!..

## Борылыр иде

Син барында карлар ап-ак иде,
Әй каралды карлар син киткәч.
Вокзал хәтле вокзал өнсез калды,
Китәсеңне синең ишеткәч.

Китте поезд...
Төнне ярып китте,
Мең тарафка безне таратып.
Мин дусларга уйнап кына әйттем,
Ә бит калдым чынлап яратып.

Шәлләреңне иңеңә салып җибәр,
Юл җилләре әгәр өшетсә.
Синең поезд кире борылыр иде,
Йөрәгемне минем ишетсә...

## Сак-Сок

Көннәрнең, айларның, елларның
Исәбен хәтердән чыгардым.
Мин сиңа шулкадәр ашыктым!
Мин сиңа шулкадәр соңардым...

Мин беләм, син дә бит көткәнсең:
«Ул килер... Ул барыбер киләчәк!..
Соңардым. Мин сизәм: гөлләрем
Үземнең учларда кибәчәк.

Төнемә уралса уйларым,
Айнымый интегә һәрбер сүз.
Син миңа шулкадәр кадерле!
Төн миңа шулкадәр кадерсез...

Ничәмә мәртәбә урадым
Сак белән Сок узар юлларны! –
Соңардым, соңардым, соңардым,
Шул бәйли, шул бәйли кулларны.

Каяндыр син йөргән яктан да
Туктаусыз яңгырый сыман моң:
«Мин сине шулкадәр сагындым!..»
Мин сиңа шулкадәр соңардым...

## Юлга табынып

Хурлап сөйләүчеләр күп булыр,
Кемдер калыр ләкин сагынып.
Ул без киттек аздан кабынып,
Ул без бардык юлга табынып.

Югалтулар, беләм, алар бар –
Югалтусыз булмый, күрәсең.
Юрамадык, алдан белмәдек
Бу башларның ниләр күрәсен.

Ерак иде безнең офыклар,
Без җитәрбез, дидек, ничек тә.
Кем сүз әйтеп торды үчекләп,
Кем күзәтеп торды ышыкта.

Таш атсалар — каршы атмадык,
Тез канатып, елап ятмадык.
Утка кердек — утта янмадык,
Суга төштек — суда батмадык.

Ялгышларның, югалтуларның
Төгәл хакын инде беләбез.
Ни җуясын алдан сизенеп,
Яңа үргә менеп киләбез.

Без барабыз аздан кабынып,
Без менәбез үргә табынып.
Хурлап сөйләүчеләр күп булыр,
Кемдер калыр ләкин сагынып...

## Тынлык авазы

Бу тынлыкны колак салып тыңла,
Ишетелер аваз: «Мең яшә!..»
Юк, эзләмә тавыш килгән якны —
Туган ягың сиңа эндәшә.

Сукмакларда эзең калган икән —
Алар сине мәңге хәтерләр.
Ап-ак көртләр, алларыңа чыгып,
«Без — якташлар!..» — диеп әйтерләр.

Тик син саклан кинәт кычкырудан:
«Хәтерлим!—дип.—Мин дә хәтерлим!
Ватаны бу, алмаштырмас иле
Минем тәүге мәхәббәтемнең!..»

Кышка калган миләш тәлгәшләре
Йөрәгеңдә, беләм, әй дөрләр.
Ак сагышлар, юлларыңда калкып,
«Без —сердәшләр!..» — диеп әйтерләр.

Тик син саклан кинәт кычкырудан,
Тынлык гамен, берүк, онытма,—
Туган ягың — синең серләреңне
Саклый торган изге нygытма.

Монда сине һәрбер капка таныр,
Монда сине һәр йорт хәтерләр.
Урамдагы кое сиртмәләре
«Без кардәшләр!..» — диеп әйтерләр.

Ә син тыңла, колак салып тыңла,
Ишетелер аваз: «Мең яшә!..»
«Туган ягым минем, мең яшә!» — дип,
Үз йөрәгең синең эндәшә...

## Шатлык эзләп

Трамвайлар китсен.
Ә без менә
Төшеп калыйк шушы тукталышта.
Төшеп калыйк.
Минем бүген монда
Шатлык табасым бар һәр тарафта.

Юк, син тыңла. Кичектермә, зинһар,
Син калдырма иртәгәгә, бәгырь!
Табасым бар шатлык,
Менә бүген,
Менә монда аны,
Менә хәзер!

Шатланырга кирәк бүген безгә,
Һич югында бер-бер сәбәп табып.
Бәлки, шатлык үзе килеп чыгар,
Үз ишләрен бездә танып алып.

Юк, чынлап та... Ә син күрәсеңме:
Яфрак ята аяк асты тулып.
Тоелмыймы сиңа бу яфраклар
Сары челтәр япкан шатлык булып?

Тоелмыймы?..
Шушы сары күзләр
Сагышларны гына кузгатамы?
Әллә бездә генә йөриме ул
Сагыну-сагышларның үзгә тәме?!

Юк-юк, бәгырь... Ә бит бүген безгә
Шатланырга кирәк үч иткәндәй!
Үз итик без бүген шатлыкларны,
Җир кояшны шулай үз иткәндәй!

Юк, чынлап та! Син офыкка кара:
Күрәсеңме, кояш баеп бара?!
Бүгенге көн белән һаман саен
Ерагая бара безнең ара...

Ерагая... Ә бит шушы көндә
Үзен, җанын, бәгърен ирексезләп,
Күпме кеше яши бу дөньяда,
Күпме кеше йөри бәхет эзләп!

Шатланыйк без бүген шушы Җирдә
Кеше барга, бәгырь, кояш барга.
Шатланыйк без бүген чын йөрәктән
Матур байый алган кояшларга!

Юк, чынлап та... Ә бит Җир түгәрәк,
Кояш чыга, димәк, кай яктадыр.
Кемдер бүген шул кояшка карап,
Безне таныр, бәгырь, үзен таныр.

Юк, син көлмә. Беркем әйтә алмас
Артык беркатлы, дип, бүген безне,—
Шатлыгы бар — инде бәхет көтә,
Бәхет тапмаганнар — шатлык эзли.

Ничек шатлык булмый калсын инде
Шатлык эзләп йөрер кеше барда?
Шатланыйк без бүген үз теләген
Шатлык итә алган язмышларга!

Без теләсәк, салып томшыгына
Шатлык ташыр иде асыл кошлар.
Без теләсәк, куш-куш учлап кына
Шатлык табар иде бу язмышлар!

Без теләсәк... Кичер мине, бәгырь...
Син аңларга тырыш мине башта!
Алдап-йолдап алып калдым сине
Сөю дигән шушы тукталышта.

Сөю дә юк... Димәк, шатлык та юк...
Үз оятым сулышыма каба.
Трамвайлар килми... Киттек, бәгырь!
Җәяү киттек, бәгырь, алга таба!

# «ТОМАН АРТЫ ЯКТЫ БУЛА»

## ШӘРИФ КАМАЛ ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЧОР ОБРАЗЫ

XX гасыр башы һәм 20-30 нчы еллар татар әдәбиятындагы үсеш-үзгәрешләрне, эзләнү-табышларны, каршылыкларны үз иҗатында шактый тулы чагылдырган әдипләрнең берсе – Шәриф Камал. Аның әдәби таланты, беренче чиратта, проза өрендә ачыла. Ш.Камал татар әдәбияты тарихына «психологик новелла жанры остасы» (Р.Ганиева) буларак кереп калды. Әдипнең «Уяну», «Буранда», «Сулган гөл», «Сукбай», «Бәхет эзләгәндә», «Чит илдә», «Козгыннар оясында» һ.б. күпсанлы хикәяләре, «Акчарлаклар» повесте кеше күңеленең гаҗәеп төсмерләрен, иң тирән хасиятләрен тәэсирле әдәби чараларда ачулары белән кызыклы һәм әһәмиятле. Ш.Камал үзенең геройларын тормышның уртасына куеп һәм табигатьнең бер кисәге буларак сурәтли. Табигать күренешләре әсәрләрдә геройларның рухи халәтен, хис-кичерешләрен бөтен тирәнлегендә һәм каршылыгында ачуга хезмәт итә. Әдип өчен табигать – кешенең юлдашы-ярдәмчесе дә, кинәшче-таянычы да. XX йөз башы татар әдәбиятында барган эзләнүләргә актив кушылып, Ш.Камал сурәтләүнең янадан-яна төсмерләрен, чараларын, формаларын эзли. Алар арасында лексик һәм махсус тасвирлау чаралары байлыгы, төрлелеге белән аерылып тора. Ә инде әдәби деталь әдип әсәрләрендә мөһим, еш кына хәлиткеч, төп фикер-идеягә ачкыч ролен үтәүче өлеш-компонент булып тора. Ш.Камал һәр әсәрендә тормышны оста күзәтүче буларак чыгыш ясый, шуңа да чынбарлык күренешләре, үзенчәлекле сыйфатлары белән ачылган геройлары гаять тормышчан булып күз алдына баса һәм озак вакытларга күңелгә сеңеп кала. Әдипнең «Акчарлаклар» повесте, күпсанлы хикәя-новеллалары XX йөз башы татар прозасының гүзәл үрнәкләреннән саналып, әлеге төрдә гаҗәеп матур традицияләргә юл сала, үзенең тулы бер мәктәбен тудыра. Үткән гасыр әдәбиятында лаеклы урын алып торган Г.Рәхим, Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, Х.Сарьян, Ә.Гаффар, М.Хуҗин һ.б. әсәрләрендә Ш.Камалның иҗат йөзен билгеләгән сыйфат-билгеләрнең яңа шартларда үстерелүен, дәвам иттерелүен күрәбез.

Әдәбиятчы галимнәр Г.Халит, И.Нуруллин, Р.Ганиева, Ф.Бәшир, Т.Гыйләҗев һ.б. хезмәтләрендә Ш.Камалның татар прозасын үстерүгә керткән өлеше тулы чагылыш таба. Без исә әдипнең сәхнә әдәбияты өлкәсендә калдырган әдәби мирасы үзенчәлекләренә кинрәк тукталабыз.

Ш.Камалның драматург буларак беренче иҗат тәҗрибәсе булып 1915 елда язылган «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе тора. Хикәя-повестьларында кеше күңеленең төрле хасиятләренә, аеруча караңгы якларына иркен мөрәҗәгать иткән, прозаның кече жанрлары остасы булып танылган әдипнең драматургиягә мөрәҗәгать итүе үзе үк игътибарга лаек күренеш. Сәбәпләре турында уйланганда, икесен аерып фаразларга мөмкин. Бердән, Ш.Камал үз чоры татар җәмгыятенең торышын, эчке хәлен яхшы белгән. Янарыш-үзгәрешләрнең акрын юл яруына борчылу хисе аны һәртөр искелек-арттагылыкны, торгынлык киртәләрен фаш итүгә китергән. Икенчедән, XX гасырның 10 нчы елларында шактый нык аягына баскан татар театры милли мәнфәгатьләрне актив алга куючы, яклаучы һәм фикер-карашларны халыкка җиткерүдә үтемле чара булып танылa. Ш.Камалда, күрәсең, бу мөмкинлекне дә файдалану теләге туа.

«Хаҗи әфәнде өйләнә» – көнкүреш комедиясе. Прозасында үзе яхшы белгән чынбарлык вакыйгаларына таянып язган әдип бу пьесасында да тормышта булган

хәлләргә мөрәҗәгать иткән дип уйларга нигез бар. Пьесада вакыйгалар 70 яшьлек Юныс хаҗиның яшь мөгаллимәгә өйләнергә йөрүенә бәйле үстерелә. Ш.Камал шактый таныш теманы тасвирларга алына. Күптөрле бәхәсләргә китергән өйләнешү мәсьәләсе Г.Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш», «Алдым-бирдем», И.Богдановның «Помада мәсьәләсе», М.Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» кебек пьесаларында сәнгати чагылыш тапкан иде. Чордашлары тәҗрибәсенә таянса да, автор заманча яңгырашлы, идея-эстетик карашлары ачык чагылыш тапкан комедия иҗат итә. Драматург татар тормышындагы һәм аерым кешеләр характерындагы ямьсез сыйфат-күренешләрдән көлүне максат итеп куя. Шуна бәйле конфликтның бер ягында Юныс хаҗи торса, икенче якны төрле социаль катлау вәкилләре булган яшь геройлар тәшкил итә. Комедиядә автор идеалын чагылдырган аерым герой юк. Бу функцияне гомумиләштерелгән яшьләр образы үти. Пьесада алар электән килгән иске гадәт-йолаларга, шулардан үз мәнфәгатендә файдаланучыларга, кеше шәхесенә, аеруча хатын-кызларга түбәнсетеп караучыларга каршы актив көрәшүчеләр булып ачыла.

Юныс хаҗи белән бәйле күренешләр пьесада төп өлешне алып тора. Ул – менә кадәр татар драматургиясендә билгеле сатирик типлар Кәрим бай («Өч хатын белән тормыш»), Сәлим бай («Помада мәсьәләсе»), Гали мулла («Яшьләр алдатмыйлар») кебекләрнең дәвамчысы. Әгәр И.Богдановның 60 яшьлек Сәлим бае 16 яшьлек кызга өйләнүне максат итсә, Ш.Камалның 70 яшьлек герое исә җәдитчә укытучы мөгаллимәгә өйләнергә тели. Драматург Юныс хаҗиның аеруча ике сыйфатын фаш итүне алга куя – саранлык-алдашу һәм әхлаксызлык. Ячучы Нәсимә хаҗины, билгеле, яхшы белә. Шулай да Җәләлгә «әүлия шикелле изге кеше» дип атый, бераздан саранлыгын яшереп булмавын аңлап, сәүдә эшендә «алдашу кирәк сыйфат» дип мактый башлый. Ахырда исә хаҗиның саранлыгын, алдашуын үзендә татыгач, «жулик» дип бәя бирә. Автор хаҗиның әхлаксызлыгын фаш итүдә төрле алымнардан файдалана. Беренче күренешләрдә үк бозыклык чыганагы булып ачылган хаҗиның начар сыйфатлары, таудан төшкән кар өеме кебек, бик тиз арта барып, мәгънәсезлек төсмере ала. Хатыны Галимә бикә аның чын йөзен тагы да ача: өйдә асрау кыз тота алмыйлар икән. Менә кадәр хезмәт иткән ике марҗа кызы хаҗиның «шаярулары» аркасында куылса, бер кыз исә, балага узып, өйне ташлап китә. Хаҗи эш-гамәлләре белән үзен-үзе тулысынча фаш итә. Чын йөзен дини фикер-карашлар артына яшергән бу кеше үз максатына ирешү өчен теләсә нинди адымга барырга әзер. Исән-сау хатынын авыру, тиздән үләчәк дип әйтү, хәтта ана ясин чыгу да хаҗи өчен берни түгел. Яшь кыз итеп киендерелгән карт хатынына үзен үк яманлап утыруында, аннары дәртләнеп мәхәббәт аңлата башлавында сарказм белән көлү иң югары ноктасына җитә. Ш.Камал югары әхлак идеалын, акылны, белемне, тапкырлыкны яклый һәм һәртөр искелекне, патриархаль гадәтләрне халыкчан көлү аша кире кага.

Драматург Юныс хаҗины типик образ буларак сурәтли. Алгы планга геройның холкы, психологиясе чыга. Хаҗи эш-гамәлләрендә инде чор, заман үзгәрешләре дә чагыла. Игътибар итик, ул теләсә нинди яшь кызны түгел, бәлки «ысул җәдид мөгаллимәсен хәләл җефетлеккә» алуны максат итә. Таһир һәм Зөһрә исемнәрен телгә алуы да аның мәхәббәт каһарманнары турындагы әсәрләрдән хәбәрдар булуын күрсәтә. Шуның өстенә Юныс хаҗи – бөтен асылы белән милли образ. Аның үз-үзен тотышында, сөйләмендә, эш-гамәлендә без XX гасыр башы татар җәмгыятенең җыелма, типик вәкилен күрәбез. Ш.Камал чеметеп көлүе белән әхлакый сафлыкның һәртөр бозыклык-мәгънәсезлектән өстенлеген, җиңү көчен һәм тормыштагы яңалык-үзгәрешләрнең котылгысызлыгын күрсәтә. «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясенең озак еллар дәвамында сәхнәдән төшми уйналуы да шулар белән аңлатыла.

Совет чорында Ш.Камал сәхнә әдәбиятына бары 20 нче еллар ахырында гына әйләнеп кайта һәм түбәндәге пьесаларын иҗат итә: «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1932), «Габбас Галин» («Томан арты»,1934), үзгәртелгән яңа варианты «Карчыга» (1935), «Матур туганда» (1938). «Ут» драмасы үз вакытында басылмыйча кала, 1956 елны чыккан дүрттомлыгына кертелә. Бөек Ватан сугышы башлангач, «Сафура» исемле пьеса яза башлый, ул тәмамланмыйча кала.

1920-1930 елларда татар драматургиясе һәм театры каршылыклы үсеш кичерә. Аеруча заман темасына язылган әсәрләргә кытлык зур була. Шундый шартларда сәхнә әдәбиятына килгән Ш.Камалның эстетик идеалы яна җәмгыятьнең нигезләрен коруда эшчеләр сыйныфының максатчан эшчәнлеген чагылдыру белән бәйле. Дөрес, ике пьесасында элегрәк булган хәлләр тасвирлана. «Матур туганда» романы сюжетына нигезләнеп язылган драмасында 20 нче еллар башында беренче коммуна-артельләр төзү вакыйгасы чагылыш таба. Ә инде 1910 елда язылган «Козгыннар оясында» хикәясе шул исемдәге пьесага җирлек булып тора. Әлеге драма Ш.Камалның әдәби-эстетик карашлары үзгәрешен билгеләүдә аеруча игътибарга лаек. Шунын өстенә ул Казан Зур драма театрында рус телендә уйналган беренче татар пьесасы. Белгәнебезчә, хикәядә эшчеләр тормышының газаплы, еш кына фаҗигале яклары тасвирлана. Авыр тормыш шартлары нәтиҗәсендә кеше күңелендә матурлыкка өмет сүнү һәм, киресенчә, явызлык, кешелексезлек сыйфатларының өстенлек алуы гаять тәэсирле сурәтләрдә, тирән психологизм аша бирелә. Байтак вакыйга-күренешләр, геройлар үзгәрешсез калган драмада алгы планга эшчеләр белән шахта хуҗалары арасындагы каршылык чыга. Вакыйгалар барышында ул татар һәм рус эшчеләренең революцион көрәшкә – забастовкага килүе белән тәмамлана. Әгәр хикәядә «козгыннар оясы» буларак эшчеләр барагы күрсәтелсә, пьесада исә үз хокуклары өчен актив көрәшкә килүче бернечә эшчене, махсус авария ясатып, таш астында калдырырга җыенучы шахта хуҗалары, аларның ялчылары, шул исәптән мулла да «козгыннар» итеп бирелә. Пьесаның язылу максатын аңлатып, Ш.Камал болай дип яза: «Капитализм эксплуатациясенең авырлыгын без нихәтле тулы итеп күз алдыбызга китерә алсак, йөрәкләребез белән нихәтле әче итеп сизә алсак, социализм төзү юлындагы авырлыкларны без шул хәтле зур шатлык белән күтәрә алабыз». Драманың үз вакытында шактый яңгыраш алуы һәм рус сәхнәсенә менүе сәбәбе, күрәсең, тагын шунда: анда, татар сәхнә әдәбиятында беренчеләрдән булып, татар эшчеләр сыйныфының формалашкан, оешкан булуы чагылыш таба һәм революцион көрәшкә татарларның рус революционерлары җитәкчелегендә килүе күрсәтелә.

Ш.Камалның бу елларда язылган драмалары дәүләткүләм алып барылган идеологиягә буйсындырылган булуын күрәбез. Бу түбәндәгеләрдә чагылыш таба: бердән, Октябрьгә кадәрге тормыш белән совет чорын капма-каршы куеп сурәтләү, ягъни буржуаз җәмгыятьне, аның казанышларын тәнкыйтьләү, кире кагу, яна җәмгыятьнең хезмәт ияләренә бәхет алып киләсенә ышану; икенчедән, Сталинның «социализмның нигезләрен төзү барышында сыйнфый көрәш көчәя» дигән фикерләрен яклау; өченчедән, дингә, дин әһелләренә каршы көрәш, аны искелек-артталык калдыгы, наданлык күренеше дип тәкъдим итү. Бу чор татар әдәби процессын бәяләп, Й.Нигъмәтуллина болай дип яза: «20 нче еллар ахырында, официаль идеология басымы астында, татар язучылары «идеяләр романтизмыннан», ягъни милли үзанны үстерү, милли азатлык хыялыннан баш тартырга мәҗбүр булдылар. Бу идеяне социализм төзү, халыклар һәм милләтләр «тигезлеге» дигән үтәкүренмәле идея алыштырды». Әлеге фикер Ш.Камал иҗатына да карый.

«Ут», «Таулар», «Габбас Галин («Томан арты») драмаларында әдип заман проблемаларына мөрәҗәгать итә. Сәнгати яктан төрле булган пьесаларны бер нәрсә берләштерә: авторның сәнгати фикерләве, иң алдыңгы, гегемон сыйныф позицияләрендә торган хәлдә, киләчәкне матур, бәхетле итеп күрүгә нигезләнә. Дошман элементларның теләк-максаты, билгеле инде, элекке тәртипләрне кайтаруга, җәмгыятьнең алга барышын тоткарлауга юнәлтелгән. Шуна да пьесаларда төп конфликт сыйнфый характерда, ягъни Ш.Камал драмаларында көрәшүче көчләрне сыйнфый чыгыш билгели.

«Ут» драмасында сурәтләнгән вакыйгалар НЭП чорына карый. Трест начальнигы Рәүф элекке миллионер кызы Галиягә өйләнә. Әнисе Гөлбанунын «Бай — бай булыр инде ул. Синең белән мина ул үзе белән тин итеп карый алмас. Еланның койрыгын киссәң дә ул башы белән һаман зәһәрен чәчәр» дигән сүзләренә игътибар итми. Яшь, чибәр хатынның туганнарын җаваплы эшкә урнаштыра, соңгылары исә корткычлык эше алып бара. Үзенең йомшаклыгын, сыйнфый дошманны вакытында сизеп алмавын сонарып аңлаган Рәүф хатынын буып үтерә.

Әмма конфликт шактый йомшак булып, геройларның эш-гамәлендә ачылмый диярлек. Әйләнә-тирәдәгеләрнең кат-кат кисәтүенә карамастан, Рәуфнең сыйнфый дошманнарга битарафлык күрсәтүе, озак вакыт анык бер карарга килә алмавында ясалмалылык сизелә. Бу уңайдан М.Максуд болай дип яза: «Пьесада уңай типлар сыйфатында тәкъдим ителгән Рәуф һәм Гомәрләр һич тә алдынгы коммунистларны хәтерләтә алмыйлар. Алар сыйнфый көрәштә артык булдыксыз, артык аңгыра итеп бирелгәннәр». Шуның өстенә әсәр эчтәлеген баетмый торган өстәмә эпизодлар кертелгән. Болар барысы да пьесаның гомуми тоныклыгына китерә.

«Таулар» драмасында ил күләмендә төрле постларны эләктергән, завод эчендә житәкче урыннарга үрмәләгән дошман элементларның житештерү процессына төрлечә аяк чалулары тасвирлана. Әмма ачык билгеле мәсьәләләрне кат-кат куерту сюжет таркаулыгына, вакыйгалар сүлпәнлегенә китерә. Бу исә конфликтның йомшаклыгын, схематик булуын билгели.

Ш.Камалның бу чор драмалары арасында иң уңышлысы булып «Габбас Галин» («Томан арты») санала. Пьеса билгеле бер схематизмнан, декларативлыктан арынмаса да, аның төп табышы булып яңа тормыш шартларында формалашкан шәхеснең эволюциясен күрсәтү тора. Вакыйгалар барышында яшь инженер-химик Габбас Галин тире эшкәртү заводының сәүдә представителе Зөфәр Талиповка каршы куела. Конфликт төрле яссылыкта булып, шәхси сыйфатларда, гаиләгә карашта, аеруча хезмәткә, ижтимагый тормышка мөнәсәбәттә чагыла. Габбас Галин яңа тормышның яңа кешесе булып ачыла. Завод житәкчеләре һәм хатыны белән аңлашылмаучылык килеп чыкса да, ул ихтыяр көчен, үз-үзенә ышанычын саклап кала. Тырышлыгы нәтиҗәсендә зур хезмәт җиңүенә ирешә.

Драматургның әдәби-эстетик карашлары чагылышы буларак, вакыйга-күренешләрдә элекке тормыш белән яңа заман каршылыгы һәрдаим урын ала: элек мохтаҗлыктан чыкмаган Локман карт бүген алдынгы эшче, ударник, ә улы — инженер-химик; элек алдынгы, тырыш эшчеләрне хөрмәтләү, бүләкләү юк иде, хәзер «кешеләргә бәхет чишмәсе агып тора»; картларның аракы эчүе дә иске заманнан калган гадәт һ.б. Драманың буеннан-буена сузылган лейтмотив — хезмәткә мәдхия. «Эш — җан рәхәте ул», — ди пьесаның бер герое. Уртак, күмәк хезмәткә бәйле коллективчылык күренеше дә үстерелә. Драма поэтикасында жыр мотивы да мөһим урын алып тора. Талипов күңел ачу турында жырласа, карт эшчеләр шул чорның популяр җырын искә төшерә — «Томан арты якты була». Пьесаның баштагы исеме дә шуның белән бәйле һәм төп идея булып тора: хәзергә каршылыклар, кыенлык-авырлыклар күп, ягъни томан сарган, әмма ул таралыр, ягъни тырыш хезмәт нәтиҗәсендә киләчәгебез якты, матур булыр. Ш.Камал әлеге драманың 2 нче вариантын яза, аны «Карчыга» дип атый. «Карчыга» — Габбас кушаматы. Пьеса исеме шуннан алынган. Яңа вариантта өстәмә эпизодлар кертелгән, аерым сораулар ачыкланган, фикер-карашлар тулыланган, кайбер образларның (Талипов, Кулаев) әдәби-эстетик вазифасы баетылган. Шулай да Ш.Камалның соңгы өч томлыгына И.Нуруллин драманың 1 нче вариантын урнаштыруны кирәк тапкан.

Шулай итеп, Ш.Камалның 1920-1930 елларда язылган драмалары, чор идеологиясенә бәйле, сыйнфый көрәшне алгы планга куюлары, конфликтның бертөрлерәк булуы, образлар эшләнешендә, вакыйгаларда схематизмнан котыла алмау нәтиҗәсендә зур яңгыраш ала алмый. Әмма әдип иҗаты шул чор сәхнә әдәбиятындагы эзләнү-табышларны һәм югалтуларны аңларга ярдәм итә. Замандашлары К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт, Һ.Такташ, Г.Кутуй, Т.Гыйззәт һ.б. белән берлектә татар драматургиясен яңа жанрлар, темалар белән тулыландыруга, тормышчанлык юнәлешендә үсүгә, поэтик яктан баетуга билгеле бер өлеш кертә. Ш.Камалның сюжет корудагы, образларны индивидуальләштерүдәге, метафорик күренешләрдән, символлардан файдаланудагы аерым табышлары күпләргә өйрәнү мәктәбе дә булып тора. Ә инде «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясенең әледән-әле татар театрлары репертуарына кертелүе, аның вакыт сынавын уңышлы үтеп, бүген дә заманча яңгырашы турында сөйли.

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ

# ГОРУРЛЫККА МӘДХИЯ

*Журналист, публицист һәм тәнкыйтьче Рәфыйк Кәләметдин улы Шәрәфиев 1939 елның 13 февралендә Татарстанның Балтач районы, Карадуган авылында туа.*

*Беренче әдәби язмалары, кыска хәбәрләре һәм шигырьләре матбугат битләрендә 1957 елда ук күренә башлый. Озак еллар буе, Балтачның «Хезмәт» газетасында эшләү дәверендә аңа «Матбугат отличнигы», Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә. 2000 елдан бирле Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Уйлы күңел» (Татар.кит.нәшр., 2001), «Татар эзләү» (Татар.кит.нәшр., 2006) һәм «Ник сызланасың, йөрәк?» («Сүз» нәшр., 2008) китаплары авторы.*

*Р.Шәрәфиев бүген дә үсештә, иҗади активлыгын киметми – публицистик язмалары, рецензияләре белән киң катлам укучыларны сөендереп тора...*

*Каләмдәшебезне олуг бәйрәме белән котлыйбыз! Алга таба да иҗади сөенечләр һәм бәхет-саулык теләп калабыз.*

1994 ел. «Чаян» журналының җаваплы секретарь бүлмәсенә Мәгъсүм Хуҗин килеп керде. Ул шулай, атна саен диярлек, хәлне белеп чыга. Кем белән ничектер, ләкин минем белән ул гел үзенчәлекле итеп, кинаяләп күрешә торган иде.

— Бу бүлмәдә мин унҗиде ел да җиде ай утырып чыктым...

«Нихәл, түзәсенме, өеңдә иминлекме?» – дигәне шушы инде аның.

— Синең батырлыкны кабатларга тырышмам! – дигән булам, мин дә анынча хәл-әхвәл сорашып вакланмыйча гына.

— Син бит Балтач кияве булырга хыялланган идең. Мә, укы! Менә шулай язарга кирәк! — Мәгъсүм абый кесәсеннән сигезгә бөкләнгән «Шәһри Казан» газетасын чыгарып салды. – «Кырмыскалар турында баллада»ны укы.

Мәгъсүм абыйның мактануына аклану эзләп мәкаләгә ябырылдым... Югары Советка сайлаулар чорында, Балтач округыннан, хакимият башлыгы Марат Әхмәтовка альтернатив буларак катнашкан район газетасы журналисты Гөлсинә Гарифуллинаны яклап язылган...

— Җинелүчене мактау – җирле хакимияткә каршы дәшү була түгелме соң, шулар кул астында эшләгән килеш? – дидем мин, мәкаләне укып бетергәнче үк сабырсызланып.

— Авторы кем? – Һәм Мәгъсүм Хуҗин, «Чаян» логотибындагы күзлекле рәсем кебек, астыртын канәгатьлек белән миңа текәлде.

— Рәфыйк Шәрәфиев! Балтачта редактор урынбасары... Беләм мин аны.

— Беләсеңдер дә... Ә ул егетне «Хезмәт» редакциясенә эшкә чакыручы кеше кем дисең?! Вәт, район газетасының ул вакыттагы баш редакторы – Мәгъсүм абзагыз Хуҗин... үзебез булабыз!

— Охшагансыз да. Икегез бериш – төртмә тел, кырын торып та туры текәлә торган җете караш, каһкаһәсез көлү, көттереп кенә җавап бирү. Тик син бит Сабадан, Мәгъсүм абый?!

— Балтач гавамы килгән кешене шундук йолып ала. Яшәү рәвеше йогышлы анда...

Ирексездән уйга калдым, әллә сон минәйтәм, Рәфыйк Шәрәфиевләр, Мәгъсүм Хужиннар кебек киная белән сөйләшергә яратучан: Батулла, Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Зөлфәт Хәким, Ләбиб Лерон һәм Искәндәр Сиражи кебек язучыларыбызнын да биографиясендә Балтач төбәгенә кагылышлы хәлләр бар микән?..

Мин үзем дә Балтачтан «ироник реализм» дигән чир иялтеп кайттым.

1980 елнын язы.

«Казан — Малмыж» автобусы тигез генә барган җирдән кинәт аска төшеп китте... Балтачка житкәнбез икән. Монарчы бу районнын кайдалыгын студентлардан ишетеп кенә белә идем.

Балтачны күрер өчен ана бик якын килергә кирәк. Кайсы гына ягыннан керсән дә, ул текә тау астында — гүя дингезеннән бушаган тарлавык төбендә. Киткән дингезне эзләп сәфәр чыккан зур кизләү булып Кече Лызи ягыннан Шушма елгасы ашыга, Балтач итәгендә тукталып тормыйча гына... Карадуган белән ике арага инглиз газоннары кебек тигез кыркылган гектарлы плантацияләр җәелгән. Анда бүген-иртәгә кәрҗиннәр, жиһазлар, бизәкләр һәм бишекләр булып үреләсе таллар үсә.

Юбиляр турында онытып, ник әле шултиклем Балтачнын табигатен сурәтләүгә күчтен дип битәрләргә ашыкмагыз. Кем әйтмешли, туган авыл — ул шәхеснен яшел бишеге! Баланын әлифбасы шунда, үсеп-ныгу өчен күзәнәк тукымасы, зиһен туплар өчен үгет-нәсыйхәте, сулар һавасы, эчәр суы шунда. Менә шушы факторлар кемнен кем буласын якты дөньяга туганчы ук көйләп куя инде.

Әйтик, Рәфыйк Шәрәфиев Балтачта түгел, ә ялгыш кына Казанда туып-үскән булса, без аны психолог, эколог, юрист, урман каравылчысы, укытучы, бәлки врачлар арасыннан эзләргә тиеш булыр идек.

Шулай итеп, институтны тәмамлар алдыннан мине Балтачнын Мәдәният йортына өч айлык практикага жибәрделәр. Диплом эшем итеп кичләрен «Тел тегермәне» дигән юмор кичәсен сәхнәләштерәм. Ә көндезләрем буш. Әйткәнемчә — яз көне!.. Агач кунакханәнен саран тәрәзәле бүлмәсендә бикләнеп ятар чагым түгел.

Иксез-чиксез илебезнен кайсы гына төбәгенә килеп төшсән дә, каләмпәрвәр ятимене үз туганыдай хөрмәтләп каршы алырлык район газетасы бар.

«Хезмәт» — олы юл чатында.

— 1 апрель унаеннан сезгә бер шаян хикәя китергән идем. Исәнмесез?! — дип әйтеп өлгермәдем, чибәрлеге белән Шәле кызларына охшаган җаваплы сәркәтип кыз (исемен сонрак белдем, Ләйсән Кариева икән) туп-туры «урынбасар» бүлмәсенә алып кереп китте.

Сагышлы портретка охшаш чырайлы, чандыр гәүдәле, жинел сөякле, басынкы тавышлы кырык яшьләрдәге абый минем шаян хикәямне яна телевизор инструкциясен укыган ише жентекләп карап чыкты — ләкин кылы да селкенмәде. Киләчәк заман белән бүгенгенен икесен дә бергә тоташтырып күрә торган күз карашын мина төбәде. Ә мин исә тизрәк акланасы иттем:

— «Идел» альманахында, «Казан утлары»нда, «Чаян», «Ялкын», «Яшь ленинчы»да басылганым бар, — дим.

— Беләбез... Укып барабыз... — диде урынбасар һәм, мине тагын бер пауза белән сынаганнан сон, өстәп куйды: — Безгә бер хәбәрче кирәк, юлда йөрергә иренмәсән, штатка алабыз, Әхәт Фазылжанов белән үзем кереп сөйләшәм.

Шул көнне үк мине эшкә алдылар. Хатлар бүлегендә бер өстәл бирделәр. Шул көнне үк мин инде кичке алтыга кадәр анда утырдым. Кайтырга чыксам, Рәфыйк Шәрәфиев Әби патша заманыннан калган велосипедын иярләп маташа иде. Ул җәен-кышын, язын-көзен күрше авылдан Балтачка эшкә шулай йөргән.

Рәсми белешмәләрдә Рәфыйк Шәрәфиев Карадуган авылында туып-үскән һәм әле дә шунда яшәүче шәхес буларак күрсәтелә. Ләкин мин аны тумышыннан бирле Малые Лызи авылында (татарча исеме дөрес түгел — чөнки ул удмуртлар авылы)

яши дип беләм. Аз санлы халыкларның фаҗигасен ул ике ракурстан күреп үскән кешегә охшый.

Субаш авылы яшьләре исеменнән «Хезмәт» редакциясенә күп имзалы хат килгән. Хәбәрче сәфәренә тәүге тапкыр юлга чыгарыма сәбәп шушы булды.

Рәфыйк Шәрәфиев мине дошман тылына разведкага җибәргән ише әзерләде:

— Безнең инде бу яклардагы негативка күзияләшкән, колак тонган. Син яңа кеше, яңачарак язып кайтырсың дип ышанам. Колхоз рәисе Хәсәнша Борһанов озак еллар эшләгән, мактаулы җитәкче, саграк бул! — диде.



*Бер төркем язучылар Балтачта.*
*(Р.Шәрәфиев уңнан беренче). 2002 ел, апрель.*

Субашта көнем үтте. Өйдән-өйгә йөреп яшьләрнең зарын җыйдым. Колхоз председателе авыл советы рәисенә язгы чәчү беткәнче авыл клубын ябарга кушкан, ә баянны конторга алып кайтып колхозның бозау сыярдай сейфына бикләп куйган. Әйтерсең лә яшьләрнең баянын бикләп кенә яшьлекнең үзен туктатып торып була?!. Колхоз председателе мине кабул итеп тормады...

Әкренләп мин шуны аңлый башладым — күңел ачып эшләү Балтачның яшәү рәвеше икән. Күпме сайрар кошы булса — шулкадәр җырчысы бар, Шушмада күпме балык булса — шулкадәр биючесе бар. Андый халыкны кимсетергә теләсәң гармунын гына яшереп куй икән...

Төне буе, кунакханәгә бикләнеп, фельетон яздым. Иртән бер полосалык язмамны урынбасар өстәленә китереп салдым. Шаян хикәямне укыган чакта да исе китмәгән Рәфыйк Шәрәфиевнең сулъяк каш өстенә төшеп торган мангай чәченә кушылып ирен чите селкенеп куйды. Кызык өчен генә Әхәт Фазылҗановка кертеп карыйм әле, дигән иде... Өч телдә чыга торган газетаның баш мөхәррире кул куймаган.

Минем кәеф төште, Субаш яшьләре ярдәм көтеп калды ласа, оятыңнан кая качарсың?

— Басылмаган фельетонның шул ягы яхшы — бюрога чакыртып сүкмиләр, — диде урынбасар. Ниһаять, мин аның көлемсерәгәнен күрдем. — Мә, ал фельетоныңны, янадан яз! — Минем берни аңламыйча аптырап торуыма каршы өстәп куйды, — формасын үзгәрт, эчтәлегенә тимә!

Мин, янадан туып, кунакханәгә йөгердем. «Ике рәис» дигән фельетонны скетч итеп үзгәртеп яздым. «Хезмәт»нең соңгы битендә әдәби сәхифәдә бастырдылар. Рәфыйк Шәрәфиев мактамады, чөнки минем өчен борчылып йөрде... Редакциягә сүгенеп шылтыратучылар табылса да, шөкер, бюрода Фазылҗановны мактаганнар гына.

Субашның авыл советы рәисе Фәриттән телефонограмма килде: клубны ачканнар, баянны иреккә чыгарганнар!

Без Рәфыйк Шәрәфиев белән кунакка йөрештек, дип мактана алмыйм, мәгәр мин гел аның осталарча кайгыртуын тоеп йөрдем. Өч ай бик тиз үтеп китте. Диплом эшен «Отлично!»га тапшырып, бухгалтерияләр белән араларны өзеп йөрим. Шулчак мине райкомның идеология секретаре Рәшидә апа Кариева чакыртып алды. Бу чаклы ук хөрмәт көтмәгән идем.

— Балтачта бөтенләйгә каласыңмы? — диде ул, ярты сәгатьлек әңгәмәне

түгәрәкләп. — Редакциядә дә, Мәдәният йортында да эшләрсен. Ике җирдән хезмәт хакы алырсың. Күп фатирлы яңа йорт өлгереп килә, берәр бүлмә бирербез, — ди.

Минем хыялларым Казанда иде шул... Зурлап рәхмәт әйттем дә чыгарга торам. Шунда гына Рәшидә апа бәгырьне кисеп алды:

— Кызганыч... Рәфыйк Шәрәфиевнен сине бер дә җибәрәсе килмәгән иде, — ди.

Мин коелып төштем. Тешләк кеше дә соң бу урынбасар! Редакция белән хушлашып киткәндә ул бит әле мине урамга озата чыкты. Кал бездә, дип бер кәлимә әйтмәде. Кулны кысты да:

— Мәгъсүм Хуҗинны күрсәң, миннән сәлам әйтергә онытма, — гына диде...

Сагынуларның логик нәтиҗәсе буларак, Балтач редакциясе тәки өчебезне бергә очраштыра алды. «Хезмәт» газетасының 70 еллыгы уңаеннан Мәгъсүм абый Хуҗин белән мине дә бәйрәм тантанасына дәштеләр. Безне кем искә төшергәнен шундук аңлап алдым. Чакыру кәгазенә хакимият башлыгы кул куйса да мәҗлестәге урыннарыбыз Рәфыйк Шәрәфиев белән янәшә туры килгән иде. Якташлар булып, борын чөеп горурланып утыру безгә дә бик килешә иде ул көнне. Әлеге юбилейдан мин утыз яшькә яшәреп кайттым — өч кенә ай эшләгән өчен дә нинди хөрмәт! Ә бит Рәфыйк Шәрәфиев «Хезмәт» редакциясендә 34 ел туктаусыз эшләгән! Хезмәтнең михнәт дигән икенче мәгънәсе барын да беләбез. Менә каян килә ул публицистның Көрәшче дигән мактаулы даны! Кәләметдиннән тусын да гап-гади кеше булып калсын имеш Рәфыйк Шәрәфиев... Мөгаен, аның өендә Җир шарының зур глобусы бардыр. Җиһаннан берәр хәвефле хәбәр килеп ирешсә, меридианнар челтәреннән әлеге җирлекне эзләп табадыр да, кешелекне коткарырга теләп Балтач үзәнлегеннән аваз саладыр. Р.Шәрәфиев өчен табигатьтәге җан ияләренең вагы-эресе юк, язмышлар хәл ителгәндә кешеләр мөлкәтле-мөлкәтсезләргә бүленми, аның өчен ин мөһиме — хаклык! Шуңа күрә дә бәхәсләрдә аның горур фикере гел өстен чыга.

Туфан Миңнуллинга китап бүләк итсәләр: «Укуын укыйм, ну фикеремне сорама, әйтмим!» — дияргә ярата иде. «Ник сызланасың, йөрәк?» дигән китапка («Сүз» нәшрияты, 2008 ел) сөекле драматургыбыз хәтта кереш сүз дә язган. Димәк, язучы Рәфыйк Шәрәфиевнен титаннарны тәүбәдән яздырырлык иҗаты бар!..

**Камил КӘРИМОВ**

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

## АЛТЫН ТАРАК

*(Г.Тукайга ияреп)*

*Тагын бер укып чыктым да Тукайның «Су анасы»н,*
*Язарга булдым борынгы бу кыйссаның яңасын.*
*Сурәтләдем замананың мазасын вә казасын,*
*Күзалладым Тукай бүген ничек итеп язасын.*

**Кыш көне. Зур бассейнда мин суда коенам, йөзәм;**
**Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым берлән суны сөзәм.**

**Әйтсәм әйтим, бу бассейн – байлар өчен генәдер,**
**Аның кайда икәнлеген бик сирәкләр беләдер.**

**Монда ничек эләктемме? Ансы калсын сер булып,**
**Башкасын сөйлим, күңелдә тормасын ул гер булып.**

**Шулай итеп, су коенгач, тиз-тиз киендем өс-башым,**
**Куркам үзем әллә нидән, – юк янымда юлдашым.**

**Бервакыт, китәм дигәндә, төште күзем басмага,**
**Карасам, бер сылу хатын килгән күңел ачмага.**

**Көнгә каршы ялт-ялт итә кулында алтын тарак,**
**Шул тарак берлән утыра йәм-йәшел сачен тарап.**

**Тарап туйгачтын сачләрен, чумды китте суга ул,**
**Чумды да тәмам юк булды күз алдыннан шунда ул.**

**Инде хәзер әкрен генә мин юнәлдем басмага,**
**Рәхмәт төшкер, алтын тарак торып калган басмада!**

**Тирә-юньдә бер адәм дә юклыгын белдем дә мин,**
**Машина газына бастым, таракны элдем дә мин.**

**Шәйләмимен алны-артны, куам йөз илле берлән,**
**Әмма минем кырын эшне тән сакчылары күргән.**

**Мин качамын, алар куа, алар куа, мин качам,**
**«Мерседес»ларын, Ходаем, җир дә упмый, ичмасам!**

**Кычкыралар: «Качма! Качма! Тукта! Тукта, и, карак,**
**Нигә кул суздың аңарга, ул бит импортный тарак!»**

**Кычкыруларга ис китми, шүрләмим хәтта «мат»тан,**
**Әмма ата башладылар «шарт» та «шорт» автоматтан.**

Инде газиз җаным өчен хәвефләнә башладым,
«Мә, алыгыз!» – дидем дә мин, граната ташладым.

Инде болар кирәкләрен мотлак алдылар бугай...
Анык кына хәтерләмим – исән калдылар бугай...

Өйгә кайттым да: «Бичә, алтын тарак таптым! – дидем. –
Кая, су булса да бирче, бик озак чаптым!» – дидем.

Сөйләгәч кыйссаны, бичә таракны куйды алып:
«Акчага әйләндерербез иртән ломбардка барып!»
Бәй, шулай итми нишлисең, юньле чара башка юк,
Эш табалмый интегәбез, шуңа күрә акча юк.

* * *

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич берлән,
Ачка үлмәскә мөмкинлек таптым дигән хис берлән.

Юрган астында уйкуга китми ятам мин һаман;
Дөп тә дөп! – кемдер ишеккә типкәли бит бер заман.

– Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә кирәк бездән сезгә, и штык–нож кергери!

– Пәлитсиә бу, ачыгыз! – ди тегеләр, җикереп,
Ачмагач, килеп керделәр ыстинаны җимереп.

Каршы торгач, аякларга–кулларга богау салып,
Айга–вайга куймаенча киттеләр мине алып.

– Сиңа кыйммәттер, ә безгә чүп кенә алтын тарак, –
Диләр болар, – иптәш карак, эшләрең күпкә харап!

Өч көн элек талагансың зур гына бер баныкны,
Мәхрүм иткәнсең акчадан син меңләгән халыкны!

Кичә кич бер бизнесменны талап, чыкканнар суеп,
Синең эш бу – калдыргансың бармак эзеңне куеп.

Элекке ел бер самолёт җиргә ватылып төште,
Гаебеңне таныйсыңмы, монсы да синең эшме?!.

Калабызга бертуктаусыз наркотиклар агыла...
Кылган җинаятьләреңне исәпликме тагы да?

Бездән котылырмын дип син берүк уйлый күрмә,
Сине көтә, иптәш карак, кимендә йөз ел төрмә!

Сорау алучы әзмәвер шундый көчле, җегәрле,
Өнсез торуымны күргәч, берне салып җибәрде.

Нигә дисез мине болар бөгәргә тырышалар?
Миңа берничә җинаять «тегәргә» тырышалар.

Шуннан инде «эш» ябыла – «җинаятьче тотыла»,
Пәлитсиә әллә күпме мәшәкатьтән котыла...

**Ярый әле килеп керде теге сылу бай хатын,**
**Әмер бирде: – Ул – минеке, килмәгез аңа якын!**

**– Әгәр, – ди миңа, – теләсәң, хәлләрең көйләнәсен,**
**Йә төрмәгә утыртам, – ди, – йә миңа өйләнәсең!**

**Моның серен белү өчен күңелкәем җилкенә.**
**Ялган никах кирәк булган икән ошбу төлкегә.**

**Никахка кергән көнне үк паспортны алып куйды,**
**Мин мәңге тапмаслык җиргә, баныкка салып куйды.**

**Уйлыйсыздыр, тора болар хатын берлән ир кеби.**
**Кайда ул! Якын җибәрми, торган җирем гүр кеби.**

**Үзе яши – берүзенә төзеттергән калачык,**
**Мин җан асраган урын – бер катыргы алачык.**

**Минем исемгә азактан ялган фирма ачкан ул,**
**Күпме кирәк, акча урлап, Әмрикәгә качкан ул.**

**Шуннан бирле мондый хәрәм гамәлләрне ташладым,**
**Ач торсам да, кырын эшкә якын бармый башладым.**

**Ә теге алтын таракны ломбардка илткән бичә,**
**Шул акчага бал–май алып, чәй эчтек әле кичә.**

**Рәдиф ТИМЕРШИН**

---

# ГЫЙБРӘТЛЕ ГЫЙБАРӘЛӘР

- Этлеге беткән эт янында мәче дә этләшә.
- Йомшак кулдан эреп киткәнне каты кулга алуы җинел.
- Куыласын килмәсә, көтүгә иярмә.
- Тамырын тоймасан,талга тотынма, агым алып китәр.
- Таш астыннан чыкканны аяк астына салып булмас.
- Сөелмәгән хатын сөйкемле булмас.
- Чүл яфрагыннан су таммас.
- Тәмәкене генә түгел, мәхәббәтне дә таптап сүндерәләр.
- Үткәннәрне сагынып сөйләгәндә, кеше бүгенге яшәүдән ял итә.
- Тормышны уйнап күрсәтер өчен дә чынлап яшәп карарга кирәк.

• Пәйгамбәрләр жир кешесе белән кавышмый.

• Үзең тарта алмаган йөккә ияреп кенә барып була.

• Чүпне өйдән чыгарырга ярамагач — өйне чүплеккә әвереллерергәме?

• Яратмаган кеше мәхәббәтне юк дип, яраткан кеше ут дип белә.

• Табак-савыт шалтырамый тормый, әмма табак-савыт булмаса дөнья үзе шалтырый.

• Үзенне япа-ялгыз дип хис итәсең икән, димәк, Алланы оныткансың.

• Тарихны ялган язу—тарихи акылдан язу ул.

• Очарга хыялланган кеше тагылып йөрми.

• Ирекнең тамыры—Ир. Димәк, ирекле булу өчен башта ир булырга кирәк.

• Бәйрәмнәр ешайса, үләт якынлаша.

• Көлке юкта көлдерергә тырышалар икән, житди уйланырга урын бар.

• Йоклаганын аңлар өчен милләт бер уянып алырга тиеш.

• Эврика: өшетә торган юрган уйлап тапканнар.

• Тел яшерергә мәжбүр милләтнең тарихта яшерен елъязмасы калсын.

• Ис тоймаса борының, синең «шунда» урының.

• Күкнең — түшәме, түбәнлекнең төбе юктыр.

• Акчаның начар ягы — аның булмавы.
Кешенең начар ягы — акча гына уйлавы.

• Тилегә каршы тел, кылычка каршы кул корал түгел.

• Алыр байлыгы булмаса, жирдә дә, тарихта да, кешедә дә казынмыйлар.

• Таш таркалса, ком була.
Милләт таркалса, кол була.

• Чөелгән борын күккә түгел,
Жиргә бәрелеп каный.

**Нәжибә САФИНА**

### Сокланырсың да...

Бер журналист Пабло Пикассодан болай дип сораган:

— Элгәреге рәссамнардан сезне аеруча кайсысы сокландыра?

— Рубенс! — дигән Пикассо.

— Ә ни өчен — нәкъ менә ул?

— Чөнки дә ул язган ике мең картинадан безнең көннәргә кадәр дүрт мене сакланып калган!

### Катлаулы сорау

Пикассоны француз мәктәбенә очрашуга чакырганнар. Рәссамны зур тантаналар белән гаять жылы кабул иткәннәр. Укучыларның да тирән белемен күрсәтү ниятеннән, укытучы балалардан бөек рәссамнарның исемен сораган. Бер кыз бала кул күтәргән:

— Гойя, Дега, Рембрандт, Сезанн... һәм Пикассо.

— Ә ни өчен нәкъ менә Пикассо? — дип, укытучы олуг кунакка ярарга тырышып, сорап куйган.

Вәләкин кызый ни дип тә жавап бирергә белмәгән һәм... кычкырып елап та жибәргән. Пикассо исә аның янына килгән дә, назлы гына башыннан сыйпап, болай дигән:

— Елама, балам. Анысын... мин үзем дә белмим...

### Зирәк җавап

Бернард Шоу бик юан бер кеше белән очрашкан. Бу Шоуның ябыклыгына карап-карап торган да, болай дигән:

— Сезне күргәч, әллә Англия ачлыктан интегә микән, дип уйлап куям.

— Ә сезне күргәч, ул «ачлык»ның сәбәпчесе кем икәнлеге шундук ачыклана... — дип жавап биргән Бернард Шоу.

### Яңартылган бүләк

Шулай бер тапкыр Шоу иске китаплар кибетендә үзенең автографлы китабын күреп алган. Ул аны кайчандыр бер дустына бүләк иткән булган. Шоу китапны сатып ала да, «янартылган сәлам белән» дип, китабын янә дустына юллый...

### Тормышчан әдип

Американың бер журналисты язучы һәм артистларга мондый сорау биргән: «Әгәр дә ялгыз утрауда калсагыз, үзегез белән нинди китап булуын теләр идегез?»

Жаваплар төрледән-төрле булган: «Шекспир әсәрләре», «Свифт әсәрләре», «Инжил», «Коръән», «Тәурат»...

Инглиз язучысы Һилберт Честертон исә әлеге сорауга болай дип жавап биргән: «Әгәр дә кеше яшәми торган утрауда үзем генә калсам, мин көймә ясау хикмәтләрен аңлаткан китапны укыр идем».

**Морад ДУСАЙ** *туплады*

# ИЗГЕ ЭШ БУ!

Хөрмәтле Рәфикъ Юныс! «Казан утлары»ндагы бу яңа елның гыйнвар санындагы мәкаләгезне укып чыктым һәм бераз гына фикеремне житкерәсем килде. Жан авазы белән әдәбият-сәнгать дөньясына мөрәжәгать итүегез күңелне бик нык кузгатты. Бу олы эштә сез беренче адымны ясадыгыз — изге сәгатьләрдә булып, жыр сәнгатебездә көтелмәгән АЧЫШ булса иде.

90нчы елларда башланып киткән үзгәртеп кору жилләре профессиональ жыр сәнгатенә бик-бик әче итеп исте! «Бездаршина»ларга яшел юл ачылды. Шулар олы сәхнәләргә менеп, талантлы шәхесләребез белән оялмыйча рәттән басып, шул изге урынга хужа булырга теләп йөрделәр. Элекке худсоветлар беткәч, башбаштаклык хөкем сөрде. Хөрмәтле профессиональ жырчыларыбыз икенче планда калып, сәхнәләрне, радио-телевидениеләрне үзешчәннәр басып алды (чүп үләне басты). Нинди кимсетелү — чәчләрең үрә торыр! Гаделсезлекнең чиге юк!

Европадан руслар күреп ала, руслардан — безнекеләр. Алла Пугачеваның «Фабрика звезд»ыннан — «Йолдызлар фабрикасы», ә инде русларның «Субботний вечер»ыннан «Жомга киче» итеп күчермә эшләп куйдылар. Һәрхәлдә, татар милләтенең үзенеке булырга тиеш, башка милләтләрдән күреп түгел — үзеннән АЧЫШың кирәк лабаса! Культура министрлыгы тарафыннан худсоветлар кире кайтарылып, татар милләтенең жыр сәнгатен чистартасы иде — андагы чуарлыкны бетерәсе иде! Оригинальлек, компактлылык, стабильлек дигән кирәк әйберләр бүген бөтенләй сизелми диярлек!

Сезнең фикерегезгә килгәндә, бу жыр язу конкурсы башланып китсә, үзешчәннәрне катнаштырырга кирәкми дип уйлыйм. Анда үзешчән, монда үзешчән — алар болай да басып алган инде. Профессиональ жырчылар белән үзешчәннәрне бер программага кертергә ярыймы соң — чуарлык болай да хәттин ашкан лабаса. Сәнгатьтә һәр нәрсә үз урынында булырга тиеш.

Конкурсны өч турдан үткәреп, жинүчеләргә матди якны мул итеп саллы бүләкләр тапшырылса иде. Спонсорлар табылыр иде әле. Жыр сәнгатебезнең югары дәрәжәсен, нәфислеген-гүзәллеген бу юлы милләтебезгә чынлап торып күрсәтергә-исбатларга бик тә кирәк шул. Шушы изге эшкә актив-булдыклы сәнгатькәрләребез алынса иде! Безнең бу олы сәнгатебезне үзгәртеп коруның ачы жилләре — базар мөнәсәбәтләре, әлбәттә, нык аксатты шул. Соңгы елларда татар жыры акча белән үлчәнә башлады — нинди кыргыйлык бу! Конкурсның исемен «БОЛГАР МОҢНАРЫ» дип атасаң ничек булыр икән? Рәфикъ әфәнде! Сезгә сәламәтлек,изге башлангычыгызда уңышлар телим! Хәерле сәгатьтә булсын!

Мин үзем — совет заманнарында филармониядә эшләп чыккан жырчы.

**Зәбир ЖАББАРОВ.**

## КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

ТР Министрлар Кабинеты карары белән, «Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасының төп чаралары планы расланды.

«Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» елын ачу тантанасы 26 апрельдә — татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнендә булды. Чаралар программасына «Уртак тел — белге» дип аталган күргәзмә, «Күренекле мәгърифәтчеләр Мехмет Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» халыкара симпозиумы, ТЮРКСОЙ скульпторларының халыкара симпозиумы һәм башка чаралар кертелгән.

## МАТБУГАТ БӘЙРӘМЕ КӨНЕ

13 гыйнварда Россия матбугаты көне билгеләп үтелде. 1703 елның 13 гыйнварда (иске стиль буенча 1 гыйнварда) Пётр I Указы белән Россиянең беренче басма газетасы — «Ведомости» дөнья күрә. Һәм әлеге көн Россия журналистикасы тарихына истәлекле көн булып кереп калган.

Шул уңайдан «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында Татарстан җитәкчелеге традицион рәвештә республика басмаларының җитәкчеләре һәм журналистлары белән очрашты. Аларны һөнәри бәйрәмнәре белән ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сафаров, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова һәм «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов котлады.

Очрашу ахырында Фәрит Мөхәммәтшин һәм Ирек Миңнәхмәтов аерым бер басмаларның җитәкчеләренә һәм хәбәрчеләренә дәүләт бүләкләре тапшырды.

## КОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ: НӘТИҖӘЛӘР, БУРЫЧЛАР

14 гыйнварда «Татмедиа» агентлыгының утырышлар залында Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының 2013 елдагы эшчәнлегенә нәтиҗә ясауга багышланган утырыш булып узды. Төп докладны Агентлык җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов ясады. Коллегия утырышында Президент Рөстәм Миңнеханов, Президент аппараты җитәкчесе Әсгать Сафаров, Премьер-министр урынбасары Юрий Камалтынов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова катнашты.

Агентлык җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов чыгышында бәян ителгәнчә, бүген республикада 381 исемдә газета һәм 170 журнал нәшер ителә. Аларның 156сы татар телендә дөнья күрә. Татарстан гаммәви мәгълүмат чаралары хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы 21 мең 300 сум булган. 2014 елның беренче яртысында республика басмаларының гомуми тиражы 1 миллион 67 мең данә, район басмаларыныкы 270 мең, федераль басмаларныкы 326 мең данә тәшкил итә. Бу — Татарстанда яшәүче һәр мең кешегә 435 данә газета-журнал туры килә дигән сүз. Татарстан әүвәлгечә иң күп укучы төбәк санала.

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Фәрит Шаһиәхмәтов үз чыгышында «Без — бергә» кушымтасының Россиядәге 15 төбәктә 100 мең тираж белән таратылуын хәбәр итте. Генераль директор искәртеп үткәнчә, кадрлар әзерләү буенча эш дәвам итәчәк. Республиканың һәм федераль агентлыкларның әйдәп баручы телекомпанияләре белән хезмәткәрләрне укыту, семинарлар үткәрү турында килешүләр төзеләчәк, диде ул.

Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова чыгышында республика матбугатын үз эшен яхшы белгән, югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин итүгә ныклап тотынырга кирәклеген ассызыклады. Ул шулай ук редакцияләрдә профсоюз оешмаларын яңадан торгызу мәсьәләсен, хезмәт хакларының түбән булуын искәртте.

Президент Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының һәм «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең Казанда Универсиадага әзерлек һәм аны уздыру барышындагы эшчәнлеген югары бәяләде.

Президент утырыштагыларның игътибарын һәр мәгълүматның дөрес һәм объектив булырга тиешлегенә юнәлтте.

«...Матбугатта бирелгән һәр яналык һәм мәгълүмат кызыклы һәм югары профессиональ дәрәҗәдә әзерләнгән булырга тиеш», — дип белдерде республика житәкчесе һәм журналистлар әзерләү мәсьәләсенә тукталды.

Президентны шулай ук журналистларның унай вакыйгаларга игътибарны аз бирүе дә борчый икән. Ул республикада тормышка ашырыла торган уңышлы проектлар, күнелле хәлләр турында күбрәк язарга кирәклеген әйтте. «Һәлакәтләр, бәла-казалар турында күбрәк сөйләгән һәм күрсәткән саен, кешеләргә авыррак була бара», — диде республика житәкчесе. Әмма Президент фикеренчә, көндәлек матбугатта тәнкыйть булырга тиеш. Журналистларның хакимият игътибар бирергә тиешле мәсьәләләр турында сөйләве һәм язуы кирәк.

Быел сентябрьдә Татарстан Дәүләт Советына сайлаулар булачак. «Халыкка сәяси фиркаләр һәм кандидатлар турында житкерү бик мөһим», — диде Р.Миңнеханов. Шул ук вакытта террорчылык һәм экстремизм кебек җәмгыятьне нык борчый торган күренешләргә каршы көрәштә дә нәтижәле алымнар табу сорала. «Бу — бик зур мәсьәлә. Гаммәви мәгълүмат чараларыннан башка без әлеге бурычларны хәл итә алмаячакбыз», — дип белдерде ул.

Президент чыгышының ахырында «Татмедиа»ның үсеш стратегиясе булырга тиешлеген искәртте, бу уңайдан кыска һәм озак вакытка исәпләнгән бурычлар тәгаенләнгән программа эшләргә тәкъдим итте.

### БОЛГАРДА МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ

Болгардагы «Ак мәчет»тә Мәүлид ән-Нәбигә багышланган бәйрәм чарасы булып узды. Аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте оештырган иде.

Тантанада Президент Рөстәм Миннеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Тажетдин, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе урынбасары Рушан Аббасов, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президентының дини берләшмәләр белән бәйләнешләр идарәсе башлыгы Илнур Гатауллин, бөтен Россиядән дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

Мәүлид бәйрәме — сөекле Пәйгамбәребезне искә алу көне. Ай дәвамында Татарстан мәчетләрендә һәм мәдрәсәләрендә Мөхәммәд Пәйгамбәргә багышланган дини мәҗлесләр үткәрү, мохтаҗларга ярдәм итү кебек чаралар уздыру каралган.

ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, бәйрәмдә катнашучыларны сәламләп, Мәүлид белән котлады. Ул ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне саклап калу зарурлыгын искәртте. «Республикабыз зур уңышларга ирешә, әмма бер икътисад белән генә булмый. Әгәр без милләтебезне, динебезне сакламасак, безнең киләчәгебез юк», — диде Президент.

Минтимер Шәймиев исә, Болгарда алып барылган эшләр нәтижәсендә, «Ак мәчет»тә Мәүлид бәйрәмен уздыру мөмкинлеге тудырылуын билгеләп үтте. Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Тажетдин Мәүлиднең инде 1425 ел дәвамында бәйрәм ителүен белдерде.

### ЛАУРЕАТЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ

ТР Министрлар Кабинетында Муса Жәлил исемендәге республика премиясен тапшыру тантанасы булып узды.

Премия лауреатларын Премьер-министр Илдар Халиков котлады. Г.Камал театры артисты Эмиль Талипов, композитор Эльмира Галимова, «Татар мультфильмнары» берләшмәсе директоры Азат Ганиев, Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире Ленар Шәехов, «Идел» журналының бүлек мөхәррире Рүзәл Мөхәммәтшин, Казан илкүләм-тикшеренү технологик университеты профессоры Николай Улитин әлеге югары дәрәҗәдәге премиягә лаек дип табылды. Аларга «М.Жәлил исемендәге республика премиясе лауреаты» исеме бирелү белән бергә, ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы дипломы һәм 100 мең сум күләмендә акчалата премия тапшырылды.

### БАШ МӨХӘРРИРЛӘР КИҢӘШМӘСЕ

22 гыйнвар көнне «Татмедиа» ААЖ караган журналларның баш мөхәррирләре жыелышы булды. Башта «Татмедиа» ААЖ генераль директоры Фәрит Шаһиәхмәтов чыгыш ясап, үткән елда башкарган эшләргә бәя бирде, подписка нәтижәләрен игълан итте, перспектив планнар турында сөйләде. Фикер алышу тәртибендә баш мөхәррирләр Артём Тюрин («Татарстан»), Илдар Миргалимов («Мәгариф»), Гөлүсә Закирова («Гаилә һәм мәктәп»), Ләйсән Юнысова («Сөембикә»), Рафаэль Хәлиуллов («Чаян»), Ришат Хәсәнов («Идел-Пресс» полиграфия һәм нәшрият комплексының генераль директоры) чыгыш ясады.

Журналларның эшен яхшыртуга юнәлтелгән бу жыелышта шулай ук «Татмедиа» ААЖ генераль директоры урынбасары Сәмбел Таишева һәм генераль директор киңәшчесе Равил Фәйзуллин катнашты.

### КОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

27 гыйнварда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының киңәйтелгән коллегия утырышы узды. Анда республика Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашты.

Мәдәният министры Айрат Сибага-

туллин «Мәдәният министрлыгының 2013 елгы нәтиҗәләре һәм 2014 ел — Мәдәният елына куелган бурычлар» дигән доклад белән чыгыш ясады.

Утырышта шулай ук премьер-министр урынбасары, Россия Федерациясендә Татарстанның вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Айдар Метшин, Европа кыллы уен кораллары буенча укытучылар ассоциациясенең Италия бүлекчәсе вице-президенты, Италиядәге А.Бойто исемендәге консерватория профессоры Йалас Рисито, композитор, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Резеда Әхиярова доклад белән катнашты.

Мәдәният министры Айрат Сибагатуллин ТР Президенты Рөстәм Миннехановка Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе күләмен 500 мең сумга кадәр арттырырга тәкъдим итте. Президент бу тәкъдимне хуплады. Бүген әлеге премиянең күләме 300 мең сум тәшкил итә. Ул ел саен, Татарстан Республикасы Президенты Указы белән, иң күренекле, җәмәгатьчелек тарафыннан танылган, ил мәдәниятен һәм милли мәдәниятне үстерүгә күренекле өлеш керткән әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, шулай ук сәнгать һәм әдәбият белеме өлкәсендәге күренекле фәнни тикшеренүләр өчен бирелә.

**ТАТАР КИТАПЛАРЫ — ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ**

Үткән ел ахырында Төркиядә татар балалар хикәяләреннән торган «FILDISU CAKI» (Сөяк саплы пәке) исемле яңа китап дөнья күрде. Әлеге китапка кергән әсәрләрне Казанда яшәүче төрек кардәшебез, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Кутлу тәрҗемә иткән. Китап Анкара шәһәрендәге «Бәнгү» нәшриятында чыккан. Гомумән, Ф.Котлы татар язучыларының әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итү буенча соклангыч эш алып бара. Үткән 2013 елда аның тәрҗемәсендә Төркиядә дүрт татар китабы дөнья күргән (А.Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» повесте, Р.Батулланың «Алып Батыр маҗаралары» әкият-романы, повесть һәм хикәяләрдән торган «SESSIZ KURAY» («Тавышсыз курай») исемле җыентык һәм «FILDISU CAKI» исемле китап).

«FILDISU CAKI» исемле китапта 14 татар әдибенең 17 хикәясе урын алган. Алар арасында Гали Рәхим, Нәҗип Думави, Фәхрелислам Агиев, Абдулла Алиш, Җәвад Тәрҗеманов, Госман Бакир, Дәрҗия Аппакова, Ләбибә Ихсанова, Газиз Мөхәммәтшин, Фаил Шәфигуллиннарның әсәрләре бар.

**«ТӨРЕКВИДЕНИЕ» БЕЗГӘ КИЛӘЧӘК**

Төркиянең Искешәһәрендә «Төреквидение — 2013» телевизион фестивале булып узды. Җыр бәйрәменә төрле илләрдән, шул исәптән Украина, Беларусь, Үзбәкстан, Казакъстан, Россия һәм Төркиянең үзеннән 24 башкаручы килгән иде. Татарстаннан анда Алинә Шәрипҗанова катнашты.

Җюри һәм тамашачыларның тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, «Төреквидение — 2013» җыр конкурсында I урынга Азәрбайҗаннан Фәрит Гасанов лаек булды. II һәм III урыннарда — Беларусь һәм Украина җырчылары. Алинә Шәрипҗанова исә IV урынны алды.

Искешәһәр мэры Гюнгер Азим Туна үзенең йомгаклау чыгышында «Төреквидение» төрки дөньяда яңа юнәлеш булачагына ышаныч белдерде. «Конкурс барлык төрки халыкларның тавышын бер сулышка берләштерә», — диде ул һәм «Төреквидение — 2014»нең Казанда узачагын да искәртте.

2014 елның 14 гыйнварында күренекле шагыйрь һәм журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Госман Садә (Госман Мөхтасар улы Зәйнетдинов)** 65 яшендә вафат булды.

СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә **Роза Заһит кызы Хәлиуллина** 83нче яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Җиләкле бистәсе. Рәссам **Мәхмүт Усманов** эше.
*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь, галим **Хәнәфи Бәдигый**.

# ИГЪТИБАР, КОНКУРСЛАР!

## Иң яхшы повестька конкурс

Татар әдәбиятында проза жанрын һәм язучыларның иҗади активлыгын үстерү максатында «Казан утлары» журналы иң яхшы бәянга (повестька)

**ачык конкурс игълан итә.**

Иҗади бәйгегә күләме 2,4 басма табактан да (компьютерда 60 стандарт бит) артмаган, беркайда да басылмаган өр-яңа әсәрләр кабул ителә. Тема чикләнми. Авторлар бәйгегә бер генә әсәр белән катнашырга тиеш. Конкурска әсәрләрне кабул итүнең соңгы көне — 2015 елның 30 апреле. Яхшы дип табылган бәяннар «Казан утлары» журналында басылып барачак.

Бәйгегә килгән әсәрләрне мәртәбәле жюри бәяли.

Җиңүчеләргә түбәндәге премияләр билгеләнде:

I урынга — **60 мең сум.**
II урынга (ике премия) — **30 мең сум.**
III урынга (өч премия) — **20 мең сум.**
**10 мең сумлык** өч кызыксындыру премиясе.

## Җилкәннәрне киерик!

2014 елның 1 февраленнән «Казан утлары» журналы редакциясе **«Ак җилкән»** дип аталган әдәби конкурс игълан итә. Конкурста мәктәп укучылары һәм студентлар катнаша ала. Әсәрләр 1 апрельгә кадәр шигърият, проза (күләме 5 стандарт биттән артмаган хикәяләр, шул җөмләдән, мажаралы һәм детектив хикәяләр дә), драматургия, публицистика юнәлешендә электрон вариантта кабул ителә. Нәтиҗәләр апрель аенда ясалачак. Конкурста Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез дә катнаша ала. Җиңүчеләрнең камил иҗат үрнәкләре журналыбызның «Ак җилкән» сәхифәсендә дөнья күрәчәк.

«Ак җилкән» конкурсы турында барлык мәгълүматны **kazanutlaru.ru** сайтыннан һәм «Вконтакте» челтәренең **vk.com/feed#/qazanutlari** битеннән таба аласыз. Ашыгыгыз!

Әсәрләрне электрон почтага **(e-mail: kazanutlari@yandex.ru)** «Конкурска» дигән исем астында җибәрергә яки редакциягә электрон вариантта китерергә мөмкин.



Хәнәфи Бәдигый

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)